ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

6.2006



# 1000 нче САНГА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘДӘН МИЗГЕЛЛӘР



*Г. Камал театры. 10 апрель, 2006 ел.*











# Казан утлары
# Qazan utları

2006

**6**

**(1004)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Мең төрле гамь... *Робагыйлар* ..... 5
Зиннур ХӨСНИЯР. Козгыннар йолдыз чүпли. *Роман* ..... 11
Шамил МАННАПОВ. Җанымның тынлыгы. *Шигырьләр* ..... 52
Альберт ХӘСӘНОВ. Җәнбәт ыруы. *Повесть* ..... 57
Рөстәм МИНГАЛИМ. Минем белән яши хәтерләүләр. *Шигырьләр* ..... 78
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Мин бәхеткә барам – җаяүләп. *Шигырьләр* ..... 96

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Хәбир ИБРАҺИМ. Артык гомер. *Драма* ..... 81

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Габдрахман ӘПСӘЛӘМОВ. Сары чыпчык ..... 101

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Солтан ШӘМСИ. Адәмне кем коткарыр? *Тарихи-эзотерик бәян* ..... 107

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Илфак ИБРАҺИМОВ. Әдәби сүзнең көче ..... 131
Камил КӘРИМОВ. Прозаның киштәдәге урыны ..... 136
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Саркылган энҗернең шәүләсе ..... 140

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ..... 147
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге ..... 162

**ТАТАР ТЕАТРЫНА 100 ЕЛ**

Дания ГЫЙМРАНОВА. Сәхнәбез каһарманнары ..... 153

**ХӘТЕР**

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Гыйбрәтле язмышлар ..... 167

«Татар энциклопедиясе» битләреннән ..... 175

**ЮМОР-САТИРА**

Тәлгат НӘҖМИЕВ. Шаян көндәлек ..... 178
Әхәт САФИУЛЛИН. Ачыклык кирәк! *Памфлет* ..... 183

Бер сорауга – бер җавап ..... 151
Укучы сүзе ..... 185
«Казан утлары» архивыннан ..... 186
Берлекнең яңа әгъзалары ..... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман З. ХУСНИЯРА «Вороны стремятся к звездам» (окончание); повесть А. ХАСАНОВА «Родословие Джанбет» (окончание); рубаи Г. МУХАМЕТШИНА, стихи Ш. МАННАПОВА, Р. МИНГАЛИМА, Г. БАЙРАМОВОЙ.
«Драматургия»: драма Х. ИБРАГИМОВА «Невостребованная жизнь».
«Из сокровищницы татарских рассказов»: Г. АБСАЛЯМОВ. «Желтый воробей».
«Публицистика»: историко-эзотерическое повествование С. ШАМСИ «Кто спасет Адама?» (окончание).
«Литературная критика»: выступления И. ИБРАГИМОВА, К. КАРИМОВА, Р. ЗАЙДУЛЛЫ, посвященные итогам 2005 литературного года.
«Наука»: статья Ф. ГАРИПОВОЙ «История наших деревень»; А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации».
«К 100-летию татарского театра»: статья Д. ГИМРАНОВОЙ «Видные деятели сцены».
«Память»: М. УСМАНОВ. «Поучительные судьбы».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Юмор-сатира»: Т. НАЗМИЕВ. «Веселая семейка».
Наш календарь.
Из фотоархива журнала.
Новые члены Союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «В деревне» — работа художника Р. ВАХИТОВА; писатель Р. Шарафиев.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel by Z. HUSNIYAR «Ravens aspire to stars» (ending); story by A. HASANOV «Janbet's geneology» (ending); rubai by G. MUHAMETSHIN, verses by SH. MANNAPOV, R. MINGALIM, G. BAYRAMOVA.
«Dramatic art»: drama by H. IBRAGIMOV «Dead life».
«From treasury of Tatar stories»: G. ABSALAMOV. «Yellow sparrow».
«Publicism»: historical-esoteric narration by S. SHAMSI «Who will rescue Adam?» (ending).
«Literary criticism»: performances of A. IBRAGIMOV, K. KARIMOV, R. ZAIDULLA, devoted to results of 2005 literary year.
«Science»: article by F. GARIPOVA «History of our villages»; A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation».
«To 100th anniversary of Tatar theatre»: article by D. GIMRANOVA «Outstanding figures of stages».
«Memory»: M. USMANOV. «Instructive destinies».
Pages from «Tatar encyclopedia».
«Humour-satire»: T. NAZMIEV. «Cheerful family».
Our calendar.
From photoarchive of magazine.
New members of Union of writers.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «In the village» - work by artist R. VAHITOV; writer R. SHARAFIEV.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.05.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3–394. Тираж 7100.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2006 ел.



Гарифҗан
Мөхәммәтшин

# МЕҢ ТӨРЛЕ ГАМЬ...

РОБАГЫЙЛАР

• • •

**Бу юллардан инде ничә буын узган—**
**Хыялланган, сөйгән, көйгән, җырлар сузган...**
**Кылганнарның ярсынуын карап торам—**
**Алар чаба ярсып-шашып, купмый тузан...**

• • •

**Талгын гына агып ята агымсулар,**
**Агымсуга баккан күзләр ник моңсулар?**
**Моңсу күзләр агымсуга баккан килеш**
**Гомер юлын әле шулай мең кат урар...**

• • •

**Ярларына кайта инеш, ташый да,**
**Идел булам, дип ярларын ашый да...**
**Язгы инеш хыяллары ничә кат**
**Әйләндерде безнең исәр башны да.**

• • •

**Без китәбез, дөнья кала кемнәргә,**
**Әйләнмәсме яшәү кара төннәргә?**
**Шундый уйлар килеп күздән йокым ала**
**Башны салу белән кичен мендәргә.**

• • •

**Бу тормыштан беләм күпне алганым,**
**Белә алмыйм алда күпме калганын,**
**Язлар җитсә көз утырткан алмагачның**
**Арып бетәм көтеп яфрак ярганын.**

---

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН (1941) — *шагыйрь; «Килегез, дусларым», «Бәхет», «Гомерлек язым» һ. б. китаплар авторы. Балтачта яши.*

* * *

Картайдыммы, уйлыйм һаман балачакны,
Һич уйламыйм тәмугларда яначакны—
Фани йортта бәгыремне өшеткәннәр
Анда миңа кайнар учак ягачакны...

* * *

Азмы җирдә аһ-зар эчкән бәхетсез,
Иң бәхетсез—хаким, калса тәхетсез,
Тәхетен җуйган хаким аһ-зарына
Ничә кабат булдык шаһит без.

* * *

Кергән чакта гомерләрнең көзләренә,
Көзге җилләр үткән чакта үзәгеңә
Колак салып газиз әткәй сүзләренә,
Бер багасы килә әнкәй күзләренә...

* * *

Хәятеңдә аера бел ак-караны,
Кара белән озакка сузмый өз араны,
Яугирләрнең ише була алмасаң да
Җәлладларның була күрмә син яраны.

* * *

Кылычыңны кынысыннан уйлап чыгар—
Кире тыксаң, куркак дигән даның чыгар,
Кынысыннан чыккан кылыч кире керми—
Йә җиңәр ул, йә орышта чатнап сынар.

* * *

Табигатьнең бар мәңгелек үз гаме,
Берни түгел аңа гомер узганы,
Оран сала әллә кайдан, тирәннән
Мең-мең язмыш, күмгән еллар тузаны...

* * *

Бу дөньяны чиккән кеше чикләр белән,
Шул чикләрне саклый хәзер чукмар белән,
Бизәргә иде Җирне чәчәк-чуклар белән,
Ызгыш әзли, талаш әзли юк-бар белән...

* * *

Бу дөньяда миңа инде бары да таныш—
Челтер-челтер ага сулар, шаулый камыш...
Аккан сулар, искән җилләр, иңрәр күкләр,
Сезгә багам, әзли-әзли яңа табыш.

* * *

Ничәмә күз күктән безгә карап тора,
Кылган һәрбер гамәлеңне санап тора,
Яшен булып йөрәгеңне чыбыркылый,
Күкрәү булып кисәтә ул, тамак кыра...

* * *

Чиксез күктә балкыйм, дидем йолдыз булып,
Каплады күкне, килде дә кара болыт,
Күк күкрәде, җир тетрәде, ишеттем өн—
Яшә, диде язмышыңа дога кылып!

* * *

Омтылдым гел яшәү серен ачарга,
Ачтым да омтылдым ташлап качарга,
Җибәрмәде ләкин нидер, гомер буе
Туры килде бәхетле йөз ясарга...

* * *

Төн караңгы булган саен йолдыз якты—
Кара төсләр җете итә һәрчак акны...
Әй Гарифҗан, ни әйтергә теләвең бу,
Кара төскә мәдхияләр җырлар чакмы?!

* * *

Бу дөньяның фанилыгын күреп торам,
Мыек астан гына карап көлеп торам,
Һәр үткән көн бакыйлыкка якынайта—
Үткән көнем саен бармак бөгеп торам...

* * *

Ни булса да гел яхшыга юрадым,
Гел изгегә таба булды юлларым,
Бу дөньяда үз-үземне күп чикләдем,
Бакый йортта күбрәк бирсен хурларын.

* * *

Аяз күктә йолдызларны барладым,
Тиң-тиң итеп берәм-берәм парладым,
Тик бер йолдыз парсыз калды. Бу дөньяда
Бер мин генә үксез түгел, аңладым...

* * *

Беркөн килеп Әҗәл керер ишек ачып
(Минем ишек кем керсә дә һәрчак ачык),
Тынгы бирми вәсвәсәле бер уй гына—
Урының бармы ул кергәндә калыр качып?

* * *

Нәрсәнедер югалттым, дип үкенмә,
Табып бир, дип Аллаһыдан үтенмә,
Кемдер табар һәм сөенер табышына,
Ул фәкыйрьнең сөенечен үтермә!

* * *

Малай чакта безнең хыял атлар иде,
Бәйгеләрдә урын бирмәс чаптар иде,
Бәйге үткән, атлар беткән бу заманда,
Абзыкаем, хыялыңа атлан инде!

* * *

Кемнең генә хәле уңай минекеннән—
Лап-лап атлап үтә таптап манекеннар,
Манекеннар дөньясында гомер кичеп
Җанын саклап кала алыр икән кемнәр?!

* * *

Бу дөньяга килгәнбез без кунак булып,
Яшик әйдә иple генә, тыйнак булып...
Бер дустыма биргән идем шундый киңәш,
Кылыч алды башкаемны кыймак булып!

* * *

Шәраб эчү гөнаһ, диеп шөбһәләнмә,
Касә тирән, төпләренә төшмә әмма,
Сискәндерә шул касәнең төпләрендә
Батканнарның юргалары кешнәгәндә...

* * *

Нигә тоньк, нигә моңсу Җидегән йолдыз?
Җиде йолдыз—берәм-берәм бары да ялгыз.
Ялгызлыктан йолдызлар да тоныклана—
Ялгызлыкка нокта куйыйк, әйдә, балдыз!

* * *

Мәхәббәт җырлары күбрәк яз, диләр,
Картлыкта да кирәк сөю-наз, диләр,
Хатын белән кайнанам тик тынгы бирми—
Әллә яшьлектә кылганың аз?—диләр.

* * *

Бер мәхәббәт җитә безнең икебезгә—
Шул учакта җылынабыз икебез дә.
...Шулай диеп юанырсыз әле сез дә
Минем кебек олпат яшькә җитегез дә.

* * *

Минем күңел бер җилбәзәк, чуар инде,
Язлар җитә, тагын гакылын җуяр инде...
Адәм белән Һауаны да ярлыкаган—
Бу гөнаһны гына Тәңре юар инде...

* * *

Хисләремне сакладым мин тирәндә,
Сер бирмәдем һәрбер сөям дигәнгә—
Һәр сарылган җилдән җиргә бөгелсә
Имән була алмас иде имән дә...

* * *

Син ут ягып җылынганда тирмәндә
Мин күбәләк булдым синең тирәңдә,
Үзе атылып керә икән кайнар утка
Мәхәббәттән башын җуйса бу бәндә...

* * *

Хәтерлимсең, бутый-бутый кәгъбәләрне,
Алларында минем кылган сәҗдәләрне?
Кәгъбәм булып калдың миңа гомер буе,
Онытсам да кайбер биргән вәгъдәләрне.

* * *

Былбыл булсам, сөям, диеп җырлар идем,
Чишмә булсам, яратам, дип чыңлар идем,
Әгәр дә син былбыл булсаң, чишмә булсаң,
Гомер буе сине генә тыңлар идем.

* * *

Мәхәббәт җырлары яздым күп итеп,
Мәхәббәт белгече булган кук итеп,
Үзенә дип уйлагандыр, укыды да
Хатын суырып үбеп алды «чүп» итеп.

* * *

Әҗәл диеп шүрлисең ник пычагым,
Хур кызлары котә җәеп кочагын,
Гомер буе мәхәббәткә туя алмадың,
Анда баргач бер кинәнер ач җаның!

* * *

Йөрәгемнең шыр буш чагы—кер булмаса,
Җылы сулышыңны җанга өр булмаса,
Синең йөрәгеңдә миңа урын бармы,
Җавап бирче, җаныкаем, сер булмаса!

* * *

Гашыйкларның күңелләре гел аһ булыр,
Шул аһларны гаеп итү гөнаһ булыр—
Алтын сарайларда ялгыз интеккәннәр
Кавышсалар, гади шалаш оҗмах булыр.

* * *

Мәхәббәтнең кануннары каттый аның,
Ләззәтләре җир өстендә ятмый аның,
Татыйм, дисәң мәхәббәтнең бар ләззәтен,
Таң чыгыдай керсез булсын гашыйк җаның!

* * *

Күзләреңдә уйный синең серле балкыш,
Иңнәреңдә ап-ак шәлең—син бер аккош...
Үткәннәргә кайтып сине уйлаганда
Күз алдымда балкый шушы рәсем-нәкыш.

* * *

Тик йолдызлар гына безне күргән иде,
Сер сакларга безгә вәгъдә биргән иде,
Йолдызлар да серне саклый белми икән—
Безнең серне бөтен авыл белгән инде...

* * *

Ипле булып, тәкъва булып кыланмадым,
Арттырып үтәдем сөю планнарын,
Күпме сөеп-сөелеп тә аңламадым,
Сөю нәрсә була соң ул, оланнарым?

* * *

Салды башны бу мәхәббәт сәмумнарга,
Буйсындырды әллә нинди кануннарга,
Күтәрелеп карарга да шүрлим хәзер
Кара кашлы, нечкә билле ханымнарга.

* * *

Бу абзагыз шактый гына акыллы
(Ышанмасаң укы кабат атымны!),
Шушы сүзнең хак булуын дәлилләп
Баш очымда якты йолдыз атылды.

* * *

Нинди гамьнәр яши синең калебеңдә,
Калыпланган җаның нәрсә калыбында?
Яшь чыгамы күзләреңнән мөлдерәшеп
Милли моңнар күңелеңә кагылганда.

* * *

Урбар суларында үскән талдан ишеп
Ясый иде әткәй шундый моңлы бишек,
Моңлы бишекләрдә үскәч тирбәлешеп
Безнең җаннар моңсыз булып калсын ничек!

* * *

Демократик ил төзибез, дидекме без?
Ни теләсәң шуны кычкыр, иреклe без!
Тик шуны бел, булмас сине ишетүче,
Син сораган мәсьәләне хәл итүче.

* * *

Безнең уйлар һәрвакытта фәлсәфәле,
Җаннар һәрчак якты гамьле, вәсвәсәле,
Уе-гаме якты, җылы булган халык
Ялалардан, яралардан үлмәс әле!

Зиннур Хөснияр

# КОЗГЫННАР ЙОЛДЫЗ ЧҮПЛИ

РОМАН

## Карга көтүе

Кунаклар икесе генә калды, хужа хатынның өйгә таң белән генә әйләнеп кайтасын белеп калдылар ул бахырлар. Мөхәммәтнең сарык белән кәҗә көтүен көткәне бар, малай чакта колхозның яшелчә бакчасына әниләре белән бергәләшеп кәбестә җыйганы да бар. Малай чактан ук кәҗәнең кәбестәгә булган мөнәсәбәтен дә күреп үсте. Бүген исә үзенең хәлләре дә шул чамадарак. Ләкин ул тук кәҗә булып кыланды, әгәр дә «кәбестә», үзеннән-үзе чәкәнен өзеп, «кәҗә» янына тәгәрәп килсә генә... Әлбәттә, бу «кәбестә»нең «чәкәне» күптән өзелгәндер инде. Бүген, ай тулган көндә, элекке иренең депрессиясе булуын алдан ук белеп торган Сиринә Самуиловна, дус хатынын махсус чакыртты, Мөхәммәтне Бөгелмәгә җибәрмәс өчен ул әлләниләр кылырга әзер, дус хатыннарының «бакчасына» керүенә дә сүз әйтерлек хәлдә түгел иде бичара...

Чөнки ул белеп тора: иртәгә егет тагын анык гына булачак. Изольда ерак Чиләбесенә китеп барачак, алар иртәгә дә, берсекөнгә дә күрешә алмаячаклар. Ә менә Гөлчәчәге янына очса, аннан егетнең кире кайтасына, дөресрәге өйләнеп, башлы-күзле булып кайтмасына аның тамчы да ышанычы юк шул... Гыйшкы әнә шул рәвешле аңын-акылын томалады хатынның...

Югыйсә, мондый хәлләрне элегрәк берәр авыл кешесе ишетсә, сүзсез-авызсыз калып—«Тфү!» дип, төкерер генә иде. Хәер, бу замандамы!.. Табигать балалары Табигать әнкәнең үзенә каршы килеп яткан бер болгавыр замандамы?... Табигать тудырган Балалар, Табигать әнкәбез ялгышкан икән бит, аның хатасын төзәтик дип, елгалар агышын кирегә үзгәртергә азапландылар, бу—һәлакәткә алып килде. Тора-бара ул Балалар жаннарына Табигать әнкәләре индергән самими, табигый хисләрне «кирегә борырга» җөрьәт иттеләр—кешелекнең рухи һәләкат башы шуннан башланды. Аклану өчен мең-миллион төрле сәбәп-теорияләр табылды: ирекле мәхәббәт, ирекле секс һәм башкалар һәм башкалар... Кешелек рухи яктан чери башлады, аннан сасы ис килә башлады. Дөньяны болгатучы таякларның юан башлары, Казандагы сабын заводыннан килгән сасы искә борын җыерган булып, шәһәр тирәсендәге урман-кырларга таеп беттеләр, әмма алар моның белән генә «рухи череклектән» урман арасына, Идел буйларына качып китеп котыла алачак түгел иделәр инде. Җәмгыятьнең каны бозылды һәм кутенә зур чуан чыкты...

...Ул төнне яһүдә ханымның фатирында «кәҗә» белән «кәбестә» төн кундылар...

...Ләкин аларның берсе таң белән тәки ике аяклана алды һәм, күзләрен җыртып ачып, аэропортка томырылды.

---

*Ахыры. Башы журналыбызның 5 санында.*

...Мөхәммәт әнә шул вакыйганы исенә төшереп барды. Хәер, ул гынамы соң! «Ул урман кызы сиңа нәрсә бирә ала, егеткәем?—дип, туп-туры күзләренә карап әйтте Сиринә ханым егет Бөгелмәдән әйләнеп кайткач.—Син—талант, сиңа үсәргә кирәк! Мин беренче чиратта синең әнә шул талантыңа гашыйк! Шуңа күрә сине зур дөньяга чыгарасым килә! Ә син гаилә баткаклыгына кереп чумарга, камыт кияргә атлыгып торасың!..» Мөхәммәт өчен болар яңалык түгел иде. «Әгәр Гөлчәчәк булмаса, мин рәссам булмый идем! Мин шуның аркасында гына кулыма пумала алдым. Әйе, яшь чакта да рәсемнәр ясаштыргалый идем ясавын, ләкин болай гына, уйнап кына... Мин ундүрт яшемдә чагында ук Гөлчәчәккә аның, урман кызының, портретын ясарга вәгъдә бирдем. Шуннан соң минем тормышым бөтенләй үзгәреп китте, мин үзем дә үзгәрдем. Максатыма ирешәчәкмен дип, антлар эчтем. Менә килеп чыкты, мин аның портретын яза алдым! Шуннан соң минем күңелем үсеп китеп, рәссам булырга, зур рәссам булырга хыяллана башладым». Сиринә ханым аны тыныч кына тыңлады да гади генә итеп әйтеп куйды: «Бу илдә зур рәссам булу өчен талант кына җитми шул әле, егетем». «Мин көне-төне эшләячәкмен дә!!!» «Көне-төне эшләү түгел... пумаланы хет шунда алтын буяуга манып язмыйсың!» Мөхәммәт, аның бу сүзләренә ачуы килеп, ишекне тибеп диярлек ачып чыгып китте Сиринә Самуиловна фатирыннан.

Мәскәүдә узачак күргәзмәдә Мөхәммәт Уразовның өч яңа картинасы да куелмаячак иде. Анкета һәм башка шуның ише кирәкле кәгазьләре янында торак-коммуналь хуҗалыгыннан гаилә хәле хакындагы белешмә кәгазе җитешми икән. Мөхәммәт бу турыда ишеткәч, әүвәл Сиринә ханымга шылтыратмакчы булган иде, ләкин Бөгелмәдән кайткач та ачуланышуларын исенә төшереп, тыелып калды һәм, хатасын төзәтергә дип, торак хуҗалыгына чапты. Дүшәмбе әлеге контора үлеп ятсаң да беркемгә дә бернинди белешмә бирми. Егет сишәмбе җиткәнен көтәргә булды. Ләкин иртәгесен дә юлы уңмады. Өстәл артында борынын казып утыручы яшь марҗа кызы чәрелдәвек нечкә тавышы белән:

—Фатирыгызга түләнгәнлек турында белешмә кәгазе кирәк!—диде. Әлбәттә, Мөхәммәт фатирына ай саен җиренә җиткереп түләп бара, ул яктан аның тәртип, шуңа күрә батыраеп, үзе дә дорфа гына:

—Ник түләнмәсен! Компьютерыннан тикшереп кара!—дип җавап бирде.

—Бухгалтериядән белешмә алып килегез!

Ни хәл итәсең, ул сораганны эшләмичә булмый, ул бухгалтерия ишеген эзләп китте. Ишек төбендә су буе чират. Тагын да гаҗәбе: шул ук бер бухгалтерга ике төрле чират: берәүләр белешмә алырга тора, икенчеләренең кулларында белешмәләре дә бар, икенче кулларына тартмалы конфетлар һәм матур кәгазьле төргәкләр кыстырганнар. Чираттагылар надан егеткә бик тиз аңлатып бирделәр: паспортистка кыздан, бухгалтер белешмәсе белән, кирәкле белешмә алганнан соң, шул кәгазьгә бухгалтердан кул да куйдырасы бар икән. Күчтәнәчле чират кул куйдырырга торучылар чираты булып чыкты. Мондый хәл бары тик Рәсәй дигән кабахәт җәмгыятьтә генә була ала иде. Мөхәммәт, тешен кысып, кирәкле чиратка басты. Ярты көн узды дигәндә ул күчтәнәчле чиратның башына килеп җитә алды. Күчтәнәчен дә бирде, ләкин аңа кирәкле белешмә бирмәделәр.

—Сезнең квартплата нигәдер ун сумга артык түләнгән бит, егеткәем!—диде кибән гәүдәле Наташа апа.

—Соң... артык булса, бик әйбәт! Миңа белешмә генә бирегез, зинһар!

—Бирә алмыйбыз!

—Ничек бирә алмыйсыз?! Минем түләнгән бит?

—Артык түләнгән. Ун тәңкә!

—Соң... хөкүмәткә файда булыр, мин ун сумны сорарга дип килмәдем бит?

Бухгалтер апай утырган урыныннан селкенеп куйды һәм каш астыннан гына Мөхәммәткә карап:

—Син нәрсә, егет, әллә монда ришвәтчеләр утыра дип беләсеңме?!

—Сезгә димим бит, хөкүмәт файдасына калсын дим!

Юан гәүдәдән тавыш бу юлы тагын да нечкәрәк, әмма зәһәррәк булып чыкты:

—Әле син хөкүмәтне ришвәтчелектә гаепләмәкче буласыңмы?!

—Сез... Сез нәрсә сөйлисез? Мин аны үлеп яратам бит!

—Яратсаң, аның законнарын да хөрмәт итәргә кирәк, егеткәем. Кызларын кочасыз, каенаналарыгызны күрә алмыйсыз! Алай булмый ул!

—Каенананы да кочарга что ли!

—Следующий!—дип чәрелдәде нечкә зәңгәр тавыш.

Егет аптырап урамга чыкты. Беркавымнан күргәзмәне оештыручы түрәгә шылтыратырга уйлап аның номерын җыйды. Тик аннан да уңай җавап ишетә алмады, кирәкле кәгазьсез күргәзмәдә катнашу хакында уйларга мөмкин түгел, Сиринә Самуиловна бу юлы таләпне бик каты куйды. Әгәр ул, күргәзмәгә җаваплы адәм, аны бозса, иртәгә үк урынымнан очачакмын диде.

Бәхетенә күрә, күп тә узмады, ана Сиринә Самуиловна үзе шылтыратты. Мөхәммәт анын Америкага кызы янына киткәнлеген ишеткән иде, шуңа күрә исәнләшергә дә онытып, гаҗәпләнеп сорап куйды:

—Сез кайдан шылтыратасыз, Сиринә Самуиловна!

—Нью-Йорктан!—диде дулкынның теге очындагы таныш тавыш. Бу тавыш әлеге минутта Мөхәммәт Уразовка гаҗәп кадерле, якын һәм сөйкемле булып ишетелде.

—Нинди проблема?

—Проблема юк,—дигән булды егет, тавышындагы битарафлыкны сакларга тырышып.

—Алдашма! Беләм мин! Чынлап та ЖКО кәгазе кирәк! Мин ул тәртипне боза алмыйм. Хәтта синең өчен булса да.—Хатын сөйләшә белә, ничек кенә баш күтәреп, мөстәкыйль булырга тырышып караса да, ул аны, итәк астына җыеп тыгып, чарасыз бер бала хәлендә калдыра ала һәм аннары шул балага ана кеше сыйфатында ярдәм кулы сузган булып, ике күкрәк арасына борыны белән төртеп куя ала иде. Талантлы хатын Сиринә Самуиловна!..—Мин төзелеш министрына шылтыраттым, ЖКОга барып белешмә кәгазенне ал!

Телефон өзелде, Мөхәммәт, ачудан төкеренә-төкеренә, кире борылды. Бу юлы теге нечкә зәңгәр тавышлы маржа апай ана: «Ник аны баштук шулай димәдең?! Ну бу яшьләр тел яшерергә яраталар да соң инде»,—дип сөйләнә-сөйләнә белешмә кәгазе янына кирәк булмаса да анын күчермәсен дә ясап бирде. Бая калдырган бер тартма конфетын да кире төртте:—Зурлап килүегез өчен рәхмәт, әлбәттә, ләкин мин бүләкләр кабул итеп утыра алмыйм, мин хезмәттә!—дип сөйләнде ул. Мөхәммәт дәшмәде, ачудан иреннәре кысылды, ул тартмасын чиратның ахырында ук басып торучы әбигә төртте дә, ишекне бәреп ябып, чыгып югалды.

Ике дус Казанга борылып китә торган юл чатына җиткәч, машиналарын читкәрәк куеп, туктадылар. Мөхәммәт Барый дустына күнелен ачып салып, барысын да сөйләп бирергә уйлаган иде. Ләкин анын бая Садыйк Сираевич капка төбендә утырган чактагы бәхетле кыяфәтен исенә төшереп, тыелып калды. Бәхетле иде шул кыяфәте, чөнки аны атаклы Садыйк Сираевич үзе чакырткан бит! Үзе!..

Сиринә Самуиловна белән аралары суынгач, Мөхәммәтнең алдында бер-бер артлы киртәләр пәйда була башлады. Юк, юк, гөнаһысына керә алмый: Сиринә Самуиловна аяк чалмады ана... тик... ярдәм кулы да сузмады. Бу кабахәт иллә зур кеше булу өчен талант кына житмәгәнлеген шуннан соң

гына аңлый башлады егет. Руль артында көр тавышлы, талантсыз-сәләтсез өч тиенлек бушбугазлар утыра. Аларга синең сәнгатең кирәкме соң!!! Әгәр дә Садыйк Сираевич белән танышып китмәгән булса?! Хәер, аның белән дә Мөхәммәтне Сиринә Самуиловна таныштырды бит... Теләсә, күз ачып йомганчы араларын да өзә ала... Әллә шуларның барысын да Барыйга сөйләп бирергәме, дустым, сиңа Садыйк Сираевич кызының күзе төшкән, Садыйк Сираевич исә синең бабаң булырга да каршы түгел дип, шәрехләп аңлатырга, ташла ул Гөлйөземеңне, Әлфия сиңа тиңрәк, син бары ул кыз белән генә кеше була алачаксың дияргәме?!

Соң... соң... бүтән юл юкмы икән ни соң?! Бу умырткасыз җәмгыятьтә кеше булам дигән кешегә шуннан башка бүтән төрле юл юкмы икән ни, чынлап та?!

Аерылганда авылдашлар җыен юк-бар хакында гына сөйләшкән булдылар да, икесе ике якка—Мөхәммәт Уразов Казан ягына, Барый Әкбәров Байтимергә таба юл алдылар. Ләкин егетләрнең йөргән юллары аерым булса да, язмыш сукмаклары бер төрлерәк булырга охшап тора иде шул...

## Этләрнең башына сугып торасы юк...

Кара каргаларның холкы тәмам чуалып бетте. Монарчы авыл халкының кара каргалардан зыян күреп, бу чаклы зар елаганнары юк иде. Хәзер исә авыл өстендә карга күтүе күренүгә, шарт-шорт мылтык аткан тавышлар гына яңгырап тора. Моның сәбәпчесе—теге кара булмаган карга баласы иде. Чөнки аның җитәкчелегендә ишегалларындагы тавык җимнәренә генә түгел, бәбкә-чебиләргә дә һөҗүмнәр бик еш булып тора, хәтта алар яшелчә бакчаларына төшеп казынырга да күп сорап тормыйлар, орлыкларны актарып чыгарып, үсемлекләргә шактый зыян салалар.

Җәй башында Байтимердә бот чабып шаккатырлык сәер хәлләр башланды. Галләм абзыйның карчыгы Җәмилә апа быел редиска чәчмәде. Югыйсә, һәр елны кар ачылуга, иртә язда витамин булыр дип, янбакчасына шуны төртә иде. Редиска узган ел Галләмнең ашказанына килешмәде, кеше ашаганда, кызыгып кабуга, эчен тырнарга кереште, тора-бара ул сару кайнауга чаклы китереп җиткерде. Шуңа күрә чәчеп тормаска булды редисканы Җәмилә апа. Аның каравы, шундый нәрсәләрне, моннан берничә ел элек Җәмиләдән күреп, ян күршеләре Сәлимә түти утырта башлаган иде. Аның ише азыкны гомерен мари ягында балта остасы булып уздырган Салих абый үлеп ярата, аларның өсталләреннән тозлаган кәбестә, көздән үк агач мичкәгә салып әзерләп куйган тозлы алма, берничә төрле гөмбә өзелми. Ярый хуш, бер күрше утыртмады редисканы быел, ә икенчесе күп итеп чәчте. Җәмилә апа, редиска урынына, ашказанына бик файдалы дигәч, үзе исемен дә белмәгән, яфрагы эт колагы кебек булып үсә торган үлән орлыклары сипте. Менә берзаман яз кояшы, җир өстендәге ак карны күккә күчереп, ак болытлар итеп таратты. Табигать биләмәләрендә чын-чынлап яз исе таралгач, теге үсентеләр борын да төртеп чыктылар, тамыр җибәреп, баш калкыттылар. Тик ни гаҗәп һәм ни хәл ди әле бу: Җәмилә апаның бакчасында «эт колагы» урынына янә редиска тишелеп чыкты, Сәлимә түти җирендә теге «эт колагы» үсеп ята иде... Әүвәл бик аптыраштылар, бик гаҗәпләнделәр, шаккатуларының чиге-чамасы булмады. Шулай булмый ни: редиска урынына башка үлән үсеп чыксын әле! Ирләр әлеге табышмакны шундук үз файдаларына чишеп тә куйдылар: тел бистәсе хатыннары, сүз белән мавыгып китеп, орлыкларны бутаганнар! Һәм шуңа күрә җавапны да алар тотарга тиеш! Бетте-китте, вәссаләм! Чү, чү! Туктагыз әле, ашыкмагыз әле сез, ир-ат дигән адәмнәр!.. Алайса нигә югары урамдагы Кадрия апагыз бакчасында, әзерләп куеп та

берни чәчелмәгән жирендә, авылга орлыгын быел беренче мәртәбә Галләмнен төпчек кызы Зәринә алып кайткан «ат колагы» борынын төртеп чыккан сон?! Тагын да сонрак, май ахырларында, яна урамдагы Әлфия апа бакчасында, бөтнек чәчә торып, мәче борчагы басып алган?! Хәер, нигә берәмтекләп санап торырга сон! Байтимердә быелгы язда янбакчалардагы бар үсемлекләр дә буталышып бетте ләбаса! Ни хәл бу? Нәрсә сон бу, шайтан алгыры!

...Халык шулай кан катып, шаккатып һәм аптырашып яткан бер мәлдә сәер мәсьәләнен серен тимерче телсез Габдерәхим «әһ» тә итмичә, жинел генә чишге куйды: каргалар гаепле!!! Әйе, әйе, чынлап та, бу адәм ышанмаслык хәлләргә кара каргалар гаепле!..

—Как-так каргалар гаепле әле ?!—дип, каршы төште шундук Сәмигулла.

—Быть не может!—дип кырт кисте фермер Сибгатуллин.

—Ике күзем чыкса чыксын—гомер ышанасым юк!!!—диде Галләм абзыйның хатыны Жәмилә түти. Бер күзенә моннан ун ел элек үк ак төшкән иде инде анын, ләкин барыбер нинди дә булса да мәсьәләгә катгый каршы чыгып, мөһер сугасы булса ул гел шулай ди: «Ике күзем чыкса чыксын» янәмәсе...

—Пантазия бу нииндидер!—дип куйды үз гомерендә берниинди жен-парига ышанмый торган Галләм агай.

—Нинди пантазия булсын. Күзен чыкканмы әллә?! Чын бит инде, чын!—дип, Әлфия апа Галләм агайның изүеннән үк эләктереп алмакчы иде. Эләктерә дә иде, әгәр телсез Габдерәхим, урамга чыгып басып:

—Яффаймайлар!—дип «аваз» салмаса. «Яффаймайлар» дип, әлбәттә, авызын тутырып яки кешегә анлашырлык итеп әйтә алмый инде ул. Бары тик шул мәгънәне анлаткан ымлыклар гына чыгара һәм халык анын авызыннан нинди сүз тәгәрәп төшкәнен тәржемә-анлатмасыз да чамалап ала. Габдерәхим тиктомалдан гына сүгенмәс, ул шулай урысчалатып жиффәрергә мәжбүр булган икән, димәк, аңа ышанырга кирәк. Һәм бөтен кеше ышана... Салих абзыйдан кала, әлбәттә. Ә Салих абзый исә үз чиратында авылда Габдерәхимгә каршы килә ала торган бердәнбер кеше. Хәтта Габдери хак булса да ул аны жөпләп сүз әйтмәячәк, чөнки алар арасында бу авылда үзенә бер аерым мөнәсәбәт: моннан шактый гомерләр элек телсез Габдеринен башсыз малае Габдулла, халык телендә сары Абдул, солдатка китәсе язгы матур кичне Салих абзыйның чәчәк кебек кызын әүвәл клуб уртасына алып чыгып, бар кеше алдында кочаклап суырып үпкән дә, аннары шул ук кешеләр алдында: «Мин армиягә китксч, Батай малаена кияүгә чыкмыйсынмы? Халык алдында ант эч!»—дип, ике кулы белән Саниянен озын толымнарыннан жыеп тоткан килеш ант иттергән. Монысы гына вак-төяк, Абдулы Чечняга китеп баргач, имеш, телсез Габерәхим авыл буенча хәбәр таратып, сөйләп йөргән ди икән: «Вәт, малай булган егет икән минем, тәки Салих кызын үзенә ярәштереп киткән бит, чукынчык!» Әйе, әйе, сөйләп йөргән,—дип сөйлиләр... Габдерәхимнен телсез булуын да онытып...

Күптән булган хәлләр инде болар, ләкин авыл өчен кичә генә шикелле. Авыл теленә бер керсән, шулай инде ул. Югыйсә, механик Батай—Бәхтияр малае—сары Абдулдан сон үзе дә солдатка каралып, Чечня жирендә башын салды. Сары Абдул, армиясеннән хезмәт итеп кайткач, икенче хатынын да аерып, мари авылындагы Үзәкәй кызына өйләнергә өлгергән иде.

—Яффаймайлар!—дип кабатлады телсез тимерче һәм авыл халкы аңлаган хәрәкәтләр белән эшнен серен анлатып бирде: каргалар... кара каргалар... шул кошлар гаепле икән бу эшкә!..

—Как-так?!—дип аптырады Сәмигулла.—Каргаларның гаебе юк монда!

—Шыттыра Габдери!—диде Салих.

—Алайса кем?—диде Галләм абзый һәм такта яручыга, белмәгән башын

белән сөйләнеп тормале, буржуй дигәндәй, каш астыннан сөзеп карап куйды.

—Кит, әкәмәт! Шул телсезгә ышанып торган буласызмы тагын!

Бу сүзләргә ачуы килгән Габдери ни ара Салихның каршысына килеп басты, ни ара якасыннан эләктереп алды һәм:

—Ааа-ууу-иии,—дигән әллә нинди куркыныч ымлыклар чыгара-чыгара аны Галләмнәрнең капка баганасына сөяп куйды. Хатыны Сәлимә арага кереп, телсезне читкә болгап атмаган булса, кул-күкрәкләрендә аю көчләре булган Габдери Салихның бер-ике кабыргасын саный иде югыйсә. Ләкин Сәлимә түти аннан да гайрәтлерәк булып чыкты—телсез юл тузанына барып кадалды. Байтимердә моңарчы бер-берсенә кул күтәргән ир-ат юк, үзара дустанә яшәделәр. Ләкин соңгы берничә елда авыл бөтенләй кире якка үзгәрде дә куйды. Әмма монысына инде кара каргаларның һич кенә дә гаепләре юк, мондый ызгыш-бозылыш вакытында кул күтәрү маһирлыгына ир-ат, «кайткannардан» өйрәнде. «Кайтканнар»,—дип Байтимердә ата-аналары кайчандыр монда туып-үскән, ә балалары авылда яшәргә кайткан буй җиткән егет-җиләнне атыйлар. Аларның бер ишесе наркоман яки алкаш, һәммәсе дә диярлек нинди дә булса вак-төякме, әллә тагын да зурракмы җинаять өчен утырып та чыккан. Ата-ана, шәһәрдә азып-тузып йөргән багалмаларын, болгавыр шәһәр тормышыннан аерып, кеше-кара күзеннән ераграк тәрбия кылу максатларында үзенең элек туып-үскән авылына озатырга тырыша. Моның өчен дистә еллар буе кешесез тора-тора тез чүгә башлаган каралты-куралар сипләнә, яңартыла, кыскасы, яшәрлек хәлгә китерелә.

Байтимердә икенче катлам да бар, алары да—әрәмтамаклар. Алары «кайтканнар»дан шушы авылда туып-үсүләре белән генә аерылып тора. Хәтта күбесе Байтимер кызына өйләнеп, колхозда төпләнеп калырга уйлаган кешеләр, аларны бөек төзелеш кенә үзенә суырып алган, төп яшәеш урыннары Чаллы һәм Алабуга тирәсендә. Җитмешенче елларда, Барый белән Мөхәммәт әле буй үстереп килгән чакларда, Байтимернең бер төркем ирләрен җыеп, колхоз аша «КамАЗ» төзелешенә җибәрделәр. Әлбәттә, вакытлыча гына. Бала-чагасы ишле булганы, авылларын, гаиләләрен сагынып, ярты ел буе кайтып-китеп йөргәннән соң, Чаллыга башка бармады. Яшьрәк ирләр исә шунда төпләнеп калдылар, аларга Чаллыдан фатирлар да эләгеп, тәмам шәһәр кешеләренә әйләнеп беттеләр, шунда туган балалары исә Байтимергә җәйге каникуллар вакытында гына кайткалап торалар. Советлар илен Америка яһүдләре «агач мылтык» белән юкка чыгаргач, Рәсәйдә эшсезлек башланды. Эшчеләр өчәр, дүртәр айга түләүсез ялга җибәрделәр. Менә шул«отпускниклар» басып алды авылны. Чөнки ашарга кирәк, эш булмагач, завод тукталып торгач, боларның кесә төпләре тишелеп бетте. Ә авылда, бигрәк тә туган авылда, туенырга була әле. Күбесенең карт ата-аналары да туган авылда яши иде бит. Чөнки алар теге чакларда шәһәр фатирларына сыймадылар, кайсысы килене белән килешә алмады, кайсыберләрен Байтимергә холыксыз кияү балакайлар кире куып кайтарды. Югыйсә, аларның күбесе, авылдагы өйләрен сатып киттеләр бит. Өй саткан акчалар шәһәр тормышына ияләшә башлаган киленнәрнең лифчик эчләренә сыеп бетте. Андый язмышка дучар булган карт-коры, туган-кардәшләре ярдәме илә көч-хәл белән туган Байтимердә иске, ташландык йортларны сатып ала алдылар. Нәкъ менә шуңа күрә дә аларның бу йортлары җиргә чүккән иде. Иң бәхетле дигәннәре иске йортларны үзләре элек сатып киткән һәм нигезеннән башлап үз хәләл көчләре белән җир тырмашып салган шыгырдап торган каралты-куралы өйләрнең күршесеннән үк туры китерә алдылар. Әмма аларны торгызырга пенсия акчалары гына җитми, ә киленнәрнең ими чүпрәкләре бу вакытта табигать биргән байлыкларын гына кысып-җыеп тора иде инде... Ләкин картлар моңа да бик канәгать булдылар, үз туган җирләренә кайтып

жыгылдылар бит, бахырлар... Шөкер, пенсияләре дә килеп тора. Һәм ул такы-токы акчалар Чаллы якларыннан өчәр айга түләүсез ял алып кайткан сакаллы балаларын туйдырырга да житми үк түгел иде әле.

Рәсәй илендәге язмышлар диген... Адәм баласына нинди генә газаплар күрсәтмәде ул. Нигә һаман мантый алмый соң бу ил?! Гасырлар буена хәерчелектә яшәп буламы икәнни ул?

Монын нинди дә булса сәбәбе булырга тиеш ич инде канә? Мөгаен, бу сәбәп милли холыкта яшеренеп ята торгандыр әле?.. Югыйсә, болай булмаска тиеш бит...

Авыл теле белән әйтсәк, «әрәмтамаклар» катламын тәшкил итүчеләр Байтимердә менә шулар.

Алар кайткач, авылда бурлык башланды, яшелчә бакчалары басылды, бураздалардан бәрәнгеләр казылып алынды, кетәклектән югалган тавык-чебеш турында әйткән дә юк инде, хәтта казлар саны кимеде, авыл халкы бозауларын арканга бәйләргә курыкты. Менә шуннан соң ызгыш-талаш китте, кайвакыт, каракны кулыннан тоткан чакларда, мөнәсәбәтләр кул сугышлары белән төгәлләнә торган иде... Ләкин ничек кенә булса да эшләр беркайчан да судларга кадәр барып житмәде. Ни әйтсән дә, алар беренче чиратта авылдашлар бит әле. Тик менә шуннан сон бер-беренә кул күтәрергә, бер-берсенен борынын канатырга гадәтләнеп калдылар бит тәки. Гомердә булмаганны...

Байтимер чаклы зур хужалыклы авыл бөтен Рәсәенә берәү генәдер әле: анда биш меннән артык кеше яши, заманында бер Байтимернен үзендә генә дә жиде мәхәллә, жиде мәчет булган! Шуңа күрә «кайтканнар» гына зур авылнын төп тормыш көен әллә ни үзгәртә алмадылар, чөнки анын борынгыдан килгән гореф-гадәтләре нык тамырланган иде. Ә караклар өчен халык усал этләр тота башлады, хәтта бер ишегалдында икешәрне!.. Шуңа күрә төнге авылда безнен Пиратка да бер дә күнелсез түгел хәзер.

...Сүз белән мавыгып, Габдеринең юкка чыкканын да абайламый калганнар иде, менә ул жыелып торган халыкның аяк астына каяндыр ике кара карга үләксәсе алып килеп атты. Каргаларның ачык авызларыннан орлыклар коелды. Бакчадан бакчага йөреп орлыкларны буташтырып йөрүчеләр тәгаен шулар икән!

—Яффаймайлар!—диде Габдери һәм бая үзен тузанга төртеп егуларына үпкәләп, тимерче алачыгына таба китеп барды.

...Пират аеруча авылдагы иң усал этне, Сәмигулла шәһәр базарыннан зур акчалар түләп алып кайткан зәһәр Барсны үз итте. Аларнын беренче очрашулары урманда булды. Хужа алып кайтып бәйләгән көннең икенчесендә үк Барс, тимер чылбырын өзеп, урманга качты, чөнки анын тамырларында ирек, бәйсезлек каны шаулап ага, ул бүре баласы иде. Дөресрәге, әнкә эт белән кушылдырылган бүре малае. Ул төнне алар Пират белән урман-кырларда йөреп кинәнделәр, икесенә бер куян да тотып ашадылар әле. Сәмигулла аны икенче көнне кичен генә табып алып кайтты һәм бу юлы чылбырнын ныклысын әзерләп куйган иде. Ләкин чылбыр белән генә котылып булмаячагын анлады хужа кеше һәм аны төрле юллар белән үз йортына, хужасына ияләндерергә керешге. Ә монын исә бер генә юлы бар, ул да булса, тәмле тел, тәмле ризык. Хәер, бүре баласын монын белән генә дә үзенә тугрылыклы иту шиктый четерекле булып чыкты. Энгер-менгер төшүгә, Барс янә тынычсызлана башлады, урманга карап улый-улый өрде мәсбүх. Үзсүзле, киребеткән Сәмигулланы алай гына жиңеп булмаячагын чамалап бетерми әле ул: хужа үзенә йокы урынын ат арбасы өстенә әзерләде. Арбаны

эт оясы янына ук китереп куйды. Менә кичне төн алыштырды, Барс торган саен тынычсызлана, вакыт-вакыт, урман ягына карап, елый, өреп тә куйгалый. Андый чакларда, Сәмигулла сикереп торып, эте янына килде, башын тез өстенә куеп иркәләде, сыйпады, муен асларын кытыклады, алдан ук әзерләп куйган ит калҗасын каптырды. Хуҗа белән эт өч көн рәттән төнне шулай уздырдылар. Дүртенче көн дигәндә хатыны Рәзифә түзмәде, өйдә кара тавыш чыгарды: «Син миннән бизден! Сиңа мин кирәк түгел! Сиңа эт кирәк! Алай булгачтын әнкә эт алып кайтырга иде!»—дип ярсыды хатын. Гомерен, инде өйләнеп, бала-чагасы булса да, Рәзифәнең мәхәббәтен яуларга багышлаган Сәмигулла, әлбәттә, сөеклесенә каршы тора алмады. Бүгенгәчә куркып яши Сәмигулла, Рәзифәдән дә курка, Мөхәммәттән дә курка, Рәзифәне ярата, Мөхәммәтне күралмый. Рәзифәне үзеннән тартып алыр дип уйлый. Тикмәгә генә шушы гомергәчә өйләнмичә йөрми торгандыр дип шикләнә. Шул хәерсез шик һаман котыртып тора. Кыргый этне дә, бүре баласын да кулга ияләштереп була, ләкин хатын-кызның мәхәббәтен яулау... ай-һай!.. Моның нинди кыен гамәл икәнлеген Сәмигулладан гына сорыйсы бар! Әлбәттә, хатынын үзе шул чаклы үлеп яратмаса, алай йөрмәс иде, ир-ат горурлыгын йөгәнләп тормас иде... Шашып ярата шул... Нишләтәсең... Тырыша торгач, максатына да ирешмәде түгел ич инде—Әнә, Рәзифә хәзер ансыз йоклый да алмый... Димәк... Бирсен Ходай...

Ләкин Сәмигулла барыбер чүпрәккә әйләнеп бетмәгән әле, «итәк астыннан» вакыт-вакыт башын чыгаргалап алгалый. Бу юлы әлеге гамәле аның өчен бик унай булды: кичтән уртак ястыкка башын төрткән булса да, барыбер сәгать саен диярлек ишегалдына чыгып, эте янына килде, калҗа каптырып, башын сыйпап кереп китте; ашарга биргән саен этләрнең башына сугып торасы юк, алар мәче түгел. Теге дөньяда алардан сорарлар ди: хуҗаң ашаттымы дип. Мәче: «Юк, ашатмады!»—дип ялганлар ди. Этләр һәрвакыт: «Әйе, хуҗам яхшы ашатты»,—дип торырлар ди. Шуна күрә, ашарына биргән саен, мәченең башына сугып куярга кирәк. Ахирәттә әгәр: «Юк, хуҗам ашатмады»,—дип алдаса, аңа әйтерләр ди: «Син ялганлыйсың бит. Әнә, башында кара тап бар, ашарына биргән саен хуҗаң синең башыңа сугып куйган булган, шунын эзе бит ул!»—диярләр, ди.

Барс та акрынлап хуҗасына ияләнә-күнегә башлады. Тик бүре баласын бүреккә салсаң да... Дүртенче төнне, Барс, дустын сагынып, капка астына Пират килеп башын тыгуга, ул янә чылбырын өзәргә талпынып карады, әгәр Сәмигулла вакытында чыгып күреп алмаган булса—өзәчәк һәм тагын Пират белән бергә урманга качачак иде. Бу юлы хуҗа кеше уяурак булып чыкты, этнең шыншуын ишетүгә, урамга атылып чыкты һәм капка төбеннән качып бара торган бер ят этне күреп алды. Тәгаен генә чамалап бетерә алмады, бүрегә дә охшатты ул аны... Һәм танып та алды! Бу... теге—Пират дигән бүре кавемле Барый Әкбәров эте бит!.. Әкбәров ничә айлар буе эзли инде аны, Сәмигулла яхшы белә: ишегалдына алып кайтып бәйләр өчен түгел, әлбәттә—атып үтерер өчен!.. Пират Әкбәровның төн йокыларын качырган һәм саташтырып, Әкбәровны җүләргә салыштыра язып, хастаханәләргә керткән җан иясе бит инде. Авыл күзеннән бернинди дә яшерен эш юк Байтимердә... Әйе, этләрнең башына сугып торасы юк—алар барын да яхшы хәтерли. Инде ничәмә ничә еллар узса да, ялгыз башы урман-кырларда каңгырап йөрсә дә, ул Әкбәровны эзәрлекли, тегесе исә аны атып үтерергә хыяллана. Шулчак Сәмигулланың башына бер уй килде. Әйбәт, яхшы уй! Әкбәровтан үч алырга менә дигән җай чыгып тора, шайтан алгыры!..

Үч алу—күнелләге давылны тынычландыруның бердәнбер кулай юлы. Мөхәммәтне дә Әкбәров кенә котырта, ул әүвәл аның гаиләсен, аннан соң

үзен юкка чыгарырга уйлый. Ничәмә-ничә еллар Сәмигулла күңелендә әнә шундый авыр хис асрый, бик теләсә дә ул аннан котыла алмаячак—акылына буйсынмый торган бер хәерсез хис ул... Гыйшык акыллы хатынны акыллы итсә, акыллы ирне акылсыз итә, дип, юкка гына әйтмиләр. Сәмигулланың акылын югалтуының тагын да бер сәбәбе бар, ул да булса, организмында барган химик реакция! Әйе, әйе. Нәкъ менә шул химик реакция организмда серотин дигән матдә бүлеп чыгара—ул кешедәге женси гармоннар өчен җавап бирә. Мари урманында исеме дә билгесез булмаган сәер агач үсә, аның исе бик тәмле, шул исңең молекулаларында серотин элементларының химик формуласы бар. Кеше организмына килеп эләккәч, ул беркавым вакыттан соң серотин бүлеп чыгара башлый.

Бу исемсез агач күрмәгәнен күрсәтте инде Байтимер халкына. Урманга җиләккә дип барган кыз-кыркын очраклы рәвештә шул агач янына килеп чыкса, алар ни кыланганнарын белми башлыйлар, урманнан кайтышлый Илләттә балык тоткан мари малайларына үзләре килеп бәйләнәләр. Юкка гына Байтимер кешеләре кытайлар кебек үрчеп биш меңгә җитмәгәндер инде!..

Безнең такта яручы Сәмигулла урманга еш йөргәнлектән, аның ашказанындагы химик реакция бер дә тукталып тормый. Ул моны хатыны Рәзифәгә мәхәббәтенең көчле булуы белән аңлата. Ә мәхәббәт белән көнчелек исә бер юрган астында йоклыйлар...

## Тыныч күлдә җеннәр үрчи

Дөнья—куләсә... Монголлар урыс җирләрен яулап алдылар. Көрәш каты булды. Ләкин чиркәүләр үз урыннарында калды, аларга тимәделәр. Ханның әмере шундый булды. Шуннан соң урыслар гасырлар буенча җинүчеләргә ясак түләп торырга тиеш булдылар.

Дөнья—куләсә...

...Үлгән һәм яраланган кешеләр сансыз: Казан елгасыннан урманга чаклы булган болынлык, шулай ук урман кырыендагы аланнар, эчендәге еланнар барысы да татар үлекләре белән тулган иде. Шәһәрнең эче белән тирәсе бигрәк тә куркынычлы булып, аның һәрбер урамнары үлекләр белән тулган, йөрүчеләр үлекләр өстеннән йөриләр иде. Хан йорты артындагы чокырлар, Казан елгасы буе, болынлык—барысы да татар үлекләре белән тулып, кайсыбер урыннарда өем-өем яталар иде... Иван татарларның хатын-кыз һәм яшь балаларын тере калдырырга боерып, эшкә яраклы ирләрнең барчасын үтерергә боерды...

...Этләргә һәм татарларга керү каттый тыела!..

Дөнья—куләсә...

...Хазарлар башлыгы яһүди Песах урысларны тар-мар итте... Карт Игорьнең гыйффәтле хатыны Ольганы кулга төшерде. Шуннан бирле урыс князьләренең каны буталды...

Дөнья—куләсә.

...Петлюра казаклары... яһүдиләрне шәп-шәрә калдырып чишендерделәр, кулларыннан бәйләп түшәмгә астылар һәм аяк очларына учаклар яктылар. Бер карт яһүднең сакалын кисеп алып үзенә ашарга мәҗбүр иттеләр, шуннан соң рәхәтләнеп көлә-көлә аны тураклап ташладылар. Калганнарның кулларын, аякларын кистеләр, иреннәрен кисеп алдылар, күзләрен чокып чыгардылар, көмәнле хатыннарның корсакларын ярдылар. Качып китүчеләрне мылтыклардан, пулеметлардан кырдылар...

Дөнья—куләсә, бер әйләнә, бер баса...

...Мин—Израэль Исаевич Воронов, туган җирем Советлар иле, гражданлыгымның икенчесе—Израэльдә. Үзем Казанда эшлим, яшәвем Казан артындагы яһүдиләр бистәсендә.

Мин Израэльдәге «Натив» дип аталган разведка хезмәте мониторгы. Гадирәк итеп әйткәндә, агент, шпион дисәң дә була. Юк, юк, шпион ук түгелдер. Болай дип атау үземә дә көлке тоела. Мин бары тик мәгълүмат җыючы гына. Әлеге мәгълүматларым бүгенгесе көндә Израэль разведхезмәтенә кирәк булса, киләчәктә ул минем фәнни эшемнең төп темасы.

Мине татарлар кызыксындыра. Аларның тарихи язмышлары яһүдләр язмышы кебек. Шулай ук алар да бөтендөнья буйлап сибелгәннәр. Шунысы кызык: Рәсәйдә һәм Казан тирәсендә яшәгәннәре милли гореф-гадәтләрен, телләрен акрынлап югалтып баралар, ә чит илләрдә гомер кичерүчеләре туган телләрен яхшы белә, милли йөзләре дә күбрәк сакланган.

«Миңа ышаныгыз, халык картаймый һәм акыллыланмый, халык һәрвакыт бала булып кала»,—дигән Гете. Бөек сүзләр. Шуңа күрә миңа бу халыкның үткәне дә, бүгенгесе дә бик кызыклы.

Дустым Барый Әкбәров бу тирәләрнең хуҗасы, бәләкәй генә булса да «власть» кешесе. Ул властьның тәмен белә торган егет. Хәер, хакимлек хисе адәм баласындагы иң көчле хис ул, хәттә мәхәббәт хисеннән дә өстенрәк тора. Барыйны өнәп бетермиләр, ләкин куркалар. Әйе, хаким белән халык арасындагы каршылык адәм баласының табигатенә үк салынган инде. Һәр җан иясе үзен башкалардан өстенрәк дип уйлый һәм тормыш рәхәтлекләре аңа күбрәк булырга тиеш дип исәпли. Кешелек яралганнан бирле иң яхшы җәнлек тиреләре, иң тәмле-том, иң гүзәл хатыннар көчлеләрнеке булган, ягъни тәхеттәгеләрнеке.

Һәр кеше дә беренче булырга һәм иң яхшысын гына үзенеке итәргә тели. Ләкин без шулай булуга карамастан, аерым гына тормыш итә алмыйбыз, безгә башка кешеләр белән бергә яшәү кирәк. Димәк, арадан кемдер берәү лидер булырга тиеш. Мәсәлән, бер урында биш-алты дистә кеше җыела икән, шулар арасыннан һичшиксез берәвен башлык, хаким итеп сайлап куярга кирәк, югыйсә, мин көчлерәк, мин әйбәтрәк дип талаша-талаша, алар бер-берсен кырып бетерәчәкләр.

Ләкин һәр кешегә дә хаким булу сәләте бирелмәгән. Бу талант адәм баласына Ходай тарафыннан индерелә!..

«Татарларның тарихы гаҗәеп гыйбрәтле». Израэль Исаевич үз хезмәтен әнә шундый җөмләдән башлап китәчәк. Чөнки бу аңа, аның милләтенә дә бик якын. Язмыш ягыннан караганда да, тарихи күзлектән чыгып та. Татарлар һәм яһүдләр дөнья буйлап таралган. Икенчедән, тарихи җепләр дә бер-берсенә килеп урала түгелме соң?! Хазарларның төп өлеше төркиләрдән торган бит. Югары катлавын яһүдләр тәшкил иткән. Алар Киев Русына барганнар, князь Игорьны тезләндергәннәр, аның хатыны Ольга малаеның атасы да... яһүд бит! Һай, бу тарихи бергәлек һәм аерымлыклар...

Татарларны милләт буларак Ислам дине саклап калган. Башка милләтләрне үз диннәре... Безнең хәтта уртак пәйгамбәрләребез дә бар: Гайсә, Муса, Якуб һәм башкалар. Без барыбыз да Илаһи көч барлыгын таныйбыз, хәтта фән дә, галимнәр дә—акыллыраклары—ул көчне инкарь итәргә кыймый.

«Җирләрдә һәм күкләрдә булган барча мәхлүклар кайберләре ихтыярый вә кайберләре ихтыярсыз Ходайга сәҗдә кылырлар вә иртәләрдә һәм кичләрдә үзләре сәҗдә кылганда күләгәләре дә сәҗдә кылыр»

«...Бар шундый кешеләр—алтын вә көмеш җыеп асрарлар, Аллаһ юлына һич тә бирмәсләр, аларга рәнҗетүче газап булачагы белән хәбәр бир. Җыйган ул алтын-көмешләре кыямәт көнендә җәһәннәм утында кыздырылып,

мангайларына вә кабыргаларына, вә аркаларына басылыр һәм әйтелер: болар дөньяда вакытта үзегез өчен асыраган алтын вә көмешләрегез. Инде саранлык белән җыеп саклаган малыгызның газабын татыгыз». Пәйгамбәрләр аша кавемнәргә индерелгән сөрән бу! Янау, куркыту түгел—Хакыйкатьнең нәкъ үзе...

Атаклы физик, Нобель бүләге иясе Вигнер әле узган гасырда гына математиканың табигый фәннәр өчен нинди зур әһәмияткә ия булганын бары тик Илаһи көч барлыгы белән генә аңлатып була дип, үзе дә шаккатып язды. Ньютон, Платон, Аристотель, Спиноза, Кант, Гегель һәм башка бик күп галимнәр Галәм Раббысының барлыгын инкарь итә алмаганнар...

Мин, Израэль Исаевич, Барый Әкбәровны зур хакыйкатькә күндердем: тау башына ул диннәр храмы салачак! Ул моны үз фикере, әүвәлдән үк үз башына килгән идея дип ышанып йөри. Ләкин бу орлыкны мин чәчкәнне сизми дә калды, бахыр. Хәерлегә булсын, мин авторлык хокукын дәгъваламыйм. Ислам җирлегендә вахаббитлар үрчемәсен, мин шуннан куркам. Югыйсә, минем Израэльдәге туганнарым алардан көн дә үлем һәм меңнәрчә төрле зыян күреп тора...

Дин кануннарын җанны коткару өчен табип тәкъдим иткән дару кебек чәйнәп нитеп тормыйча тоташ кабул итү зарурдыр...

Тигезлек. Туганлык. Ирек! Менә безнең максат нидән гыйбарәт!..

## Вәлиев Сибгат, аның кызы һәм җимеш сатучы кияү

Капкасын Барый Әкбәров дөбердәткәндә Сибгат абыең җиләнче төшеп күрә иде инде. Капка тавышына иң әүвәл хатыны Сәнифә уянды. Һәрхәлдә Сәнифә үзе шулай дип уйлады. Чынлыкта исә кызлары Сәлимә бу вакытта күзен дә йоммаган иде—үзе йоклаган бүлмәнең тәрәзәсен Нури килеп шакыр дип өметләнеп ята иде ул җиде төн уртасында. Юеш май җиле төнне тагын да суытуга карамастан, Сәнифә эчке күлмәктән генә өйалдына атылып чыкты һәм әче тавышы белән:

—Кем бар анда?—дип сорады. Үзе бер кулы белән өйалды ишегенең тоткасына чатырдап ябышты, теге нәмәрсә, ягъни азербайҗан кияү булса, бар ишегалдына кара тавыш чыгарып, ире Сибгатны уяту иде. Хатын җәһәт кенә өйалды почмагында сөялеп торган сәнәккә карап алды, салкын корал урынында тора. Кызганыч, Казаннан алып кайткан усал этләрен, кемдер агулап китте.

Тавышының әчелеге аның үзенә дә ошады, тик урам яктагы кешенең колхоз рәисе икәнлеген белгәннән соң әлеге әче тавышка мизгел эчендә нидер булды—ул чишмә челтерәвенә охшап калды.

—Хәзер, Барый Хаҗиевич, хәзер ачам.

Хатын инстинкт белән өстендә юка эчке күлмәк икәнлеген тоеп, әүвәл тиз генә иненә халатын салып чыгарга уйлаган иде, ләкин өйгә кире кереп йөрү хуҗа кешене күтәрү була дигән фикер белән Сибгатнең бусага төбендә торган кырык бишенче үлчәмле калошларын эләктерде дә, лаштор-лоштыр, капкага таба китте. Хатынны бастырыкка чаклы: «Барый Хаҗиевич мине эзләп килгәндер, бозауларның ач калганлыгын ишеткәндер дә... Мина склад ачкычын алып килүедер, бригадир итеп куймакчы була торгандыр мине. Кәримәне төн уртасында эшеннән чыгарып ыргыткандыр да... ну тәвәккәл кеше инде безнең председатель!»—дигән тәмле уйлар озата барды.

—Сибгаткә әйттем бит мин, капканны бикләми тор дидем!—Авыл хуҗасының тавышы чак кына ачулы. Башка чак булса, Сәнифә апаң үзенең бозау ирен председательдән күбрәк һәм аяусызрак сүктерер иде, ләкин бүген

ул гаепнең үзендә икәнлеген танмыйча булдыра алмады, исәбе хужа кешегә йортларына бәла килгәнлеген дә сиздерәсе килү бугай.—Теге җимеш сатучы тәмам үзәккә үтте бит, имансыз! Көн-төн тынгылык бирми, килмешәк!

Барыйның: «Нинди килмешәк ул тагы?»—дип, авыз ачуы булды, кызы Сәлимәнең базарда җимеш сатучы кавказлы белән чуалып китеп, качып шуңа кияүгә чыгарга йөрүен сөйләргә әзерләнгән хатын, Сибгатнең зур галошларына сөртенеп тә китте һәм, Барыйга таба авып, колхоз хуҗасын дәү имиләре белән капка баганасына терәп куйды. Житмәсә, бер имие пылт итеп эчке күлмәк изүеннән атылып, һава суларга да чыгып өлгерде һәм, егылмыйм дип, аз гына чүгәләгән Барыйның нәкъ борын тирәсенә туры килде. Кайнар иде хатынның тәне, дымлы май җиле белән генә суынып өлгермәгән иде әле.

Сәнифә Барыйның Һади абыйсы белән яшьтәш, ун ел буе бер сыйныфта укыдылар. Һадиның сыйныфташ кызлары, мәктәптә укыганда, үзләреннән шактый яшьрәк Барыйны «минем киявем буласыңмы!»—дип шаяртып, теңкәләренә тияләр, алай гына да түгел, юлларында туры килсә, бәләкәй буйлы малайны тотып алып суырып үбәргә дә күп сорап тормыйлар һәм шул рәвешле аны тәмам оялтып бетерәләр иде. Менә... әллә... ничә еллардан соң «кияү» булып алырга да язганмы соң?.. Барый, теге чактагы шаяртуларны исенә төшереп, учы белән Сәнифәнең кайнар имиенә орынды.. Тегесе, шаяргандай булып, Барыйның күкрәгенә ике кулын терәде дә аны читкә этәргәндәй итте. Итсә дә итте, итәсе килмәсә дә итте: өйдә «бозау булса да» ире бар ич!..

—Сибгат кайда?

Барый житди кыяфәт алып өлгергән иде.

—Соң... бу вакытта? Кайда булсын инде, йоклый.

Сәнифә аның бу соравына иренеп кенә җавап бирде, чөнки Барыйны Сибгат янына түгел, үзе янына, ана җиде төн уртасында амбар ачкычларын тоттырып, мөдир итәргә килүе дип өметләнгән иде ләбаса. Элекеге «складчица»ны эштән алып, бүген бозауларны ач калдырганы өчен. Малларга он үлчәп бирүче тол Кәримә кичтән исерек килеш амбарга кереп йоклаган. Юк, ана Сибгат кирәк булып чыкты бит әле. «Каравыл тавында берәр машинасы батып калгандыр да, Сибгатьтән тракторын кабыздыртырга исәплиләрдер... Хәер, колхоз маллары кайгысымы соң боларда!..»—дип, тагын да иренебрәк фикер йөртеп алды Сәнифә.

Вәлиев Сибгат Барыйның иң алдынгы, ин булган механизаторларыннан берсе. Барый аның янына юкка гына килмәде. Кешеләр янына төнлә йөри ул хәзер. Чөнки чәчүләр тәмамланганнан соң тау башына күчү хакында хәлиткеч соңгы җыелышларның берсе буласы.

—Сибгат абзый,—диде ул әле һаман уянып җитә алмаган хуҗага:—Сиңа җирне мәчет яныннан ук бирергә булдым... Тау башында дим. Анда урыны да тигезрәк.

—Мәчет яныннан?—Сибгат капылт уянып китте.—Нәрсә, үзбәк кияүгә мәчеткә йөрергә якынрак булыр дисеңме! Син дә мыскыл итәргә уйладыңмы инде, Барый туган, ә?!

Аның бу сүзләреннән Барый югалып калды, ни дип җавап кайтарырга да белмәде, чөнки ул мәсьәләне белеп бетерми иде әле.

—Ишеткәнсеңдер инде, минем кыз, олы кыз Сәлимә, базардагы җимеш сатучы үзбәк белән чуала башлаган. Капканы да шуңа күрә кичтән бикләп куям хәзер,—дип, әлеге хәлгә Сибгат үзе ачыклык кертте, әйе шул: председатель ишетеп тә бетермәскә мөмкин бит. Ә ишетсә, ярдәм итүе бар, бик бар. Уен түгел, Сибгат абзаң аның карап торган механизаторы да.—Кудырт шул үзбәкне Казаннан, Барый, ә?! Этне дә шул мәлгунь гына агулап китте бит, ә?..

Ул ялварулы күзләрен авыл хуҗасына төбәде.
—Һем.. мәчет янындагы урынга ризамы соң син?
—Риза, риза, кудырт кына, чокырлы, ташлы җир булса да риза.
Алар кул сугыштылар.
—Борчылма, Казан-Ташкент поезды йөреп тора бит әле.

Кызганыч ки, бу сөйләшүне җимеш сатучы үзе ишетмәде, әгәр ишетеп калса, чатыр-чабып, вокзалга атылган булыр иде, бахыр...

Чынлыкта, Сәлимәнең башын әйләндерүче үзбәк кешесе түгел, әзербайҗанлы Нури иде. Нури да, башка кардәшләре кебек, озын акча эшләргә Казанга килгән адәм.. Бүтәннәр, ана чаклы килгәннәр, кайсы-кая йортка кереп, ялгыз татар хатыннарына өйләнеп, урнашып беткәннәр, андый уй белән шәһәрдә һич тә баш тыгарлык түгел. Нури аптырап калмады, шәһәргә ерак булмаган авылдан үзенә «яр» эзләргә керешге һәм бер дә бер көнне ана да бәхет кояшы елмайган шикелле дә булды: ул Байтимер кызы Сәлимә белән танышты. Сәлимәгә өйләнеп алса,—югыйсә, Нуриның Сумгаитта хатыны, өч баласы бар,—эшләре тагын да көйләнеп китәчәк. Беренчедән, авыл шәһәр түгел, монда, кияү булган очракта, әлбәттә, тонналап җимеш саклап була, икенчедән, теркәлү кайгысы бетәчәк бит. Шул рәвешле ике-өч ел уңышлы гына сәүдә итә алса, аннары ул, барысын да ташлап, беренче чиратта Сәлимәне, Сумгаиты ягына карап, койрыгын сыртка салачак, кыскасы, моннан кыяклаячак, төзелә башлаган нигезенә ике катлы йорт күтәрәчәк һәм үз хатыны Зөллә белән рәхәтләнеп гомер кичерәчәк иде.

«Сәлимә, Сәлимә»,—дип уйлап куйды Барый Сибгатләр капкасыннан чыккач. Чү! Тукгале!.. Аның язмышында Барыйның да катнашы бар түгелме соң?.. Әйе шул, теге чакта шабашник әрмәннәргә аш пешерергә куйдыртты бит ул аны. Көчләп диярлек. Үгетли-үгетли. Ата-анасы белән сөйләште сөйләшүен... Ул чакта бәләкәй генә Т-25 тракторында эшләп йөргән Сибгатне зур тракторга утыртты, Сәнифәгә амбар ачкычларын вәгъдә итте. Сибгатнең әни карчыгы гүр иясе булган вакытлар. Кечкенә трактор белән генә дүрт баланы аякка бастырырлык акча эшләп булмый, әни карчык китеп баргач, бердәнбер карап торган акча чыганагы—пенсия дә килүдән туктады. Авылдагы күз карасыдай медпункт та ябылган, шәфкать туташы һөнәренә укыган Сәнифә дә эшсез калды. Дөресрәге, Сәнифә эшсез калмады, ә акчасыз калды. Авыл халкы табип ярдәменә кая барсын—һәммәсе дә Сәнифәнең капкасын шакырга мәҗбүр. Сибгат әүвәл моңа каршы торды. Шуннан соң авылдагы карчыклар кан басымын үлчәтергә дә районга—кече Филигә йөрергә тиешләр иде. Шул рәвешле юлда ике карчык, хастаханәгә барып җитә алмыйча җан-тәслим дә кылдылар. Ирләрен сугышта югалткан хезмәт, тыл ветераннары... Картлык көннәрендә алар хөкүмәткә артык кашык булып чыктылар. Шуннан бирле Сәнифәләрнең йорты медпунктка әверелеп китте, күрә торып, авылдашлырның юк кына чирдән дә кырылганын карап торып булмый бит инде.. Ә теге карчыкларның чак кына уйнап алган кан басымнарын көйләү өчен бирәр укол гына кирәк булган икән, югыйсә!..

Шабашник әрмәннәр—алар колхозда бозаулар фермасы салу белән берочтан Казан читендә кече Филидагы бер иптәшкә коттедж да төзиләр иде—пешекче итеп яшь татар кызын таләп иттеләр. Барый аларның теләкләренә каршы килә алмады, әнә шул рәвешле җиләк кебек ять-яшь кыз пешекче булып эшли башлады. Югыйсә, шул көздә педагогика институтына укырга кереп, хыялы укытучы булу иде. Дөрес, ярты ел уздымы икән, юкмы, Сәлимә Казанга качты качуын. Ләкин бу адымы түгәрәкләнеп килгән корсагын әти-әнисе һәм авылдашлар теленнән яшерү өчен иде. Билен кысып буып йөри торгач, бер дә бер көнне «әрмән калдыгы»тулай торак туалетында агып та китте... Шәһәрдә эшсез интегеп йөргәннән соң кыз янә әти-әнисе янына

кайтып егылды, ләкин ул кара тутлы Нури атлы егет белән танышып өлгергән һәм иртәгә үк ана кияүгә дә чыгарга әзер иде.

Усал этка агуны Сәлимә ашатты...

## Бәрхетгәрәев Галләм һәм аның кызы Зәринә

Тракторчы Галләм капкасын да төнлә шакырга уйлады Барый. Төнлә килеп керү, беренчедән, халыкны каушатып җибәрсә, төнге сөйләшүләр гадәттә үтемле була, аңа берәү дә каршы килми торган иде. Бу инде сыналган алым.

Ни гажәп, төн уртасы булуга кармастан, Галләмнең капкасы бастырыкланмаган иде. Барый ишегалдына керде дә, үрелеп, тәрәзәгә чиртте. Лапас ягыннан эт өргән тавыш ишетелде. Тракторчының бозау чаклы бик усал эте барлыгын белә Барый, шуң күрә җәһәт кенә шул якка күз ташлады, урам баганасындагы лампочка бар ишегалдын яктыртып тора, лапас ишегенең бикле икәнлеген күргәч, тынычланып, янә тәрәзәгә тырнак очы белән тиеп алды. Галләм агай үзе чыкты, төнлә борчучының Барый икәнлеген күргәч, аптыраган булды, әмма аның нигә килгәнлеген сизгер карт белә һәм шуңа күрә дә алдан ук кабырга йоннарын тырпайтты.

—Минем тракторга ут капмагандыр бит, Барый энем. Ут капса да минем эшем юк, чөнки кичә яшь малай эшләде, мин билемне кузгалттым, сыктаулап торам әле.

—Беләм, Галләм абый, беләм. Мин башка йомыш белән.

Галләм, өйалды утын яндырып, төнге кунакны баскычка утырырга чакырды, үзе тәмәкесен кабызып җибәрде.

—Җә, ни булды?

—Ни дип инде, үзең дә беләсең бит, Галләм абый, шул күченү турында инде, тау башына дим.

Галләм тәмәкесен тәмләп суырды да яшел күзләре белән Барыйга карап куйды, аннары көлемсерәп:

—Тау башына дисең инде алайса?

—Әйе... авыл белән.

—...жил белән, давыл белән, килсә килсен, эшербез ил белән, авыл белән дисең инде алайса?..

—Алай димим бит әле, Галләм абый.

—Димисең, әмма ләкин шулай дип уйлыйсың син, энем.

Зур гәүдәле, көрәк куллы Галләмдә юмор хисе бардыр дип, башына да китерми иде Барый, карт шаяртырга да оста икән. Ләкин аның тавышы кинәт житди төсмер алды.

—Син беләсеңме, энекәш, утыз жидедә минем әтине нәрсә өчен алып киткәнннәрен?

—Белмим, Галләм абый.

—Алайса сиңа авыл тарихын өйрәнергә кирәк, энем, кешеләрнең үткәнен. Әйтим белмәсәң, утыз жидедә синең бабаң, кызыл коммунист Әкбәр агай тау башындагы Байтимер авылын тау астына күчереп йөргән. Минем әти күчмәгән, каршы килгән. Шуның өчен аны, син халык дошманы дип, сөргенгә озатканнар. Шул елны мин туып калганмын. Әти кире әйләнеп кайтмады, мин аны бер тапкыр да күргәнем булмады.

—Минем бабай гаепле булмаган бит анда!

—Белмим дигән буласың, менә үзең дә беләсең икән бит, энем. Ие, синең бабаң гаепле булгандырмы, юктырмы... эш узгач, әтине яклап караган, чөнки дус булганнар алар, энем. Әкбәр абыйга, авыр туфрагы жиңел булсын, үзенне дә ябып куябыз дигәч кенә районнан кайтып киткән ул. Әтине соңгы юлга

озатып калучы да шул булган. Әнигә кайтып сөйләгән... и гомер буе безнен гаиләгә ярдәм дә итеп торган әле. Әтинең сөрелүендә, күрәсең, үзен гаепле санагандыр инде...

—Шулай булгач, нигә карышасың, Галәм абый, мин сина иң шәп урыннан җир бирдертер идем. Әйт халыкка, синең бер сүзең җитә.

—Беләм бер сүзем житкәнен. Тик әйтмим, энем, әйтмәячәкмен. Үзем дә күчмим. Лучше биреп җибәр син мине... Сизәсеңме, тагын утыз җиденче еллар исе килә башлады бит... Мине рәхәтләнеп бөгәрләп тыгачаклар. Себергә үк барып җитә алмам алуын, карт сөякләрем юлда ук таралып бетәр...

Барый дәшмәде, тракторчы белән саубуллашты да капкага таба атлады. Тик соңгы сүзе итеп әйтеп куйды:

—Бурзаенны бәйдән ычкындыра күрмә, Галләм абый, эт атучылар йөри...

Барый котычкыч авыр һәм күңелсез уйлар белән машина ишеген ачты һәм егылып китә язды: машина эчендә ниндидер шәүлә бар иде. Ләкин «шәүлә» ана хуштан язарга ирек бирмәде, телгә килде:

—Мин бу, Барый абый, Зәринә.

—Зәринә?! Нишләп утырасың монда, кайдан килеп чыктың син?!

—Тәрәзәдән чыгып шылдым. Сез әти белән өйалдында утырганда.

—Йә, нәрсә кирәк инде сина, кызый?

—Мин кызый түгел.

—Мина димәгәе!..

—Барый абый, зинһар, кызма әле. Мине тыңла син әүвәл. Синең әти янына ник килгәнеңне беләм бит мин. Тик син ул кире беткәнне үгетли алмаячаксың, әти тау башына күчәргә ризалык бирми икән, ана карап бүтәннәр дә кузгалмаячак.

—Йә, шуннан!

—Шуннан шул, Барый абыкаем, әйдә, тау башына киттек. Безгә йорт урыны сайлыйбыз. Әти минем сүзне тыңлаячак!

—Тыңламаса?

—Тыңлар! Тыңлаячак! Мин вәгъдә бирәм! Сез вәгъдәгездә тордыгыз бит, мине культурага укырга керттегез!

Машина тау башына алып менә торган юлга таба борылды.

Тау башына менеп житүгә, Зәринә машинадан сикереп төште дә:

—Барый абый, ә клуб, культура йорты кайсы урында булачак?—дип сорады. Кыз төнлә очарга гадәтләнгән күбәләк кебек иде, бер урында гына тора алмый, бөтерелә, әйләнә, тулгана, баскан жирендә биеп тора. Кәефе дә шәп күренә.

—Барый абый дим!

Барый ана мәдәният йорты салыначак урынны күрсәтте. Зәринә, жил-жил атлап, шул урындагы бер түмгәккә басты да:

—Тау Башы Байтимеренең беренче сандугачы Зәринә Бәхетгәрәева!—дип, әүвәл игълан итте һәм шуннан соң үзенең көчле, бормалы-бормалы затлы тавышы белән жыр сузып жибәрде.

Очар кошлар бездән китеп бара,
Әллә житте инде көзләр?
Аерылганда нигә шулай моңлы
Карый микән синең күзләр?

Моңсу да шул, бигрәк ямансу да
Бу жәйләрдән китеп барыш...
Аерылулар, кавышулар—
Шушыдыр ла безнең язмыш...

Мәхәббәткә озын гомер телик,
Гаепләмик әле көзне.
Очар кошлар канат сынагандай
Язмыш үзе сыный безне.

Моңсу да шул, бигрәк ямансу да
Бу җәйләрдән китеп барыш.
Аерылулар, кавышулар—
Шушыдыр ла безнең язмыш...

Язлар безне кабат якынайтыр,
Артта калыр моңсу көзләр.
Синең күзләр, кавышуны көтеп,
Очар кошлар юлын эзләр.

Кызның тавышы Барыйны таң калдырды! Бигрәк тә моңы! Юкка гына мәдәнният академиясенә атлыкмаган икән кыз!.. Барый үзенең тәне буйлап рәхәт җылылык узганын тойды, Барый, хуҗа Әкбәров, бу мизгелләрдә кечерәеп калды, әллә ничек юкка чыгып бетте дисәң дә була. Менә тавыш, менә моң!!!Ул шул рәвешле әсәрләнеп басып торганда, Зәринә, йөгереп килеп, аның кочагына ташланды һәм битеннән үбеп алды.

—Рәхмәт Сезгә, Барый абый!

—Рәхмәт?

—Әйе, минем моңарчы Сезгә рәхмәт тә әйткәнем юк иде бит әле! Тагын җырлыйммы, Барый абый! Барый абый! Бу җырым Сезгә багышлана!

Елмаясың, көләсең син,
Нигә сөям димисең?
Мәхәббәтең юлга чыккан,
Ник каршына килмисең?

Таң сызылгач тәрәз ачып,
Күк йөзләренә кара,
Килер бер көн, сизәр әле,
Үпкәләп булмый ярга.

Җанымдагы ут-ялкынны
Сизмисең икән, сизмә!
Көл(ә) алганда көл инде син,
Моңая гына күрмә.

Йөрәккәен ялкын алгач,
Үзе дә белер әле.
Сердәшенә бик яшерен
Сүз итеп сөйләр әле.

Басмалардан чыккан чакта
Күләгәң суга төшә.
Әнә килә, көлә-көлә
Чын сөю үзе килә!..

Билләхи газыйм дип әйтим, Барый бу минутларда тәмам эреп бетте... чишмәгә әйләнеп тау башыннан түбән таба агып төшеп китте Барый... шушы тау башында басып торган килеш кенә, кулы белән үрелеп, күктән йолдыз алды Барый... һәм ул йолдызны каршысында еш-еш сулап басып торган

затлы тавыш иясенә тапшырды...

Төнге салкын җил исеп куйды. Барый, үзенә килеп сыенган кызыкайны күтәреп алып, машинага утыртты... көчле куллары белән анын башын күкрәгенә кысты.

Ул төнне яше җитмеш ягына авышса да тракторчы булып эшләүче Бәхетгәрәев Галләмнен каладан сатып алып кайткан усал эте яман тавыш белән бары бер генә мәртәбә улап куйды... Аннан сон, алга ыргылып, тәү тартылуда ук юан сипне шартлатып өзде дә кунакчага менми калган бер яшь чебине ботарлап атты. Әллә лапастан иреккә чыгасы килгән иде эт-җаннын, әллә инде бер яше тулган кыз-эт авылга урманнар хуҗасы Пират килгәнне сиздеме сон? Улавы куркуыннан булдымы, әллә урман егетен үзенә кунакка чакыруы микән?..

Хәер, ни генә булса да бер яшь чеби харап ителгән иде инде...

## Миңлекәев Арыслангали һәм аның хатыннары

Урманчы Арслангалинен капкасы бастырыкта, эте исә ишегалдында иде. Барый капка янына якынлашуга, көчек вакытында ук Казаннын кош базарыннан шактый бәһагә сатып алып кайтып бәйләнелгән немец овчаркасы калын тавыш белән өрергә кереште. Эт тавышына уянып чыгарлармы, юкмы дип, баш ватып торганда ишегалдыннан Арслангали хатыны Мәймүнәнен тавышы ишетелде:

—Кем бар анда, Арслангали, син кайттынмы әллә?

Шакучының Барый икәнлеген белгәч, Мәймүнә, Әкбәровнын сыйныфташы, этне оясына кертеп ябып куйды да бастырыкны шуыштырды. Нәкъ шушы мизгелләрдә, хуҗа кешенен өйдә булмавын аңлап алган Барый ник килүенә үкенеп куйды, Мәймүнә, авыл башлыгынын төн ката йөрүенә гаҗәпләнеп, тәмам аптырашка төште... ә мунча өйалдында качып яткан тол хатын Әсма куанычыннан чак кына кычкырып җибәрмәде!.. «Менә бит, тәки эләкте бит! Булды болай булгач, булды гына түгел, кая ул булу гына!» Ул, Әсма, күпме гомер караулаганнан сон, мунчага качып, әле капка төпләрендә саклаганнан сон тәки максатына иреште, теләге тормышка ашты ләбаса? Мәймүнә янына... Арслангали хатыны янына, хуҗа үзе юк чакны туры китереп, унайлы вакытны чамалап, сөяркәсе килде? Сөяркәнен дә нинди генә әле? Барый Әкбәров үзе! Әлбәттә, председатель кеше төн ката эшкә кушарга килмәгәндер инде! Классташлар да бит әле, сөешәләрдер, яратышалардыр... Бетте! Моннан сон, бу хәлләрдән сон Арслангалине Мәймүнәдән башы-аягы белән йолкып алачак ул, Ходай кушып!.. Ә ватык тәрәзәләрнен үче үзе ни тора!!! Имансыз хатын... тик торганда бит, Әсма өенә килеп, сыерга башак болгата торган таяк белән бар булган тәрәзә пыяласын кырып китте! Имеш, Әсма Арслангалине качырып яткыра! Бик качты ди Арслангалиен! Ишегалдында хатыны дулаганны ишетүгә, чоланнын арткы ишегеннән бәрәнге бакчасына чыгып шылмады әле, бары мич кырыена сыенып, тәрәзәдән ялтырап күренмәс өчен посып кына торды. Хатынынын Әсма ишеккә өйгән баррикадалар аша барыбер өйгә керә алмаячагын белеп тора бит ул!..

Әсма ире Сәетгәрәйдән тол калганнан сон урманчы ялгыз хатынны утын һәм башка кирәк ярак белән тәэмин итеп, вак-төягенә булышкалап тора. Әсма Мәймүнә белән яшьтәш, Сәетгәрәй вафатына чаклы да, кыз чакта да бик дус ахирәтләр иделәр. Арслангали исә балта остасы мәрхүм Сәетгәрәй белән дус булды. Урманчы агач белән тәэмин итә, Сәетгәрәйнен балтачылар бригадасы исә атна саен берәр бураны коеп кына тора, аннан сон аны—

Казан читендә коттеджлар төзү чәчәк аткан чор—шәп кенә бәягә озаталар. Бер дә бер көнне урманда Сәетгәрәйне агач басты, Әсмасы ике ыштансыз бала белән тол калды. Элеккеге дустының хатынына ничек итеп ярдәм итмисең, ике нарасые белән ничекләр итеп аны язмыш ярында ялгызын калдырасың ди инде! Бик теләп ярдәм итә Арыслангали тол хатынга. Житмәсә, Әсмадан һәрвакыт шәп көмешкә дә өзелми, идән асты тулы яһүдләрдән сатып алган шәраб булыр. «Самогон» түгел, нәкъ менә көмешкә, күз яшьләре кебек чиста көмешкә. «Самогон»ны мари авылында ясыйлар, ә яһүдләр яшәгән авылда көмешкә белән шәраб коялар. Мари үзе ясаган «самогон»нга каты булсын, эчкән кешене тизрәк җүләрләндерсен, тилертсен дип, тавык тизәге тондыра, ә яһүдләрнең көмешкәсе исә чишмә суыннан. Заманында Барый яһүд авылына өр-яңа трактор-комбайннар да кайтартып карады, иң ундырышлы кара туфраклы җирләрне бүлеп бирде—чәчегез, урыгыз, сугыгыз, җилгәрегез, кыскасы, рәхәтен күрегез! Тик яңа тракторлар да, буяулары елык-елык килеп торган комбайннар да озак эшләп, берәүгә дә рәхәт күрсәтә алмадылар шул, аларны бик тиз ватып сафтан чыгардылар да, яһүднең Арслангали урманнында элек үскән, хәзер сагынып сөйләргә генә калган калын имәннәр кебек гөрнәдердәй ирләре тагын көмешкә кою белән шөгыльләнә башладылар. Көмешкә һәм шәраб сатып яту күпкә файдалырак иде шул. Яһүд авылы тирәсендәге җирләрне алабута, эт эчәгесе каплап китте.

Әсма көмешкәне өзлексез яһүд авылыннан алып тора һәм шул аның чите кителгән тормышын алга таба сөйрәп тә бара. Ул гына микән?!. Иреннән яшьли тол калган хатынның үзенең дә яз саен чәчәккә бөреләнеп алган чаклары—һәр күзәнәге пылт-пылт итеп торган яшь организмны урман каравылчысы китерткән коры-сары утын җылысы белән генә җылытып булмый шул, ул «домна миченә» ир-ат күмере кирәк. Нәкъ менә шул сәбәп белән генә Арыслангали белән түшәк тә бүлешкәләп ала иде Әсма апаң... Аларның бу кырын эшен ахирәте Мәймүнә дә сизенде һәм бер дә бер вакыт, икенче көнен өенә кайтмаган каравылчысын эзләп, Әсма ахирәте өенә килде. Шунда икәнлеген белеп килде һәм рәттән тәрәзә пыялаларын да кырып чыкты.

Сәетгәрәе Арыслангали эшен эшләгәндә һәлак булды бит, шуңа күрә Арыслангали Мәймүнәгә генә түгел, үзенә дә тиеш дип фикер йөртә иде тол хатын... Ләкин кырын эшләре Мәймүнәгә сизелгәч, хәлләр катлаулыга китте һәм аннан котылу чарасын табарга кирәк иде. Иң яхшысы бозыклык эшендә Мәймүнәнең үзен каптыру һәм ире белән араларын бозу, дөресрәге, кыек эшләренне иренә җиткерәм дип өркетеп торып, Арыслангалине курыкмыйча бүлешү. Әйе шул, нишләп ахирәтенең ире исән-сау да, ә ул ялгыз башы салкын түшәк җылытып ята? Бер дә гадел хәл түгел бит инде бу?!. Кайчак Арыслангали атналар буе урманыннан кайта алмый. Шул вакытларда Мәймүнәнең капкасын да читләр какмый торгандыр дисеңме? Бары тик төнге йокыларыңны кызганмыйча, качып, сагалап кына торасы бит инде, югыйсә!. Чү, тукта! Барый Арысгалине сорады да, өйдә юклыгын белгәч, чыгып китте түгелме соң?! Чукынды! Ник кермәде икән? Әллә аның караңгы мунча тәрәзәсеннән качып карап торганын сизенүче булдымы соң? Алай дисәң, Мәймүнә ишегалдына күптән теге усал этен ычкындырып җибәргән булыр иде. Кара, кара, чынлап та бәеннән ычкындырды түгелме соң? Барый киткәч, капкасындагы бастырыкнны этеп куйды да... Хәзер моннан ничек чыга инде ул? Караңгы мунча эчендә кыштырдаган тавыш ишетелеп куйды! Нәрсә булыр бу?! Әсманың коты ботына таба тәгәрәде, ул артка чигенәм дип, нәрсәгәдер абынды һәм лыпылдап арты белән сәкегә утырды. Ай!!! Нәрсә бу!!! Бака өстенә утырдыммы әллә?!! Кара, кара, бака күтен тешләп алды түгелме соң?!! Әсма, уктай атылып, ишегалдына чыкты һәм капкага таба йөгерде, этнең бәйдән ычкынган икәнлеген онытып җибәргән иде,

артында ырылдаган тавыш ишетелгәч кенә абайлап алды:бозау чаклы эт ана тешләрен ыржайтып басып тора. Ләкин Әсмада эттән курку хисеннән бигрәк, Мәймүнә күзенә чалынудан шүрләү хисе көчлерәк булды, ул акырын гына бастырыкны кире шудырды да капка келәсенә басты. Урамга чыгып чабам дигәндә генә, овчарка аның күтен умырып алды...

## Мирхәйдәр—«тас хәбәрчесе»...

Байтимернең Мирхәйдәр атлы кешесе фермада каравыл тора. Чәнгелдек тавышлы кечкенә этен ияртер дә һәр кичне авыл читендә урнашкан колхоз фермасына китеп барыр ул. Көндезләрен дә йоклап ятмый Мирхәйдәр абзаң, ат җигә, колхозның вак-төяк эшләрендә катнаша.

Мирхәйдәрнең авылда берәүнекенә дә охшамаган кушаматы бар, ул—«Тас хәбәрче», ягъни барлык соңгы яңалыкларны җиткереп торуы өчен аны «ТАСС хәбәрчесе» дип үртиләр, кыскартып әйтсәң, «тас хәбәрче»се була инде.

Бүген, төн уртасында, каравылын ташлап, авылга кайтты Мирхәйдәр. Максаты изге иде. Чәчү башланыр чак, быел апрель ае җылы килде. Колхоз амбарында көне-төне ашлык чистарту эше бара. Әкбәров күрмәгәндә, машина-машина ашлыкны йә сатып җибәрәләр, йә үз амбарларына алып кайтып бушаталар иде. Мирхәйдәрнең моңа бик тә эче поша, алай гына да түгел, ашказаны тырный ук башлый, ачудан барысын да Әкбәровка җиткерәсе килә. Тотсын гына әле менә! Әкбәровка ярарга тырышуның исә үз сере бар: тау башында яхшырак җир әләктереп калу. Югыйсә, аның бәрәңге бакчасы гел таштан гына тора, тәмам җелегенә үтте инде, күзен күршеләре капчык-капчык бәрәңге ташыганда, ул җүләр нәрсә кебек бакчасыннан таш җыеп йөри. Әлбәттә, моның да үз сәбәбе бар. Моннан биш-алты ел элек Мирхәйдәр баш ташлап эчүче, тагын шулай дәвам итсә, тәмам алкашлыкка чыгып бетәсе бер бәндә иде. Шулай, бер эчкән вакытында, «белая горячка» башланып, урамда ыштансыз чабып йөргәннән соң, ниһаять, Мирхәйдәр нәтиҗә ясарга булды. Хатыны күптән ташлап киткән, ялгыз башы гына яшәп ята иде ул бу вакытта. Аннан соң басудагы менә дигән кара туфраклы бәрәңге бакчасын да бер литр аракыга авылдашына сатып җибәрде бит. Айныгач, җир янә кирәк булды. Әмма авылда яхшы җир калмаган иде инде. Ул, аптыраганнан, читтәге ташландык җирне эшкәртергә булды, әлеге урын исә галәмәт ташлы булып чыкты.

Ул төнне Барый авылда мулла булып йөрүче Алихан капкасын шакырга уйлады. Урамда алар Мирхәйдәр белән маңгайга маңгай диярлек очраштылар.

—Нигә каравылыңны ташлап йөрисең болай?!—диде Әкбәров каравылчыны танып алуга. Тегесе дөресен әйтергә курыкты, чөнки карак тотылмаган бит әле, шуңа күрә хәйләләргә булды:

—Кичтән хатын сыкрап калган ие, тиз генә шуның хәлен белеп килим дигән иєм.

Рәис кеше артык бәйләнеп маташмады, бары сүз булсын дигәндәй:

—Эше урыныңны калдырып йөрмә!—дип кисәтәсе генә итте һәм төнге караңгылыкка кереп югалды.

Аның төн уртасында кешеләр белән сөйләшеп йөрүен ишеткән Израэль Исаевич дусларча гына шелтәләп тә алган иде алуын. «Сталин заманы түгел бит, нигә төн уртасында кеше борчып йөрисең?»—диде ул. Барый ана каршы көлеп кенә куйды, аннары, җавапсыз калырга унайсызланыптыр инде: «Ул заманнар тагын килмәстер дип кем әйтә ала, Израэль Исаевич?! Әнә бит, хәзер стукачларга яңадан яшел юл ачылды». Мәскәү президентының террорчылар хакында сөйләгәндә әйткән сүзләренә ишарә иде бу үзенчә.

Сүз, чыннан да, террорчылар хакында барса да, халык аны үзенчә кабул итте: телисең икән рәхәтләнеп әләклә! Сиңа рәхмәт кенә әйтәчәкләр... Барый шул сөйләшүне исенә төшерде дә, кинәт аптырап калды. Туктале, тукта?... Израэль Исаевичнын үз киңәше түгелме соң бу?.. «Кешеләрне бер йөреп чыгарга кирәк, көндез өлгермәсән, башка вакыт тап, әмма зур җыелыш алдыннан кылларын тарткалап, үз ягыңа аудара башла!»—дип, үзе киңәш итте ләбаса?! Аңламассың бу яһүдне дип уйлап куйды ул Алихан мулла капкасы янына килеп җиткәндә.

Ә Мирхәйдәр заманның кай якка таба барганың күңеле белән сизенгән, күрәсең. Ул төнне Байтимер урамы буйлап таңга чаклы йөрсә дә бер генә карак очрату бәхетенә дә ирешә алмады. Күңелсез генә фермасына таба атлады. Анда каравылчыны шаккаттыргыч яңалык көтеп торган: кечкенә этен каравыл өенә кертеп мичкә ябып куйганнар, мескен көчек шуннан чәңгелдәп ята. Мирхәйдәр, этне тоткынлыктан азат итте дә, сыерлары янына чыгып чапты һәм анда исә тагын да хәйран калырлык күренешкә тап булды:ишек тышкы яктан анынча бикләнмәгән, чит кеше йөргәнлеге әллә кайдан кычкырып әйтеп тора; каравылчының эченә курку йөгерде. Абына сөртенә ферма эченә керсә, ни күрсен—алгы якта аерым ояларда бәйдә торган үгезләрдән җилләр искән! Өчесенең берсе юк!!! Мирхәйдәрнең аяк буыннары калтырарга кереште, чак-чак сөйрәлеп, сыерларны барларга китте, бәхеткә, алары үз урынында икән. Ул янә урамга чыкты, кергәндә игътибар итмәгән булган икән, ишек янында машина тәгәрмәче эзләре ярылып ята иде...

## Шәңгәрәев Алиханның кендеге селкенә

Урланган өч үгезне Байтимердән ераккарак алып китеп өлгерсеннәр әле, без Әкбәров артыннан куып житик. Ни дисәң дә, мулла йортына бара бит. Байтимер мәчетендә мулла вазыйфаларын башкарырлык бер генә кеше бар, ул—колхозның элеккеге агрономы, парткомитет секретаре Шәңгәрәев Алихан абзый иде. Алихан муллалыкка махсус укымаган, ләкин ул догаларны яттан белә һәм гарәп язуын рәхәтләнеп таный. Шәңгәрәевнең әбисе Гайфә карчык бик гыйлем кеше булган дип сөйлиләр, Алихан, имеш, яшь чагында дин гыйлемен әнә шул әбисеннән эләктереп калган ди. Аннан соң, пенсия яше житкәч, ул кулына китаплар тоткалый башлады һәм шушы көннәрдә генә районның рәйүзәк мулласы янына барып сабаклар да алып кайтты шикелле.

Әлбәттә, Алиханның әүлия түгел икәнлеген авылның олы кешесе генә түгел, бала-чагасы да бик яхшы белә. Ләкин аның догаларны шартлатып яттан укуын, акыллы вәгазьләрен бик яраталар һәм нәкъ менә шуңа күрә дә инде аның кайбер вак-төяк гаеп-гөнаһларын күрмәмешкә дә салышалар иде бугай. Байтимердә күптән түгел генә яңа мәчет салып чыктылар. Элек каравыл өенә җыелышып, балта элеп куярлык тәмәке төтене эчендә төрле гайбәт сөйләшүдән узмаган авыл ирләренең күбесе хәзер, тәһарәтләнеп, мәчеткә жыйнала. Каравыл өендәге гадәт буенча мәчетне дә гайбәт сөйләү йортына әйләндерергә теләүчеләрне Алихан бик тиз урыннарына утыртты. «Әй Аллаһының ачулы кемсәләре, сөйләшүдән туктагыз! Бәс, сезгә Аллаһының ләгънәте булсын. Сөйләшүдән туктагыз»,—дип, фәрештәләрнең әмерләрен укып күрсәтте ул. Әгәр дә без пакь калебле мөэминнәр булсак, безгә фәрештәләр: «Әй Аллаһының намаз ияләре! Сезгә Аллаһының рәхмәте булсын, киләсе намазга кадәр без Аллаһыдан сезең гөнаһларыгызны истигъфар кылуын сорарбыз»,—диеп шатланып калырлар дия иде. Ә без, кеше гайбәтен сөйләшкән булып, мәчеттән фәрештәләрнең ләгънәтен алып кайтабыз, гаиләбезгә афәт һәм кайгы-хәсрәт ирештерәбез.

«Үә үәрадә фил-мәсәжиди йәкүлүл-хәсәнәт кәмә тәэкүлү әлбәһимәтүл-

хәшишә», ягьни китапларда әйтелгәнчә, мәчеттә дөнья сүзләре сөйләшү, хайван печәнне ашаган кебек изгелекне ашыйдыр.

Моннан анлашыла ки, мәчеттә дөнья хәлләре турында сүз куерту, берберенне кимсетү-кыерсыту, бүтәннәргә яла ягу мөселманлыктан түгелдер. Шулай ук «минем гөнаһым юк, мин фәлән доганы укысам, җәннәткә керәм» дигән тәккәбер кемсәләр дә Аллаһ каршында монафикълык кылган булырлар. Җәмәгател-мөслимин, тәннәребездә җаннарыбыз бар чакта истигъфарга ашыгыйк. Аллаһы Раббыбыз—гафу итүче. Тәкъвә мөселманга истигъфардан да кыйммәтле нәрсә бар микән? «Иннәд-динә гыйндәл-лаһи исләм»—Аллаһы каршында бердәнбер хак дин ислам дине генәдер. Белгәннәребез белән Аллаһ йортларын буш тотмыйк. Яраткан догаларыбыз белән намазлык өстенә басып, керсез сабыйлар күнеле белән Җәллә җәләлеһкә сәҗдә кылуны көндәлек табындагы ризыкка тиң итик.

Менә шундый рухтагы вәгазьләрне Алихан бик белеп, килештереп сөйли белүе белән халыкны авызына каратып тора ала.

Алиханның әүлия түгел икәнлеген беләләр дигән идек. Әйе, ул элек аракы мичкәсе эчендә йөзгән кеше булып, шуның белән гаиләсенә генә түгел, колхозга да шактый зыян салган бер адәм иде. Хәзер ул көннәрен исенә төшерсә, үзе дә элеккеге халәтен мыскыллап көлә, әмма ләкин аның бу көлүендә нидидер үкенү хисе бардыр дип һич кенә дә әйтеп булмый шул. Бары мең төрле сәбәп табып акланулар гына... Алиханның әле дә сирәкмирәк ычкынып китә торган гадәте барлыгы да сер түгел.

Үзенең кылган-гамәлләре хакында көлеп, үзен җинелчә генә юмор дәрәҗәсенә күтәреп читләргә сөйләп йөрү адәм баласыннан зур батырлык сорый. Теләсә кем булдыра алмый мондый нәрсәне. Алиханны моңа көче җитә. Әкият сөйләгән кебек тәмләп сөйли ул аны. Ә тыңлаучылар көлә. Тәгәри-тәгәри көлә, бахырлар, элек эчеп ташлаганы да көлә, махмырдан булганнары да, чак кына«чиертеп» алганнары да аны тыңлаганда шыркышырык көләләр. Алиханның үзенә көләргә ярамый, катырак көлеп җибәреп, корсагына ябыштырылган «пластыр»е ычкынып китүдән курка ул.

«Запой» гадәттә вак-төяк сәбәптән генә башланып китә торган иде. Мәсәлән, ышна басуында быел бодай бик уңган. Моны, агроном буларак, ничекләр итеп юмыйсын ди инде. Юмасаң, гөнаһ булыр. Ә кабинада һәрвакыт бер ярты малае йөри. Алиханның үзенең аерым машинасы юк, аны басулар буйлап, эштән бушаган арада, сөт ташучы машина йөртә. Менә шул рәвешле күнелле көннәр башланып китә. Аракы аның корсагына кергәннән соң гадәти булмаган, бик сәер реакция башлана, әйтерсең, ул сусыз чүлдә бил тиңеннән ком ярып бара, авыз чатнап кибә, ашказаны киндек турысыннан мелт-мелт селкенә башлый: тагын аракы соравы имансызның. Шул рәвешле бер атна үтеп тә китә, ахыр чиктә, Алиханың тәмам агулана, коса-коса эчүгә керешә, урыныннан да торалмыйча башын күтәрми ята. Андый чакта бөтен гәүдәсе сызларга керешә. Хатыны эшкә, балалары мәктәпкә укырга киткәч, сулыш алулары чак кына җиңеләя, хатынының йокыдан торуга, артка чигенә-чигенә, дөньядагы иң актык сүзләр белән әрләүләре дә онытылып тора. Алихан бик җинел хәрәкәтләр белән урынннан тора, көзгегә карый: кыяфәт кирпеч сорый, йөз шешенгән, күзләр кызару өстенә кысылып та беткән. Димәк, урамга чыгып, кеше күзенә күренеп йөреп булмый. Ни дисән дә, колхозның агрономы гына түгел, партия оешмасы секретаре да бит ул әле. Димәк, өйдән генә эзләргә кирәк хатынның яшереп куйганын. Ишегалдына чыгып, бер тирән итеп сулыш ала Алихан—баш шөрепләре кыймылдый, селкенә башлый. Суыткычта юк та юк инде ул, кухнә шкафында да юк... Чормада! Кыш килүен көтеп яткан киез каталар эчендә! Алихан мәче кебек чорма баскычыннан өскә үрмәли һәм җәһәт кенә киез каталарны эзләп табып, ин

беренче туры килгәненең эченә кулын тыгып җибәрә! Бармак очы салкын шешәгә тиеп китә... И, шул чактагы ләззәтне ничекләр итеп аңлатмак кирәк?! Аны тел белән сөйләп тә, каләм белән язып та сурәтләп биреп булмастыр! Ул ләззәтнең иң югары ноктасы!!! Адәм баласы җир астыннан бер чүлмәк алтын тапса да бу чаклы сөенә алмастыр, мөгаен!.. Алтыннары ни чуртыма бу вакытта! Аның белән баш төзәтеп булмый ләбаса!

Хатын эштән, балалар мәктәптән кайтканчы табылган шешә акрынлап суырылып бетә, Алиханны йокы баса. Хатыны капкадан кайтып керүгә, бер кат ишегалды һавасын тирән итеп сулап, сизгер борыны белән иснәп алганнан соң иренең каяндыр табып эчкәнен шундук сизенә, шуның дәлиле булып, Алихан гырлап йоклап ята. Тапкан! Кайдан, кайсысын тапты икән, имансыз. Хатын мәче кебек чормага үрмәли һәм киез каталарны актара башлый. Буш, тапкан, имансыз! Ничек тапкан, ничек сизгән?! Бу хатын өчен мәңге чишеп булмаслык шаккатмалы табышмак... Иртәгесен ире тагын баш авыртып уяна. Кан басымы соңгы чиккә җитеп күтәрелгән, авыз чатнаган, иреннәр бер-берсенә ябышып каткан, йөрәк дөбер-шатыр килеп селкенә. Соңгы көченә тибә, ул типкән саен карават та селкенә. Хатыны уянганчы борыныннан гына бер чәйнек су эчеп бетерә. Күп сыеклык кан басымын соңгы тамгасына чаклы күтәреп куя. Хатын мыр-мыр эшкә җыена, вакыт бик акрын бара, тизрәк чыгып китсен иде бит канә! Менә Алихан өйдә янә ялгыз башы гына кала, хатынын тынычландыру өчен, «башка эчмәс идем»диеп антлар эчеп кала. Хатын, аның сүзенә ышанып, тынычлана да, тагын эшенә китә, балалар мәктәпкә тарала. Өйдә эссе, эсседә йөрәк тагын катырак кага. Ул ишегалдына һавага чыга. Монда да бөркү. Алихан, махмырлы башын, кыегайтып, баз өстенә керә, монда карават бар, баздагы кардан салкын бәреп тора. Беркавым шулай ятканнан соң чак кына хәл кереп киткән төсле була, Алиханның башы яңадан эшли башлый. Тик бүген эчәсе килми, ул чынлап торып авырырга керешә. Баз өсте аның кайнарлыгыннан җылына башлый, шуннан соң ул базның капкачын ачып куя. Рәхәт булып китә. Базга аякларын салындырып утырган Алиханның башына шулчакта төрле зур уйлар, планнар килә—бер айныган вакытында базны зурайтып, менә бу тимер караватны шунда төшереп куясы булыр, кар өстенә үк. Аңа карап кына кар өстендә торган чиләкле сөтләргә чуртым да булмас әле!... Шулай эшләргә кирәк булыр—Алиханың сәгать эчендә кеше булып аягына басачак аннан соң... Мунча ягыннан бер бака малае килеп чыга һәм күзләрен дүртләндереп, Алиханга карап утыра башлый. Курыкмый да мәлгунь, әллә ул да махмырдан инде?.. «Йә, бака дус, алайса әйтеп кара, кайда яшерелгән шешә бар? Ә-ә-ә, мич артында дисеңме? Юк, анда юк, карадым инде. Келәттәге арыш капчыкларының берәрсе эчендә дисеңме? Юк, аны да тишереп чыктым. Чормада да юк, теге юлы аннан тапкан идем бит инде... Точно, дөрес уйлыйсың син, бака дус! Каз оясында булырга мөмкин!!! Каз бәбкә чыгарып утыра бит. Апаң көн саен аның йомыркаларын тикшерә!.. Шунда яшереп куймас дисеңме син аны? Хәзер, хәзер тикшереп киләбез аны. Алихан, абына-сөртенә, лапаска таба атлый. Әнкә каз әле яңа гына йомыркалары өстенә кереп утырган.. Ул, Алихан якынлашуга, ысылдый башлый. Тегесе аңа игътибар итми, казның муеныннан каптырып, оясыннан өстерәп чыгара да, кулын йомыркалар салынган салам астына тыга... Молодец икәнсең син, бака дус! Рәхмәт сиңа, мең яшә! Тапты бит! И бу хатынның аңгыралыгын әйтер идем, тапкан яшерер урын, пәрәме аяк астында гына бит. Җәһәннәмгә үк олактыра алмаган шуны яшергән юлы!.. Менә... аракыны яшерә белмәгәне өчен дә хатын гаепле...

Хатын эштән кайтканчы шешә тагын бушый, ишегалдында бары гырлаган тавыш кына ишетелеп тора. Каз да никтер бүген оясыннан чыккан, ата каз белән ишегалдында йөри. Алихан хатыны аны оясына куып кертте дә баз

өстенә керде. Алихан трактор кебек тавышлар чыгарып гырылдап йоклап ята. Баз капкасы ачык. Хатын, ирен төртеп уята да:

—Баз капкачын нәрсәгә ачтың?! Сөтләремне ачытып бетерәсең бит!

—Бакаларны пленнан коткардым...—дип мыгырдый Алихан йокы аралаш кына.

—Салкын базда, кар өстендә нинди бака булсын!

Хатынның ачуы чигенә житкән, ул исерек иренә әйтерлек бүтән сүз таба алмый. Аптыраганнан: «Беләсеңме кем син?! Алкаш син, белдеңме!!!»—дип сүгә. Алиханның иң яратмаган сүзе инде бу, шул сүзне ишеткәч, аның йокысы ачылып китә һәм ул хатынына усал итеп карап: «Ә син? Син, үзеңнең кем икәнлегеңне беләсеңме соң, хатын. Ә?» «Мин кем булыйм?! Нәрсә, мин синең кебек эчеп ятаммы әллә?! Йә, мин кем! Мин нишләгән әле, жә?» «Синме, син... хатын, син ... мин алкаш булсам, син алкаш хатыны, белдеңме!» Хатын мондый көтелмәгән сүздән әүвәл каушап кала, аннан соң иренең тапкырлыгыннан эчен тотып көлә башлый. «Алихан дим, Алихан. Айнырга кирәк бит инде, болай ятып булмый бит инде, ә, алтыным...» Хатынның шул сүзе житә Алиханга, бетте, күреп торырсыз, иртәгә ул эчмәячәк, грамм да. Бугазыннан койсалар да... кире төкерәчәк!!!

Иртәгесен янә шундый ук махмыр. Тагын чәйнек борыны... Житмәсә, бүген башының гына түгел, эчененң дә кәефе юк. Бәдрәф юлыннан кайтып керә алмый. Ах, кашыклап тоз салып... шуны әйбәтләп болгатып... бер стакан, ә?

Юк, бүген эчте юк дип уйлый ул аннан соң. Житте! Әле менә кәефе дә ярап торган шикелле. Беркавым шулай ятканнан соң Алихан караватыннан сикереп үк торды. Көзге каршына килде. Күлмәген күтәрде һәм артына ава язды: кендек, кендеге корсак буйлап астан өскә таба йөри иде, хәрәкәт итә иде!!! Бер төшә, бер менә!.. Һәм шулвакыт аның үтереп эчәсе килә башлый. Ул бер кулы белән кендеген тота, кендек пылт-пылт селкенмәкче була, ләкин ычкына алмый һәм ни гаҗәп, шул мизгелә аракы эчәсе килү теләге сүнеп тора! Менә сиңа мә, барысына да шул каһәр кендек гаепле икән ләбаса?! Ул һава суырткыч кебек эшләп тора һәм аракы сорый. Алихан кулын кендегеннән алуы була, янә астан өскә, өстән аска хәрәкәтләнергә керешә, тагын эчәсе килү теләге уяна! Ачыш бит бу! Гаҗәп зур ачыш! Үзенең дөнья күләм ачышыннан соң Архимед та болай ук сөенмәгәндер, билләхи! Шатлыгыннан Алиханның хәтта баш авыртуына кадәр бетеп торды, ул һаман бер кулы белән кендегенә басып тора иде әле. Алиханның үз башы гына житәрлек хәл түгел бу! «Медицинский подход кирәк монда»,—дип уйлап куйды агроном. «Медицинский...» Тик кемгә барасы? Медпункт эшләми. Сибгат хатынының өенә барып, ана корсагынны ачып күрсәтә алмыйсың, Сибгате бик көнче адәм... Кинәт башына сукты: Алиханның дусты, бергә эшләгән дусты, мал врачы Гаптегани дусты бар бит! Мал врачы булсын, ат докторы булсын, ләкин ул да барыбер врач бит!

Алихан бәрәңге бакчасы буйлап кына Гаптегани өенә таба китте. Табигатьнең «кендек» серен чишәргә кирәк бит инде канә! Бер кулы һаман кендек турысында иде әле, эчәсе килүе дә басылып тора. Бәхетенә күрә, Гаптегани эштән кайткан, абзар-кура тирәсендә йөри. Капкадан килеп керешкә Алихан ана:

—Яшьти—алар икесе дә бер яшьтә иде—карале монда, бер кызык нәрсә күрсәтәм!—дип кычкырды. Алар икесе бергә эчә башлаганнар иде, Гаптегани туктаган. «Кара син аны, каһәр, тормозга салган бит бу!»—дип уйлап куйды шул мизгелдә Алихан.

—Кил әле монда, карале!

Алихан, күлмәген күтәреп, кендегеннән кулын алды.

—Күрәсеңме, селкенәме?

—Селкенә... Шуннан ни?

—Беләсең килсә, аракы сорап селкенә ул!

—Кит, булмаганны!

Ышанмасаң, йөз грамм салып биреп кара менә!

Гаптегани йөгереп өенә кереп китте һәм аннан башланган шешә күтәреп чыкты.

—Син түлке күп салма, илле грамм и җитте. Менә карап торырсың.

Алихан, кулын кендектән алды да, стаканны тотып эчә башлады.

—Күрденме, туктадымы?

Гаптегани бу хәлгә шаккатып карап тора иде. Гаҗәпләнүдән ачылып калган авызын кире ябып, яңадан ачты да:

—Шаяртмыйсыңмы син, яшьти. Чынлап та шулаймы ул?!

—Соң... үзең күреп торасың бит инде! Ярты сәгатьтән тагын селкенә башлаячак! Менә, яшьти, эчүнең бөтен сәбәбе кайда икән! Кендектә икән, яшьти, кендектә! Син доктор кеше, берәр чарасын уйлап тап. Алайса эчеп үләм бит мин, яшьти!

Гаптегани беркавым башын кашып уйланып торды да аннан соң ботын чабып куйды!

—Хәзер, хәзер, таптым, яшьти,—дип, ул тиз генә өенә йөгереп кереп китте һәм үзенең эшкә асып йөри торган кирәк-яраклары салынган сумкасын күтәреп чыкты. Аннан ябыштыргыч тасма алды.

—Менә шушы пластырь белән ябыштырабыз да куябыз аны хәзер.

Ат докторы кендекне берничә кат ябыштыргыч тасма белән беркетеп куйды.—Йәле, селкенәме хәзер?

—Ярты сәгать үттеме соң әле?

—Көтик соң.

Көттеләр, ярты сәгать узды, кырык минут вакыт авышты, әмма кендек беркеткән урыннан кыймылдый да алмады.

—Йә, ничек? Эчәсең киләме хәзер?

—Грамм да килми, яшьти.

—Алайса пластырьны куптара күрмә инде син, яшьти.

Хатыны эштән кайткач, Алиханның аек икәнлеген күреп, шаклар катты. Алихан аңа эшнең нидә икәнлеген сөйләп бирде. Ябыштыргычны куптарып карадылар, кендек янә астан өскә таба йөри башлады, хатын тиз генә аны киредән ябыштырып куйды. Хет чукын, эчәсе килми иде инде хәзер. Димәк, бар гаеп кендектә булган икән, баш ташлап эчеп ятуында Алиханның бернинди дә гаебе юк, тамчы да юк менә!.. Хатыны белән икәүләшеп алар әнә шундый фикергә килделәр... Менә шуннан бирле Алихан абыең шешә яныннан әйләнеп уза торган булып китте. Тик, һәр мунча саен, ябыштыргыч тасманы алыштырып кына торасы. Бу эшне хатыны бик яратып, шуннан үзенә тәм табып башкара иде. Кушамат таралды таралуын. Авылның телен кисеп булмый бит инде. Ямаулы корсак дип үртиләр аны үз артында. Ник?.. үртәсеннәр. Аның каравы Алихан үзе хәзер рәхәтләнеп яши башлады, тормышның тәмен табып, мәгънәсен күреп яши. Менә, пенсиягә чыккач, дин юлына да кереп китте әле. Ходай кабул итсен инде...

Иртә-кич хатыны һаман белешеп тора: «Селкенәме, Алихан?..» «Юк, селкенми, карчык, Аллага шөкер...»

## Кара булмаган кара карга баласының соңгы сәгатьләре...

Урман өстеннән каргалар очып узганда аларның каркылдавы Пиратның эчен пошыра иде. Кара булмаган карганың тавышы бигрәк тә аерылып тора. Көтүләре белән авыл ягыннан очып киләләр дә көтелмәгәндә, кинәт кычкырып җибәрә ул, табигать ялгышы!

Әйтерсең, Байтимердә ниндидер хәвеф булган... Аның Актырнактан туган малае тагын авыл ягына чыгып чапкан иде. Әллә... әллә шуна берәр хәл булганмы?! Әллә аның муенына да әнисе кебек кызыл тасма салганнармы?! Пират тынычсызлана, борчыла. Аны коткарырга барырга ашкына. Ләкин көпә-көндез авылга йөрми Пират. Малаен да шул гадәткә күпме өйрәтергә тырышып карады—файдасыз, яшь шул әле, аңламый. Кешеләрнең кайвакыт урмандагы бүре туганнарга караганда да явызрак икәнлеген төшенеп бетерми.

Май бәйрәме алды авылда сугым вакыты, чираттагысы сабантуе алдыннан була, гадәттә. Моны эт-бүреләр сизенә һәм андый көннәрдә алар төннәрен авылга сәяхәткә әзерләнә. Бу элегрәк шулай иде, авылның һәр кешесе шәһәрдән усал бурзайлар алып кайтып бәйләп куйгач, суелган малларның адәм балаларының үзләреннән арткан санакларын бәйдәге эт туганнары хәл кылып бара. Фермада берәр бозау-мазар үлсә генә инде. Пират белән Актырнак малае—әнисенекенә охшаган ак тырнаклы шук малай—Агаяк ферма тирәләрен урап килергә дип киткән иде. Кара булмаган карганың, болай ямьсез кычкырып, әллә Пиратка шуның һәлакәте хакында хәбәр салуы булдымы соң?..

Пират үзе картаеп килә инде. Элеккеге сизгерлеге дә, ташып торган гайрәте дә сүнеп бара шикелле. Шулай да кыргый тормыш рәвеше ана бөтенләй мәлҗерәп төшәргә ирек бирми, ул һаман да көчле, өстәвенә еллар буе тупланган акыл-тәҗрибәсе дә юк түгел. Шулай да бу юлы Агаякны авылга барудан тыеп кала алмады. Инде зур үскән малайның урман-читлектә генә бикләнеп ятасы килми.

Кара булмаган кара карганың иләмсез ямьсез тавышын Барый да ишетте. Аның таң белән урман юлы аша Галләм кызы Зәринәне райүзәктән Казанга йөрүче автобуска илтеп барышы иде. Тау башындагы хәлләрдән соң бу чикерткә кыз аны үзенә бәйләде дә куйды. Ләкин Барый үзе моны вакытлы хәл дип исәпли. Менә ул, Зәринәнең үтенече буенча, аларга ансамбль оештырып җибәрергә ярдәм итә дә... аннан соң кызның җыр-клипларыннан бер-ике видеокассета чыгарырга ярдәм итсә... Зәринә моны бик тели һәм Барый абыйсына тагын да рәхмәтле булачак... Ни хәл итәсең, ул дөньяга—шоу-бизнеска—Әкбәров кебек иганәче-спонсорлардан башка борыныңны да тыга алмыйсың. Коточкыч конкуренция бара, бигрәк тә талантсызлары котыра. Кем әйтмешли, авызына микрофон төртсәң, балык та җырлап җибәрер иде, билләһи! Чөнки техника-аппаратура хәзер бик көчле, аның ярдәмендә кәҗә тавышын да былбылныкына әйләндереп булыр иде, мөгаен...

Кара булмаган кара карганың шөкәтсез тавышы Барыйны сискәндереп җибәрде. Ул машинасын туктатып, мылтыгын алды да, тәрәзә пыяласын төшерде.

—Бүре-фәлән бармы әллә, Барый абый?

Барый Зәринәгә җавап биреп тормады, ишеген ачты. Әнә карга көтүе алан өстеннән очып бара. Барый мылтыгын өскә күтәрде һәм чакмага басты. Һавага чәчелгән ядрәләрнең берсе кара булмаган кара карганың мәгънәсез башын кыеп төшерде. Адәм баласы үз гомерендә беренче мәртәбә Табигатьнең ялгышын төзәтә алды!..

Шулчаклы төз атуы бүген нигәдер Барыйны сөендермәде. Кара булмаган кара карга җиргә кыелып төшкәч, кинәт аны ниндидер сәерлек биләп алды, сул як чигәсендәге кан тамырларының мелт-мелт кыймылдаганына чаклы тойды ул.

Җил тегермәне капылт кирегә әйләнә башлаган кебек аның баш шөрепләре дә нәкъ кирегә таба эшли башлады бугай: Израэль Исаевичның тау башына салыначак дин йорты хакында әйткән сүзләре исенә төште.

—Диннәрне берләштермәсәк, халыклар арасындагы талаш-сугыш мәңге

дәвам итәчәк...—дигән иде яһүд дусты шулай бервакыт. Ә үзе күптән түгел Барыйның бу эшенә каршы килеп, әллә нинди дәлилләр китерә. Югыйсә, теге чакта ул шулай димәгән булса, өч динне берләштерү уе кайдан килер иде Әкбәровның сөт планын арттыру максаты белән чүпләнгән башына? Нигә шулай ике төрле сөйләшә Израэль Исаевич?! Берәр төрле яшерен максаты бармы әллә, югыйсә?.. Һәм нигә күптән түгел күренеп киткән ФСБ кешесе Барыйдан Воронов хакында кызыксынасы итте икән? Үз илендә яши ләбаса ул? Хәер, монда андый шаккатмалы сер юктыр да әле, бәлкем. Израэль Исаевич ике илнең гражданины бит, шуңа кызыксынгандыр.

Иң гаҗәбе шул: нигә бу уй аның башына моңарчы килмәде, карга атып төшергәч кенә билеп алды күнелен төрле каршылыклы, сәер хисләр?.. Ахыр чиктә кара булмаган кара карга белән Воронов арасында нинди уртаклык булуы мөмкин соң?

—Барый абый. Бүре аттыңмы әллә?

—Аю... Ак аю...

Кыз, гаҗәпләнеп, аңа карады:

—Ник... безнең урманда ак аю бармыни ул?

—Безнең урманда бала башлы бүре дә бар, Зәринәкәй.

—Бүре?! Бала башлы???

—Юк, шаяртам гына,—диде Барый машинасына кире утырып.—Син минә миңа шуны әйт әле, Зәринәкәй, син танылган җырчы булып киткәч, миңа сәлам бирерсеңме соң?

Кыз, чытыкланып, аның беләгенә башын куйды.

—Бирүен бирермен дә... тик Сез ул вакытта өйләнгән кеше булырсыз бит инде?

—Кемгә?

—Урман кызына!

—Урман кызына? Урман кызына шүрәле өйләнсен, яме!

—Чынлап та шулаймы, Барый абый?

—Чынлап та шулай...

—Ә Гөлйөзем? Аннары шул дөресме, Барый абый, Мөхәммәт Уразов Гөлчәчәк аркасында гына зур рәссам булган дип сөйлиләр?

—Сөйләсеннәр. Дөрес сөйлиләр.

—Ә Гөлйөзем?—дип соравын кабатлады кыз.

—Күрәсең, мин атаклы рәссам булып китмәдем бит...

Кече Фили—райүзәккә килеп җиткәннәр иде инде.

—Тиздән концерт бригадасы белән районнарга чыгарга исәп. Безнең концертны сатып алырсыз әле, Барый абый, яме?

—Алырмын. Хәбәр итәрсең.

Саубуллашканда соңгы сүз алышу әнә шул булды.

...Израильнең дәүләт булып оешып яши башлаган беренче көннәрендә үк читтән күпләп яһүдләр тарту була. Үзенә дошман булган гарәп илләре белән чорнап алынган Израиль шул рәвешчә ныгырга, дәүләтен аякка бастырырга тели. Ләкин моңа күп кенә илләрдәге иммиграция кануннарының кырыс булуы комачаулык итә һәм нәкъ шул сәбәпле дәүләт махсус разведка оешмаларының эшчәнлеген җәелдереп җибәрә. Кырык сигезенче елда шул максат белән «Алия-Бет» институты оеша, шул исемдәге разведка хезмәте эшли башлый. Әлеге оешмалар Израиль өчен бик зур эш башкаралар, читтән күпләп яһүд гаиләләре китерелә. 1948-1949 нчы елларда Ирактан илле мең гаилә, ә 1950-1951 нче елларда йөз илле мең яһүд күчерелә.

Ләкин «Алия-Бет» ничек кенә уңышлы эшләмәсен, эмигрантларның барсы

диярлек Якын Көнчыгыштан гына килә. СССР һәм Көнчыгыш Ауропадан күченүчеләр бик аз була. Өстәвенә 1949 нчы елларда СССР белән Израиль арасындагы мөнәсәбәтләр бозыла башлый һәм Тель-Авив күбрәк АКШ ка йөз тота.

Премьер-министр Бен-Гурионның махсус указы нигезендә, «Алия-Бет» таркатылып, анын урынына 1951 нче елда «Натив» разведка хезмәте төзелә. Анын максаты социалистик илләрдә сионизм идеяләрен таратып, Израильгә күпләп яһүдләрне күчерү була.

«Натив» турыдан-туры Премьер-министрга буйсына һәм аның эшчәнлеге аерата яшерен була, оешма эшчәнлеге хакындагы мәгълүматлар исә жиде йозак астына бикләнелә.

Израильдәге яһүдләр санын арттыру өчен нинди генә чараларны файдаланмый «Натиф»! Мәсәлән, 1980 нче елда «Натиф» хезмәткәрләре Лондонда СССР га барырга «теләүчеләрне» оештыралар. Йөздән артык яшь англияле турист рәвешендә Советлар Союзына барып иврит телендә әдәбият, видеокассеталар һәм башка пропаганда материллары тарата. Бу зур халыкара шау-шу тудыра һәм шуннан соң Б. Бегин «Натиф» житәкчесе яһүд Леванонны эшеннән азат итәргә мәжбүр була.

«Натиф» башка социалистик илләрне дә тынычлыкта калдырырга уйламый. Мәсәлән, Румыния Израильгә яһүдләрне чыгарган өчен барлыгы 60 миллион доллар акча ала, шуның яртысын Чаушеску үз кесәсенә салып куя. Израиль хөкүмәтенә бер яһүд башы 3 мең долларга төшә.

Кызганыч, без исә читтән үзләре теләп кайткан татарларыбызны да кайда куярга белмибез!.. Адәм типкесендә йөриләр...

1985 нче елда Горбачев дәүләт башына килгәч, яһүдләрнең Израильгә чыгуына яшел юл ачыла һәм илне ярты миллионлап яһүд ташлап чыгып китә. Күрәсең, СССР президенты масоннарның якын дусты булган дип фаразларга гына кала...

1991 нче елда СССР рәсми рәвештә таркалгач, «Натиф»нын бурыч-максатлары да үзгәрә. Хәзер аларның хезмәткәрләре талантлы яһүд яшьләрен генә «чүпләп» тора башлый, шуның өстенә Рәсәй галимнәре һәм белгечләре белән элемтә урнаштырып, фән өлкәсендәге алдынгы фикерләрне жыя, Рәсәйнең сәяси-икьтисади хәлен өйрәнә, анализ ясый, аерым халык-милләтләрен өйрәнә, алар хакындагы мәгълүматны Израиль белгечләренә-аналитикларына тапшырып тора.

Израэль Исаевич соңгыларыннан иде. Фәнни институтта эшләү өстенә Воронов татарлар белән ныклы элемтәдә тора. Тормыш-яшәеш рәвеше бик тыныч кына барган кебек булса да, тыныч күлдә женнәр үрчи дигәндәй, Израэль Исаевичнын күлендә дә «шпион жен» утыра, ләкин аның күле бик тирән булып, «женнәре» су өстендә күренмиләр иде... Әмма ул беркайчан да үзләренең яһүд авылындагы милләттәшләрен Израильгә күчерүне максат итеп куймады... Мондагы яһүдләрнең хатыннары татар кызлары булып, андый катнаш гаиләдә туган балалар исә интеллектуаль яктан да, талант ягыннан да калган милләтләрдән биш-алты башка өстенрәк торганлыктан, Израильдәге тормышны бик яхшы күз алдына китерә һәм берсенең дә палестиналылар, гарәпләр бомбасыннан шартлыйсы килми иде...

## Очты-очты... авыллар очты, кешеләр очты...

Иртәгә тау башында урын бүлешәсе дигән төнне халык йокламады, һәркемнең дә иң шәп урынны, иң шәп жирне эләктереп каласы килә иде. Вәлиев Сибгат хатынының колагына кат-кат тукыды— тау башында андый-мондый берәр ызгыш-талаш кебек нәрсә чыга калса,

уяу булып тор, янәсе, этне бәйдән ычкындырырсың дип кисәтте. Фермадагы өч үгезне урлатканнан соң, элеккеге каравылчы Мирхәйдәр, кечкенә гәүдәле чәнгелдек этенең муенына таш бәйләп су астына җибәрде дә каладан зур овчарка сатып алып кайтты. Дөрес, Әкбәров ана үгезләрне гафу итте итүен. Тик бер шарт белән: иреннән тол, Барыйдан көмәнле калган мари хатыны Наташаны ул өенә алып кайтып утыртырга тиеш иде. Башы себер китәсе килмәгәч, килеште Мирхәйдәр. Наташа белән бик тиз уртак тел дә таптылар. Мирхәйдәр тау башына менеп киткәч, Наташага да уяу булып торырга кушылды. Бу хакта күршеләренә сөйләп йөрмәсәләр дә, ир-атның барысы да өендә шундый әмер калдырды.

Алиханның әүвәл менәргә исәбе юк иде, кичкырын аларга Гаптегани килеп керде.

—Син нәрсә, ятасың, яшьти?! Жирсез каласың киләме әллә!—диде ул бусагадан атлауга.—Кайтканнар белән әрәмтамакларга эләксен дисезме иң яхшы җирләр?

Алиханнын җавабы әзер иде:

—Мин мулла кеше бит, мәчет яныннан берәр урын калдырырлар әле.

—Нинди мәчет, дивана,—дип сүгеп алды аны Гаптгани үз итеп, якын итеп.—Анда мулла гына түгел, поп та булачак бит әле. Поп кына да түгел, еврей мулласы да!

Бу хәтлесен уйлап бетермәгән иде шул Алихан. Ул кырын яткан урыныннан торып утырды да күзләрен төбәп Гаптеганига карап утыра башлады.

—Шулай дисеңме, яшьти?

—Соң! Шулай булмыйни!

—Алайса менәргә кирәк, име!

—Син, яшьти, нәрсә саңгыраеп утырасың соң! Кендегең селкенә башламагандыр бит?—Ул аптырап Алиханның хатынына карады.—Нәрсә, селкенми торгандыр бит?!

Алихан хатыны ашыгып башын чайкады:

—Юк, юк, селкенми, Ходайга шөкер!

—Селкенмәсә, тор, әйдә! Карале, мылтыгың барые синең, исәнме ул?

Исәнен исән, атмый ул түлке.

—Атмаса атмас, барыбер ал син аны.

Сүз мылтык хакында киткәч, Алихан хатыны да кушылмыйча булдыра алмады:

—Сез нәрсә, җир өчен авылдашларыгызны атарга җыенмыйсыздыр бит?

—Җир өчен, мин сиңа әйтим, авылдашларыңны мылтыктан гына түгел... туры килә калса, бомба белән дә шартлатырсың! Җир бит ул! Җир! Аңлыйсыңмы?!

—Абау, Гаптегани, ни сөйлисең син? Дөнья малы өч көнлек бит ул. Тегендә баргач, ничекләр җавап бирерсең?!

—Бирербез!—дип көлеп куйды ат докторы.—Мулла үзебезнеке бит, әйеме, яшьти!

Алихан аңа җавап биреп тормады, кендек турысындагы ябыштыргычының бер чите кубып маташа иде, ул баш бармагы белән шуны басып куйды да, хатынына карап әйтте:

—Бурзайны бәйдән ычкындырсаң да ярый. Әгәр дә мәгәр тау башыннан минем кычкырган тавышны ишетсәң... Ни, яшьти, төнге һавада тавыш каты яңгырый бит ул, име?

Механик Батай малае сары Абдул дуңгыз танаулы явыз этен үзе белән ук алып менгән иде. «Аудан кайтып килеш»,—дип акланган булды ул. Тол хатын Әсманың кулында ике җәпле сәнәк иде. «Урам тулы эт, каршыңа килеп чыксалар!»—дип, ул да аклану җаен тапты. Телсез Габдеринең башсыз

малае Габдулланың кесәсендә үзе ясаган пистолет, дары урынына шырпы күкерте генә булса да ул каты шартлый иде. Ядрә урынына вак кадаклар кисеп тутырды.

Барый Әкбәров ул кичне авылда түгел иде. «Израэль Исаевич өйгә кайтмады»,—дип, хатыны килеп әйткәч, ул шәһәргә чыгып чапты. Барый тиз генә Мөхәммәтне эзләп тапты. Тегесе бу вакытта иске татар театры янындагы затлы йорттан өч бүлмәле фатир алып, шунда күченгән иде. Мөхәммәтнең атна ун көн элек Парижддан кайтканлыгын белә, яна фатирында да булганы бар.

Мөхәммәт Уразовка Луврдагы халыкара күргәзмәдә катнашу бәхете эләккән иде. Сиринә Самуиловна белән икесе бардылар. Һәм хәзер бөек рәссам Уразовның күкнең жиденче катында йөзгән көннәре.

Мөхәммәт өйдә булып чыкты, ике дус кочаклашып күрештеләр. Кунагы хөрмәтенә авылдашы затлы француз коньягы чыгарып утыртты. «Без моны тегендә стаканлап эчтек!—дип мактанып та алды Мөхәммәт.—Без дигәч тә ... почти мин генә инде. Бүтәннәр уймак чаклы рюмкадан гына сөзеп утыра. Ә бездә, татарларда, урыс холкы бит хәзер. Чиләкләп тондырабыз!» Чиләкләп эчкәне күренеп тора иде авылдашының, йөз-кыяфәте шактый таушалган. Гомумән, соңгы вакытларда ул мондый эш белән еш шөгыльләнә башлады. Кайтканына күпме гомер узды, Гөлчәчәге янына барып кайту түгел, хәтта шылтыратып хәлен белә алганы да юк. Париж хисләреннән һәм француз коньягыннан һаман айнып бетә алмый атаклы рәссам. Аның каравы, Гөлчәчәк, ул кайтуга, Казанга үзе йөгереп килеп житте һәм салмыш Мөхәммәтнең Сиринә Самуиловна белән кочаклашып подъездга кереп киткәнен читтән качып күзәтеп торды. Кыз ул вакытта Мөхәммәтнең Сиринә Самуиловна белән бергә тора башлаганын белми иде әле. Әнә хәзер дә ишектә Сиринә Самуиловна иде, кулында хужалык сумкасы, күрәсең, «яшь хатын» якынтирәдәге кибеткә генә чыгып кергән булгандыр. Мөхәммәт Уразов үзенең ничек өйләнгәнен үзе дә сизми калды бугай. Ләкин Барыйның бу хакта төпченеп сораштырып торырга да, кызыксынырга да вакыты да, андый кәефе дә юк иде. Ул мәсьәләне Сиринә Самуиловнага аңлатты, Мөхәммәт дусты килгәч, янә ярты тустаган коньяк чөмерергә өлгерде бугай, бөтенләй жебеп төште. «Француз коньягын стаканлап эчәрлек булгач, әйбәттер инде...»,—дип уйлап куйды Барый. Сиринә Самуиловна каядыр, кемгәдер шылтыратты һәм: «Вороновның биш минуттан монда булачак!»—диде. Шул арада Сиринә Самуиловна Барыйга Мөхәммәттән дә зарланып алырга өлгерде. «Эчә башлады!—диде хатын, йөзенә канәгатьсезлек чыгарып.—Шулай инде ул, татар аз гына талантлы булса, башын тизрәк аракы мичкәсенә тыгарга ашыга! Югыйсә, үзен Франциягә даими эшкә чакырырга торалар, әсәрләрен бик ошаттылар». Барый ана каршы бер сүз дә әйтмәде. «Эчеп ала да Гөлчәчәгем дип елый. Нинди кыз булды соң ул шулхәтле?! «Урман кызы» портретына бөтен Париж шаккатты. Зур акчалар тәкъдим иттеләр, сатмады үҗәт татар!» Барый бу юлы да елмаеп кына куйды. Анысын да көчәнеп кенә елмайды. Югыйсә, үз хәлләре дә көләрлек түгел, Зәринә белән буталуы Гөлйөземгә барып ишетелеп, тегесе хәзер, ул офыктан күренүгә, капкасын ук бикләп куя. Үзе генә түгел, ничектер дөньясы да чуалып китте әле, жепнең очы югалды. Аны кайдан эзләп табасы булыр?..

Израэль Исаевичны куркынычсызлык комитетына чакырганнар иде. Ул бу хакта җәелеп сөйләп тормады. Шулай да кайтып житәр алдыннан әйтеп куйды: «Мөгаен, китәргә кирәк булыр...» Эшнең нидә икәнлеген күңеле белән сизенгән Барый кызыксынып сорау бирүне кирәксенмәде. Чынлыкта исә Мәскәүдә Вороновның туганнан-туган энесен шпионлыкта тотканнар

иде. Жепнең очы нәселләренә дә килеп тоташты.

Воронов язылачак хезмәтенең соңгы җөмләсен көндәлегенә төртеп куйды: «Татарлар—борынгы милләт. Берничә гасыр ул үзенең «картлык чорын» кичереп, йокымсырап утырды.

Хәзер әлеге уңдырышлы җирдә бәрәкәтле орлыклар тишелеп чыгып, алардан яшь үсентеләр китте һәм болар инде тамырланып, ныгып, кояшка таба үрелделәр.

Алар тарихында зур хата-ялгыш гамәлләр дә, бөек эшләр дә бар. Хаталарыннан арына-арына (туган телләрен үстерү, аның кулланылыш даирәсен арттырып, туган телне милли университет аша (анда шәрекъ факультеты да булдырып) фәндә раслау, бер-берсенә булган хөсетлек, көнчелек, әләктән арыну, һәр милләттәшләренә дә ярдәм кулын сузып яшәү, катнаш никахлардан саклау) алар киләчәккә ныклы адымнар белән барырга мәҗбүр. Бу—котылгысыз. Башка юл юк. Калган юллар упкынга илтәчәк!»

## Тау башында ай сүнгән...

Тулган Айның тау башында утырган чагы...

Астан, Байтимердән караганда, чынлап та, нәкъ тау өстендә утырган кебек күренә ул. Йолдызларын ияртеп, төнге җиһанны күзләп йөри-йөри, әйтерсең, арып киткән дә монда тукталып чак кына ял итәргә уйлаган, тау башында утырып тора... Шулчакта бик күпләр Айны таудан тәгәрәтеп төшереп, абзарларына бикләп куярга хыялланалар. И! Шуннан соң бар дөньядан алар капка төбенә халык җыелыр иде!!! Акча түләп Айны тотып карарга чират торырлар, бер генә нурын булса да зур бәһаләргә сатып алырга хыялланырлар; адәм сукмагы гомергә өзелмәс иде капка төпләреннән!.. Ә Ай урынына, тау башына, бик көчле прожекторлар менгереп куярлар иде!!! Соң... шул хәтле акчаларга...

Бу хакта бигрәк тә Садыйк Сираевич хыялланырга ярата. Байтимер аша төннәрен мари урманындагы үзенең умарта бакчасына узып йөргәндә килә иде аның башына мондый тәмле уйлар... Менә дигән туристлык бизнесы оешырып җибәрер иде ул аннан соң!

Әлбәттә, моның көлкеле, тормышка ашмас, җүләр хыял икәнлеген яхшы белә Садыйк Сираевич. Элек ул эшләгән җүләрләр йортындагы авырулар башына да килмәслек тиле хыял бит инде, югыйсә. Юк! Адәм баласын хыялланудан беркем дә тыя алмый! Бик тәмләп хыяллана ул һәм шуннан әйтеп бетергесез ләззәт таба... Садыйк Сираевичның бу дөньяда бар нәрсәсе бар, һәммәсе житеш, кызы да кияүгә чыгып куйса... Тулган айны да үзенеке итсә әгәр... Менә малай гына... нихәл итмәк кирәк!

Тау башында утырган тулган Ай аныкы булсамы? Садыйк Сираевич, татлы хыяллардан ләззәтләнеп, күзләрен йома, янәшәсендә утырган китек колаклы этенең башыннан сыйпый, шоферына ниндидер җылы сүз әйтмәкче була, ләкин капылт кына әлеге фикереннән кире кайта. Этенең колагы китек. Урманда бүре токымлы усал эт белән сугышкан. Колагын өздерсә өздергән, әмма бирешмәгән. Хәер, соңыннан дуслашып та алганнар бугай.

Алар умарталыкта вакытта бүре токымлы җан иясе агачлар арасыннан сыртын күрсәтеп-күрсәтеп ала, ләкин якын килергә курка, аның Казбегын эт теләндә үз янына дәшеп китерә, шуннан соң алар беркавым югалып торалар, уйнап туйгач, теге эт-җан Казбекны хуҗасына китереп тапшыра. Адәм акыллары бар диярсең, билләхи!..

Тулган Айны тау башыннан тәгәрәтеп төшерәсе иде дә, джипка тагып, өйгә алып кайтып китәсе иде! Бар халык шаккатсын, көндәшләре ачуларыннан шартласыннар иде. Хәзер халыкны байлык белән кызыктырып булмый.

Халыкның күпчелеге шыр хәерче, шуна күрә аңламый. Фикердәшләре исә үзләре дә бай. Алар аңлый микән, ә? Хәер, ул үзе аңлыймы соң?! Атасыннан калган мал түгел бит. Карт бабасы батрак булган, атасының атасы көтүче, атасы исә гомер буе ат җикте. Нәселдән килә торган байлык булса, бәлки, аңлар иде. Әүвәлрәк, төрле хәйлә-мәйләләр белән мал туплаганда, хөкүмәттән урлаганда, ул бер дә бер көнне боларны югалтырмын да ыштансыз калырмын дип курка, һәрхәлдә, җанын аңдый куркыныч хис туктаусыз кимерә, көн саен бер баш калкытып ала иде. Хәзер ияләнде инде. Әйтерсең, ул җиде бабасыннан калып килгән мал хуҗасы. Гәрчә аларны яңа байлар дип йөртсәләр дә, атасалар да... Тау башыннан аның янына тәгәрәп төшәчәк ай кебек, байлык-муллык аңа кителмәгәндә ишелеп килде. Ул аны ычкындырмас өчен кул бармакларын гына түгел, ирешкән нигъмәтенә аяк тырнакларына чаклы батырды, ычкындырмаска!.. Бүлешмәскә! Мәдәнияткә, дин юлына, милләт эшенә сарыф итмәскә!!!

Хәерче баеса, чабатасын түргә эләр. Ул рухият эшен кайгыртып йөрүчеләр белән сөйләшеп тә тормый. Аларны бөтенләй кешегә санамый... Татар баеса, хатын алыр ди. Садыйк Сираевич үзенчәлекле татар булып чыкты, хатынын аермады, болай гына типтерде. Менә хәзер дә умарталыктагы мунчасына арка ышкытырга барышы иде.

Тау башындагы төнге тавышларны ишетеп, Садыйк Сираевич шоферына туктарга боерды. Аның Аен урларга менгәннәр мәллә?

Чыннан да, бу вакытта тау башында хәлләр башлана башлаган иде.

Тау Байтимер ягыннан менгәндә генә текә булып, ары таба иксез-чиксез тигезлек китә, тауның аргы ягы юк—аңа менәсе дә шундук капылт төшәсе түгел, җәйрәп яткан болын чакрымнарга сузыла һәм бары Казан читенә житәрәк кенә ул, чак кына чүгеп, Казансу елгасына барып тоташа. Анда менеп баскач, артка, Байтимер ягына борылып карамасаң, тау икәнлеген дә белмәссең. Ләкин ни генә әйтсәң дә тау башы тау башы инде, туфрак һәр урында да бертөсле генә түшәлмәгән: кара җирләре бар, комлысы, арырак киткәч исә ташлы һәм чокырлы-чакырлы урыннары күбрәк очрый. Тауның Байтимер ягындагы битен артыш куаклыклары чолгап алган. Чәлтерәп чишмә тибеп утырган җирләр дә шактый очрый. Кем әйтмешли, һәр калҗа да майлы түгел иде шул.

Үзенең яхшы, иң уңдырышлы җирләреннән урман-чытырман арасына куылганына инде гасырлар узуга да карамастан, халыкның хәтере тарих төпкеленнән үк килә, җир аның өчен бердәнбер яшәү чыганагы, кыскасы, җир җир инде ул...

Җир өчен булган зур гаугаларны, дәһшәтле сугышларны тулган Ай да хәтерли... Кая хәтер генә! Җир өчен, аның мае өчен җирдәге адәм балаларын, бар тереклекне Ходайның шул ук бәндәләре йөзәрләп-меңәрләп җир куенына озата барган бер замандамы! Җир өсте бомбалардан шадраланып беткән замандамы?!

Шул дәһшәттән Ай кызының бер күзенә ак төште, чиләгендәге суы болганчыкланды, хәзер еш кына чайпалып та куйгалый... Цунамилар шул сәбәпле килеп чыга!

Бер аршын җир өчен туган белән туган ызгышты, илләр белән илләр чәкәләшеп, җир өстен кан елгаларына батырып бетерде...

Җир өченме?! Җир өчен кешеләр генә түгел, авыллар, шәһәрләр юкка чыктылар, җир йөзеннән югалдылар, беттеләр, очтылар!..

Дин йортының дивары өелеп, түбәсе ябылган инде. Гаптегани Алиханны туп-туры шунда таба алып китте.

—Синең урының Алла йорты янында булырга тиеш. Ә мин, синең яшьтиең, күршең булам,—диде ул.

Алар казык кагып әвәрә килеп йөргәндә яннарына Батай малае башсыз Абдул килеп җикеренергә кереште:

—Нишләп әле сез, кеше котыртып, казык кага башладыгыз?! Менә, пример, мин казык та алып менмәдем, балтам да юк.

—Күнеленә охшаган жиргә сузыл да ят!—дип әче теллеләнде Гаптегани.

—Минме, мин сузылып ятыйммы?! Син мәчет янындагы иң шәп жирне эләктергәнне яткан килеш карап торыйммы!

—Баскан килеш карап ят!

Телсез Габтери малае Габдулла Алиханның мылтыгын күреп ана бәйләнергә кереште:

—Нишкә син монда мылтык алып менден әле, мулла абзый, ә?

—Атмый ул.

—Тем более?

Габдулланың авызыннан аңкып самогон исе килә иде.

—Атмаса, күтәреп йөрмәсиең син аны! Ата торган мылтык ул. Белденме!

—Юк дим бит, атмый дим! Ник шул агач мылтыкка бәйләндең соң?

—Мин бәйләндемме! Мин бәйләнмәдем! Менә хәзер, шул мылтыгың белән айны атып төшеримме соң? Атып төшерәм бит!

Габдулла жирдә яткан мылтыкны җәлт кенә кулына алды да, Айга төбәде һәм аннары шарт-шорт күтәреп беткән чакмасына баскалый башлады. Мылтык чынлап та атмады. Ул, гарьләнеп, мылтыкны читкә томырды. Урыс-француз сугышында катнашкан иске мылтык чык итеп жирдә яткан таш өстенә төште һәм гөрест итеп атып та җибәрде. Тулган Ай Байтимергә таба тәгәрәп төшеп киткән кебек булды, беркавым колаклар тынып торды, ләкин тынлык озакка сузылмады, кемнеңдер: «Аллай! Үтерден бит!»—дип кычкырган тавышы тау башын янә бер кат сискәндереп җибәрде. Ядрәләрнең берсе Сибгатнең аягына эләккән иде, «үлдем» дип кычкыручы да шул үзе иде. Бу вакытта, күнеле сизенепме, Сибгатнең хатыны бозау чаклы этен бәеннән ычкындырып, капканы ачып маташа иде. Мылтык гөрселдәгәнен һәм шунын артыннан ук кычкырышкан тавышлар ишетеп, хатын үзе дә эт артыннан йөгерде! Бозау чаклы этнең калын тавышы башка хатыннарны да аякка бастырды: акчага сатып алынган явыз этләрнең барысы да бәйдән ычкындырылып, капкалар киерелеп ачылды...

Этләр белән этләр, кешеләр белән кешеләр бугазлашып, тулган Айның ак йөзенә өч кенә тамчы кып-кызыл кан чәчрәгән бер мәлдә, Барый Әкбәров машинасы авыл башына килеп кергән иде.

Садыйк Сираевич халык җыелган урынны, ыгы-зыгы, шау-шуны гомумән яратмый, шуңа күрә ул шоферына кузгалырга боермакчы булып, муенын борган иде, Казбегының багана төбендә аяк күтәреп алырга төшкән жиреннән юкка чыкканлыгын шәйләде дә машинадан төште. Эт-җан тирә-юньдә дә күренмәде. Садыйк Сираевич һафага төшмәде, артык борчылмады. Белә бит ул: анын этендә адәм акыллары бардыр; бер сызгыруга йөгереп килеп житәчәк иде Казбек.

Әмма Казбек чынлап та эт-җан булганлыктан, еректан ук таныш исне сизеп алып, шул тарафка таба йөгерде. Машинада селкенеп йөри-йөри тәмам туйган, алҗыган, ләкин бу хакта хуҗасына теле белән генә аңлата алмый, шуңа күрә кылган гамәле белән төшендереп бирсен әле. Элеккеге танышы Пират белән бераз уйнаклап алырга да җай чыгып тора менә; бүре токымлы урман эте, Казан кунагы килгәнлеген әллә каян белеп, бая ук үзенең янәшәдә икәнлеген сиздергән иде. Казбек, хуҗасы туктап торган арада, җәһәт кенә шул тарафны урап килергә булды. Күптәнге дуслар иснәшеп күрештеләр. Тик Пират, нишләптер, борынын капылт читкә алды: Казбектан дары исе килә иде. Хәер, ул каян белсен: Казбек машинанын арткы утыргычында

хужасының бүре ядрәсе белән корылган ау мылтыгы белән янәшә килле ләбаса. Казбек үзе бу искә күнеккән, ә Пиратның мылтык исен җене сөйми, аны сагаерга мәҗбүр итә. Әмма Пират «төпченеп» тормады, Агаякны ияртеп, эт тавышлары килгән тарафка—тау башына йөгерде. Алар артыннан тагылмыйча Казбекның башка чарасы калмады. Этләр менеп җиткәндә тау башы Бородино кырына охшап калган, кешеләрне талап, тешләп, җәрәхәтләп бетергәннән соң, бәйдән ычкынган усал этләр үзара әүмәкләшергә керешеп, тулган Айның котын алырлык дәрәҗәдә чинаша-өрешәләр иде.

Пират, мондагы канлы бәрелешне күргәч, тулган Айга карап, уларга керешге. Эттән туган бүре тавышы тау башын сискәндереп куйды.

Киемнәре теткәләнгән һәм кайсыдыр бер усал эт тарафыннан ун кулының ике бармагы чәйнәлгән Сәмигулла, бу вакытта, шыбырдап аккан канга да игътибар итмичә, авылга төшеп, үзенең Барсын ычкындырды. Ул ерактан ук Әкбәровның килгәнен күреп алды һәм, тиз генә артыш куагы артына посып, этен Барыйга таба өстерде...

Садыйк Сираевич, дәшеп-дәшеп тә, Казбегы янына килмәгәч, мылтыгын кулына алып, шау-шу килгән тарафка—тау башына менеп китте һәм, берара узуга, колагына Казбегының—кыйммәт бәягә Мәскәүнең үзеннән сатып алып кайткан этенең!—ачыргаланып чинаган тавышын ишетте дә, уйлап-нитеп томыйча, әүвәл һавага атты, аннан соң кая төбәгәнен үзе дә белештермәде.

Казбек—Мәскәү эте—чит кешеләрне сөйми иде. Дөресрәге, аны яшьтән үк шуңа өйрәттеләр. Бу холкы аның хәтта ерак бабаларыннан ук килә иде. Буыннан буынга дәвам итеп, нәселдән нәселгә күчте... Дөньяда аның өчен үз хуҗасы һәм берничә ияләнгән кешесеннән башка калган адәмнәр кан дошманнар. Ул тау башында әрле-бирле чабышкан хатын-кызларга ташланды. Аларны талап, тешләп, киемнәрен аерганнан соң да кайнарлыгы сүрелмәде Мәскәү этенең. Шул унайдан ул янәшәсендәге Агаякны буып ыргытты. Моны күреп торган Пират, Бүре токымлы безгә яхшы таныш кыргый урман җанвары Мәскәү этенә сикерде.

Этләрнең көче бер караганда тигез иде кебек. Менә беркавымнан хуҗасы янында пәннек кенә ашап яткан Мәскәү этенең хәле бетә башлады. Урман-кырлар баласы, ирек һәм азатлык сөйгән бүре токымлы эт инде яше хәйран булуга да карамастан, Мәскәү этенә караганда тәҗрибәлерәк тә, елгыррак та иде .

Шул арада алар янына Сәмигулла эте дә килеп басты. Ул артыш куагы төбендә бер адәмне тәгәрәтә-тәгәрәтә талап, бармакларын һәм кайбер башка әгъзаларын чәйнәп, инде күңеле тәмам булганның соңында, Пират тавышына менгән иде. Казбекка каршы алар хәзер икәү булдылар.

Казбек Көньяк-Көнбатышка—Мәскәү ягына—карап, ачыргаланып чинарга керешге...

Тулган Ай, бу мәхшәрне бүтән күрмәс өченме, үзенә таба болыт-пәрдәне тартып китерде...

Тау башында ут сүнде...

Мәчет-чиркәү-синагога шулай ук дөм караңгылыкка чумды. Ләкин беркавымнан анда ниндидер хәрәкәт башланды һәм озак та узмады дин йортыннан дүрт Күләгә шуып чыкты. Әйе, әйе, күзгә төртсән күренмәслек караңгы булса да күләгәләре шәйләнә иде аларның!.. Күләгәләр артыннан аларның ияләре—өч Фәрештә һәм бер тәмуг кисәве пәйда булды. Алар, гәп корып җибәреп, үзара бәхәсләшәләр иде. Араларыннан нурлы вә сөйкемле Фәрештә үзен бик горур, ышанычлы тота, һәр сүзе ташка басылган кебек һәм кире каккысыз. Ул:

—Бисмилләһир-рахманир-рахим,—диде дә, җиде мәртәбә тын алып,

моңарчы үзе яхшы инанган җиде төрле хакыйки сүз-җөмләләр әйтте. Аннан соң балчыктан яратылган Адәмгә сәҗдә кылды.

—Аллаһтан иңгән китапка гына табыныгыз.

—Юк, без аталарыбыз юлыннан барачакбыз.

—Сез Аллаһ әйткән дөреслекне яшердегез һәм аны арзан бәягә җибәреп көн итәсез. Сезнең корсакларыгызда ризык түгел, ялкынлы ут тулган. Кыямәт көне килеп җиткәч, сез әйткәннәргә табынучыларга Аллаһ тарафыннан авыр җәза биреләчәк!

Калган ике Күләгә, ризасызлык белдереп, баш чайкадылар, күрәсең, каршы килмәкче булдылар.

—Әй сез, китап әһелләре, нигә бәхәсләшәсез! Ибраһим мәсьәләсендә дим. Тәурат та, Инҗил дә аннан соң гына индерелде бит! Шуңа да башыгыз җитмиме? Сез бит мөселманнарны юлдан яздырып, алдарга телисез! Ләкин бит сез бу рәвешле аңламыйча бары үзегезне генә юлдан яздырасыз! Ибраһим христиан да, яһүд тә түгел ул. Ул Аллаһны бердәнбер дип танучы мөселман булыр.

Күләгәләрнең берсе кымшанып куйды һәм әйтте:

—Көндезен ышанган булыгыз да, кичен аннан баш тартыгыз.

—Аллаһның юлы иң дөрес юл булыр. Тәуратка, Инҗилгә охшаш тәгълимат бүтәннәргә дә бирелә ала. Бу пәйгамбәргә ышаныгыз, монысына инанмагыз,— дип әйтүчеләр, иман белән көферлек арасындагы юлны сайлаучылар юкмы әллә? Шулар чын кяфер була да инде. Белегез, кяферләргә Аллаһ тарафыннан каты җәза әзерләнгән.

Тегеләр һаман каршы килеп маташтылар.

—Нигә килешмисез?! Яһүдиләр белән христианнар арасында барган тарихи сугышлар вакытында Инҗилегезне югалтып, буталып беттегез бит инде. Хәзер аны төрле рәвешләрдә шәрехләп маташасыз ләбаса! Шундамы чын хакыйкать?!

Калганнар һаман килешмәде.

—Бүген кыямәт көне. Бу гаделлеләрнең үз гаделлекләреннән файда күрә торган көн. Алар өчен гөлбакчалар арасыннан чишмәләр агып торучы җәннәтләр булыр. Аллаһ алардан бик канәгать, алар да Аллаһтан разый һәм аңа рәхмәтле!..

Калган ике төнге Күләгә каршы килә алмадылар...

Тәмуг кисәве—Иблис моңарчы сүзгә катнашмый тора иде. Аңа шулчак: «Адәмгә сәҗдә кыл!»—дип әйтелде. Ул каршы килеп, баш тартты. Үзенчә дәлиле дә бар иде: «Мин Адәмнән яхшыракмын. Мине уттан-ялкыннан яраткансың. Аны исә балчыктан». Аңа әйтелде: «Бәс, җәннәт чык! Инде син, шик-шөбһәсез, ташлар белән атып сөрелгән мәлгунсең. Вә, әлбәттә, җәза-кыямәт көненәчә сиңа барысының ләгънәте булыр!»

Шул рәвешле Иблис көферлек җәтмәсенә эләкте, Ходайның бәддогасына тарыды, мәңгелек җәһәннәм—тәмуг кисәвенә әверелде. Иблиснең нәсел-кабиләсе—аңа тәлинкә тотучы җеннәр, шайтаннар, кешеләр вә хайваннардан гыйбарәттер. Шайтаннар аеруча куркыныч: алар бәндәләрнең, төп эшләреннән читләшеп, башка мөһимсезрәкләре белән михнәт чигүләрне хуп күрә. Аяныч ки, күпләр моны аңламый, илаһи вә шайтани гамәлләрне аермый. Әмма аларның хәленә керергә дә мөмкин, чөнки шайтан мәлгунь хәер-хаклыкның җитмеш ишеген ача да, гаҗәп, алар аша бәндәне, аңа һич сиздермәстән, яманлык һәм фәсадлык ишеге бусагасына китерә дә бастыра. Чөнки ул Иблиснең һәр әмерен төгәл үтәп баручыдыр. Ә Иблис—тәмуг кисәве. Ул—Явыз. Аның чын йөзе түбәндәгеләрдән гыйбарәт булыр: Исеме—Иблис, шәһәре—ваемсызлар күңеле, даими хәят урыны—тәмуг, мал-мөлкәте—буш хыяллар, мәҗлесе—базарлар, сәфәрендәге дошманнары—мөселман татарлар, шөгыле—әхлактан яздыру, төс-кыяфәте—төсен үзгәртүче кәлтә елан, яраткан

хатыннары—ярым-ялангач киенгәннәр, йорты—бәдрәф вә мунчалар, табигате—аумакайлык, дөньяга килгән көне—Адәмгә сәҗдә кылудан баш тарткан көне, дус-ишләре—икейөзле бәндәләр, дине—көферлек, дәһрилек, вазыйфасы—Аллаһ хозурында булганнарның баш хуҗасы, хезмәт вакыты—кыяматкә кадәр, сәфәр дуслары—җеннәр дә шайтаннар—бәндә сурәтендәгеләр, курыкканы—дога, җәтмәсе—хатын-кыз, яраткан шөгыле—ир-атның ирләр, хатын-кызның хатыннар белән җенси мөнәсәбәтләре.

Дин йортында янә шау-шу купты. Озак та узмады, аның морҗасыннан, утлы төтен булып, ике шайтан бөркелеп чыкты һәм җиргә төшеп, кагынгандай итенделәр. Шайтаннарның берсе телгә килде:

—Фәрештәләр китте. Фәрештәләр булмаган җирдә без үрчибез!

Икенчесе аның сүзләрен җөпләп тормады, үз уен әйтте:

—Ник шаулашты болар бик каты?!

—Адәмнәр гадәттә ике очракта бер-берсенең бугазларына ябыша: хатын-кыз, җир яки акча-байлык бүлгәндә!

—Һәм милли хисләренә кагылсаң!

—Әйе, Иблиснең исемлегендә татар аерым графада тора, мишәр аерым графада, үз күзләрем белән күрдем. Димәк, алар аерым милләт! Шул исемлекне без шыпырт кына антропология институтына илтеп бирдек! Мәскәүгә үк! Директорның өстәлендәге исемлекне алыштырдым да куйдым. Ул моны үзенең исемлеге дип уйлап йөри. Ха, ха! Директор чаклы директор шайтан коткысы белән йөрсен әле! Кемнәрне генә юлдан яздырмыйбыз без, ахири, ә!...

—Укый белмисең бит син!

—Һа, белмәс сиңа! Мин ун ел буе Казандагы татар гимназиясендә укучы кызларны тәмәке тартырга юкка гына өйрәтеп йөрдем мени! Грамотаны да шунда эләктереп калдым!

—Ярый, бүтән йөри алмассың! Татар гимназияләрен ябалар ди анда. Мәскәүдән берәү Казандагы берәүнең колагына шулай дип пышылдаган.

—Ул Мәскәүнең берәве, бик беләсең килсә, мин булырмын! Мәскәү чиновнигына әверелдем дә... пышылдадым инде колакларына! Чөнки мине настоящий чиновник дип кабул иттеләр!

—Хе, алайса ул гимназияләре дә шайтан коткысы белән генә ябыла микәнни?!

—Шулай булмый ни! Менә үзеңнең дә башың эшли икән бит!

—Нәрсә көлгән буласың?

—Ник мина төртәсең?!

—Йә, ярый, безне алда зур эшләр көтә. Безгә ачуланышырга ярамый.

—Адәмгә әверелгәч тә тукмашырга өлгерерсең әле дисеңме!

—Шулай булмыйни!

—Баш түгәрәк синең!

—Әйе шул. Чү, тукта, адәмнәрчә сөйләшә белергә дә өйрәнергә кирәк сиңа! Адәм кыяфәтенә кергәч, нинди шартларга эләгәсең бит әле! Мафиозникларына тап булсаң...

—Ә мин сихер белән җинәчәкмен!

—Җиңүең җинәрсең анысы. Тик сөйләшә дә белергә кирәк! И крыша кирәк!

—Крыша? Анысы ни тагын?

—Крыша там, наверху!

—Син нәрсә, хочешь сказать, что у меня крыша поехала?! Тагын мыскыл итәргә керештеңме! Мин! Сине хәзер!

—Йә, йә, тынычлан! Мин алай димәдем бит әле! Баклан ты, понял?

—Баклан?

—Әйе, мин сиңа хәзер адәмнәр арасында, бигрәк тә яшьләр арасында еш

кулланыла торган сүзләрне өйрәтәм. Баклан—аңгыра кеше дигән сүз була.

—Баклан—аңгыра. Аңладым, тагын?

—Жопа на два базара—икейөзле адәмгә шулай дип әйтәләр.

—Один базар, два базара и... и-или-ии... одна жопа да?

—Да, да? Гринь—доллар!

—Аһа, доллар.

—Дичь—ямьсез хатын-кыз.

—Ә нормальный кыз?

—Тема... Кыз—«тема» була.

—Профессор әфәнде, сез бүген нинди тема өстендә эшлисез? Ха, ха!

—Чымерь—начар адәм.

—Чымерь! Фу! Чымерь!

—Шнурки в стакане.

—Анысы ни тагын?

—Эти-әниләр өйдә дигән сүз.

—Шнурки! Ха, ха!

—Доить самовар.

—Самовар доить? Бәлкем, сыердыр ул, ә?

—Юк, сыер түгел. Әтидән акча сорау дигән мәгънәне аңлата. Тагын менә «лечить» дигән жаргон.

—Дәвалаумы?

—Лечить, ягъни акыл сату. Йә, шулары җитеп торыр сиңа. Боларның һәммәсен Иблис агаң үзе уйлап чыгарды да ярдәмче шайтаннары аша кешеләр арасына кертеп җибәрде.

—Карале, әгәр дә Иблис кушканны башкара алмасак, безгә нинди җәза булыр дип уйлыйсың?

—Нинди җәза? Хе... бернинди дә физик җәза булмаячак. Просто Иблис безне эштән генә куачак һәм гомерлеккә кешеләр арасына җибәрәчәк. Шайтан итеп түгел, ә менә кешегә әйләндереп!

—Ә минем кеше буласым килми! Килми!

—Минем дә килми! Чибәр хатын-кызны бүлә алмыйча кем беләндер пычакка пычак киләсем килми! Власть, дан-дәрәҗә өчен сугышып канга батасым килми!

—Тормыш алып барам дип, борыным белән җир сөрәсем килми!

—Йә, булды, чинама! Әйдә лучше кеше булырга өйрәнә торабыз. Иначе безгә шунсыз булмый. Алар арасында яшәргә дә кирәк бит әле.

—Бу нинди шешә? Анын эчендә нәрсә бар?

—Аракы!

—Аракы?!

—Безнеңчә әйтсәк, шайтан суы. Без гомер буе адәмнәрне шуны эчәргә котыртып йөрдек, нәрсә, оныттыңмы әллә: сихер көчебез кимегән очракта адәмнәрнең авызларына аракы гына коя идек. Сихерең дә кирәк түгел, шундук бер-берсе белән талаша, сугыша башлыйлар иде.

—А как же! Хәтерләми ни! Күпме гаиләләрне җимердек! Күпме җүнле кешеләрне юлдан яздырдык, шул үзебезнең шифалы су ярдәме белән! Хәзер үзебезгә дә эчәргә туры килә инде.

—Ә эчкәннән соң нишлибез?

—Нишлибез? Нәкъ кешеләрчә эшлибез. Әүвәл җырлап җибәрәбез, аннан соң мактанырга тотынабыз, аннан соң инде сугыша башлыйбыз. Бер-беребезне тукмап туйгач, өйгә кайтабыз да хатыннарга бәйләнәбез!

—Ә ул адәм затларының хатыннары бер дә эчми микәнни?

—Ничек кенә эчәләр әле! Эчәләр дә үзләренең хуҗабикә икәнлекләрен бөтенләй оныталар!

—Ничек оныталар?

—Һай бигрәк наивный инде син! Ничек онытсыннар инде?! Адәмнәрнең аракы эчәргә яраткан хатын-кызлары... даже... үзләренең... бер нәрсәләренә дә хуҗа була алмыйлар. Анладыңмы?

—Анладым кәнишне! Хәтта үзләренең... менә... колак яфракларына кадәр хуҗа түгелләр уже, әйе бит?

—Соображаешь!

—Әйдә, әүвәл мактанышып алыйк.

—Бик рәхәтләнеп!

—Карале, минем чынлап та кеше буласым килми бит. Без аларны, без аларны унҗиденче елдан бирле бозабыз, котыртабыз бит инде! Алар арасында хәзер бездән явызраклары да күренгәли башлады бит!

—Әйе шул. Мин моның белән горурланам гына. Без Иблис агайның приказларын җиренә җиткереп үтәп барабыз.

—Әүвәл, кулаклар дип, иң уңганнарын, тырышларын җәһәннәмгә олактырдык. Аннары миллионлаган адәмнән халык дошманы ясаттык. Мин ул Сталин дигәннәренең җанына шундый ныклап кереп урнаштым ки! Минем әйткән сүзләрнең һәммәсен карышмыйча үтәп барды.

—Ә мин ананчы Ленин дигәннәренең баш миенә кереп урнашып, күпме дөньяны болгаттым!

—Ә мин моннан соң ин Дәү түрәнең аңына кереп урнашам да милләтләрне юкка чыгарырга боерам! Чөнки бу татар дигән адәмнәрдән тәмам туйдым. Коткыга бик авыр биреләләр.

—Ә мин аның язган указларын алып чүплеккә ташлыйм да өстәленә Иблис агай язган указларны салып торачакмын! Тик уйлап йөрсен мин чыгарган указ бу дип! Ха, ха!

—Әйдә, әүвәл яшьләрен бозудан башлыйк эшне. Аларны китаптан, әдәбияттан, сәнгатьтән, кыскасы, матурлыктан аерыйк. Телләрен кисик, дөресрәге, туган телләреннән мәхрүм итик! Шуннан соң алар үзләреннән үзләре бозыла башлаячаклар! Күреп торырсың менә!

—Ә мин авылларны бетерттерәчәкмен! Аларның бар көчләре, әхлаклары авылларда иде элек! Хәзер без мона таяк тыгачакбыз! Бар дөньясы шайтан коткысы белән яшәвен дәвам итсен!

—Дәвам итсеннәр!!!

—Карале, ә син чыбыркы шартлата беләсеңме соң?

—Нигә кирәге бар аның? Без көтү көтәргә бармыйбыз бит?!

—Кирәк! Коммунистлар халыкны сарык көтүенә әйләндереп бетергәннәр иде бит инде, хәтерлисеңме?

—Хәтерләмәгән кая ул!

—Һәм стукач көтүенә!

—Ә монысын хәтерләп торасы юк! Бүген шул нәрсә тагын кире кайтты бит! Понимаешь ты?

—Конечно понимаю!

—Чү, туктале, нигә без капылт кына урысча сөйләшә башладык соң әле? Без татарлар арасына барабыз бит?

—Без урысча сөйләшмибез, без сүгенәбез!

—Как так?

—Татарча сөйләшкәндә урыс сүзләрен кыстыру ул сүгенү дип атала! Иблис аганың кешеләр өчен язган Әхлак кодексын оныттыңмыни! Анда шул хакта отдельный статья бар бит!

—Точно, точно, искә төште.

—Син хәзер кай тарафларга юл тотасың?

—Мин—Мәскәүгә! Президент папкасында яткан указ-күрсәтмәләрне, яна

законнарны Иблис агай биргән кәгазьләр белән алыштырып куясым бар!

—Син чамалап. Белә күрмәсеннәр!

—Чуртым да белмәячәкләр, моңа чаклы беркем дә сизмәде бит әле!..

Ике шайтан, кочаклашып, тау башыннан аска—Байтимергә таба тәгәрәделәр...

Моны күреп торган нурлы Фәрештә, тылсымлы дога сүзләре әйтте. Шул мизгел эчендә нурлар ишәеп, әүвәл биш миллион сөйкемле фәрештә пәйда булды, тора-бара аларның саны җиде миллионга җитте һәм беркавымнан фәрештәләр егерме миллион иделәр инде! Алар нәкъ татарлар кебек үк дөнья буйлап сибелделәр һәм һәр Алла бәндәсенә берәр фәрештә туры килергә тиеш иде.

Иман яңарту башланды. Хәзер бернинди иблис-шайтаннар да куркыныч түгел иде инде бу Ходай бәндәләренә...

## Мөхәммәт һәм мәхәббәт

Тау башындагы хәлләрдән соң кала яны һәм шәһәр хастаханәләре яраланган, җәрәхәтләнгән байтимерләр белән шыплап тулды. Барый Әкбәровны Казанның үзенә үк алып киттеләр. Эт тарафыннан чәйнәлгән сул кулының бармакларын, уң колагы һәм башка әгъзаларын кире «терелтергә» кереште табиплар. Барыйның абыйсы Һади, Мөхәммәтне эзләп, Казанга китте. Чөнки энесенә җитди ярдәм кирәк, Мәскәүдән яки чит илдән зур белгечләр чакырту өчен Мөхәммәт элемтәләре кирәк иде.

Һади Казанга бер барды, икенче тапкыр чыгып китеп карады, ләкин Мөхәммәтне тапмады.

Атаклы рәссам бу вакытта өендә бикләнеп һаман да коньяк чөмереп ята һәм аның дөньялыкта кайгысы юк иде. Дөрес, кичтән ул матур уйлар белән эш бүлмәсендә яза башлаган картинасы өчен бар кирәк-яракларын, буяупумалаларын әзерләп, хәстәрләп куя да иртәгесен инде рәссам күңелендә таң атуга сүнгән ай кебек иҗат ялкыны сүрелгән була. Өйдә алар Сиринә Самуиловнаның эте белән икәү генә. Сиринә Самуиловна үзе командировкада, андый чакларда ул яраткан көчеген Мөхәммәткә кертеп китә. Чөнки аны песи янында калдырып китәргә шикләнә иде Сиринә Самуиловна.

Фатир ишеген берәүгә дә ачмады, телефонны исә өзеп үк куйды Мөхәммәт.

Бер дә бер көнне ул иртән уянып, чәйнек борыныннан гына йотлыгып су эчте дә, аптыраганнан, эш бүлмәсенә керде һәм шулчак артына авып китә язды: кемдер аның өчен картинасын язып тәмам кылып куйган түгелме соң?! Ул аңа кичтән бер-ике сызык сызып, яхшырак күренсен өчен идәнгә сузып салган иде. Ләкин көймәсе комга терәлде, ул комны «юып» җибәрергә дип, кухнәгә чыкты һәм тутырып бер стакан җибәргәнен хәтерли. Тик шуннан соң эш бүлмәсенә башка кереп тормады бит инде?! Дөрес, ул әлеге рәсемнән бернәрсә дә аңламады, әмма монда Пикассо кулы уйнагандай иде!!! Мөхәммәт, гаҗәпләнүдән колакларын тартып, тәнен чеметеп карады—авырта, димәк, ул төш күрми һәм үз аңында... «Бәлки, галлюцинация башлангандыр?!»—дип куркынып уйланды ул акылы шактый саф булуга да карамастан. Бәлкем, салган баштан кичә үзе нәрсәдер эшләгәндер дә бүген исә оныткандыр... һаман да шул салган баштан инде?..

Мөхәммәт, аптырап, кухнәгә керде һәм ачык шешәдән чәшкегә коньяк агызды. Шул рәвешле баш шәрифләрен майлап, фикерләрен кыймылдатырга, хәтерен кире кайтарырга иде исәбе. Ул янә курка-курка гына эш бүлмәсенә чыкты, бәлкем, теге рәсем бая күзенә генә күренгән булгандыр да хәзер исә ул юкка чыккандыр дигән уй белән атлады ул. Тик ялгышты, картинада бернинди үзгәреш юк, һаман да шул ук әллә нинди аңлаешсыз сызык-күренешләр!...

Ул, ике чигәсен кысып тотып, балконга чыкты. Шушы мизгелләрдә акылдан шашар хәлдә иде егет. Тик, бәхетенә, Сиринә Самуиловна кайтып керде, ул ишекне үз ачкычы белән ачып кергән иде.

Сиринә Самуиловна, картинаны күргәч, йөгереп диярлек килеп, Мөхәммәтне кочаклап алды.

—Ты мой гений! Ты—Пикассо!—диде ул аның махмырлы йөзеннән үбә-үбә.—Бүген бит, бүген бездә халыкара күргәзмә ачыла бит! Тизрәк моны шунда илтергә кирәк!—дип, ул телефоннан шоферын чакыртып алды.

Ләкин... әмма Мөхәммәт һаман да берни аңламыйча, тинтәк башын тотып, диван читендә утыра иде. Әлбәттә, ул күргәзмәгә бармады, картинаны алып, Сиринә Самуиловна үзе китте. Ни генә әйтсән дә, бүген француз белгечләре килеп караячаклар бит!

Мөхәммәт Уразовның соңгы эшенә зур бәя бирделәр...

Сиринә Самуиловна шул хакта кайтып әйткәндә, Мөхәммәт диван кырыена чүмәшеп, йоклый иде. Дөресрәге, ул йокылы-уяулы, күзен ачып аягына да торып баса да алмый, йоклап та китә алмый, башы исә комбайн кебек эшли, күз алдында әллә нинди, кадрлары еш алмашынып торган төсле кинофильм. Алмагач бакчасында йөриләр икән, Гөлчәчәк белән икәүләшеп. Гөлчәчәк ап-актан киенгән, йөзе шат, бертуктаусыз сөйли, аннанан соң капылт кына туктала да алар үбешә башлыйлар. Шулчак кинәт Мөхәммәт алмагачка әйләнеп кала, Гөлчәчәк тә алмагач булып янәшәсендә чәчәк ата. Ул алмагачтан тел белән әйтеп, каләм белән язып бетергесез якты нурлар сибелә, Мөхәммәткә рәхәт, ул ләззәтнең иң югары ноктасында итеп хис итә үзен. Гаҗәп дөнья, искиткеч матур Җиһан! Яшисе килә—Сөясе, сөеләсе килә!..

Уразовның соңгы картинасына бер француз тәмам каныкты, сатып алырга теләде, мин аны Луврга куячакмын дип, вәгъдәләр бирде. Тик моның өчен Уразовның рөхсәте кирәк иде. Мөхәммәт исә шул ятуыннан бүтән аякка баса алмады, ара-тирә аңын да югалткалап, бер авыз сүз дә әйтмичә күзләрен түшәмгә терәп ята бирде. Бу халәтенә икенче көн китте дигәндә, Сиринә Самуиловна табиплар чакыртты. Ләкин бернинди укол да, бернинди дару да егетне аңына китерә алмады. Сиринә Самуиловна үзе дә, якыннары да пошамангa төштеләр. Өченче көн дигәндә, ниһаять, аның күзләренә җан кергәндәй булып, ул бары бер генә сүз әйтте: «Гөлчәчәк...» Бу исемне ишеткән Сиринә Самуиловна чак кына артына авып китмәде. Эшне шундук төшенеп алды сизгер күңелле хатын һәм бер-ике көн икеләнеп, вәсвәсәләнеп йөргәннән соң катгый карарга килде: Мөхәммәтне югалтасы, Мөхәммәт Уразов атлы бөек талант иясен һич тә югалтасы килми иде сәнгать белгеченең... Әлбәттә, иң беренче чиратта Сиринә буларак югалтасы килми... Аннан соң... аннан соң Ходай каршында... Табигать әнкә каршында көчсез һәм бер чарасыз икәнлеген аңлады Сиринә. Ләкин ул беркайчан да җиңелергә, ике кулын югары күтәрергә өйрәнмәгән иде. Ул моның вакытлы хәл икәнлеген белеп, тирәнтен аңлап эш итте.

Ишек ачылуга, Гөлчәчәкнең килүен сизеп алды Мөхәммәт. Әйтерсең, өйгә гап-гади бер хатын-кыз түгел, бүлмәләрне тутырып, якты нур инде.. Аның тавышы... Аның хәрәкәтләре... Аның бәләкәй кулын маңгайга куюлары!.. Аның... аның сак кына орынып, кулын тотулары... Йа, Ходай! Син генә булса да ышан инде бу хәлгә!!! Юкса, Синең кодрәтең бит бу!!! Әйе, әйе, һич кенә дә башкача булуы мөмкин түгел... түгел!.. Мең кат түгел!!!

...Мөхәммәт Уразовны Парижга Лувр музеена эшкә чакырдылар. Сиринә Самуиловна Гөлчәчәккә дә виза эшләтеп алды. Озатырга да барды. Аның Мөхәммәт колагына гына әйтәсе бер сүзе бар, ул сүз түбәндәгедән гыйбарәт иде: «Син бер кайчан да мине онытырга тиеш түгел! Син беркайчан да мине ташларга тиеш түгел!!! Без барыбер бергә булачакбыз! Аңлыйсыңмы?!!»

«Аңлыйм бугай...»

Яраткан көчегеен өенә алып кайтырга дип, Мөхәммәтнең фатирына кире кайткач кына этенең койрык очы һәм тәпиләренең буяуга каткан икәнлеген күрде Сиринә Самиуловна. Көчек Мөхәммәтнең эш бүлмәсендә, рәссам абыйсының картина язарга әзерләп куйган полотносы өстеннән узган, (Мөхәммәт аны мольберттан алып, стенага сөяп куйган иде, ул шуып идәнгә төшкән) шул җәһәттән буяуга манылган койрык очын да болгап-болгап алган иде. Бу күренешләр Сиринә Самуиловнага нәрсәнедер хәтерләтте сыман. Ләкин ул озак уйлап тормады, астына нечкә пумала белән: «М. Уразов. «Через тернии к звездам»,—дип язып куйды да аны күргәзмәгә илтергә әзерләде. Ерактан ук күренеп торсын өчен авторның исемен чекерәеп торган зур хәрефләр белән язды Аннан соң кыра-кыра бик озаклап көчегенең койрыгын юды...

## Соңгы сүз алдыннан

Байтимернең тракторчы Галләм абзый Казандагы махсус хастаханәне бик озак эзләде. Көн кичкә таба авыша барганда гына тапты ул аны, Барый Әкбәров яткан палатаны да эзләп тапты карт. Тик кыяфәте авыру хәлен белергә килгән кешегә һич кенә дә ошамаган иде. Барый һаман урын өстендә. Сул кулының бармаклары бинтка уралган, билдән түбән өлеше ак җәймә белән капланган. Янында Һади абыйсы һәм Гөлйөзем утыралар.

Галләм карт килеп кергәч, икесе дә гаҗәпләнеп калдылар һәм, аптырашып, бер-берсенә карашып куйдылар.

Галләм карт унайсызланып кына тамагын кырып алды да Һадига карап:

—Син, Һади энем, белмисеңдер инде. Без менә алтмыш еллап инде кешеләрдән, авылдашлардан яшереп килдек... Безнең нәсел белән сезнең нәсел ... бик якын туганнар бит! Әкбәр бабаң ягыннан... Әтине алып киткәч, мин бабагызга бик нык кисәтеп әйттем: «Безнең туганлыкны бездән соң килгән буын онытырга тиеш!»—дидем. Ул риза булды. Ул әтине... минем әтине... Бер сүз белән генә әйткәндә, ул бик нык үкенә иде. Әтине кире кайтарырга артыннан да йөреп карады каравын. Тик эш узган иде. «Йөрмә, алайса үзеңне дә утыртып куярбыз!»—дип, куып кайтардылар аны районнан. Үзе сөйләде. Менә шул... без туганнар, кан кардәшләр...

Ул шул сүзләрне әйтте дә Барый ягына таба күтәрелеп тә карамыйча ничек керде шулай чыгып та китте. Бу мизгелләрдә Галләм картның кызы Зәринәне искә төшергән Барый Әкбәров эшнең нидә икәнлеген бик яхшы аңласа да сүз әйтерлек хәлдә түгел иде. Әлеге сүзләрнең серенә төшенгән Гөлйөзем исә, көлемсерәп, башын чайкады. «Барыйның яшь сөяркәсе кан-кардәш сеңлесе булып чыга икән алайса»,—дигән уй узды аның башыннан. Тик ул бу хакта әле һаман берни аңламыйча аптырап утырган Һадига сиздермәскә булды. «Ишеттерерләр әле, авыл халкының теле озын...»—дип көрсенеп куйды урман кызы...

## Соңгы сүз

Садыйк Сираевичны хастаханәгә барудан кызы Әлфия туктатты.

—Йөрмә!—диде ул.—Миңа андый кияү кирәк түгел инде хәзер.

—Нишләп, кызым?

—Он не мужик сейчас.

Бу минутларда Барый Әкбәровны катлаулы операция ясау өчен Мәскәүгә алып китәргә әзерлиләр, бәлки, Америка белгечләренең үк ярдәмнәре кирәк булыр әле, моны Мөхәммәт сөйләшеп киткән иде.

Мөхәммәт Уразов Парижлан шылтыратып яшьлек дустының хәлен белешеп торды. Бу вакытларда Мөхәммәт үзе жиденче кат күктә йөзә, канатлары исә янында яшәгән Гөлчәчәге иде. Шулай бер көнне урман кызы шаккаттыргыч сүз әйтеп, аның исен-акылын китерде!

—Карале, Мөхәммәт, монда талантның кадерен беләләр икән ич!

Әйе шул, беләләр, хәтта моны Гөлчәчәк тә аңлаган, бахыр. Алай гына да түгел: рәссам буларак, иҗат кешесе буларак Мөхәммәттә үз-үзенә Ышаныч хисе уянды! Әлеге хис бу юлы аның үзенеке генә. Ул сәламәт һәм көчле иде. Әйе, әйе, нәкъ шул хис аны тагын бер башка күтәреп куйды, ул аның Талант чәчәкләренә шифалы яңгыр кебек тәэсир итә, алар тагын да ачылып, тагын да матураеп киттеләр!.. Әлеге бөек хис—әлек аны гел таптап, изеп, сытып киләләр иде—егеттә яшисе, иҗат итәсе килү теләген арттырды!.. Мескен укытучылар, табиплар, әдәбият-сәнгать әһелләре кайчан да булса бу хисненн тәмен сизәрләрме икән соң, ә? Аларның хезмәтләрен (бу төр һөнәр ияләренен хезмәтен югарыда кемнәр бәяләп утыра икән?—шуны беләсе иде!!! Болар бит бәһасез һөнәр ияләре! Синең хезмәтен «өч» тиен, синеке «биш» тиен булыр дип, югарыда нинди адәмнәр исәпләп-санап утыра икән, ә?! Бу башка һөнәр ияләренә дә кагыла, урам себерүчедән алып, мәшһүр академикларга чаклы!) чүпкә дә санамыйлар, кадерләре юк!.. Югыйсә, болар балалар, яшь буын тәрбияли, шуларны дәвалый! Нәрсә, Рәсәйдә балаларның да кадере беттеме икәнни инде, Ходаем?!!

Мөхәммәт әнә шулар хакында бик еш уйлана башлады. Әлбәттә, чит ил кешеләренең яшәеш рәвеше, гореф-гадәтләре ана ят, сәер иде. Гомумән, ул монда үзен көн саен иртән тозсыз ботка ашаган кебек хис итә, туган җир сагындыра, нишлисен, туган җир барыбер кадерле шул... Шөкер, Гөлчәчәге үз янында. Хатыны аның туган җиренең бар табигатен—мен яшәр имәннәреннән алып ак күлмәкле каен кызларына чаклы—үзе белән «ияртеп» килгән! Тагын шунысы шаккатмалы—туган җиреннән еракта, Татарстан дигән Ватаныннан шактый читтә ул үзенең «коеп куйган» татар баласы икәнлеген ныграк аңлый башлады! Һәм ул һәр әсәренә милли сурәт, милли моң һәм шундый тагын әллә нинди төсмерләр бирергә омтыла. Французлар аның бу сыйфатын бик ошаталар, ул аларның бер дә эчләрен пошырмый, киресенчә, кызыксынуларын гына арттыра иде... Ләкин күршең алмагачы ботагында утырып сайрап, үз бакчаңа дан җырлап булмый. Мөхәммәт моны да яхшы аңлый. Тик Ышаныч хисенең һаман арта, үсә баруы аны күбрәк тәэсирләндерә, ул хиснең тәмам ныгып житкәнен түземсезлек белән көтә. Шуннан соң киләчәк гамәлләре хакында да ныгытып уйларга мөмкин булыр кебек...

...Бәгырьдән суырылып чыккан бер кошчык, уктай зәп-зәңгәр болытларга таба атылды. Ул тургай баласына да охшамаган, сыерчык баласы да түгел, үзенә күрә бер аерым кошчык иде. Ул күз күреме биеклегендә күкләр белән хозурланып әйләнде-тулганды да, кинәт югарыга: аккош каурые сыман ак болытларга таба күтәрелә башлады. Күренеп тора: ул иксез-чиксез зәңгәр күк белән хозурланып туя алмый иде...

*Казан, 2005 ел.*



Шамил
Маннапов

# ҖАНЫМНЫҢ ТЫЮЛЫГЫ

## Җитте вакыт...

**Гаҗәп инде:
Ничек үскәнбездер
Дәрдемәндсез, Исхакыйларсыз?
Тукай яшьли үлгән,
Юкса, бәлки,
Калган булыр идек Тукайсыз...
Ә Тукайсыз тору—Айсыз тору,
Айдан башка җаннар карала.
Ярымайлы булган өчен генә
Киселгән бит күпме манара!**

**Шул айларны Тукай алыштырган,
Якты сирпеп безнең күңелгә...
(Нурларының ләкин догалысын
Тоткан Иблис яшереп үзендә.**

**Иблискә бит—адашканнар юлдаш,
Адашканның җанына хуҗа ул.
«Тукай—атеист!»—дип,
Шагыйрьне дә
Үзенә юлдаш итмәк булган ул.)**

**Тик нурларны яшереп, караңгыда
Мөмкинмени тоту һаман да?!
Саркып чыкты нурлар дөньябызга,
Дәва булып безнең җаннарга.**

**И Туган тел,
Синдә булган ласа
Тукай кылган изге догалар.
Җитте вакыт:
Безгә дә Ходайдан
«Ярлыкагыл...»— диеп сорарга...**

Шамил МАННАПОВ (1938)—*шагыйрь; "Тамырлар", "Кайту" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Хак юл эзләү

Борын заманнарда пәйгамбәрләр
Юнәлткәннәр кешене Хак юлга...
Пәйгамбәрләр заманасы узган,
Ничек тайпылмаска туры юлдан
Җир өстендә, күкләр астында?

Астрологлар, жрец, багучылар
Юраган юш килә кайчакны;
Мәгәр алар сүзе хәтерләтә
Сукыр кулындагы таякны...

Алга таба гранит кулын сузып,
«Юл күрсәткән" күпме даһилар.
Инде шул юлларда адашканнар
Чыгу җаен таба алмыйлар.

Акыллы баш сәясәтчеләр дә
Бәхәсләшеп юлны эзлиләр.
Берсе уңга, берсе сулга тарта,
Ә халыклар
Кайсын сайларга да белмиләр.

Кемнәр күрсәтер соң дөрес юлны,
Ялгышмыйча алга барырга?
Иңемдәге фәрештәме шунда
Пышылдады: "Шагыйрьләрен Ходай
Тудырды бит—вәхи алырга...
Һәм рәсүлдән Изге Китап калды:
Таныганнар укып баксыннар.
Күңел күзе сукыр булмаганнар
Тайпылмаска тиеш Хак юлдан..."

## Мин бит затлы бер алмагач идем...

Мин бит затлы бер алмагач идем,
Алмаларның биреп татлысын,
Кешеләр, сезне сыйламакчы идем,—
Җимешләрем нигә ачы соң?

Тормыш бакчасында ни җитмәде?—
Тәрбияләү, карау җитмәде.
Ә шулай да җимеш биргән чакта
Күпләр мине урап үтмәде.

Ачырак һәм ваграк булсалар да,
Җимешләрем алар яратты.
Татлысы да аның, ачысы да
Бу дөньяга бердәй ярашлы.

Мин хуҗасыз калган бакчаныкы,
Зарланырга ләкин соң инде.
Җимешемне җыйган узгынчылар
Ботарлады мине, сындырды...

Кыргый алмагачка әйләндем мин,
Ачы язмышыма түземле.
Күзен койган яфракларым белән
Тамырларым ашлыйм үземнең.

Ә кемнәрдер хәзер йөзен чытып,
«Җимешләре ачы...»—димешләр.
Белмиләрме, нинди булсалар да,
Болар—безнең уртак җимешләр.

Ботакларым ботарласалар да,
Тамырларым, шөкер, сау әле:
Ачырак һәм ваграк булсалар да,
Җимеш бирер җаем бар әле.

* * *

Яңа сүзләр керде телебезгә:
«Цинк табут», «Бетон саркофаг"...
Тел галимнәренең әйтүенчә,
"Мондый сүзләр тагын артачак."

Фиргавеннең тәнен мумияләп,
Саклаганнар, күр, дип, тыйб* көчен.
Без дә тердек бетон саркофагка
Чернобыльнең атом гыйфритен.

Ул үлмәгән, яраланган гына,
Әҗәл үзе шүрли аңардан.
Бетон табутында ул үзе бит
Үлем чәчеп ята, кадалган!

Җирне тетрәндергән бу фаҗига
Чираттагы гыйбрәт Ходайдан:
«Атом җенен бәйдән җибәрдегез,
Сакланыгыз инде сез аннан.
Юкса, Хиросима, Нагасаки
Гыйбрәтләрен күргән идегез.
Сак булыгыз,
Тоташ саркофагка
Әйләнмәсен газиз Җиребез ! . .»

Сүз—беренчел, диләр,
Инде хәзер
Сүзме, гамәл микән—белмәссең.
Мәгәр шундый теләк күңелебездә:
Яңа сүзләр керсә-керсен телгә,
Яман сүзләр берүк кермәсен...

## Җәбраил китергән вәхи сыман...

Ишекләрдә безнең кат-кат йозак,
Дөнья бабаң шулай өйрәтте.
Бәреп керер карак-угрылар бар,
Биреп тора шулар гыйбрәтне.

*Тыйб—медицина.

**Ишегемне бикләү—түгел ләкин**
**Угрылардан гына куркудан,**
**Алардан да яманраклары бар,**
**Җаныма да шуңа бик куям.**
**Кермәсеннәр, димен, күңелемә**
**Шайтан шомлыклары:**
**Гайбәтләр,**
**Яла сүзләр, төрле бәла-каза,**
**Имансызлык, яман гадәтләр...**

**Тик алардан котылу юк икән**
**Йозак куеп кына ишеккә,**
**Килеп керә гөнаһ шомлыклары**
**Әллә кайсы ярык-тишектән.**
**Торагыңа керә, колагыңа,**
**Колак аша бәрә йөрәккә!**
**«Әй, Ходаем, үзең ярдәм бир...»—дип,**
**Карашымны Күккә юнәлтәм.**

**Җәбраил китергән вәхи сыман**
**Аваз ишетәм күк:**
**“И бәндә,**
**Сизмисеңме, Илгә Иман кайта**
**Шайтаннарның юлын буләргә...»**

* * *

**Әйа, Дөнья, холкың яман икән,**
**Син түгелме үзеңә гашыйк иткән,**
**Соңра уттан алып суга салган,**
**Яратуың булдымыни ялган?**

**Җавап бирде Дөнья:**
**“Адәм, тыңла,**
**Синең белән җиңел димсең миңа?**
**Кыенлыклар безнең уртак, җаным,**
**Шулай булуы мәгәр әйбәт аның.**
**Гомер юлың булса шома гына,**
**Барып җиткәч аның азагына,**
**Мине ничек ташлап китәрсең,—**
**Үлем бар бит, ни хәл итәсең...**
**Дөньялыкта гел рәхәттә торсаң,**
**Дөнья белән булсаң гел тату,**
**Бакыйлыкка күчеп киткән чакта**
**Күп мәртәбә**
**Кыен булыр иде хушлашу...**

**Бер-берләрен артык яратканнар**
**Күбрәк яра ясый бәгырьгә.**
**Битарафтан гына берни дә юк,—**
**Рәхәт күрсәтү дә,**
**Җәбер дә...”**

## Җанымның тыюлыгы

Бу дөньяның оҗмах кебек
шундый бер җирен беләм,
анда бар да саф көенчә,
берни дә керләнмәгән.

Адәм аягы басмаган
болыны—чәчкә тулы,
чытырманлы карурманын
яңрата кошлар хоры.

Яшьлек ярым күзләредәй,
зәңгәр-зәңгәр күлләре.
Камыш-керфекләр пышылдый
«Сөям...»—дигән сүзләрне.

Анда искән йомшак җилләр—
әнкәемнең назлары,
анда картаюны белми
шаулы яшьлек язларым.

Анда минем ялантәпи,
коеп чирәм чыкларын,
балачагым иртәсендә
көтү куган чакларым.

Башакларын җиргә иеп,
тынганнар арышларым.
Алар хәтерлиләр, бугай,
югалту сагышларым.

Дөньяның бу почмагында
Терек сулы елгалар.
Анда керә ала бары
Күңеле саф булганнар...

Үземнең дә анда атларга,
табигыйлеген таптарга
һич җитми кыюлыгым:
Бу бит—гомергә саклаган
үз җаным тыюлыгы...

* * *

Васыятьнамә яза кемнәрдер,
Малы бардыр, димәк, җитәрлек.
Ә мин андый мәшәкатьтән азат—
Байлыгым юк мирас итәрлек.

Васыять язмасам да, сезгә калыр
Җан җырларым—күңел байлыгым.
Язылмаганнарын калдыралмам,
Үзем белән бергә алырмын...

Сезгә калыр сандугачлы таңнар,
Кояшлы көн, айлы төн яме.
Бабайлардан калган туган җирне,
Васыятьнамә язмый-нитми генә,
Исәннәргә мирас итәмен...

Альберт
Хәсәнов

# ҖӘНБӘТ ЫРУЫ

ПОВЕСТЬ

## Беренче китабым

Беренче китабын—беренче балаң кебек—бик кадерле була икән ул. Беренче китабым «Озын аяк»ны чыгарырга дустым Шамил абый Бикчурин бик булышты. Бу егетне Ибраһим абый да бик ярата иде. Ул аны «Турыга үскән жиз кадак» дип йөртә иде. Шамил абыйның озын буйлы вә жиз төсендәге чәчләре өчендер. Шамил абый ач борчак кузагы төсле юка, ә мин биш көн җылы суда торткан фасоль борчагы төсле йомры. Әкъли белән Чакли инде. Бик тату, бик дус яшәдек без аның белән. Гаять талантлы кеше иде ул. Язучылык хезмәтенең бик нечкә серләрен чишге ул миңа. Бер тәлинкәдән ашаган, һәрчак берәр хәтәр эзләп кенә йөргән тиле башларыбызны бер мендәргә салып йоклаган төннәребез дә күп булды. Бикчи дустым мине үзенә ияртеп Хисам абый Камалга алып барды. 1966 нчы ел инде бу. Хисам абый—Татарстан китап нәшриятында яшьләр-балалар редакциясе башлыгы. Казанда транспорт ягы мәңге-мәңге катлаулы. Метро чын куәтенә сафка баскач, бераз рәтләнерме-юкмы?

Хисам абый сыңар аягы белән кичен өенә кайтып йөри алмый. Трамвай-автобуска әле ике аягың белән дә керешле түгел. Обком кушуы буенча, аңа нәшрият каршында гына бер бүлмәле фатир биргәннәр. Нәшриятның байтак эшләрен, үз вазыйфаларын ул күп чакны шушы фатирыннан торып кына башкара. Авторлар белән дә эшли.

Хисам абый белән Шамил Бикчи—күптәнге ахириләр. Ул бит Шамил абый кебек үк—Әлмәт районыннан. Болар өстенә, аның Лениногорскида бертуган сеңлесе дә бар. Жәен туган якларына кунакка кайткач, безгә дә килә. Аның кайтуы Шамил абый белән миңа зур бәйрәм була. Машинасын парткомнардан алабыз. Без аны үзе теләгән жирләргә, буровойларга, промыселларга алып барабыз. Шул ягы да әйбәт, ул безнең кесәдән бер тиен дә чыгартмый. Алай гынамы?! Шамил абый белән икебезне һәр кичне «Урал» ресторанына алып керә. Бикчиның, жил тегермәне хәтле канатларын як-якка жәеп, изәп-изәп сөйләгәнен сәгатьләр буе тынлап утыра. Йөзеннән елмаю китми.

—Бикчинең сөйләгәннәре бары да дөресме соң?—дип миннән сорап куя әле.

—Булмыйча! Үзем шаһит!—дип куәтлим.

Казанга бу килүебездә дә туп-туры Хисам абыйның Островскийдагы фатирына киттек.

—Ләбибә, монда кереп чык әле,—дип, ул нәшриятка шалтыратты, Ләбибә

*Ахыры. Башы журналыбызның 5 санында.*

апа Ихсанованы дәште. Ләбибә апа Хисам абый редакциясендә, аның кул астында эшли, редактор. Ләбибә апа тиз арада кереп тә житте.

—Шамил бик талантлы бер егет алып килгән. Менә үзе дә монда утыра. Шуның китабын быелгы ел планына керт тә җибәр,—диде.

—План расланган бит инде.

—Расланса, резервта урын бар бит. Резервтан җибәр.

Шуның белән, шалт Мөхәммәтҗан!—Мәсьәлә хәл ителде дә куйды. Ләбибә апа, матурым, байтак кына яшь авторларның беренче китапларын чыгаргандыр. Минем дә беренче китабымны чыгаруын онытkандыр. Әмма мин Ләбибә апаның юбилейларына телеграммалар сугам, күрешкәндә битеннән үбәм. Шушы хәлгә сәерсенеп, аптырап калучылар да була.

—Ләбибә апам, минем беренче китабымның редакторы!—дим мин аларга.

Аннан соң өч китабымны Мәхмүт абый Хөсәен чыгарды. Шулай ук дөнья бәясе егет иде. Гвардия майоры, тупчы. Аның редакциясеннән дә китапларымның ничек чыгып китүләрен сизми дә калдым. Башка кайбер редакторлар төсле авторның кәҗә маен сыкмый иде ул. Утыра да үзе эшли. Төзәтә. Коррективаларын кертә. Автор стилен дә саклый. Юкса, тәмам маемны сыккан редакторларга да эләккәләдем. Аларга да мең рәхмәт. Маемны бит китабым начар чыксын дип түгел, укучы аны кулына бер алгач, бер тында укып чыгарлык булсын, дип сыктылар. Гариф Ахуновның «Хәзинәсе» Татарстан китап нәшриятында 17 тапкыр кабат басылды. Зур тиражлар белән. Кемгә хаҗәт? Димәк, нәшриятка үз шигырьләре белән беренче тапкыр аяк баскан яшь талантлар «кәгазь җитмәгәнлектән» басылмый калдылар. Ә ул «хәзинә»—китапларны шул атнада ук «Камаз»ларга төяп «Утильсырье»га тапшыралар иде. Килештермәсәгез, ышанмасагыз, шул чорларда китап кибете директоры булып эшләгән ханымнардан сорагыз.

Бер җәйне, Мәхмүт абый һәм гаиләләребез белән Кырымда, украиннарча Коктейбель, Кырым татарлары телендә Күк Түбә дип аталучы иҗат йортында ял иттек. Мәхмүт абыйның белмәгән кешесе юк. Мине Булат Окуджава белән таныштырды. Аның гитарада уйнап, җырлавын тыңладык. Сугыш каһарманы, Советлар Союзы Герое, танкист Татьяна Левченко да безнең сменада ял итте. Кара дингездә хезмәт иткән бер су асты көймәсе коллективы Т. Левченконы үзләрендә чыгыш ясарга кунакка дәшкән. Безнең иҗат йорты «Голубой залив»та урнашкан. Моряклар су асты көймәләрен ярдан бер чакырымнар өстә туктатканнар. Ярга катер белән чыктылар. Мәхмүт абый—бик көчле трибун. Шигырьләрен дә яттан бик оста сөйли. Моряклар арасында үземә генә кыен булыр дип, Левченко үзе белән Мәхмүт абыйны да дәште. Мәхмүт абый мине дә ияртте. Ул заманда су асты көймәсенә эләгү өчен Мәскәүнең үзеннән рөхсәт кирәк иде. Ә Татьяна Левченко Советлар Союзы Герое, Мәхмүт абый сугыш ветераны, гвардия майоры. Ә минем белән «вакланып» та тормадылар. Бик матур, бик күңелле чыгыш булды ул. Соңыннан безгә армейски йөз грамм бирделәр, украин борщы белән сыйладылар. «Командирские» дигән, циферблатлары төнлә дә янып торган кул сәгатьләре бүләк иттеләр.

Шулай бер кичне, дингез ярында учак ягып утырганда, Мәхмүт абыйга урыс шагыйрьләре төрттерә башладылар:

—Махмут, какой ты поэт? Вот сочини нам тут же двоестишие, скажем, про... буи, что качаются на волне.

—Вот в море лежат, на волне качаются, буи, похожие на русские... уи!—дип шундук әйтеп тә салды.

Аһ, итәрлек шигырь юллары түгелләр, әмма шундый чакта югалып калмавы исне китәрә Мәхмүт абыйның. Иҗат йортыннан без аның белән нык дуслашып кайттык. Кызык, кешегә ярдәмчел, колоритлы егет заты иде.

Хәзер уйлап-уйлап куям да, карале, язмыш мине нинди олуг затлар, әдәпле,

ярдәмчел кешеләр белән таныштырган, эш йөрттергән икән, дип сокланам, сөенәм. Кызганыч ки, күбесе юк инде дөньяда. Берәм-берәм әлеге, моржасыннан төтен чыкмый торган, тәрәзәсез, ишексез йортка күчеп баралар. Алар адресына әйткән җылы сүзләрем якты рухларына изге догалар булып инсеннәрие!

* * *

Мин бит әле һаман да берлек әгъзасы түгел. Ибраһим ага исән булса, аның «шома егете» булып шалт кына кереп китә идем дә... Ул көтмәгәндә генә йөрәге тотып, вафат булып куйды. Минем заманда союзга керү өчен ике китап авторы булу кирәк иде. Бер карасаң, әллә ни кыен шарт та түгел. Әмма бу шартның төбендә бик мәкерле бер хәйлә ята. Китабымны чыгарыгыз әле, дип нәшрият каршына бару өчен, Берлек әгъзасы булу кирәк. Чөнки син—профессиональ язучы. Ә әгъза булу өчен кимендә ике китап чыгаруың шарт. Койрыгын алса, томшыгы ябыша, томшыгын куптарса, коерыгы ябыша. Ләкин мине ике китабым чыгу белән генә Берлеккә якын да китермәделәр. Алты китап чыгаргач кына алдылар. Берлеккә керү өчен, иҗатлары алдында син баш игән, һәм алар да сине таныган өч язучыдан җылы гына рекомендация кирәк. Аларын гына мин дә юнәткәнием. Алмадылар. Аннары мин сигез рекомендация китердем. Соныннан уникегә җиткердем. Мина рекомендация бирүчеләр арасыннан Г. Минский, Б Камалов, Р. Төхфәтуллин, Х. Сарьян, Х. Камал, Г. Әпсәләмов, Р. Фәйзуллин, А. Расих, Х. Туфан исемнәрен бүген дә тирән ихтирам хисе белән искә алам.

Берлеккә керергә беренче омтылыш ясаганда алмауларының сәбәбе мондый булган. Рекомендацияне беренче булып мина Габдрахман ага Минский язды. Дөньяга обьектив карашлы, бик күркәм кеше иде ул. «Казан утларын»да басылган хикәяләремне укыган да:

—Нишләп читләтеп кенә йөрисең? Әйдә, Союзга керергә әзерлән. Рекомендацияне үзем бирәм,—диде. Ул чакта Кабул итү комиссиясенең рәисе Фатыйх ага Хөсни иде. Аларның арасына кара мәче йөгергән чак булган икән. Берлеккә Габдрахман ага Минский тәкъдим иткән егетне алсалар, аның төркеме көчәя төшә бит. Стоп! Ашыкмасын әле. Фатыйх абый мина отказ бирдерә. Минем кем икәнне белеп җиткермәгән ахры, картлач. Минем тел бит—бләүләгән пәке, бритва. Тормышта «янсам» да, шул телем аркасында гына «яндым» инде. Әле хәзер дә, урамга-мазар гына чыкканда да, Мәдинәм-Гөлкәем, мина таныклык—кенәгәңне алдыңмы, дими, авызыңны кләйле лента белән ябыштырып чык, зинһар, ди. Югыйсә, бер чыгуда урамнан биш дошман табып керәсең, ди. Әлбәттә, начар галәт.

Ул чагында, жай килгәндә, Фатыйх абыйны да «чукып» кына торам.

—Гариф абый Ахунга ярарга тырышып, бик җитди әдәби җыеннарда, проблемалар күтәрәсе урынга, гел буш сүзләр сөйлисең, публиканың башын төрле уен-көлке белән катырасың,—дип тә «чукып» алганым булды.

Ярты взводка торырлык күренекле язучыларыбыздан рекомендацияләр китергәч, Берлеккә мине барыбер алдылар. Кабул итү комиссиясе рәисе урыны да—атаңнан калган мирас, патшалык түгел. Аны да корылтай саен алыштырып торалар. Кулында власть барында гаделсезрәк кылануыннан Фатыйх ага да минем алда унайсызлана төсле. Кеше дигәнең олыгая барган саен йомшагракка әйләнә, авыр сүзне дә кичерә, читкә тайпылып, ашыгучыга юл куя. Яшьләр исә кечкенә генә җәберне дә онытмый, аларга гафу итү хисе дә ят. Мин дә, Фатыйх абыйны күрү белән, йоннарымны кәпертәм. Бу үпкәне күпмегә сузарга була, нимаешь? Әдәби ел йомгакларының берсеннән соң, нәшрият баскычыннан төшкәндә, Фатыйх абый минем җиңемнән тотты.

—Альберт, энем, синнән йөз сум, миннән йөз сум. Брудершафт ясыйбыз.

Киттек «Кызыл шәрыкъ» ресторанына. Канса да канис, безгә аңлашырга кирәктер бит инде,—диде ул. Шап иттереп аркама да сугып куйды. Мин ике куллап риза булдым. Фатыйх абыйны култыклап алдым. Киттек. Анда бик күңелле итеп утырганнан соң, Фатыйх абый мине үзенә алып кайтып китте. Бу вакытта аның үз җәмәгате мәрхүмә иде. Нәшриятта дүртенче катта, машинистка булып, тутырган тавык төсле тулы гәүдәле бик матур ханым, Әминә апа эшли иде. Аңа минем дә хикәяләр, повестьлар бастырганым булды. Хатыны мәрхүмә булгач, Фатыйх абый шул Әминә апага өйләнгәние. Мине ияртеп кайтканга Әминә апаның әлләни исе китмәде. Әмма соңыннан Фатыйх абый нык үкенгәндер. Китә белмичә, мин аларның тәмам тәкатен корыттым бугай. Ул көннәрдә футбол буенча дөнья чемпионаты бара иде. Без Фатыйх абый белән иртәнге өчкә-дүрткә кадәр матч карыйбыз. Берсе артыннан икенчесен күрсәтәләр. Аннары көндезге уникегә хәтле йоклыйбыз. Илләдә нык коры закон игълан ителгән чор бу. Ак башлы яртыны талон буенча гына бирәләр. Фатыйх абыйлар торган йортның аскы катында—гастроном. Аның директоры—безнең Биектау егете Мидхәт. Танышып та өлгердек.

—Мидхәт энем, бик кадерле кунагым бар иде бит. Бер коньяк бирә күр,— дип, Фатыйх абый записка яза. Мин аскы катка төшеп китәм.

—Кадерле кунак, син әле китмәдеңмени?—дип каршылый мине Мидхәт. Алай да шкафыннан бер коньяк чыгарып бирә. Әминә апа безгә бәрәңге кыздыра. Шул коньяк белән, кыздырган бәрәңгене кетер-кетер китереп башны төзәтәбез дә, янәдән матч карарга керешәбез. Өч кич кундым мин аларда.

—Әйдә, синең белән күңелле икән. Тагын бер генә матч карыйк инде,— дип Фатыйх абый мине үзе җибәрми. Әмма Казан халкында бәрәңге санаулы гына була. Бәрәңге запасларына тәмам корт төшердем бугай мин аларның. Аның каравы, тәмам аңлаштык! Бер-беребезгә мыскал да үпкәбез калмады.

Шәҗәрәмә кагылышлы бу әсәремне кече оныгым Бикташирдан башлаганыем бит. Ходайның рәхмәтедер инде, әлегә «Әннә», «Мәммәм» дип тә әйтә алмаган башы белән, ике сүзенең берендә «дәти, дәти!» дип кабатлый. «Дәү әтием!»—дип әйтергә маташуы бит шук малайның. Хәер, шулай булырга тиеш тә! Шушы сүзнең иң тулы мәгънәсендә ахирилләр бит без аның белән.

Шушы тулы гәүдәле, матур малайны кочагыма алам да, янә тирән уйларга чумам. «И-и, Раббым»,—дип куям. Мине дә шулай сөйгәннәрдер инде. Күп кешеләр кулында булсам да, аларның барчасы алдында да бурычлы бит мин. Нинди авыр, кырыс елларда исән калганмын. Күзем дә исән, колагым да акмаган. Ачлы-туклы яшәүдән күтәнем дә төшмәде. Югыйсә, андый яшьтиләремне дә күп күрдем.

Әйе, әтине хатынлы иттем, үзем әниле булдым. «Әти кәкәй!» дип әйтеп кенә кара, хәзер авызына шапылдаталар. Бер-ике тапкыр ярыйсы гына элэкте дә, иренем дә шешеп чыкты. Үзем тапкан Өммегөлсем әниемне мин үз әнием дип кабул итәргә тиеш. Больше никаких гвоздей! Мондый политика алып барырга әле соң түгел. Ул кадәресен үзем дә аңлый—төшенәм бугай. Үги әни нәрсә инде ул, ачуым да бер килмәгәе. Дөньяда үз әниең булсын! Өммегөлсем әнием—минем үз әнием. Бетте, китте и вәссәлам! Моны миннән дә бигрәк, әни үзе дә теләде бугай. Без аның белән бик тиз дуслашып, үз кешеләр булып киттек. Ул мине алдына алып сөя. Мондый чакларны минем түбәм күккә аша. Монарчы ана назы күргән баламы? Кечкенәдән үк үзсүзле, бер шыптый бала булганмындыр инде. Йә берәр нәрсәне аударам, йә өй ачкычын яшереп куям. Әти чын педагогика фәне белән бөтенләй таныш түгел. Югыйсә, директор үзе. Берни булса, миңа берәрне сыптырырга гына тора. Әни бирми, кочагына ала, йә итәк астына яшерә.

Әти ни кырыс торса да, ара-тирә Габдрахман бабам да килеп чыга. Аның гозере бер инде, әтидән мине сорый.

—Гаделбарый, әнә, яшь катыныңнан бала-чаганы өй тутырып табарсыз, Әлбиртебезне бир мина,—дип ялынып, ялварып сорый. Бер кызы—Мәрьям апам, Мәскәүдә кечкенә кибет тоткач, алтын алка, беләзек-йөзек белән сәүдә иткәч, бабам да авылда урта хәллеләрдән саналган.

—Габделбарый, иң яраткан киявем иден бит. Бир мина Әлбиртне, башка кешем юк, бар йорт-жиремне, мал-мөлкәтемне ана калдырам. Игелеген бергәләп күрерсез,—дип ялвара. Аның елый-елый ялваруын мин дә күреп торам, килеп башыннан сыйпыйм, сакалын сыпырам. Мине хәзер аның кулына сөяргә дә бирмәскә, янына да жибәрмәскә тырышалар. Кече Кавалда әбием-бабаем барын мин бөтенләй онытырга тиеш икәнмен. Әтиемнең, үз әнием Шәрәфелбанатның әтисе Габдрахман бабамны, бүтән киләсе булма, гаиләмне бутап йөрмә, күземә дә күренмә, дип куып чыгарган чаклары да булды. Өммегөлсем әнием, алай да, бабамны почмак якка гына дәшеп, чәй эчертә, әбиемә күчтәнәч итеп, чәй-шикәр төргән төенчек тә тоттыра иде.

Әтиемне һич кенә дә танылган сәүдәгәр Әбү-Бәкер агасына ияреп, бөтен шәрекъ илләрен йөреп чыккан, аш тәмләткеч товарлар төягән кәрваннарны ком чүлләре аша куган, күп телләрдә сөйләшкән, Казанның Проломный урамында пайлар белән кибет тоткан өлкән приказчик Хәсән бабамның улы димәссең. Кеше дигәнең, һай ничек үзгәрә! Ул—гамәлдәге системаның үз баласы. Система аның миен үз идеологиясе белән мөлдерәмә итеп сугарган. Әйе, аның яраткан жыры да:

Итек, шинель, фуражканы
Без киябез бит аны.
Яшәсен совет власте,
Без сөябез бит аны,—булырые.

Системаның төпле ышанычлысы иде ул. Теләнә килгәнне сөйләде, бернидән куркып тормады. Пышылдап кына сөйләшкән чагы булмады. 1937, 1947, 1952 нче үтә кырыс репрессия елларында да аңа ник берәрсе кырын карасын! КПССның Дөбъяз райкомы пленумнарында кайчак бик кискен чыгышлар ясаган чаклары да булды. Залдагылар исә, аның чыгышларын, партия халыкка дөресен ярып салырга тиеш, дип кул чабып кабул итәләр иде. Алай да, инде Ватан сугышыннан соң, язмыш аны, корулы мылтыгын прәме маңгаена терәп, бик нык сынап алды. Өлешенә тигән көмешеннән авыз итми булмый икән ул. Хәер, болары турында соңрак сөйләрмен.

## Әнигә яучылар килде...

1942 елның язы иде. Әти беркөнне:

—Броньне алдылар. Үзебезнең Дөбъяз районы егетләреннән тагын бер полкмы, батальонмы туплыйлар. Мине шунда комиссар итеп билгеләделәр,—дип кайтты.—Әнисе, син миңа юл капчыгы жый, бераз сохари, бер пар жылы оекбаш тык.

Әнинең кулында—елак сеңлем Гөлкәй. Әнвәр абый Казанга барып, хәрби заводта токарь өйрәнчеге булып эшләргә урнашып кайтты. Башына яңа бүрек кигән. Өстендә—зәңгәр бушлат. Билен каеш белән буган. Аягындагы калын олтанлы ботинкасыннан бик тәмле булып ачы дегет исе килә.

—Син анда, энем, дөнья хәлен белеп булмый, минекеләрне ташлап бетермә, ни дисәң дә, син—егет кеше,—дип озатты аны әти Казанга. Әнвәр абый чыннан да егет булып житлегүен раслап, кесәсеннән «Прибой» папиросы чыгарды. Аны кабызды. Берне әтигә дә сузды. Башка чак булса, әти аның кирәген биргән булыр иде. Хәзер исә папироска иртә үрелгән энесенә акыл биреп торыр чакмы?

—Энем, иртәгә мин дә фронтка чыгып китәм. Әллә кайтам, әллә юк... Кайтмасам, жиңгәнә балаларны үстереш. Бер үзенә генә кыен булыр,—диде.

—Авыл советы Айсылу белән сөйләшеп кайттым. Сезне өч атка төяп, Таш-Кавалга илтеп куячаклар—дип, әнигә дә сүз катты.—Сугыш әлләни озак бармас. Мин әйләнеп кайтканчы шунда торып торырсыз. Ризамы шуңа?

Риза гынамы соң? Таш-Кавал—Өммегөлсем әниемнең туган авылы. Анда аның үз йорт-жире белән әнисе Шәрифә әбием яшәп ята.

Шәрифә әбием гомере эчендә ундүрт бала тапкан. Шуларның икесе генә исән. Берсе—улы Шәйдулла абый, икенчесе—минем әнием Өммегөлсем. Шәйдулла абый әле өйләнергә дә өлгермәгән. Сугыш башлану белән аны фронтка алганнар. Шуннан аның бер хәбәре дә килмәде. Әбием аны соңгы сулышына кадәр көтте. Китап ачтырды да, китап яптырды. Сандыктан буй-буй зәңгәр сатин күлмәген ала. Ука белән чиккән камзулын кия. Бер генә таба төче коймак пешерә дә, аны каз мае белән майлап, югары очтагы багучы, китап ачучы Әсмакамал апайларга менеп китә. Шәйдулла абыйга китап ачтыра. Әсмакамал апай да бик хәйләкәр. Шәйдулла абый бәлкем сугышның беренче көннәрендә үк һәлак булгандыр. Бер хәбәре дә юк. Хәрби комиссариат та—ләм-мим.

Фал китабын ачып жибәрү белән:

—Шәйдуллаң исән бит, Шәрифәжамал. Беләсеңме, кайтырга жыена бит бу егет. Түлке нәрсәдер итәгенә чорналып тота балакайны. Жибәрми генә. Юкса, үзе бик талпынып та карый,—дип сүзен сүзгә укый Әсмакамал апай. Дипломат булгандыр ул. Беренчедән, әбиемнең өметен сүндерәсе килмәгәндер... Икенчедән, «Улыңны көтмә инде. Шәйдуллаң һәлак булган»,—дисә, әбием аңа төче коймак тыгып, бүтән менми бит инде. Багучы апайның дипломат булмый хәле юк. Бу кадәресе инде сугыш бетеп, байтак еллар узганнан соңгы хәлләр. Әсмакамал апайның шушы сүзләреннән соң әбиемнең йөзе ачылып китә. Бик матур карчык иде ул. Дөньяда мин эчкерсез ярату белән яраткан затларның берсе иде.

—Әсмакамал, әйтеп кенә бетермисеңдер. Берәр маржага өйләнгәндер ул. Йә йортка кергәндер. Мимеч жирендә калгандыр. Ул мимеч маржаларын бик чибәр диләр бит. Шул маржасы жибәрми торгандыр. Әйтеп бетер барын да!—дип, әби Әсмакамал апайдан Фал китабында ачылганнарның барын да укып бетерергә куша.

Шәрифә әбием бик булган, бик унган, бик зирәк акыллы карчык иде. «Әбием ядкәре» дигән, соңыннан «Дружба народов» журналында «Несказанный свет» исеме белән басылган повестемда аның кабатланмас образын иркенләп бирдем. Повесть журналның премиясенә лаек булды. Журналның ул чактагы баш редакторы, күренекле шагыйрь Сергей Баруздин аның хакында: «Один из талантливейших вещей литературного года»—дип язганые. Ул, гомумән, татарларны бик ярата иде. Шоферы да—татар егете. Житмәсә, чыгышы белән безнең Лениногорск районы Бәкер авылыннан. Мин Мәскәүгә китап чыгарырга килгән чакларны Сергей Алексеевич миңа:

—Альберт, моя «Волга» в твоем распоряжении,—дип әйтер иде. Мәскәүгә килгән кеше күбрәк жир астында, метрода йөри бит. Берни күрми. Ә Мәскәүдә үз күзең белән күрергә кирәкле тарихи урыннар санап чыккысыз. Сергей Баруздинның шоферы Исмәгыйль белән без Мәскәү урамнарын айкыйбыз гына. Сергей Алексеевич ул чакта—СССР Верховный Совет депутаты. Шул хокук белән ул мине иң дәрәжәле «Москва», «Россия» кунакханәләренә урнаштыра, кайтканда поездга билет алып бирә. Минем дә аңа нинди дә булса яхшылык эшлисем килә. Ул моны сизә. Танылган шагыйрьгә, СССР Верховный Советы депутатына нәрсә эшли алам инде мин?!

—С тебя, дорогой, я требую только одно. Принеси в мой журнал еще и

еще такие же талантливые произведения,—дип, аркамнан кага.

Сүзем сугыш чорында калган иде бит. Мәктәптә укыткан әнине район мәгариф бүлегенә инспектор итеп куйдылар. Сугыш бара дип кенә бер бала да мәктәптән читтә калмасын дип, ул район авыллары буйлап чаба башлады. Әбием белән икәүләп без аңа чабата ясап өлгертә алмыйбыз. Бер кием чабата аңа бер әйләнеп кайтуга да түзми.

Сугыш башлануга ике-өч ай да узмагандыр, йорт-җирләре безнең бакча артында гына булган Шап-Шап Шакирның улы озын Вәлиәхмәт абый, уң кулын янбашыннан ук өздереп, фронттан кайтып төште. Үзе болай җил тегермәне буйлы егет. Алар яшьлекләрендә минем Өммегөлсем әнием белән бераз йөргән булганнар. Йөргәннәр дип, бер очта яшәгәч, күрше егете Вәлиәхмәт абый, әнине бер-ике тапкыр кичке уеннан озата кайткандыр инде. Вәлиәхмәт абый әле өйләнмәгән. Аны, бер кулсыз килеш сугышка да бүтән алмаячаклар. Ә минем әни, әти фронтка киткәч, мин үгиен ияртеп, сеңлем Гөлкәй белән, Таш Кавалга, әнисе йортына кайтып төште. Әти фронтта, хатхәбәре дә юк. Әллә кайта, әллә күптән инде батырларча һәлак булган? Менә, малай, әнине, яшьли йөргән егете Вәлиәхмәт абыйга димли башладылар. Бу никахка мин дә, сеңлем Гөлкәй дә, әлләни комачаулык итмәскә тиеш. Сеңлем Гөлкәй—чирләшкә. Менә-менә үлеп куюы бар. Ә мине—Казанга, детдомга!

Көннәрдән беркөнне Вәлиәхмәт абыйлардан яучылар менде. Вәлиәхмәт абыйның апасы белән ике сеңлесе, әнине яшь чагындагы мәхәббәтенә кыстапкыстап димлиләр. Бишектәге авыру сеңлем, бүген булмаса, иртәгә үләсе. Ә мине Казанга озатырга киңәш итәләр. Кирәксә, үзебез булышабыз, диләр.

—Бу маңка малайның әтисе коммунист бит. Ә комунистларның ятимнәрен Казанда җыялар икән. Ач та, ялангач та булмас. Аларны анда әйбәт ашаталар, җылы кием дә бирәләр икән,—диләр. Миннән дә котылгач, әни бөтенләй иркле каласы икән. Вәлиәхмәт абыйның бер сеңлесе—авыл советында секретарь, икенчесе—салым җыю инспекторы.

Беркөнне болар мине туп-турыдан Казанга озатырга кирәкле кәгазьләрне үк тотып килеп керделәр. Ул детдом дигән җирнең мин нәрсә икәнен дә белмим. Казанда да булганым юк. Әмма мине коточкыч бер җиргә озатырга йөрүләрен сизәм. Әни дә өйдә юк ичмасам. Кайчакларны ул берәр атна йөреп кайта. Түр яктагы зур сәке астына кереп постым болардан. Аннары күз күрер тагын.

—Юк эш белән йөрисез, кызларым,—дип каршылады аларны әбием. Алар өчесе дә сәкедә утыралар. Мин сәке астында тынлап ятам.

—Әйе, дөрес әйтәсез, бер сынык ипигә җаның сатышлы. Юк чак. Иллә ачлык. Әмма мин бу малайны беркемгә дә бирмим. Сугыш кырында монарчы күрелмәгән кан коеш бара. Әнә, хат ташучы Расфирә похоронкаларны авылга ташып кына тора. Ир заты кырыла. Сугыштан соң ирләрнең бәясе баш бәясе генә тормас. Ә бу малай бүген үк пычкы башы тота. Ике-өч елдан бөтенләй кул арасына керәчәк. Ундүрт бала тапканымны искә алып, картлык көнемдә Ходай аны миңа бүләк итеп биргән. Игелеген күр, дип. Җүләрләр сез. Бүгеннән кул арасына керергә торган ир затын ятларга бирәмме соң? Үзем ачтан үлсәм-үләм, бу малайны гына үстерәм инде. Ир-ат заты булган нигезгә пәри-җен, шайтан ияләшми, мал куна.

—Бу коммунист малаеның ир-атлыгын әйтер идем инде, Шәрифә абыстай,—диде кызларның берсе. Мин аста барысын да ишетеп ятам. Әбием авызыннан мондый сүзләр чыккач, җан керде миңа. Суган салган кәрҗиннәрне, шомырт-миләш, балан тутырган чүлмәкләрне аударып чыктым сәке астыннан. Карга Әминәсенең ботын тешләп умыруымны бөтен Таш Кавал белә. Сәке астыннан пәрәвез челтәрләренә уралып чыктым, тешләремне ямьсез чытырдатып куйдым.

—Апа, бу азгын малайның бик ямьсез тешләшә торган гадәте бар. Беләгеннән каптырмасын,—дип, кызлар берсен-берсе кисәтеп, тизрәк чыгып ычкыну ягын карадылар. Әбием дә күз кысып алды. Тешләремне шытырдатып, өстәвенә һау-һау дип өреп, кызларны капка төбенә хәтле озата бардым. Берсенең юри генә итәгеннән эләктереп тарттым. Шыр-шыр кычкырып качтылар кызлар.

Ашыйсы ризыгы бетмәсә, адәм баласы хәлләнә икән. Сеңлем Гөлкәй дә күзгә күренеп тернәкләнә башлады.

### «Эчке этләр министры»

Ошбу җиһанда яшәгәч, тереклек иткәч, һәркемнең тормышында үзенә бер куанычы, сөенече, мактанычы һәм дә горурлыгы буладыр инде ул. Ә минем куанычым, мактанычым, горурлыгым этием булды. Мин аны бүген дә, үзем оныкларымның дәү этие булгач та, өзелеп сагынам. Исән булсамы әгәр?! Өрмәгән җиргә дә утыртмый, учымда гына кадерләп йөртер идем. Һай, матур да, үзенә бер сөйкемле егет иде ул. Ә тормыш аны күп тапкырлар бөгеп-бөгеп китереп сынады. Әмма ул бирешмәде. Һаман да матур, сөйкемле булып, үзе яшәгән дөньяны бизәүче кеше булып калды. Ирекле холкы, төпле фикере, мәрхәмәтле, шәфкатьле, һәркемгә ярдәмчел йөрәге белән!

Заманында әти Дөбъяз халкына нык ярдәм итте. Кемнең малаен ФЗО мәктәбеннән калдыртты, кемнекен төрмәдән юллап алды. Ялгыз карчыкларның улларын армиядән кайтартты. Грамоталы да булгач, зур урында да эшләгәч, бар халык кайгы-хәсрәте белән безгә килә иде. Килгән кеше идәнеңне таптый, кем килсә дә, булганын өстәлгә чыгарып, чәй куймый да хәлең юк. Әни бик еш кына аны әрли дә торган иде югыйсә. Хәер, кемнең хатыны иреннән канәгать? Кайсы хатын иренең бар гамәлләрен хуплап, «җә»,—дип кенә тора? Анысына инде барыбыз да күнегеп киләбез. Иң яхшысы—алар белән булашмау, бер тоткан юлыңнан атыңны куалау.

Әти искитмәле йомшак-мамык телле, җор телле иде. Ике сүзнең берендә калҗа-калҗа юмор, шаян сүз катыштырып җибәрә. Һәр гаиләдә була торгандыр инде ул, атаң-анаңның яшәү рәвешләренә дә, сөйләмнәренә дә әзрәк тәнкыйть белән карыйсың бит. Алтынның кадерен базарга чыккач кына беләсең. Мин дә шулайрак идем. Әтинең никадәр уникаль булуын дөньяга чыккач, кат-кат төшендем.

Өйләребезгә көлеп, елмаеп, шаярып килеп керүче «Чаян» журналын байтак еллардан бирле Рәшит Зәкиев җитәкли. Рәшит Казан университетын тәмамлаганнан соң, юллама белән, безнең Дөбъяз районы «Колхозчы» газетасына, әти кул астында эшләргә кайтты. Мин ул чакта әле институтта укып йөрим. Әти аны үз улы кебек кабул итте. Мин кайчакларны хәтта алардан көнләшәм дә. Кара айгырны җигеп, тарантасның түренә утырып, икәүләп, авылларга чыгып китәләр. Аннан, рәхәтләнеп укый торган, матур, мамыклы тел белән язылган мәкаләләр пәйда була. Рәшитнең мәкаләләре аеруча җанлы чыга. Аларда әтинең йогынтысы да сизелә. Шуңа күрә мин хәтта бүген дә, Рәшит дустым белән күрешкән саен:

—Их, Рәшит, молодец егет тә булып чыктың бит. Әтинең бар тел байлыгын үзеңә йоктырдың бит,—дим.

Рәшит Зәкиев—Азнакай районы Тымытык авылыннан, муллалар нәселеннән. Төпле гаиләдән. Аның бертуган абыйлары да икешәр институт тәмамлаган егетләр.

Рәшит исә, «әтинең бар тел байлыгын үзеңә йоктырдың»,—дигәнгә, күзләрен хәйлә белән генә кысып, мыек астыннан матур гына елмая.—Барый

абыйда тел байлыгы мина да, сина да житәрлек иде. Сыкранма, синең дә кесәң буш түгел, язган бер әйбереннән Барый абый теле, сүзе, фикерләве сизелә,—ди. Һәрхәлдә, мона икебез дә шат.

Алдагы бүлектә мин, әтинең, Ватан сугышы башлангач, бер авыз сүз русча белмәгән, кулларына мылтык та тотып карамаган ярау гәүдәле район егетләренә комиссар булып, сугышка чыгып киткән жирендә туктаган идем. Аларны башта сугыш уеннары уйнатырга Суслонгерга жибәргәннәр. Анда эләккән бәхетсезләрнең ничек ачтан кырылулары турында белмәгән кеше юктыр. Әсәремнең бу урыннарын аеруча шәрехләп мена ни өчен язам. 1942 нче елның салкын кыш урталары бу. Сугышка алынасы яшьләрне утыз-кырык кеше туплыйлар да, Әлдермешләрне Алатка, Алат егетләрен Әлдермешкә илтеп, сугыш уеннарына өйрәтәләр. Русча бирелгән команда буенча ятырга, торырга, йөгерергә, шуышырга күнектерәләр. Аларны өйрәтүчеләр инде сугышта булып бер кат яраланырга өлгергән солдатлар булдымы икән соң? Әмма барысы да рәхимсезләр иде. Безнең Таш Кавалга да иллеләп егет китерделәр. Колхоз аларны ашата, кундыра. Шушы рәхимсез инструкторлар типсә тимер өзәрдәй, тегермән ташын тауга каршы тәгәрәтердәй егетләргә: «салома!», «сено!»—дип кычкырып торсалар да, тегеләре сафларда абынмыйча гына йөреп килә алмыйлар. «Скоты!»—дип кычкыралар аларга инструкторлар, кулларындагы шома чикләвек таяклар белән яралар гына бичараларны. Кай жирләренә туры килсә, шунда сугалар. Мин дә, биш яшь тирәләрендәге малай, күрше малайлары белән, көн буена шул бичаралар белән бергә. Артларыннан калмыйбыз. Шушы хәлне күреп, авыл халкы зар елый. Ә минем Шәрифә әбием, яшь рекрутларның жилкәсендә чикләвек таягын аеруча житез уйнаткан бер инструкторның кулын барып тотканые, теге урыс әбиемне сукты да очырды. Аның итәгенә мин барып ябышканыем, әлеге урыс мине күтәреп алып, айкап торып, кар көртенә тондырды. Чак муеным сынмады. Алай да, чикләвек таяк маңгаена туры килеп, башы тишелгән бер егетне, канын юып, башын бәйләргә әбием өйгә алып керде. Анисына рөхсәт бирделәр. Әбием беркатлы шул.

—И-и, балакаем, нигә шулай кыйнатасыз? Сез күп бит,—дип сөйләнә.

—Абыстай, мең рәхмәт инде сина. Кулларың нәкъ минем әниемнеке төсле йомшак, жылы икән,—дип, әлеге егет йотлыгып-йотлыгып бер касә кайнар чәй эчте.—Әлегә ярамый карышырга. Шундук трибуналга озатачаклар. Мена кулга корал алыйк әле, бу жәберләүләрнең, бу кыйнауларның барын да чыгарырбыз...

—Минем дә берданбер улым Шәйдулламны сугыш башлану белән алганнарые...—дип, әбием бу егетнең кесәсен чикләвек белән тутырды, лесникка дип хәстәрләп куйган тураган тәмәкесен бирде, иптәшләренне дә сыйла балам, дип куенына бер түгәрәк ипи тыкты.

Бер капчык сохари киптереп, ун стакан тәмәке туплап, Суслонгерда иза чиккән әти янына әни дә барып кайтты. Аннары аннан байтак кына хат килмичә торды. Кара көзлектә, шыбыр-шыбыр янгыр яуганда, капканы шакыдылар. Бу юлы аны әни чыгып ачты. Ир тавышы. Әти тавышы! Мин сикереп торып басканыем. Әни кереп:

—Ят! Тынынны чыгарасы булма!—диде. Теге ир дә шунын белән юк булды. Әти булган ул. Аны мунчада яшереп тотмакчы булганнар. Яшерерсең, бар! Таш Кавал халкының белмәгән нәрсәсе бармы соң анын? Әтиләрне Суслонгердан поездга төяп, Мәскәү юнәлешенә озатканнар. Мәскәүгә тәмам килеп житәрәк, алар составын немец самолетлары бомбага тотарга керешкән. Төн. Дөм-караңгы. Ә самолетлардан немец десантчылары коела. Ә боларда бернинди корал да юк. Бомбежкадан исән калган солдатлар урманга сибеләләр. Әти дә йөгерә. Составнын тетмәсен тетеп бетерәләр. Исән калганнарны

баштанаяк кораллланган десантчылар кыра. Әти ничек кирәк алай, үз бәхетеннәнме, балалары бәхетеннәнме, исән кала. Соңыннан кемгәдер күренгәндер, учетка-мазар баскандыр. Аны бер атнага гаиләсенә җибәргәннәр. Ә халыкка күренергә теләмәвенең сәбәбе бар. Аның кайтуын да күргәннәр, кем капкасын шакуын да күреп калганнар.

—Барый, минем Габидуллам кая, минем Шәүкәтем кая?—дип күрше хатыннары килә башлаган. Аларга ул барын да сөйләп тормагандыр. Һәркемгә күнел юатырдай сүзен тапкандыр. Әмма бу турыда ул озак еллар узгач кына, бик нык салган чагында гына елый-елый искә алгалый иде. Тиздән аны янәдән военкоматка чакыртып алдылар, тагын фронтка чыгарып җибәрделәр.

Әмма язмышның аны иң кырыс кыскычлар белән сынавы сугыштан соң булды. Ул инде Дөбъяз районы «Колхозчы» газетасын чыгара иде. Сугыштан соңгы елларда, Казан халкының урта хәлле гаиләләрендә, ял көннәрендә Кабан күленә көймә белән чыгу модасы бар иде. Кеше арасында көнчелек-соклану берлән телгә керәсең килсә, көймә белән Кабанга чык. Гармун белән! Бүген Канар атауларына барып гаиләң белән ял итү чүп ул. «Алар үткән ялда Кабан күленә көймә белән чыкканнар!»—дигән сүз—«бәхет» төшенчәсенең ул чактагы иң бөек ноктасы. Яна Бистәдә үз өйләре белән торып, 22 нче заводта өлкән мастер булып эшләгән Рәхимҗан абыйларга без дә гаиләбез белән кунакка килдек. Рәхимҗан абый—Җәнбәтләр нәселеннән, әтинең якын туганы. Үзләре дә безгә бик еш кайталар. Ул көймәләрне шунда яр буенда прокатка биргәннәрдер инде. Аңа кимендә ун-уникe кеше сыя. Кабан буйлап сәяхәткә чыгучылар ашарга-эчәргә алалар. Һәр көймәдә гармунчы. Чыр-чу, бала-чага. Мондый көймәләр белән су өсте тулы. Әмма бер көймә икенчесе яныннан узып киткәндә, хуҗалар бер-берсе белән, монарчы таныш булмасалар да, туганнарча сәламләшәләр. Бер-берләренә үзләренең әче балларын татып карарга тәкъдим итәләр.

Шулай бер тапкырында без ярдан кузгалып кына киттек.Бөтен Кабан өстен тутырып «Рамай» көен суздырырга дип, Рәхимҗан абый кулына тальянын гына алды. Ат менгән берәү, безне кулын изәп-изәп, ярга чакыра.

—Булмас ла. Безне чакыруы түгелдер. Башка берәүне дәшәдер,—диештеләр безнекеләр. Әти, алай да, ярга таба ишәргә кушты. Чыксак, кара айгырны ак күбеккә төшергән кеше—шагыйрь Самат абый Шакир. Ул чакларда ул әтидә җаваплы секретарь булып эшли иде. Мина яшь чагымнан ук язучы булмыйча, башка һөнәр иясе булырга хут та булмады. Әтинең бар дуслары—язучылар. Мөхәммәт абый Садри белән детдомда бергә үскәннәр. Безгә Кави Нәҗми, Әхмәт Ерикәй кайта иде. Чөнки Ашыт якын. Әти аларны Ашыт буена балыкка алып йөри. Дөбъяз үзе дә Казанга терәлеп кенә тора. Казан халкына Дөбъяз катыгын соңгы елларга хәтле Дөбъязлар ташып торды бит инде.

Самат абый белән әти, бик шомлы кыяфәттә нидер пышын-пышын сөйләшеп алдылар. Әти, бичаракаем, күз алдында коелып төште. Самат абый кесәсеннән алып аңа нииндидер кәгазь кисәгеме, газетамы бирде. Шуны тотып, әти айкала-чайкала көймәгә керде. Без барыбыз да тыныбыз катып тора бирәбез. Әти, көймә читенә утырып, газета битен ачты, уйга калды. Үз күзләрем белән укыдым. Анда: «Эчке эшләр министры Л. П. Берия» урынына «Эчке этләр министры Л. П. Берия» дип язылганые. Шунда әти:—Беттем!—диде, пулт итте дә суга чумды. Өстендә җилән иде аның. Чуму белән генә төпкә китмәде. Аның артыннан суга Рәхимҗан абый да сикерде. Яр кырые булганлыктан, әлләни тирән дә булмагандыр. Аны ярга сөйрәп чыгардылар. Көймәдәгеләр ни булганын да аңлап бетермәделәр бит әле. Аларга еларга гына булсын.

—Газизнең эше генә бу,—дип ыңгырашты әти. Газиз абый—редакциядә метранпаж. Алар нигәдер гел конфликтка килеп тораларые. Әллә инде ана

Казанга кунакка барырга Кара айгырны биреп тормаганмы әти? Араларында нидер булган инде. Менә хәзер шуның үчен алган булса кирәк. «Эшләр» дигән сүздә, «ш» хәрефе урынына «т» хәрефе генә куйган. «Этләр» килеп чыккан. Әмма моның өчен, ким дигәндә, егерме биш ел төрмә яный.

—Без анда бераз саклык чаралары күрдек,—дип Самат абый әтине тынычландырмакчы була. Икесе бер атка атланыпмы дигәндәй, алар шул сәгатьтә үк Дөбъязга кайтып китteләр.

Мондый ситуациядә, бичара әтиемнен башы шундый хәлләргә тарыгач, бер акыллы агай турында искә алып китми ярамас. Ул чорларда Дөбъяз коммунистларының башында Галим абый Шәмсетдинов тора иде. Галим абый, урыны җәннәттән булсын, әз-мәз генә җыештырып укый, әмма бер сүз дә яза белми иде. Кирәкле документларга «Г» хәрефен генә язып имзасын куя. Партиянен сыналган һәм тугрылыклы улы булгач, шул бик житкән. Документларнын барын да сугыш вакытында Ленинградтан эвакуация белән кайткан бик укымышлы һәм булган ханым Лукоянова алып барды. Ә Галим абый КПССның Дөбъяз райкомы беренче секретаре булганчы, мондый тормыш юлы уза. Бик ярлы бер агайның улы була ул. Армиягә аны көтү көткән жиреннән алалар. Әфган чигенә эләгә, чик сакларга. Басмачыларнын нәкъ котырган чагы әле бу. Көн саен диярлек чикне бозып торалар. Бер кичне Галим абыйны да дозорга жибәрәләр. Чик буена килеп кенә баса, теге яктан, көймәләргә төялешеп, басмачылар кузгала. Ниятләре—чикне бозу, безнен якка бәреп керү. Галим абый каушап калмый. Тревога игълан итә, басмачыларга винтовкасыннан ут ача. Ә тегеләр һаман безнен ярга таба йөзәләр. Кыю егет билендәге гранатасын алып тегеләр өстенә тондыра. Ул шартлый, көймә бата. Ике басмачы бу як ярга чыгып егылалар. Галим абый аларны әсир итә. Ул арада бирегә чик сакчыларынын көчле отряды да килеп житә.

Галим Шәмсетдиновны бу батырлыгы өчен Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләклиләр. Үлгәнче тагарга рөхсәт белән наган бирәләр. Армиядән киткән чагында анын кулына: «Бу егетегезне партия эшендә, житәкче урында файдаланыгыз. Бик ышанычлы, Ленин-Сталин партиясенең сыналган улы!»—дигән кәгазь тоттыралар. Галим абый сугыш вакытында да, аннан соңгы елларда да бездә беренче секретарь булып торды. Беренче секретарь агаебыз авылларга кешеләрен ат чаптырып, әлеге газетаны әти кайтып житкәнче үк жыйдырып бетергән. «Колхозчы» газетасынын тиражы сигез йөз данә тирәсе. Тапканнарынын барысын да жыеп яндырткан. Табылмаганнары да булгандыр. Ул елларда кәгазьгә бик кытлык иде. Мужикларга тәмәке төрергә кәгазь юк иде. Кулларына берәр газета кисәге эләксә, алар аны үлсәләр дә бирмиләр. Бу этлекне эшләгән агай да тик ятмагандыр, Казанга да хәбәр иткән күрәсен. Яшерен исем белән генә. Ул газетаны эзләп Казаннан да килеп төштеләр. Берәр шундый газетаны табып булмасмы дип, Черек күл агайлары авылларга да чыгып эзләп карадылар. Тапмадылар. Кулга төшкән газетаны безнен Дөбъяз тәмәке пыскытучылары кире бирәләрме сон? Булмаганны! Әти дә, кайту белән үк типографиядә жыйган хәрефләрнен барын да таратты, бәлүкләрне эреттерде. Шик тудырырлык мыскал да эз калдырмады. Бу эштә ана, берни дә белмәгәндәй, Газиз абый да булышып йөрде. Дошманнын иң хәтәре шушындый була торгандыр инде ул. Йөзенә елмаеп караучысы... Ул чакта әтинең башын элмәккә тыгудан, йә мәңгегә Магаданга сөрелүдән райком секретаребыз Галим абый Шәмсетдинов кына алып калды. Соңыннан аларнын икесен дә, «ВКП(б) нын кыскача курсын» яттан белеп кенә бүгенге тормышны гөрләтеп алып барып булмый, картлачлар, укырга кирәк»,—дип, партиянен Арча кырында урнашкан Югары мәктәбенә укырга да жибәргәннәрие. Телләренә остарышып, кәрт уйнап, шунда укып яттылар.

* * *

Һай, әти белән уздырган ул мизгелләр! Шулай бер чакны, мари авылыннан чыккач, әти киерелеп «Гөлмәрфуга»ны жырлап жибәрде: ятимлек күргәнгәме, яшьли кыерсыту-жәбер күргәнгәме, әти матур тавыш белән, бик моңлы итеп жырлый иде. Ә бу юлы үзе яраткан «Гөлмәрфуга»ны күтәренке күңел, яхшы кәеф белән жырлап жибәрде.

Агыйделгә төшә яздым, төшә яздым,
Тотмадың беләгемнән, Мәрфуга!
Ай-ли, Гөлмәрфуга, бар суга.
Гөлмәрфуга, барсаң суга,
Сөйләшербез барсын да.

Әтинең матур, моңлы тавышы, кайтаваз булып кайтмыйча, тын гына тугайларга тарала. Кара Айгыр да, жыр тыңлый-тыңлый, ипле генә юырта. Нинди матур мизгелләр кичергән чаклар булган икән дөньялыкта. Рәхәтләнеп, сагынып бер искә алып сөйләрлек мизгелләр!

## Контра Шәйхи

Ә менә Шәйхи бабамның жыры бөтенләй башкача иде.

Совет властен минем Шәйхи бабам кадәр күрә алмаган, аның пычракка кадалуын теләгән тагын берәр жан иясе булдымы икән ошбу жиһанда? Яшерен-мазар, эчтән генә сыкрап түгел, ап-ачык төстә, баш очында ике потлы гер кадәр йодрыгын янап! Боларын мин кәттә сүз өчен генә, ягъни укучыма әйтәсе сүземнең көчен, тәэсирен арттыру өчен генә язмыйм. Дөресе шулай. Югыйсә, әлеге власть Шәйхи бабамның алтын-көмеш белән тулы ювелир кибетен дә таламаган, аңа һәр көнне меңнәрчә сум өстәмә табыш, ягъни прибавочная стоимость китереп торган, бер түбә астында йөзләрчә кеше эшләгән завод-фабригын да тартып алмаган. Властьлар аның ике жил тегермәнен алганнар. Алар өчен генә үчле булмагандыр инде бабам. Тегермәнсез яшәп кара син авыл жирендә! Шуңлыктан, бер тегермәнен киредән үзенә кайтарганнар аңа. Бу властьны система буларак кабул итмәде ул. Шуның өчен, карт башы белән, кыенны да күп ашады. Кече Солабашның Каенсар юлы өстендәге тегермәнендә котырынып, сүгенеп ятканда, аны еш кына тоталар да Дөбъязга төшереп зинданга ябалар. Башта әле, күз төпләре күгәргәнче, әйбәтләп кенә яралар да. Ярмаска соң! Һәй, минем артымнан милиция егетләре үзләре менгән икән, дип алар каршына кулын югарыга күтәреп чыкмый бит ул. Карыша. Милиция егетләре аны дүртәүләп-бишәүләп әвереп алып кына жиңәләр. Берочтан шунда, куллары туйганчы тукмыйлар да. Чын контра бит. Аның да ниндие әле! Сугыштан соң без Таш Кавалдагы әбием йортын калдырып, Дөбъязга, район үзәгенә күченеп килдек. Әти, пролетар кавемнән, системаның нык ышанычлы кадры. Детдомда үскәч, шулай булмыйни. Башта райкомда идеология буенча эшләде, аннары «Колхоз»чы газетасын чыгарды. Һәрхәлдә, районда беренче обоймада йөри торган житәкче. Кичләрен безгә еш кына районның милиция начальнигы:

—Минем егетләр сезнең теге, акылы качкан, женле абзагызны тагын яптылар бит. Тагын контр сүз сөйләгән,—дип безгә шалтырата. Аның белән әтинең аралары яхшы. Әти шунда ук милициягә төшеп китә. Шәйхи абыйны алып чыга, кунарга үзебезгә алып кайта. Тукмаганнар бабамны. Йөзенә карарлык түгел. Үзе болай зарланмый. Кыяфәте дә горур, Берлинны алган, диярсең. Тагын шунысы гажәп, шушы Шәйхи абыйны әти үлеп ярата. Шәйхи бабай—бер тау байлык калдырып, ике нарасыен ятим итеп, үпкәсе шешүдән нибары утыз жиде яшендә үлеп киткән әтиемнең әтисе Хәсән бабамның кече энесе. Безнең

Жәнбәтләрдән аермалы буларак, ул мыскал да укымаган, чеп-чи надан. Авылдан да китмәгән. Латин хәрефләрен дә, чуер таш чүпләгән сукыр тавык кебек, бик кыенлык белән генә таный иде. Әмма әти аны бик ярата, әтисе урынына күрә, беркайчан орышмый. Берәр кич бездә кундыргач, тарантасын жиктереп, янәдән тегерменәнә менгереп куя. Күп тә узмый, салган баштан ул:

—Тиздән совет власте бетә икән!—дип сөйләп куя. Тегермәндә көн эчендә кемнәр генә булмый. Куштаннар, әләкчеләр Солабашта да житәрлек. Бу сүзләрен шундук милициягә житкерәләр. Аны янә алып төшеп ябалар.

—Кем әйтте мондый сүзне?—дип допрослыйлар аны.

—Кем әйтсен? Минем тегермәндә кунып киткән Потаниха, Алат урыслары сөйләп киттеләр. Казаннан кайтышлары иде, шуннан ишетеп кайтышлары. Потаниха, Алат урысларын эзләп кара син, табарсың бар. Андый хәтәр сүзләрне алар да сөйләп йөрми инде анысы. Шәйхи абыйның жил тегермәне Казан юлы өстендә. Юлчылар, товар белән йөрүчеләр ана Казанга барганда да, кайтканда да кунарга керәләр. Атларын ял иттерәләр, сбруйларын көйлиләр. Шәйхи абый болай үзе бик булган агай. Төнгелеккә атларны куярга өсте ябулы абзары бар. Юлчыларга кереп кунарга чәчрәп тир исе, сарымсак исе, тәмәке, үтә әчкелтем аякчу исе анкып торган, ике тәрәзәле генә, уртасында тимер мич торган, жәен чебен, кышын кандала котырган өе бар. Май сөрткәнме, бал сылаганмы, диярсен, анын тегермәненнән жәен-кышын атлылар, юлаучылар өзелмәс иде. Совет властеннан үчен шулай алган.

Базарга төшкән жиреннән Шәйхи бабам безгә сугылса, әти өстәлгә өйдә булган ризыкнын иң тәмлесен куйдыра. Бабамның ашыкмый гына:

—Менә... Үткән атнаны миндә Әтнә мужиклары кунып киттеләр. Казанга тире төяп илткәннәр... Шуннан кайтышлары. Алар сөйләп киттеләр...—дигәнен рәхәтләнеп тынлап утыра. Шәйхи бабамның сүзен ни белән тәмамлыйсын белеп тә тора инде, югыйсә. «Тиздән совет блачы бетәчәк икән»,—була инде ул сүз.

Шәйхи бабам турында ни өчен шулай озаклап сөйлим сон? Мина сигез-тугыз яшьләр булгандыр. Потаниха урысларына утыртып, ул мине үзе белән Казанга алып барды. Бабамның аягында тула оек, яна чабата. Өстендә изүенә озын итеп ак сәдәф тезгән кызыл сатин күлмәк. Жәй көне бу. Тукай урамында бүрәнәләрдән салган йорт каршында басып торабыз. Төп бабам Хәсәннең асты таш, өске каты агач йорты бу. Әтием шушында туган.

—Синең йортың бу, улым! Синеке! Сәүит блачы бетәчәк. Көтәргә күп калмады,—дип сөйли бабам. Бетәр, бар. 1947-48 еллар бу. Беренчедән, илдә коточкыч ачлык. Икенчедән, Сталин репрессиясенен яна дулкыны күтәрелеп кенә килгән чорлар. Ә мина сон, тугыз яшьлек малайга, ике дөнья бер, уртасы камыр. Мин гамьсез калып, кулымдагы тундырманы ялыйм. Авылда үскән малайга—күргән нәрсәме?! Тундырма түгел, төшенә кермәстәй бәхет минем кулда. Бабам да бик кадерле!

Әлеге йорт алдына Шәйхи бабам мине тагын ике-өч мәртәбә алып килгәләде әле. Анын иң кызыгы шунда. Гомерлек ярым итәргә жыенган Мәдинәм-Гөлкәем белән йөри генә башлаган чагыбыз. Конкурентларым муеннан ашкан. Кәләшемне кулыма ныграк ияләндерү максаты белән, әлбәттә, аны да, мин хужасы булырга тиешле йорт каршына алып киллем. Әйе, ул чорда анда 17 нче даруханә иде бугай. Күрсен, янәсе. Әлегә, пружиналары идәнгә хәтле сыгылган караватта, тулай торакта яшәп ятсам да, көтүчеләр, тире жыеп көн итүчеләр нәселеннән түгел. Без «Жәнбәт жәвере—жиде табын!»ныкылар! Мәдинәм-Гөлкәемнең исе китте. Кыз чагында ул «ирис» конфеты ярата иде. Кесәм тулы конфет булмаса, мин аны свиданиегә дәшмим дә. Үзе дә чыкмаска мөмкин. Ул инфакта укыды. Берьюлы ике чит тел өйрәнүе жинел түгел. Дәресләрне бик күп бирәләр аларга.

Укыган чакта матди яктан начар яшәмәдем. Елга порты, Усия, Бакалтай бар ич. Беләкләр таза, җилкә киң. Портка төшәбез дә, пароходтан, баржадан паркет, цемент, карбыз бушатабыз. Икенче, өченче курсларда укыганда радиога хәбәрләр дә яза башладым. Татарстан радиосының «Соңгы хәбәрләр» редакциясендә Иванова фамилияле, «Казбек» папиросын авызыннан өзмәгән юан гына бер яһүдә ханым бар иде. Үзебезнең институт тормышыннан икеөч хәбәр китерү белән ул миңа «Внештатный корреспонтендт Татарского радио» дигән таныклык бирде. Аның белән башта бүлмә малайларын шаккаттырдым. Минем белән тупасрак сөйләшеп карагыз хәзер! Эльс Адылов белән бер бүлмәдә тора идек. Миннән күрә ул да радиога иялләште. Эльс соныннан гына Гаделевкә әйләнде. Кабатланмас көмешчән тембрлы! Эльс Гадел бер дигән диктор булып китте. Соныннан «Югары категорияле диктор» дигән дәрәҗә дә алды. Аның артыннан Ильяс Латыйпов та радиога китте. Шулай ук безнең бүлмәдән. Ильяс—тумышы белән Шөгер егете. Ул да диктор, русча текстлар укый. Аннары, пенсиягә чыкканчы, Россия радио һәм телевидениесенең Татарстан буенча үз хәбәрчесе булып эшләде.

...Дүртенче курсларны тәмамлап, җәйге каникулларга икебез ике якка, Мәдинәм-Гөлкәем пионер лагерына җәйге практикага, ә мин Кавказга альпинистлар лагерына—Альпиниадага китәр алдыннан, йөрәк маемны янәдән Тукай урамындагы аскы каты таш, өсте юан бүрәнәләрдән салынган, закон буенча мин аның төп хуҗасы булырга тиешле йорт каршына алып килдем. Килсәкме?!—Бүгенге «Татарстан проспектын» нәкъ шул заманнарда сала башлаганнарые. Киңәйтеп, бик иркен итеп. Бик зур гер таккан, атлап йөрешле экскаватор өебезне методик осталык белән җимереп маташа бит, әй! Тонна ярым авырлыктагы гере белән китереп суга, колаклар чынлап китә. Бу йортка бернинди өмет-мазар тотмасам да, егылып китәрдәй булып, карап торам. Хуҗаларына иң кимендә йөз еллап кына тугры хезмәт иткән, әле дә тазаның нарат өйнең бүрәнәләре шул хәтле карышалар, ямьсез чытырдыйлар, сукраналар, бозык, кыллары чамасыз тарттырылган скрипкә сымак чиныйлар. Башка сыймаслык фаҗига булып тоелды бу күренеш. Киң проспект салу өчен бу урамны сүтәргә кирәклеген һәркем анлый. Тик шуны бирелә гасыр буе яткан бүрәнәләр генә аңламыйлар, төшенмиләр. Китереп суккан саен чатнап кына сыналар, бахыркайлар. Моны карап тору бик авыр иде безгә. Алай да, ике сәгатьләр чамасы торганбыздыр. Китеп кенә булмый. Тузан монда. «Йорт иясе» җибәрмиме? Тыз да быз машиналар чаба. Чүп төйиләр. Экскаваторчы егет ялга туктагач, түзмәдем, хәрабәгә таба атладым. Аягыма кадак керүе дә бар, абынып егылуын да мөмкин. Әмма бабаң нигезен, атаң туган йортның көлен күккә очырганда алар турында уйлап тормыйсың инде.

Подвал өлешен караганда борынгы бизмән таптым бит, әй! Бераз күгәргән күгәрүен. Күгәрмичә соң? Монда ул күпме еллар ятты икән? Әмма чылбырлары да, җиз тәлинкәләре дә исән. Һәрхәлдә, безнең көннәрдә кулланыла торган үлчәү коралы түгел инде бу. Борынгырак корал. Бәлкем аннан Хәсән бабам да файдалангандыр әле.

Тузанын кагып, бераз сөрткәләп, бизмәнне портфелемә салдым...

Ни йодрык янаса да, Совет властеның беткәнен тәки күрә алмыйча, Шәйхи бабам, туксаннарын тутырып, вафат булды. Сиксәннән өстә булса да, чабарга түгел, яшьләргә чалгы кайрарга дип, печән өмәсенә алып чыкканнар. Үзе сораган. Утыз градуслы эсседә, бөтенесе дә бераз көн басыла төшкәнне көтеп, агач күләгәсендә ятканда, ник бер утырып карасын, гел аяк өсте булды, дип сөйләде әти.

—Шәйхи абый, утыр, безнең белән бераз ял ит, дигәч:

—Колынлы бияләр генә ятып ял итә. Ә нәселле чабыш атларының ятып

торганнарын күргәнегез бармы? Алар аяк өсте йоклап ял итә,—дип жавап биргән.

Аны жирләгәндә мин булмадым. Вафатын да авылга кайткач кына белдем. Алай да бик еш искә төшә, сагындыра әтиемнен бу абыйсы. Нибары ике жил тегермәнен тартып алган өчен совет властен жене сөймәгән кеше... Үз сүзле, үз фикерле, көчле ихтыярлы матур кеше иде ул. Үзебезнен «Жәнбәт жәвере—жиде табын» ыруыннан!

## Бәгырь җимешем

Эш өстәлемә каршы гына шкафта—үзем язган китапларым. Алар ике дистәләп. Эш көнемне еш кына алар белән гәпләшүдән башлыйм. И-и! Барысы да балаларым, оныкларым кебек якыннар. Аларны дөньяга чыгару өчен күпме йөрәк жылысы, күпме акыл көче салынган. Аларны кулларына алып, битләрен ачкан укучыларына акыл, гыйбрәт, кинәш, йөрәк жылысы бирерлек иткәнем өчен, Китапларым мина рәхмәтлеләр. Китап буларак, алар—ике дистәләп. Әгәр роман, повесть, хикәяләр буларак бүлгәләсән—бихисап! Әле дә, шөкер, кулымнан каләмне төшергән юк. «Нулла диэс синэ линиэа!»—Һич югында бер юл да сызмыйча, бер көнне дә бушка уздырмаска! Күп еллардан бирле үз алдыма куйган таләп, яшәү рәвешем бу минем.

Әлләни мактанырлык булмаса да, бөтен унайлыклары белән үз өем, гаражда машинам бар. Бакчамда—үзем утырткан алмагачлар. Кайбер агачта дүрт-биш төрле сорт үсә. Андый осталыкка бер күршем өйрәткәние. Ишек алдымдагы бакчама бәрәнге «падишаһны» да бик хасиятләп, жаен белеп, көлен сибеп утыртам. Һәр төптән куш йодрык хәтле сигез-тугыз бәрәнге алу безнен өчен гадәти хәл. Еллары белән егерме-утыз баш умарта тоткан чакларым да булды. Тәнре мине шат, булган, кулыннан эш килешле егет итеп яраткан. Өй артымда гына ун чишмә чылтырый. Барысынын да исемнәре «Гөл» белән башлана. «Гөлсем», «Гөлнар», «Гөлшат»... Өемнән илле адымнар читкәрәк атласан, кара урман башлана. Яз башларында шашып-шашып кошлар сайраганга түзәр хәл калмый. Яшә! Рәхәтлән! Ә күнелнен... тулаем яртысы китек... Аны мон, сагыш, сыкрау баскан. Чал гына түгел, ә ап-ак башымны кая куярга, кайсы ташка бәреп чәлпәрәмә китерергә урын тапмаган чакларым хәттин ашкан. Тәнремнән мен-мен катлар ялынып-ялварып сораган теләгем кабул булмады. «Жанымны ал! Шушы минутта ук! Ә кызыма тимә. Яшәсен! Жиһанны үзенең барлыгы, яшәү рәвеше белән бизәргә дип яраткансын түгелме сон син аны?»—дип үтендем. Күп тапкырлар. Юк икән жиһанда синең гозерләренә колак салырдай кодрәтле зат. Барысы—бутафория!

Югыйсә, әдәпле, инсафлы Мәҗүси мин. Күп еллардан бирле жан дустым—эш өстәлемне яратам, ана табынам. Командировкаларымнан Мәдинәм-Гөлкәемнән болайрак аны сагынып кайтам. Беренче эшем итеп аны сыпырам, аны иркәлим.

—Син дә мине шулай сагындынмы?—дип кочам. Гармунымны яратам, ана табынам. Йорт иясе белән дә бик тату яшибез. Каядыр-мазар киткәндә, өйне ут-күздән, су басудан, карак-угрыдан, башка хәвеф-хәтәрләрдән сакларга тулысы белән ана тапшырабыз. Бу әсәремнен бер урынында «миндә бик хәтәр көч-кодрәт бар, тик бу турыда әйтергә генә куркам»,—дип авызымнан ычкындырганыем бит. Хәзер дә куркам. Мине шарлатан бу, бераз акылдан да тайпылганмы, дип әйтүләреннән түгел. Аларына исем киткән ди бик! Алай да, шул хәтәр кодрәтемнен бер чагылышын гына, тешемне кысып кына булса да, ачам. Үзем белән ни буласын мин күп алдан белеп торам. Йә ап-ачык итеп төшемә керә, йә күнелем сизә. Укыган чакларымда, иң кыен

саналган фәннәрдән имтихан биргәндә нинди билет керәсенә кадәр төшемә керә иде. Ләкин шунысы кызганыч, бу көч-кодрәт белән мин идарә итә алмыйм. Гәрчә кайтып-кайтып баш ватканым булса да. Бер карасаң, бик вак детальләр. Кайчак шулай исемә бер таныш җыр төшә. Кара, бу матур җырны күптән радиодан ишеткәнем юк, дип уйлап куям. Шушы җыр ун минуттан ук радиода яңгырый. Кара, менә бу егетне күптән күргәнем юк, исән генә йөриме икән, дип уйлап куям.—Куркам. Әмма әсәремнең ахырындарак әйтми дә булмас... Бу кадәрлесе шушында торып торсын.

Ходайның үзеннән сорап, махсус заказ белән алгандай, бик матур килгән җәй көне. Июнь урталары. Казаннан кайтышыбыз.

Рульдә—киявем Нәфис. Аның янында—олы кызым Гөлнарым.

Казаннан, рак авырулары шифаханәсеннән, чираттагы «химия белән бомбардировкадан» кайтышыбыз. Хирургия һәм онкология кафедрасы профессоры, танылган хирург Рәфкать Таҗиев:

—Шушы яшемә туплаган бөтен осталыгымны җиктем. Мөмкин булганча рак шешләреннән арындырдым... Ләкин бик соң килгәнсез. Озак яшәмәс. Күп булса, алты ай гомере бар,—диде. Бу серне якыннарымның берсенә дә әйтмичә, мин сакларга тиеш бит әле. Ә кызым, кошчыгым, баш миемнән алып, табан очларыма кадәр безләп сорый:

—Әтием, мин котылдыммы соң инде?

Шушындый чакта үзеңдә телең камашмаслык нинди көч табарга кирәк соң?! Мона кадәр мин тормышымда бер дә алдашмадым. Кирәге дә чыкмады. Алдаша да белмим. Хәзер нишләргә? Күземне читкә яшерергә дә ярамый.

—Кызым, моны сиңа мин әйтәм, Аллага шөкер, котылдык!—дим.

Таҗиев шулай кушты. «Әйтмә,—диде.—Булган гомерен берни дә белми яшәп калсын»,—диде. Үлемнең котылгысызлыгын ачып салмавым өчен кайбер якыннарым соңыннан миңа үпкә дә белдерделәр. Ә белгән булсалар, нишләрләр иде? Мәдинәм-Гөлкәем бер атнадан ук сизде, белде. Сизмәс, бар...

—Яшермә карашыңны, йөзеңә бер карау белән, мин барын да сиздем. Бу кайгы бер үзеңә генә авыр булыр. Икәү күтәрик,—диде.

Рәфкать Минһаҗ улы Таҗиевның да аягына ятып ялындым.

—Аһ, шуны эшләмәдем бит, дип әйтерлек бер үкенечем дә юк. Операция өстәленә кызым белән рәттән сал. Нинди әгъзам кирәк, шунысын кисеп ал. Кызыма күчер. Тик ул гына исән калсын, тик ул гына яшәсен,—дип ялвардым. Һай, шулай гына булса икән лә соң!

...Нократ елгасы аша салынган күпергә килеп кердек. Ап-аяз, җилсез җылы көн. Баш очыбызда, күк түбәсе астында уйнаган бихисап тургайларның чуты юк. Шашып-шашып сайрыйлар да, ук булып җиргә атылалар, машинабызның борын төбеннән үк очып китәләр. Уйнаулары шулай күрәсең. Болыннарны чәчәк, алар өстен күбәләк баскан. Күпергә кергәч, кызым машинаны туктаттырды. Чыгып күпер читенә килде. Бездән утыз метрлар аста ургылып-ургылып мул сулы Нократ ага. Су өстендә чүлт-чүлт вак балык уйный. Чуртан куа бугай үзләрен—эре дулкыннар да куба...

—Әтием, ташланыйм шушыннан аска. Мин дә котылырмын. Сез дә... бер утырып еларсыз да, онытырсыз. Эзләп тә тормагыз,—диде балам.

Шушы сүзләрне ишеткән ата нишләргә тиеш?!

Дөнья булгач, егет башы күп сынаулар кичә. Тормыш аны минем чал башыма да күп салды. Әмма болай каушап калганым булмады. Сине дә аңлыйм, балам. Тәмам сабырың төкәнгәч, яшәүдән тәмам өметеңне өзгәч, шулай әйткәнсеңдер инде, кошчыгым. Шушы хәлләрне күрәсе булганга, кечкенәдән, туган сәгатеңнән шулай өзелеп яратканмындыр инде үзеңне...

Хатирәләр шаукымына бирелеп, өзеп-өзеп, ташлап-ташлап яза торгач,

фикерләрне мәржән бөртеге итеп тезүдә дә өзеклекләр туа торгандыр инде. Әмма кыйблам—бер. Уйнаклатмыйм. Юнәлешне гел шуңа таба тотам. Вәләкин дөнья сагышларыннан котылып буламы сон?! Тик мин сер бирмәскә тырышам: елмайган, шаярган төс чыгарам. Беркемгә берни сиздермәскә маташам. Гөлнарымны Себер трактындагы Онкологик авырулар бүлнисенә салдым. Балакаем, күз нурым:

—Әтием, әйдә, Мәскәүгә чыгып киттек. Акчабыз да, долларларыбыз да житәрлек. Ә безнең анда белгән профессорларыбыз бар. Миндә бит язва чире генә. Мәскәү профессорлары бераз дәваласа, ярасы хәзер ябылыр,—ди. Мәскәүнең ата жулик Брантлары, Крандтлары моңарчы да аларның долларларын күп саудылар инде. Ашказаным авырта, дип табын яныннан кузгалып китүгә, киявем Нәфис аны шунда ук Мәскәүгә алып чыгып китә. Ике-өч атнадан алар:

—Тереллдек!—дип кайтырларые. Әмма күп тә узмый, ашказаны кызымны яңадән борчый башлый. Болар яңадән Мәскәүгә очалар, долларларын саудырып кайталар. Ах, шул чакта йөгәнне, дилбегәне үз кулыма алган булсам! Дөнья булгач, адәм баласының ашказаны да, башка әгъзаләре дә авыртмый тормый, узар, дәваларлар,—дип уйладым шул. Чөнки студент елларымда үземнең дә ашказаным еш кына «ыңгырашып» куя иде. Кызымның ире дә шулай игътибарлы булгач, араларына кермәдем. Соңгы тапкыр Лениногорск бүлнисендә тикшергәч, шәһәр онкологы Илья Никитин:

—Сезгә бүген үк Казанга очарга кирәк,—диде. Беләгемнән тотып:

—Крепитесь! Крепитесь!—дигән сүзләрен гомердә онытасым юк.

Бәгырь жимешемнең көннәре бик санаулы калган иде шул.

Эш болай, кадерлеләрем. Минем халәт дошманына язмасын. Мәк чәчәге кебек, тулып пешкән кура жиләгедәй кызым Гөлнарым, көннән-көн сызып китеп бара. Дөньяның бер чибәре, бер гүзәле бит ул. Бии башласа, үкчәсеннән чаткылар чыгара. Урта мәктәпне алтын медальга тәмамлап, Мәскәүнең нефть институтында инженер булып чыкканые. Рак дигән мәлгунь харап итә бит баламны. Бу фажигане бик көчле рухлылар гына күтәрә аладыр. Мин исә күтәрә алмадым. Бу хәлдән котылу чарасын эзли башладым. Әлмәт төбәгендә жиде-сигез районга корреспондент булып эшләгән елларым. Төнлә берялгызым гына йөргән чакларым да булды. Бүрегемне дә урлап качтылар. Аннары миңа милиция бүлегенә дәшеп, бер ипле генә револьвер бирделәр. Кул куеп алдым. Мин аны өемнең өске катындагы тимер сейфта саклыйм. Алты зарядлы ул. Бакчага чыгасың да, шалт берне маңгаеңа, йә чигәңә. Әнә шул уй төште минем башка. Чөнки кызым, балам:—Әтием, коткарасыңмы мине бу чирдән?—дип сорый. Оятсыз төстә алдашам. «Коткарам!» дим. Бакчага чыгасы да, алма агачы төбенә утырып, «Шалт!» берне маңгаеңа. Бөтен кайгы-хәсрәтләреңнән шундук котыласың. Әмма сейф ачкычын таба алмыйм. Ә пистолет сейф эчендә. Мәдинәм-Гөлкәемне утлы табага бастырам.

—Бир ачкычны яхшылык белән! Үтерәм бит үзеңне,—дим.

—Мин аны бөтен көчемә айкап, бакчага ыргыттым. Кая төшкәнен дә белмим. Чык та эзлә. Минёрлар дәш, бәлкем табарлар, ди...

## Раббым каршына юл тоттым

Башка чара юк, бармыйча булмый иде. Әллә безнең «Жәнбәтләр—жиде табын» нәселен башлап жибәргән бабаларыбыз жиде буынга житешле каргыш алмаганнардыр бит? Юк, бу ни хәл бу?! Бабам ятим үскән. Әтиемне дүрт яшендә үк детдомга илтеп тапшырганнар. Мин әниемнән алты көнлек кенә булып калганмын. Кызымның улы Арыслан жиде яшендә калды. Бу ни хәл бу? Кем безнең белән шулай усал шаярта?

Чиге бармы монын?! Раббым каршына мена шул турыда «икәүдән икәү» хәл итү ниятеннән бардым. Канса канис, хикмәт нидә соң? Аннан—өстән торып—безнең ыру өстенә ни дип ләгънәт яудыралар? Кем тарафыннан, кайчан кылган гөнаһларыбыз өчен? Бер өстәл артында кара-каршы утырып сөйләшү нияте белән бардым аның каршына. Менә шул...

Бүгенге көндә, җәмәгать, гозерең төшеп, президентыбыз Минтимер Шәймиевкә эләгүе дә бик җиңел түгел. Үзендә түгел гаеп, якыннары, аеруча куштаннары аны шулай халыктан аерырга тырышалардыр. Ә Илбашы халкыннан аерылса, бетте диген инде.

Әүвәл чын хыялыйлар хәленә калдым. «Очты күңелем дөнья читлегеннән»... Җиде кат җир астына төшеп, җиде кат күккә күтәрелеп, барып чыктым бит тәки Хак Тәгаләнең приемныена! Беренче минутларымнан ук нигә килгәнемә үкендем. Анда да—шартларлык булып, соңгы чигенә җитеп күпергән штат. Бер креслода, этешә-этешә, өчәү-дүртәү утыралар. Монда да коточкыч бюрократия, әшнәчелек, туган-тумачалык, ришвәтчелек. Бер Ходаем, үзең кичер. Күзенә карап, кайсына куй сарыгы, кайсына ак тәкә дигәндәй, кулларын сузып, синнән ришвәт көтеп торалар. Кыланышлары нәкъ куначада утырган тавыкларныкыча: үзләре белән янәшә утырган иптәшләрен, җае чыккан саен чукыштырып, канатлары белән бәргәләп, кысрыклап, һаман өскәрәк үрмәләргә тырышалар. Үзләреннән аста утырганнарның башына пәч тә пәч кәкәй яудырып кына торалар.

Дөресен әйтим, Хак Тәгаләнең үзенә үк кереп булмады. Булыр сиңа, тот капчыгыңны!

—Бүген юк бит ул, вакытын белмичә килгәнсез,—диделәр. Больничныйда,—дигән булдылар.

—Ничек инде больничныйда? Хак Тәгаләнең больничный алырга хакы юк!—дип чәпчеп алмакчы булам.

—Ничек инде хакы юк?! Ул да бит тере җан иясе. Аның да вакыт-вакыт тешләре сызлап куя. Кан басымы да күтәреләдер.

Үткән атнаны балыкка барганые, аякларын өшеткән. Хәзер ангина белән азаплана,—дип ипле генә аңлатты приемныйда утырган бер фәрештә кыз.

Алай дигәч, ышандым инде. Бигрәк тә—«ангина»,—дигәч. Аның белән үзем дә еш азапланам. Тереләй генә күрсен инде Хак Тәгаләбез. Аңсыз калсак, нишләрбез?

Юлламама мөһер суктырып, саубуллашкан чагында, ап-ак күлмәкле, кара галстуклы, чибәр генә бер егет, шулай ук фәрештәләр затыннан:

—Вакытсызрак килгәнсез шул. Нинди гозерләр белән йөрешегез иде соң? Әйтегез, үзебез генә хәл итәрбез,—диде.

—Гозерләр генә түгел, таләпләрем дә зурдан һәм җитдиләрдән иде,—дидем.—Әмма күреп торам, сез аның берсен генә дә хәл итмәячәксез. Чөнки сез биредә бернинди җаваплылыкны дә үз өстегезгә алмаслык дәрәҗәдә каешланып беткәнсез. Монда, күрәм, шундый мохит. Чөнки сезне өегездән чыкканда ук әти-әниегез, хатыныгыз, балаларыгыз: «Бер җаваплылыкны да үз өстеңә ала күрмә, үзеңне танытырга теләп инициатива күрсәтмә. Иң изге гамәлләреңне дә ялгыш аңлаулары бар. Көнең узса, бик җиткән, эшеңне, урыныңны гына югалтма»,—дип башыгызга тукып җибәрәләр. Җибәрмәскә соң! Мондый абруйлы, дәрәҗәле, җылы урынга гомердә бер генә эләгергә була. Җитмәсә, көндәшләрегез дә бер көтү. Чак кына абынганыгызны, сөртенеп китүегезне генә көтеп тора булырлар...

—Безнең мондагы аппаратның эшчәнлеген,—сез кайсы планетадан, Җирдән килдем, дидегезме әле?—Бозыклык чиренә башы белән чумган җирдәге үлчәмнәр белән үлчәмәгез әле, зинһар,—дип кенә әйтә алды әлеге чибәр егетем. Хак Тәгалә аппаратының якын түрәсе, фәрештәләр өммәтеннән инде, әлбәттә.

—Ни дип шулай безнең ыруны каһәрлисең, нарасыйларыбызны ятим калдырасың?—дип өстәл сугарга барганыем югыйсә Раббым каршына. Житте инде!—димәкче идем...

Хыял дингезенә чумып, шул каләр араны гизеп килгәчтен, берочтан Газраил әфәнде кабинетына да сугылдым. Ул да өйдә юк. Шуна күрә безобразие икән жирдә. Өстән контроль юк икән. Жиде кат күк түрендәге ник бер начальник, ник бер түрә эшендә булсын. Газраилне, җәйге ялын уздырырга, барча бала-чагасы белән Андромеда йолдызлыгына китте, диделәр. Түрәләр кайда да түрә икән. Ялларын да беләләр кайда уздырырга.

Аның кабинетында, әремдәй чал чәчен әйтерсең лә селте белән юган, бите бозау чәйнәгән сөлгедәй жыерчыклы, авызында сынар теше дә калмаган Әҗәлбикә карчык кына утыра иде. Әллә әз генә салметдин да? Үзенә күрә түгел, биек үкчәле туфли кигән әле, жубалгы капрон оектан, прәме үзенә күрә түгел. Мине бик төксе каршылады.

—Анда, үлем эзләп шаяруыгыз турында бик төгәл хәбәрдарбыз. Тик утырган юк. Документацияне бик төгәл алып барабыз,—ди бу.—Дөнья йөзендә, кояш нуры астында яшәүнең кадерен онытканcыз,—дип ишеттек. Хәбәрдар, бик хәбәрдар! Кайбер нәтиҗәләр дә ясарга жыенабыз...

—Булмагаегыз! Анысы—минем эш.

—Юк шул, ангырабаш, кемгә кайчан, нинди әҗәл жибәрү, билгеләү—анысы нәкъ менә минем эш,—дип өстәл үк сугып жикеренә Әҗәлбуки.—Яшьтәшләрең, иптәшләрең яшәп туймыйлар. Гомерләрен бер генә көнгә булса да озайтуны ялварып сорыйлар. Тәңренең үзенә телеграммнар яудыралар. Ә син!..

—Нәрсә, «син»? Сарыгынны урлап суйдым мәллә?

—Алай кыланып йөрсәң, дөньядан туйсаң, хатыныңнан пистолетларыңны таптырсаң, момент кыскартырмын гомереңне... Монысы безнең кулда!

—Тот менә моны!—уң терсәгемне кендегемә терәдем, йодрыгымны күрсәттем. Бу жен карчыгына беренче күрүдә үк ачуым чыкты, селте белән юган чәчләреннән сөйрисем килде.

—Син алаймы әле-ә!—ди бу, шушы сүзләренә бөтен зәһәрлеген салып. Сул кулын баш өстенә күтәреп бармак яный.

—Син уйлаганча! Нәкъ шулай! Менә сина!..

—Алайса-а-а! Син, тилебашны, мин бик тиз акылга утыртам.

—Утыртмый гына тор әле, жубалгы! Синнән куркучыларны куркыт! Ә мин аларны узган инде. Баш өстемә өч кояш чыкса да, дөньяның тәме калмады. Мәк чәчәгедәй кызым юк. Син гаепле. Күзенне чекерәйтеп син йөрден бит безнең өй тирәсендә.

Әҗәлбикә белән шушы тарткалашудан соң шундый сәер хәл булды бит, әй. Җәйнең матур бер көнендә, киявем, оныгым һәм Мәдинәм-Гөлкәем белән кызымның каберен төзәттек. Матур итеп таш яздырганыек, аны куйдык. Кабер әйләнәсенә цементлап ак кирпеч тездек. Кабер өстендәге кызыл балчыкны читкә түгеп, кара туфрак ташыдык, гөлләр утырттык. Аста, кабердә, нибары утыз өч яшендә дөньядан киткән, яшәргә дә яшәргә тиеш булган, өзелеп яраткан кызың ятсын әле! Син—шул кабер янында...

Кич житте. Башкалар автобуска утырып кайтып киттеләр. Без, оныгым Арыслан белән, машинада кайтырга чыктык. Мин рульдә, ул янымда. Шунда минем белән хәтта бүген дә аңлап-аңлатып бетерә алмаслык хәл булды.

Көндезге авыр кичерешләрдән соң мием тәмам алжыган булгандыр инде. Зират чатында, юлның уңайсыз бер җирендә, шып итеп тормозга басасы урында, бар көчемә газга басканмын. «Жигули»ебыз юл читендәге тимер баганаы аударып, чыбырны өзеп, бетон бүкәннәрне егып, дүрт-биш метр биеклектән ком карьеры төбенә очты. «Оныгымны харап иттем!»—дигән уй

гына узды башымнан. Үзем турында уйларга вакыт юк. Беттек бугай... Котылдым... бу фани дөньядан...

Бераздан аңыма килсәм, Ходаемның рәхмәте, машинам дүрт көпчәгендә карьер төбе буйлап тәгәри. Моторы сүнгән. Кул тормозын тартып туктаттым. Улым да аңына килде. Кабаланып кына ишекне ачты да, ут капкандай читкә йөгерде, таш артына ятты. Бераздан кычкыра миңа:

—Дәү әти, кач! Машина шартлый бит хәзер!

Киноларда, телевизорда һәрчак шулай бит. Һәлакәткә дучар булган машиналарга ут каба, шартлыйлар. Оныгым да шуны көткәндер, бала бит. Машинадан чыгып янына килгәч тә, таш артыннан алып булмый, дер-дер килә, балакаем. Таш карьерына биш метрлар биеклектән очсак та, машинага әлләни зыян килмәгән. Йә, Ходайның рәхмәте, дүрт көпчәгенә төшкән ул җиргә. Шунлыктан гына исән калганбыздыр. Әгәр әйләнгән булсак...

Сизәсезме, җен карчыгы Әҗәлбикәнең үч алуы бу. Теге чакта бик янап калганые бит. Янәсе, якты дөньядан туеп, әҗәл эзләп йөрсәң, без әле күрсәтербез сиңа күрмәгәнеңне! Юлда очраган «Камаз»ны туктатып, машинаны гаражга кайтарып куйдык.

—Машина да булдымы мал! Үзегез исән калгач!—дип әнием дә ике кулын йөрәге өстенә куеп сөенде. Ничә ел бергә гомер итеп, әниеннең болай сөенгәнен күргәнем юк иде әле, кызым.

Тормыш гыйбрәтләрдән тора шул. Карьерга очу безгә зур гыйбрәт булды. Елап, сыкрап кына эш чыкса икән ул! Үлгән артыннан үлеп булмый, диләр. Бөтен матурлыгыңны, акыл-зирәклегеңне, зиһенеңнең дәвамчысы—улың Арысланны аякка бастырасы, кеше итәсе бар бит әле. Белеп, тоеп ятасыңдыр, балам, егетебез әлегә гел бишкә укый. Күп олимпиадаларда катнашып, гел җинеп кайта...

Кызым, васыятьләреңдә кат-кат сорадың, баламны ташламагыз, дидең. Ташлыйбызмы соң?! Синнән дә якынрак, синнән дә кадерлерәк тагын берәү бармы соң безнең өчен?!—Арыслан тугач, мин бит аны синнән дә болайрак ярата башладым. Аның йодрыклары зур иде. Оныгым үземә ошаган, мин бу егеттән йә балта остасы, йә краснодеревщик ясыйм, дип кертә идем бит аны чәп-чәпләргә.

—Кыз бала булса, сездә генә калырые. Кыз баланы карау, үстерү әти кешегә кыенрак. Арыслан әтисендә үссен,—дип әйттең васыятеңне.—Сез дә инде байтак яшь белән барасыз. Сезнең белән ул-бу хәл булса, улыма әтисенә иялəнү кыен булыр. Арыслан әтисендә үссен. Әтисенә дә васыять итеп әйтеп калдырам. Кыенлыкларга тап булганда, сезгә таянсын,—дидең...

* * *

Узган җәйне әти-әниләре, Биктаһирның абыйсы Искәндәрне дә алып, җәйге ялга җылы якка бардылар. «Бу эсседә, юлда, баланы чирләтерсез»,—дип, нибары ун айлык Биктаһирны бирмәдек. Үзебездә калдырдык. Дәү әти булуның бар тәмен, бар ләззәтен, бар бәхетен янә дә бер рәхәтләнеп татыдым бу җәйдә. Шар кебек түп-түгәрәк ун айлык малай алпан-тилпән йөри, мин сиңа әйтим, ишек алдын икегә яра бу! Килә килешкә башын пәке белән «Под Фонтамас» алып җибәрдем. Ишек алдына ванна чыгарып куйдым. Өстән июль кояшы кыздырып тора. Ваннадагы суы суынып китсә, чәйнектән кайнарын өстәп торабыз. Көненә бишәр тапкыр коендырабыз. Суда сәгатьләр буена үрдәк булып чупырдый бу, әй! Тавык шулпасында пешкән куе токмачлы аш салынган тәлинкә тотып, дәү әнисе дә янәбызда гына тора. Укробын тураган, катыгын туглаган. Оныгыбыз тамакны ваннада кырын яткан килеш кенә ялгап ала. Әнкәсен имүне, «юк-бар эш бу»,—дип, инде ул күптән ташлады. Бар ашаганы—катык туглаган токмач ашы.

Нәкъ шушы көннәрдә безгә Бөгелмәдән кунак төште. Нибары утыз өч яшендә яман шештән вафат булган олы кызым Гөлнарның улы, олы оныгым Арыслан килгәние. Биктаһирны карашырга ул да бик булышты. Бу ике туган егетләр тиз арада нык дуслашып киттеләр. Менә да сөенеп туя алмыйм. Бу малайларда Җәнбәт җәвере ыруының каны ага бит. Үскәч тә, бер-берләрен ташламаслар әле. Ташламасыннар иде, Йә Раббым! Ул фикерне инде үзләренә тукып кына торам. «Бу дөньяга мин мәңгегә килмәгән, зинһар өчен, берүк шәҗәрәләрегезнең очын җуймагыз!»—дим.

Әйе, без—Җәнбәт ыруыннан! Әйе, бабам ятим үскән. Әтиемне дүрт яшендә үк детдомга илтеп тапшырганнар. Мин исә әниемнән алты көнлек кенә булып калганмын. Кызымның улы Арыслан жиде яшендә калды. Пәйгамбәребез Салләллаһү галәйһис-сәлам—Үзе дә бик яшьли ятим калган бит. Шагыйрь әйтмешли:

Әлләниләр кирәк сыман
Бу адәм баласына.
Барысы да сынау юкса,
Сынау гына—барысы да.

Әллә ниләр кирәк сыман
Бу адәм баласына.
Кала бары шул кирәкне,
Кала... табасы гына...

Аллага шөкер, сер бирмәдек. Адәм балаларына хас булганча, лаеклы яшәргә тырыштык. Тырышабыз. Җәнбәт ыруы дәвам итә!

*Алхәбәр*

## Без кабызган утлар... китап булыр

**Кадерле укучыларыбыз!**

**Озакламый «Сүнмәс утлар балкышы (мең санлы хәзинәдән)» дигән китап дөнья күрәчәк.**

**«Казан утлары»нда 85 еллап вакыт дәвамында басылган иң шәп әдәби әсәрләр дә, кызыклы һәм гыйбрәтле истәлекләр дә, халкыбызның үткәнен һәм бүгенгесен—яхшырак аңларга, киләчәген дөресрәк корырга ярдәм итәрдәй уникаль мәкаләләр һәм документлар да бар монда.**



Рөстәм Мингалим

# МИНЕМ БЕЛӘН ЯШИ ХӘТЕРЛӘҮЛӘР

## Еракларда

**Урман монда—авыр яшел,
учак артык якты.
Чатный кисәү хуш ис сибеп,
чәйгә төшә чаткы.
Ылыс яна,
безнең канда
чиксез җегәр сыман.
Һәрберебез—
йодрык белән
аю җиңәр сыман.
...Гөрли пычкы,
кара яшел наратларны ялап,
Монда узган минутларның
ак төпләре кала.
Көннәр төпкә баш куялар,
айлар балта тоткан—
алар шулай безгә карап,
үз хәлен оныткан.
Кандай кызыл уйдык-уйдык
җиләк ята мүктә.
Җирдә шәһәрләр
юк кебек,
һәм без монда күптән,
әйтерсең
җиләк нәселе,
учак нәселе без.
Дымлы бу кич һавасында
мең тәм төшенәбез.
Әйтерсең шунда туганбыз,
гел калырбыз торып.
Тик безне юлга чакыра
автобус кычкырып...**

Рөстәм МИНГАЛИМ (1937)—*шагыйрь, драматург; егермедән артык китап (лирика, балалар өчен шигырьләр, поэмалар, пьесалар) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Якташлар яныннан

«100 нче буровой»—
Гомердән бер өзек,
Якташлар яныннан —
Себердән бер өзек:
Кояшлы ачыклык,
Караңгы ешлыклар...
...Кар беткәч,
Җир тулып,
Өр-яңа эш чыккан.
Сазлыклар, урманнар
Көтмәгән яңа эш —
Башланган бораулау,
Кузгалган төзелеш.
...Трактор артына
Тагылган тростан
Балыктай наратлар
Качарга тырыша, —
Үләннәр йолкына
һәм баса тырпаеп
Кулларын күтәргән
Кыз кебек яшь каен.
(Борчылып аю да
Йөридер куеда...)
...«100 нче буровой».
Чәй—учак көлендә.
Тәмәке төтене
Ылыска эленә.

Көннәргә ак төннәр
Төенсез бәйләнә,
Кояш — ал тәлинкә —
Туктаусыз әйләнә.
Үкереп үр ала
Кып-кызыл «Татр»лар.
Йөк баскан елганы,
Соры су тартылган.
Шыгырдап баржалар
Ярларга туктала.
Йөк зурга краннар
Ухылдап тын ала
...Җиңү бар урында
Ник әле хәвеф бар?! —
Кешеләр өстендә
Чайкалды торбалар
һәм тимер мәйданга
Төштеләр гөрселдәп...
Ярдәмгә ташландык —
Якташның берсенә...
Тиз аны илтергә —
Үзәккә очарга...
Бик иртә шул аңа
Гомерен очларга.
Калабыз ышанып,
Терелер, йөрер дип.
...Киң Себер күгендә
Вертолет дерелди.

## Нәкъ унбиш ел үткәч...

Көзге төнгә йөзен куйган иде
Күкчәтауның иркен даласы.
Тракторлар уты уйный кырда,
Утка керер төлке баласы.
Тракторлар уты калды кырда,
Анда минем сөргән Җирем бар,
Анда серем белгән дуслар эшли,
Барысы да анда калдылар.
Мине алып китте машиналар,
Хәтерләүләр арттан калмады:
Кайчан гына әле буразнада
Тирли-тирли чылбыр ялгадым.
Уйга килде кинәт бер чибәркәй,
(Хаталанып куйдык бугай шул:
Җанын бүлеп миңа бирер иде...
Тик башкага иргә чыкты ул.)
Сөю хакындагы безнең сүзләр
Балаларча җиңел алданды, —
Ятимнәрне җыйган ана кебек,
Дала җыеп калды аларны.
Минем белән китте хәтерләүләр,
Ни дип калды икән дусларым?
Авырлыктан качты бу егет, дип
Әйтүче дә бардыр ул барын...

Китүченең юлы — гел уңаймы?
Эшләгәннең эше — җиңелме?!
Нәкъ унбиш ел үтте,
Бер уйласам,
Эшлим кебек эшем җимереп.
Бер уйласам, күзгә йөзен куйган
Күкчәтауның төнге даласы...
Һәм кайчаннан бирле тракторым
Кабыза алмый йөдим ләбаса.
Дуслар сөрә әнә.
Төн караңгы,
Шырпы сызып карыйм моторга.
Ни булды соң әле?
Мотор салкын...
Тәмәкем дә беткән тартырга.

## Туган-үскән якларда

Туган-үскән якларда,
иркәләнеп җилләргә,
уздым бер бала сыман
каенлык арасыннан.
Күзләрең карар сыман
каенлык арасыннан.
Туган-үскән якларда,
изү ачып җилләргә,
уздым сулар буеннан,
суда камыш куерган.
Күзләрең карар сыман
камышлык арасыннан.
Туган-үскән якларда,
күптән узган чаклардай,
уздым бер бала сыман
арышлык арасыннан.
Күзләрең карар сыман
арышлык арасыннан.
Карамады күзләрең,
тик һаман да без әле
икәү барабыз сыман
каенлык арасыннан...
Арышлык арасыннан.
Камышлык арасыннан.



Хәбир Ибраһим

# АРТЫК ГОМЕР

ДРАМА, 2 ПӘРДӘДӘ

**Катнашалар:**
Мәүлия—урын өстендә ятучы авыру карчык, 80 яшьтә.
Ярулла—аның ире.
Сабир—Мәүлиянең бертуган энесе, пенсия яшендә.
Сария—аның хатыны.
Халисә—Ярулланың бертуган сеңлесе, пенсия яшендә.
Әмир—аның улы.
Тәүфыйк—Мәүлия апасының малае, 50 яшьтә.
Регина—Сабирның кызы, 28 яшьтә.
Карт.
Күрше хатыны.

Вакыйга безнең көннәрдә авылда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авыл. Өй эче. Уң якта—иске, таушалган диван, диванда—мендәр, мендәрдә—Коръән Китабы.

Чаршау белән корылган караватта авыру карчык Мәүлия ята. Ул тәсбих тартып, дөньядагы һәр тавышка колак салып ята.

Кич булып килә. Күзгә шыксыз вакыт. Монсу көй агыла. Чолан ягыннан бер таба ботка күтәреп Ярулла керә. Табакны карчыгының алдына куя.

Ярулла *(тупас).* Аша!

Мәүлия *(дога кылып).* Ходаем, тамактан аерма.

Ярулла. Синекен аермас, безнекен аерса да...

Мәүлия. Син шулай дисең дә, соңгы вакыт тамактан ризык үтми башлады... Эчем поша нигәдер...

Ярулла *(кул селтәп).* Әй! Эч пошулар булыр инде ул. Бер синдә генә түгел... Тыныч кына ятсана!

Мәүлия *(ризыкка орынмыйча).* Алай, алай...

Ярулла. Тәүфыйкның бер капчык тары ярмасы озакка житәр, Алла боерса, кыш чыгарбыз әле ничек тә.

Мәүлия. Житәр, житәр, Алланың биргәненә шөкер! *(Ботканы, ашамыйча, читкәрәк этәрә.)*

Ярулла. Сарыкларга тимик. Киртән

---

Хәбир ИБРАҺИМ (1958) — *язучы; «Аһәң», «Йокыга талган гүзәл», «Гализ ярым» исемле шигырь, проза, пьеса китаплары, дистәдән артык сәхнә әсәрләре авторы. Казанда яши.*

тулып сарыгың тормагач, авылда яшәүнең ни куанычы бар. *(Утыра.)* Кәҗәбез корышып үлде. Шул кәҗә кебек миңа да корып үләргә язгандыр инде?!

Мәүлия *(коты очып).* Алла диген!! Сиңа кадәр мин үләсе бар әле.

Ярулла. Сөйләмә юкны—син әле үлмисең. Үләреңне ун ел көттек бит инде. Ә үлем синең бер генә жиреңә дә кереп карамады. Аякларың йөрмәсә дә, йөрәгең таза синең, йөрәгең. Нужаң юк, минем күк нужа куып йөрмисең. Урының жылыда...

Мәүлия *(юмалап).* Әй, мулла абзый, зарланма ла, зарланма. *(Кеткелдәп көлеп куя.)*

Ярулла. Минме мулла?! Аптырагач, кеше табалмагач, миннән мулла ясадылар да куйдылар. Көлке инде! «Әлһәүледән» башка берни дә белмим.

Мәүлия. Аптырама: галимнәр аз хәзер, гыйлем тикшерүчеләр дә юк.

Ярулла *(кисәк кенә күтәрелеп).* Ярар. Синең эшең беткән -мин чыгып терлекләргә су эчертеп керим әле. *(Тора.)* Уф, кәеф юк бүген нигәдер. *(Сулы ләгән каршына килә.)*

Мәүлия. Ярулла!

Ярулла. Нәрсә инде?

Мәүлия. Син кая?

Ярулла. Кая... Ләгән каршында...

Мәүлия. Нишлисең ул ләгән каршында?

Ярулла. Күтәрәм.

Мәүлия. Күтәрмә!

Ярулла. Күтәрмичә ничек чыгарасың ди аны, син торып күтәрмәссең бит.

Мәүлия. Күтәрмә, зинһар, өстерәп кенә чык.

Ярулла. Өстерәп йөрергә арба түгел бит ул! *(Күтәрә.)* Ай! Ай! Билем! *(Бөгелеп төшә.)*

Мәүлия. Әй, Аллам, ни булды тагын?

Ярулла *(бер билен, бер эчен тотып).* Ай... үләм... эчем... билем...

Мәүлия *(елап).* Кил монда, кил якынрак...

Ярулла, шуышып, Мәүлия янына килә.

Ярулла. Мәүлия...

Мәүлия. Әү, жаным?! *(Кулы белән Яруллланы эзли.)*

Ярулла *(аның кулын тотып).* Мәүлия... Тыңла мине. Авыр булса да тыңла. Әгәр дә мин үлә-нитә калсам...

Мәүлия. Алла диген!

Ярулла. Тыңла, бүлдермә. Синең үзең генә калуың бар. Балабыз юк, син туганнар кулына калачаксың. Авыру кешене, үзең беләсең, берәү дә бушка карамас, акчаң булса гына... Безнең жыйган акчабыз бар, кассада... утыз мең... *(Тынлык.)* Гөнаһ шомлыгына каршы, мин синең алда зур хата кылдым. Кешегә эшләгән яхшылыгым сиңа яманлык булып төшә күрмәсен дим...

Мәүлия *(картының башыннан сыйпап).* Алланың күңеле киң. Борчылма...

Ярулла. Тыңла... Мин ул утыз мең акчаны, ашыгып, Халисә малае Әмир исеменә яздырган идем. Алдады мине Әмир, әгәр әби үлсә, мин сине шәһәргә жылы фатирыма алып китәм, диде. Хәзер инде берни дә кирәк түгел, мине хәзер мәңгелек караңгы фатир көтә. *(Тынлык.)* Кичерәлсәң, кичер мине, Мәүлиякәй. Мин карт юләр сине акчасыз, ач-ялангач калдырдым. *(Елый.)*

Мәүлия. Йә, йә, шулкадәр хафаланма инде, Аллага тапшырган, нишлисең бит. *(Дога кыла.)*

Ярулла. Синең өчен кайгырам, сине жәллим. Яхшылап тыңла: кассадагы акчаның кенәгәсе сандыкта ята, ә сандык, үзең беләсең, синең караваt астында. Әгәр дә мәгәр Әмир каладан кайтып, акча кенәгәсен даулый башласа, бирмә—ишеттеңме?!

Мәүлия. Ә кемгә бирим соң?

Ярулла. Сабирга бир. Энеңә. Ул карт, ышанычлы кеше, сине бәладә калдырмас...

Радиодан бер көй яңгырап ала. Мәүлия хыялга чумып тора.

Мәүлия. Әү, жаным?!

Ярулла. Исеңдәме?

Мәүлия. Исемдә...

Ярулла. Өйгә килен булып төшкәнең.

Мәүлия. Син мине кыш көне чанага салып, бүләккә дип алган ак мамык шәленә аякларымны төрөп алып кайткан идең... Кулукуллары да бар ие...

Ярулла. Бар идеме?

Мәүлия. Уң як тәртәгә тагылган

ие. Әле менә шуның тавышы колак төбендә чынлап тора.

Ярулла. Болай начар яшәмәдек бугай инде яшәвен. Рәнҗеткән чакларым булса, кичер, үпкәләп калма... Балабыз гына булмады, бала! Картаймыш көнебездә бер таянычыбыз, ярдәмчебез булган булыр иде. Булмады! Тәуфыйкны биш ел карап үстердек. Качты... әниләренә...

Мәүлия. Үзең алып биргән виләсәпидкә утырып...

Ярулла. Кеше баласы кеше баласы шул инде. Нишлисең бит... Тәуфыйк болай ярый ла ул, бабасын онытмый, әз-мәз булса да тондыргалап тора. Халисә малае Әмирне генә аңлап бетерә алмыйм әле мин... *(Тынланып.)* Сумалет тавышы димме суң? *(Капка тавышы ишетелә.)* Кеше бар димме суң? Авыр булса да торып карыйм әле. Уф! *(Бик авыр тора.)* Аның пагудасы каһәр төшкән кебек бит—янгыр коя да коя... *(Тәрәзә янына килә.)* Кемне күрәсең?

Ярулла *(каранып)*. Нинди дер бер шәүлә күрәм, ир кешегә охшаган димме?!

Мәүлия. Әмир түгелдер ич?

Ярулла. Шул, кара әле, шул ахрысы! *(Тынлык.)* Ул!

Мәүлия. Ни дип кайтты икән?!

Ярулла. Улыңны, йә килененне бәрәңге алырга җибәр дип әнисенә хат язып җибәргән идем. Менә кайтып та житте... бәрәңге алынып беткәч. Шул бәрәңге аяктан екты да инде мине. *(Коръән китабын янына салып диванга ята.)* Йә, Алла! *(Мәүлияне кисәтеп.)* Кара аны! Берүк җебеп төшә күрмә! Бирмә кенәгәне!

Әмир керә. Әзрәк кызмача. Кулында сумка.

Әмир. Берәр җан иясе бармы бу йортта, юкмы?! Әллә инде үлеп, дөмегеп беттегезме?! *(Каранып тора.)* Ә?

Ярулла *(күтәрелеп)*. Ә, Әмир! Кайттыңмы, уз әйдә, торып каршы алырга хәлем юк.

Әмир. Кычкырып сөйлә, тавышың ишетелми.

Ярулла. Улым!

Әмир. Нәрсә?

Ярулла. Аягыңнан салганчы әнә шул ләгәндәге суны терлекләргә чыгарып керсәнә.

*(Әмир ләгәнгә кереп баса.)* Тьфу! Ләгънәт! (Пауза) Син нәрсә инде шулкадәр, мин сина ләгәндәге суны терлекләргә чыгарып сал дидем, ә син шакшы аякларың белән ләгәнгә кереп бастың.

Әмир. Гафу ит, бабай, мин монда сарык карарга кайтмадым, сине күрергә дип кайттым.

Ярулла. Мине күрергә иртәрәк кайталар аны!.. Ярар. Сүз сөйләп торуның мәгънәсе юк: өйдәгеләр ничек анда?

Әмир. Ярый шунда...

Ярулла. Әниең ни хәлләрдә?

Әмир. Ни булсын ана! *(Исәнә килеп.)* Авырып ята иде әле. Сезгә сәлам әйтергә кушты. Бүтән авылны күрәлмәм инде дип, арттан елап калды. *(Түргә уза.)* Авырый инде, авырый. *(Үз алдына.)* Овчар-ка!

Ярулла. Минем хатны алдыгызмы?

Әмир. Алган идек кебек.

Ярулла. Алгач, нишләп суң кайтмадыгыз, бәрәңге алышырга?!

Әмир. Әй, бабай, һаман шул бәрәңгеңне сөйләмәле, ә?! Мин бит сине сагынып кайттым, йә бер кочаклаем инде үзеңне! *(Кочагын җәеп, Ярулла янына килә.)*

Ярулла. Кит, кит, орынма мина, баш күтәрерлек тә хәлем юк. Әнә башта әбиең белән исәнләш!

Әмир. Ә, хәзер! *(Мәүлия янына килә.)* Исәнме, әбекәй! *(Мәүлия куркып чаршауны ябып куя.)* Минем, бабай, бу йортта кирәгем шулкадәр генә икән, минем белән кайберәүләр хәтта исәнләшергә дә теләмиләр.

Ярулла. Бәйләнмә ана, авыру бит.

Әмир. Юк, бабай, юк, нәрсә инде син, мин бит әбекәйне яратам, би-и-ик яратам. *(Чаршауны ачып.)* И, карт тәре! Сөйләшмәгән була бит әле, кара, кара, ничек күз кырые белән генә карап ята. Ха-ха! *(Чаршауны каты итеп ябып куя.)*

Ярулла. Ярар, кил әле монда, утыр...

Әмир *(Ярулла янына килеп)*. Бабай!

Ярулла. Әү?!

Әмир. Беләсеңме, мин бит машина алырга җыенам! Машина... «Девятка!»

Ярулла. Шулаймыни! Гаҗәп: мона

кадәр бер дә машина алам дип сөйләнгәнең юк иде.

Әмир. Алырга кирәк. Бөтен кеше машинада йөри, мин кемнән ким?! Хәзер кассада акча тотуның мәгънәсе юк.

Ярулла. Кассада шулкадәр акчаң бармыни синең?

Әмир. Бар. Утыз мең.

Ярулла. Ай-яй! Белмәдем... Миннән яшереп йөргәнсеңдер инде...

Әмир. Юк, бабай, минем синнән бер генә нәрсә дә яшергәнем булмады. Яшергән бер генә нәрсәм дә юк. Менә шул утыз мең акчаны колхоз кассасыннан алырга дип кайткан да идем инде мин.

Ярулла. Каян? Нәрсә ул?

Әмир. Белмәгәнгә сабышма, бабай. Минем авылдагы сберкнижкамда утыз мең акчам бар. Исеңдәме?

Ярулла. Ә, син шул акчаны әйтәсеңмени?! Исемдәсен исемдә лә... Әмма син ул акчаны ала алмассың шул.

Әмир. Ә нигә?

Ярулла. Без исән бит әле, без.

Әмир. Сез үлгәнне көтсәң, ул акчаларның кирәге чыкмавы да бар. Миңа хәзер кирәк! Арзанга машина алам, сөйләшкән кешем дә бар.

Ярулла. Авырга алма, улым, юк, булмый.

Әмир *(басым ясап)*. Димәк?! *(Пауза.)* Бирмим дисең инде. Алдадың, сүзеңдә тормадың. Васыять яздырганда син бөтенләй икенче кеше идең, ә хәзер башка төрле сайрыйсың. Уйла, бабай, уйла...

Ярулла. Мин уйлаган инде, улым, уйлыйсы уйларым күптәннән уйланып беткән.

Әмир. Бердәнбер ышанычлы кешеңне, яраткан оныгыңны югалта күрмә. Кыскасы, йә мин, йә акча! *(Күкрәгенә суга-суга чыга.)*

Ярулла. Уф! Сулыш кыса... китереп терәделәр... кабер авызына...

Мәүлия. Йә, Ходаем, китте мәллә?

Ярулла. Китте. Китәр, бар... тиз генә котылам димә инде син аңардан. Васыятьне дә бит ул эчертеп кенә яздырды... ялгыштым, әй, ялгыштым... *(Тезләнеп Мәүлия янына килә.)* Миңа хәзер берни дә кирәкми, ни акчасы, ни дөньясы!

*(Әмир керә. Кулында бер шешә ярты.)*

Әмир. Бабай!

Ярулла *(сискәнеп)*. Нәрсә?

Әмир *(ярты күрсәтеп)*. Әйдә, берәрне!

Мәүлия *(күреп)*. Әмир җаным, эчертмә бабаңны, болай да чак кына йөри.

Әмир. Әй, бабай, бабай, мине әзрәк кызгансагыз иде! Мин бит сезгә кунакка кайттым. Эшләмим, заводны яптылар. Эшсез, бер тиен акчасыз йөрим.

Ярулла. Ә син үзең кеше җәлли беләсеңме соң?! Кала кадәр каладан кайткансың, әби белән бабайга дип күчтәнәч тә кыстырып кайтмагансың.

Әмир. Күчтәнәч?! *(Исенә төшереп.)* Бар ул күчтәнәч, бар. Мин сезгә алып кайткан идем, сумкада ул. Сумканы кая куйдым соң әле?! Ә менә монда ята, идәндә... *(Күтәрә.)*

Ярулла. Алып кайткан күчтәнәчен дә кешечә тапшыра алмаган бәндәдән ни көтәргә була инде?!

Әмир. Бабай, менә алар... күчтәнәчләр... Әни тыгып җибәрде, юк нәрсә юк монда... Мә, менә! *(Суза.)*

Ярулла. Миңа түгел, әбиеңә бир.

Әмир *(сузып)*. Әби, мә!

Мәүлия *(алып)*. Рәхмәт яусын инде, Әмир улым, аяк-кулларың сызлаусыз булсын! *(Дога кыла.)*

Әмир. Әйдә әле, бабай, утырышыйк әле, сиңа салкын идәндә утырырга ярамый. Биленә салкын тидерерсең җә... *(Ярулланы торгыза.)*

Ярулла. Рәхмәт... их, шушы картлыкны... *(Өстәл янына утыра.)*

Әмир *(стаканнарга аракы салып)*. Бабай, әйдә, бәлкем хәл кереп китәр үзеңә!

Ярулла *(ымсынып)*. Юк инде, син нәрсә! Бу зәхмәтне миңа күрсәтәсе дә булма, ишеттеңме?! Күрмисеңмени соң соңгы хәлемдә утырганымны?!

Әмир. Яшисең әле син, таза син...

Ярулла. Яшәрсең, бар. Аллаһы Тәгалә гомернең артыгын бирми ул — вакыты җитүгә бер минут та тотмый, ала да китә...

Әмир эчеп куя да тагын сала. Ярулла стаканга ымсынып карап тора.

Мәүлия *(тыңланып).* Нишләп тынып калдылар соң әле болар? Ул-бу булмагандыр ич? *(Тынлык.)* Ярулла!

Ярулла *(сискәнеп).* Нәрсә кычкырасың инде?!

Мәүлия. Ярулла!

Ярулла. Суймый торганнардыр ич?!

Мәүлия. Ярулла дим!

Ярулла. Нәрсә инде, җә?!

Мәүлия. Син кая?

Ярулла. Монда... өстәл янында...

Мәүлия. Эчмә! Синен иләс-миләсләнеп китә торган гадәтен бар...

Ярулла. Ярар, тик кенә ят, син әйтмәсән дә беләм.

Әмир. Ну нәрсә, бабай, бирәсеңме? Бүләбезме акчаны? Мин бик нәзберек кеше түгел, акчаның яртысына да риза.

Ярулла. Әбиеннән сора, ул риза булса, алырсың. Кенәгә миндә түгел.

Әмир. Нәрсә, әбидәмени?! *(Ярулла дәшми.)* Их, бабай, бабай!

Ярулла. Мин хуҗа түгел бу йортта, миндә берни дә юк. *(Аракы салган стаканны тиз генә күтәреп эчеп куя.)*

Әмир. Тагын?

Ярулла *(йөткереп).* Юк... житәр... *(Хәлсезләнеп, диванга барып ава.)*

Әмир *(урыннан торып, үзалдына).* Булмады бу—килеп чыкмады. Хәйлә житмәде, хәйлә. Акчасыз кайтсам, теге овчарка башымны чәйнәр инде. Алып кайтсам, шул акчаның чиреген бирермен дигән иде дә бит... Нишләргә соң инде? Почтага барып книжкасыз гына сорап карарга мәллә? Юк, бирмәсләр шул. Бабайның гомере күп калмаган, үлә-нитә калса, акча—минеке! Тик книжка кирәк, книжканың кулда булуы кирәк. Ә книжканы әбидә диде бит! Ә ул, иманым камил, әбинең сандыгында инде. Ә сандыкның ачкычы? Ачкычы кая микән? Шайтан белсен! Әллә сандык капкачын каерып кына ачаргамы?! *(Мәүлиянен караватастында торган сандыгы янына килә).* Менә ул! *(Сандык капкачын каерып, эченә кулын тыга.)* У-у-ух!

Мәүлия *(чаршавын ачып).* Ярулла, синме ул?

Әмир. Мин, мин...

Мәүлия. Ни эзлисең анда?

Әмир. Сандыкның ачкычы кая? *(Бер кулы белән матрац астын капшый.)* Кая соң ул?

Мәүлия *(таянып).* Әстәгефирулла! Әмир, нишлисен син? *(Әмир ягына авыша. Әмирнен кулы сандык капкачына кысылып кала.)*

Әмир *(әче тавыш белән).* Ай! Ай! Кулым бетте, кулым! У-у-у! *(Кулын тартып ала да сикереп тора.)*

Ярулла *(күреп).* Әмир! Тилмертмә безне!

Әмир *(сызланып).* У-у-у! Кулым! Кулым!

Ярулла. Без үлгәч, барсы да сина калыр. Бакчасы да, йорты да... Көт инде әзрәк!

Әмир *(сүгенеп).* Кирәкми! Кирәкми! Акчагыз да, йортыгыз да, үзегез дә кирәкми... Дөмегеп китегез! *(Чаршауны Мәүлиянен башына каплап, йөгереп чыгып китә.)* Мин сезне күмәргә дә кайтмаячакмын...

Мәүлия. Ярулла... кил әле... *(Чаршауга чорналып.)* Ярдәм ит...

Ярулла *(кузгалып).* Киләм, киләм...

Мәүлия. Киләсенме...

Ярулла. Киләм бит инде... Сабыр ит бераз... жайраплан түгел ләса...

Мәүлия. Чаршауны рәтлисе иде...

Ярулла. Чаршауны түгел, безне рәтләргә кирәк, безне. *(Чаршауны күтәрә.)* Бирмәденме?

Мәүлия. Нәрсәне?

Ярулла. Кенәгәне, мәйтәм, бирмәденме дим?

Мәүлия. Юк, нишләп бирим, сандыкны ача алмады. Ачкычы юк. Ә кая соң аның ачкычы?

Ярулла. Матрац астында, синен аяк очында.

Мәүлия. Ярар, Аллага тапшырган инде!

Ярулла. Халем бер дә әйбәт түгел... Мәүлия... үләрмен, ахры... *(Бөгелеп төшә.)*

Мәүлия. Әй Аллам, нишләргә соң инде? Ичмасам, Сабир да килеп чыкмады. Ике айга бер булса да килә торган иде... Күрше дә керми...

Ярулла. Мәүлия...

Мәүлия. Әү, жаным?!

Ярулла. Бәхил бул... Ятып торыйм әле... үлә калсам... бәхил бул...

Мәүлия *(күз яшьләрен сөртеп).* Әй

Аллам! *(Ярулла янына диванга үрмәли.)* Ярулла!

Ярулла. Нәр...сә?..

Мәүлия. Алай-болай... шундый хәл була калса... Синең үлгәненне мин ничек белермен соң?

Ярулла *(көч-хәл белән диванга авып)*. Мин... менә шулай кулымны күтәреп ятармын. Әгәр кулым төшсә... бәхил бул...

Мәүлия. Йә Хода, берүк мәрхәмәтеңнән аерма! *(Тиз-тиз генә дога укып ала.)*

Машина килеп туктаган тавыш килә. Бераздан өйгә, шаулашып, Сабир, Сария, Тәүфыйк керә.

Сабир. Йә, малайлар, килеп життек! *(Тынлык.)* Нишләп яталар икән инде бу пәри йортындагы адәмнәр?! *(Тынлык.)* Йә Хода, бөтенләй тәртип калмаган бу йортта. Бу чаршау нишләгән соң бу? Ауганмы? *(Чаршауны күтәрә.)* Апа! Апа!

Мәүлия *(сөенеп)*. И, Сабиржан, рәхмәт төшкере! Ходай ишеткән минем ялваруымны, ишеткән. Йә, бер дога кылыйк. *(Барсы да утырышып, дога кылалар.)*

Сабир. Хәлләрегез ничек?

Мәүлия. И-и, әйбәт түгел шул бер дә, әйбәт түгел.

Сабир. Ни булды?

Мәүлия. Бабагыз, бабагыз үләргә ята.

Сабир. Кая?

Мәүлия. Әнә шунда... диванда...

Сабир. Нишләп аны керүгә үк әйтмисең, сөйләндереп утырасың. *(Сариягә.)* Сария, кара әле, ни булган аңа?

Сария Ярулла янына килә, Тәүфыйк та аңа иярә.

Мәүлия *(Сабирга)*. Үзең генә килденме?

Сабир. Юк. Сария дә, Тәүфыйк та монда.

Мәүлия. И, Алланың рәхмәте!

Сария *(кычкырып)*. Жизни!

Тәүфыйк. Жизни!

Сария. Дәшми...

Сабир. Үлмәгәндер ич?!

Тәүфыйк. Исән булырга тиеш.

Сария *(тотып)*. Аяк-куллары бик салкын. Врач чакыртырга кирәк.

Сабир. Ә кулы нишләп күтәрелеп тора?

Тәүфыйк. Акылындадыр ич?

Мәүлия. И-и... исән... кулы күтәрелеп тора. *(Елмая.)*

Сабир. Ә нишләп күтәреп тора соң ул аны?

Мәүлия. Без шулай сөйләшкән идек... Исән булса, кулы күтәрелеп торыр, төшсә... үлгән булыр... Йә, Рабби...

Сабир *(Тәүфыйкка)*. Төшереп карале кулын—нишләр микән?

Тәүфыйк Ярулланың кулын төшерә. Кул төшми.

Тәүфыйк. Агач күк каткан... Төшерә торган түгел...

Сабир. Ярар, төшмәсә. Димәк, исән әле.

Регина керә.

Озак йөрисең, кызым. Машина ишеген яптыңмы?

Регина. Ишегалдыннан кергәндә нindiдер бер ир кеше белән очраштым. Мине күрүгә, киртә эченә кереп качты.

Сабир. Күзенә генә күренәдер. Караңгыда агач кәүсәсе дә кеше шәүләсе булып күренә.

Регина. Күрдем. Яшь егеткә охшаган.

Тәүфыйк *(елмаеп)*. Яшь кызларның күзенә гел яшь егетләр генә күренә инде.

Сабир. Эшләр начар, кызым, әнә жизни бабаң үләргә тора.

Сария. Якынрак кил, кызым, ишек катында торма.

Регина *(читенсенеп)*. Куркам... үлгән кешедән...

Сабир. Нәрсә куркасың, ул бит әле үлмәгән, исән. *(Сариягә.)* Сөйләшеп карале жизни белән, бәлкем берәр сүз чыгара алырсың?

Сария *(Яруллага)*. Жизни! Жизни!!!

Ярулла. Ә-ү-ү...

Сария. Мине ишетәсеңме?

Ярулла. И...ше...тәм...

Сария. Танийсыңмы мине?

Ярулла. Та...ныйм... Са...а...рия...

Сабир. Сора әле, көткән кешесе юк микән?!

Сария. Көткән кешең юкмы, жизни, беркемне дә көтмисеңме?

Ярулла. Юк, көт...мим... *(Башын*

*чайкый.)*

Сария. Халисәне дә көтмисенме?

Ярулла. Юк... кайтмыйм... дигән...

Сария. Кара әле, Сабир, жизнидән гел аракы исе килә, әллә салган ук инде?!

Тәуфыйк *(стаканнарга күрсәтеп).* Салуы хак. Әле үзе генә дә түгел, ике кеше салганнар.

Регина *(тәрәзәдән карап).* Ишегалдында кемдер йөри кебек...

Сабир. Син кеше куркытып йөрмә әле, кит тәрәзә буеннан! *(Мәүлиягә.)* Апа, сезнең янга бүген берәр килүчекитүче кеше булмадымы?

Мәүлия. Булды, булды. Халисә малае Әмир кайтты.

Ярулла *(кычкырып).* Мәүлия!

Мәүлия. Әү, жаным?!

Ярулла. Би-и-ирмә!

Сабир *(Мәүлиягә).* Нишләп аны безгә, килүгә үк, әйтмәдең?!

Мәүлия. Аның әле менә кучтәнәчләре дә бар... бер сумка...

Сабир *(Тәуфыйкны чакырып).* Бар, чыгарып бир сумкасын, үз юлын карасын! *(Тәуфыйк сумканы әләктереп чыгып китә. Сабир тәрәзә янына килә.)*

Ярулла *(Соңгы сулышын алып).* Мәү...лия... Мә...ү... бә...хил... бул... би...р...мә... *(Кулы төшеп китә.)*

Сария. Балалар! Балалар! *(Тынлык.)* Бабагыз үлде!

Мәүлия *(яшь аралаш).* Ясин, ясин! *(Дога укый.)* Ясин вәлкурәәнилхәкиим.

Регина *(сискәнеп).* Әти!

Сабир. Нәрсә, кызым?

Регина. Бабай үлде!

Сария. Жизни... үлде...

Мәүлия *(укып).* ...Вәжә галәмин...

Сабир *(тәрәзәдән күзен алмыйча).* Амин.

Монсу көй агыла.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Төштән соң. Кич булып килә. Шул ук сәхнә. Өй эчендә бушлык сизелә—җиһазларның күбесе тышка чыгарылган. Өстәлнең бер читендә бәлешләр, җимешләр өелеп тора. Өйдә Мәүлия, урта бер урында Сабир, аның тирәсендә—Сария Тәуфыйк, Регина.

Сария. Бабагызның өчесе дә үтеп китте. Жидесен үткәреп булырмы, юкмы?

Сабир. Жидесен генә түгел, кырыгын да үткәрербез. Бездән калмас. Мине, балалар, бүген бөтенләй икенче нәрсә борчый әле... Нәрсә дисезме? Әбиегез белән нишлибез? Карчыкны кая куябыз?

Тәуфыйк. Уйлашырга кирәк инде, абый.

Сабир. Әбиегезнең кассада утыз мең акчасы барлыгын барыгыз да яхшы беләсез. Тик кызганыч: кулыбызда книжка була торып та без ул акчаны әлегә ала алмыйбыз. Бабагыз Ярулла үзе исән чагында бик зур хата жибәргән һәм бу турыда әбиегезгә дә сөйләгән. Ул кассадагы барлык акчаны Халисә малае Әмиргә васыять итеп яздырган. Безгә хәзер апаның акчасын үзенә кайтарып бирергә кирәк. Нишлибез? Ничегрәк хәл кылабыз?

Тәуфыйк. Судлашырга кирәк Әмир белән, дөреслек безнең якта. Халык безне аңлый, яклый, суд та аңлар, яклар дип уйлыйм.

Сабир. Дөрес. Кайвакыт син дә акыллы гына сүзләр әйтеп куясың. *(Көлә.)* Закун дигән гамәлнең безнең өчен бер унай ягы да бар. Анда болай диелгән: «Караучысыз калган гарип-горабаның васыять ителмәгән байлыкның да яртысын алырга хакы бар». Ул утыз меңнең яртысын без судлашмыйча да ала алабыз. Калган яртысын да мин жилгә очрырга уйламыйм. Мин башта ул утыз меңне бабагызның сеңлесе Халисәләр белән урталай бүләргә уйлаган идем. Ләкин аларның монда кайтып, эшләгән әшәкелекләрен күргәч, аларның карчыкка тиешле акчаны бүлешергә теләмәгәнлекләрен аңлагач—мин ул имансызларга бу йорттан бер генә тиен дә бирмәскә булдым.

Тәуфыйк. Дөрес. Бик дөрес. Башта Халисә абыйсын күмәргә дә кайтмады. Ә инде мал бүләргә кирәклеге исенә төшкәч, шундук кайтып та төште.

Сабир. Шушы мескен карчыкның соңгы валчык икмәгеннән дә мәхрүм итәргә жыенган ул адәм актыкларына мин берни дә бирмәячәкмен!

Сария. Акрын, ишетә күрмәсен!

Сабир. Ишетсен! Ә нигә син аннан куркасың, мин аңардан курыкмыйм, мин аңа кергәч тә шул сүзне әйтәчәкмен. Ә кая әле ул?

Сария. Келәттә йөри, һаман әйбер актарына.

Сабир. Менә, менә.

Сария. Абыйсын жирләгәннең икенче көнендә үк әйбер бүләргә тотынды бит ул. Башта книжка эзләде. Табалмады. Аннан абыйсының яндырасы иске-москыларына кадәр жыйнарга тотынды, почтальон керткән соңгы пенсия акчаларын бөтереп кесәсенә тыкты...

Сабир. Күпмеләп иде анда?

Сария. Сигез йөз.

Сабир. Син шуны бирдеңме?

Сария. Тартып алгач, нишлим инде. Аның әле бу гына түгел, планнары бик зур.

Сабир. Нәрсә тагын?

Сария. Бабагызның өеннән дача ясарга хыяллана.

Сабир. Дача? *(Көлеп куя.)* Дача кирәк түгел аңа, йортның акчасы кирәк. Мөмкинлеге булса хәзер үк сатар иде ул йортны. Тик юк шул инде—эзрәк соңгарак калды. Мин колхоз рәисе белән сөйләшеп куйдым: йортны колхоз үзенә алачак, ә акчасы—апага!

Тәүфыйк. Сатарлыгы юк инде бу йортның—нигезе черек. Белмим, күпмегә алырлар?

Сабир. Күпмегә алсалар да ярар, үзенеке үзенә булыр.

Тынлык урнаша. Мәүлиянең чаршау артында бәет көйләгән ишетелә. Регина елмаеп аны тыңлап утыра.

Сабир. Йә, ярар! Бу кадәресе аңлашылды бугай. Менә апа белән нишләргә инде?

Тәүфыйк. Ничек нишлибез?

Сабир. Кая куябыз апаны?

Тәүфыйк. Кая?! Авылга алып кайтабыз.

Сабир. Авылга алып кайтачагыбызны мин үзем дә яхшы беләм. Тик кемгә?

Тәүфыйк. Кемгә дип... Бергәләп карарбыз инде...

Сабир. Апаның авылда өч тугань бар: мин, Тәүфыйк һәм Зөлфия. Мәүлия минем бертуган апам, Тәүфыйк—Мәүлия апасының улы, Зөлфия—апаның бертуган сеңлесе.

Сария. Зөлфия качты.

Сабир. Кешенең кем икәнен бәла килгәч кенә беләсең икән. Йә, нишлибез апа белән?

Тәүфыйк. Мәүлия апаны бергәләп карарга кирәк булыр. *(Тынлык.)* Акчасын бүләргә дә...

Сабир. Ничек?

Тәүфыйк. Бер ай бездә, бер ай сездә, бер ай, әйтик Зөлфия апаларда.

Сабир. Анда-монда йөртергә ул бит футбол тубы түгел, энекәш. Авыл халкы ни дияр? Ул мона үзе дә риза булмас!

Тәүфыйк. Бөтенләйгә алалмыйм. Минем үземнең дә өйдә бер карчык ята бит инде: хатынның анасы: Аны бит мин түгел, хатын караячак. Ә хатыннар...

Сабир. Аңлашылды. Дәлше сөйләмәсәң дә була. Мин сине шулай әйтерсең дип көткән дә идем. Әйе, син дә карчык өстенә карчык жыялмыйсың. Шуңа күрә сиңа көчләп тәкъдим итүнең мәгънәсен күрмим.

Тәүфыйк. Юк! Карый алмыйсыз ул карчыкны, хәзер сезнең үзегезне карар вакыт житкән.

Сабир. Ансы да дөрес. Авыруны жилкәмә күтәреп мунчага йөртә торган вакытларым үтте шул инде. Тыштан ялтырасам да, эчтән тузган. Без хәзер шул алдагы инерция белән генә йөрибез инде... Ләкин авыру карчыкны барыбер карарга кирәк, ул безнең өстә. Шуның өчен дә уйлашырга кирәк...

Тәүфыйк. Акчасын бүләргә дә...

Регина. Мин аны үзем белән общагага алып китәм, минем белән торыр. Шулай бит, әби?!

Сария. Туктагыз әле, нишләп сон баядан бирле курчак уены уйныйбыз. Апаның үзеннән сорарга кирәк, ул да кешедер бит?! Әйтсен—кемгә кайтырга теләгәнен!

Сабир. Акыллы сүз әйттең, хатын. Чынлап та, сорыйк үзеннән. Нишли ул—йоклыймы, уянганмы?

Тәүфыйк. Эше беткән аның. Ята Аллаһысы белән сөйләшеп...

Мәүлиянең тыныч кына бәет көйләгәне ишетелә.

С а б и р *(елмаеп).* Эше худта монын. Без монда жан талашып анын язмышын хәл итеп утырган булабыз, ә ул жыр көйләп ята.

С а р и я. Нәрсә көйли соң ул?

Р е г и н а. Бәет. Бабайга багышлап бәет чыгарган.

Мәулия бәет көйли. Елый.

С а б и р *(Сариягә).* Әйдә, ярар, сора инде!

С а р и я *(Регинага).* Кызым, син генә сорасана!

Р е г и н а. Әби!

М ә у л и я. Әү, жаным, ни бар?

Р е г и н а. Кемнәргә кайтырга уйлыйсын, шуны сорыйлар. Безгәме, Тәуфыйк абыйларгамы, әллә...

М ә у л и я. Ә... ни... төш күрдем, кызым... Төп йортка кайтып төшкәнмен икән...

С а б и р. Төп йортка диме?

Р е г и н а. Әйе.

С а б и р. Димәк, безгә инде.

Т ә у ф ы й к. Төш кенә бит ул...

С а р и я. Сөйләсен, әйдә, тынлыйк әле!

М ә у л и я. Төп йортка кайтып төшкәнмен икән дә, терелеп аягыма басканмын. Кап-карангы төн. Бакчага кереп барам.

С а р и я. Кайсы бакчага икән: арткысынамы, алгысынамы?

С а б и р. Хе! Кайсысына булса да бер түгелмени инде?!

Т ә у ф ы й к. Соң төш кенә бит инде ул...

М ә у л и я. Бакча тулып кызарып чияләр пешеп утыра...

С а р и я. Чияләр булгач, арт бакча инде.

М ә у л и я. Бер чия агачыннан өч жимешен алып ашадым. Тагын берне алып ашарга дип үрелгән идем, кемдер артымнан килеп кулымнан тотып алды...

Р е г и н а. Ә кем, әби?!

М ә у л и я. Шайтан белсен инде, кызым. Берәр иблис токымыннандыр инде...

С а б и р. Беттеме?

М ә у л и я. Менә шул адәм мина болай ди: «Бу бакчада тукланыр ризыгын калмады, бар, башка жирдән эзлә!»—диде. Ул шулай дигәч, мин бакчадан чыгып йөгердем... Тамак өзелү инде бу. Төшне дә шуна юрадым.

С а р и я. Нәрсә дип юрадын?

М ә у л и я. Болай дип... өч чия ул өч ел гомер инде... Доньялыкта тагын өч ел гына гомер яшисем калган...

С а б и р. Нәрсә ди ул?

С а р и я. Өч ел гомерем калган, сезне тагын өч ел жәфалыйсым калган ди...

Т ә у ф ы й к. Яши әле ул, озак яшәячәк.

С а б и р. Яшәве көн кебек ачык. Йөрәге таза—жил тими. Консерва банкасында яткан кебек ята рәхәтләнеп... Мин бит аны авылга алып кайтып бер аякка бастырган идем инде. Ишегалдынын бер башыннан икенче башына шырпы ташыттым мин анар. Жепкә тотынып барды, жепкә тотынып кайтты. Тәмам аякка бастырып жибәрдем. Терелеп китте. Ә өенә кайткач, авырыйм дип, кабат урын өстенә менеп яткан. Шулчакны аларга шул Халисә кайткан булган. «И, апам, жаным, син авырыйсын, сина жылы кирәк бит!»—дип, тегене жылы мич башына менгереп яткырган. Шуннан тагын кәкрәеп катты ул. Тагын аяксыз калды. *(Тынлык.)* Ну, мин аны торгызам әле, торгызам!

Т ә у ф ы й к. Сон инде, абый, сон.

С а б и р. Сон түгел, нишләп сон булсын. Теләгем булса, мин үлгән кешене дә торгыза алам. Үз кирәгенә йөрерлек булса да йөрерлек итәм әле мин аны! *(Мәулия янына килә.)* Әнә, карагыз сез ана, сул кулы бөтенләй йөрми, ә ун кулыннан өч кенә бармагы хәрәкәттә... Ризыкны авызына алып кабар өчен өч кенә бармак калдырган. Жайгә чыккач, терелтәм әле мин аны, билләһи, терелтәм! *(Мәулиягә)* Апа, әйдә, бераз кыймылдат әле аякларынны, яле, йә!

М ә у л и я *(анламыйча).* Нәрсә?

С а б и р. Бераз физкультура ясадим—аяк-кулларынны селкет!

Мәулия теләмичә генә аякларын селкетә.

С а б и р. Менә! Маладис!

М ә у л и я. Сызлый... аякларым... булмый...

С а б и р. Сызлар да бетәр! Әйдә, әйдә! Иренмә! Мин синнән кеше ясаячак әле, ясаячак!

Сабир арты белән борылгач, Мәулия аягын селкетүдән туктый, Сабир борылгач, тиз-тиз селкетә.

Сария *(Сабирга).* Синнән генә шикләнә!

Сабир. Йә, Хода! *(Көлешәләр.)*

Тәүфыйк. Полиартрит.

Сабир. Полиартрит түгел, ялкаулык көчле аңарда, ялкаулык. Озак яшәр, әле бездән дә калыр.

Сария. Бездән дә калмасын иде инде.

Сабир. Калачак. *(Регинага)* Әнә яшьләр кулына кала күрмәсен инде.

Регина. Сиңа, әти, яшьләрне хурларга гына булсын инде.

Сабир. Хурламыйм. Дөресен әйтәм. Хәзерге яшьләр үзләрен генә көйләргә өйрәнгәннәр.

Регина. Яшьләрнең дә төрлесе бар. Авыру әти-әниләрен караучылар шактый.

Сабир. Бала әти-әнисен карарга тиеш инде ул, шуның өчен үстерәсең дә баланы. Мин, әнигә ярдәмем тисен дип, Үзбәкстанга киткән җиремнән кайттым. Ач, хәерче җиргә кайттым. Әткәй сугышта үлде, ә әни, мин кайткач, икенчегә кияүгә чыкты. Әниең белән өйләнешкәннән соң, минем әнием үлеп китте. Без әниең белән авыру үги атаны соңгы сулышына тиклем карадык...

Сария. Ул вакыт халык икенче иде: мәрхәмәтле, иманлы...

Сабир. Хәзерге киленнәр үги аталарын түгел, үз аталарын да карамыйлар.

Сария. Элек хатыннар ирләреннән куркып торганнар. Хәзер ирләр хатыннарыннан куркалар. Минем атап әйткән сүзем шул: апаны мин караячакмын. Теләп түгел, мин үзем дә сау-сәламәт түгел. Сабирның туганы булганы өчен генә караячакмын.

Регина *(торып).* Әни, ә без кайчан авылга кайтабыз?

Сария. Туйдыңмы?

Регина. Ардым.

Сабир. Син генә түгел, барыбыз да ардык. Беребезнең дә бу үрмәкүч оясында минут та торасы килми. Без инде өйдә терлек, аларны карыйсы бар дип ашыгабыз, ә сиңа нәрсә ашыгырга?

Регина. Авылга кайтуга ук районга китәм. Яңа спектакль чыгарасы бар.

Сабир. Нәрсә куясың? Мәхәббәтме?

Регина. Мәхәббәт.

Сабир *(ирония белән).* Водевиль!

Регина. Во-де-виль!

Сабир. Ясалма әйбер, димәк. Юкбар әсәрләргә кызыкмас иден, кызым, куйсаң син чын әйбер куй, тормышчан, халыкчан булсын. Халык күрә ул, халыкны алдап булмый.

Регина. Андый әсәрләрне сирәк язалар хәзер.

Сабир. Юк икән, үзең утырып яз. Син язгалыйсың бит. Әнә яз әбиең турында, чагылдыр аның ачы язмышын... Нинди вакыйга! Нинди гыйбрәтле тормыш!

Сария. Яз, кызым, яз, белмәгәнеңне үзем әйтеп яздырырмын.

Сабир. Ул теге Халисә белән Әмирнең кыланышлары үзе бер театр бит!

Регина *(тәрәзәдән карап).* Театрың әнә капкадан кереп килә. Артыннан бер егет тә ияргән.

Сария. Улы Әмир кайтты микәнни?! Әнисен алырга кайткандыр!

Тәүфыйк *(тәрәзәгә килеп).* Шул инде шул, Әмир.

Сабир *(көлеп).* Нас-лед-ник!

Халисә керә.

Халисә. Малаем кайтты. Бүген үк китәргә исәп.

Сабир *(исе китмичә).* Ярар инде, хәерле сәгатьтә!

Халисә *(усалланып).* Бик тиз котылырга җыенасың әле син бездән, Сабир!

Сабир. Мин сезне куарга уйлаганым да юк—калыгыз!

Халисә. Яратмыйсың инде безне?!

Сабир. Әйе, яратмыйм. Ә ни өчен сезне яратырга?! Ни өчен мин сезне яратырга тиеш?!

Халисә. Безне бөтенләйгә исәптән чыгарып ташларга уйладың. *(Күкрәгенә сугып.)* Начармы-яманмы, мин мәрхүмнең туганы, сеңлесе. Безгә дә бу йорттан нинди дә булса өлеш чыгарга тиештер бит инде?!

Сабир. Тиештер. Мин башта сезгә бүлеп бирергә уйлаган идем, тик соңыннан кире уйладым. Ә ни өчен кире уйлаганымны син инде бик яхшы беләсең!

Халисә. Син мине үзең белән чагыштырма, Сабир. Син гомер буе начальник булдың, шуңар да бал да майда гына йөздең. Малың да, абруең да бар. Ә менә минем бернәрсәм дә юк.

Сабир. Казанда өч бүлмәле фатирың бар түгелме соң?

Хәлисә. Бар. Фатир гына коткармый. Мин хәзер пенсиядә. Улым эшләми. Утырып ашарга урындык та юк өйдә.

Сабир. Мескенләнмә, Хәлисә, мескенләнмә, без барсын да беләбез.

Хәлисә. Мәрхәмәтсез!

Сабир. Ә синең үзеңдә бармы соң ул мәрхәмәтлелек? Авыру карчыкның соңгы тиенәнә кул тидерергә теләүче син түгелме соң?

Тынлык.

Хәлисә. Ярар. Бәхәсләшүдән файда булмас. Тыңлагыз, минем сезгә бер тәкъдимем бар.

Сабир. Нинди тәкъдим?

Хәлисә. Болай: минем малаем бар.

Сабир. Беләбез.

Хәлисә. Сезнең кызыгыз!

Сабир *(торып)*. Җә, шуннан?! Сөйләп бетер!

Хәлисә. Менә шушы ике яшь йөрәкне бергә кушсак, безнең арадагы бәхәсләр бик тиз тынар иде.

Сария *(чәчрәп)*. Бусы ни инде тагын? Нәрсә, минем кызым риза булыр дип уйлыйсыңмы синең исерек малаеңа чыгарга.

Регина *(Хәлисәгә)*. Сез нәрсә мине хурларга уйлыйсызмы? Ул исерек малаена кияүгә чыгарга түгел, мин аның чыраена карарга да чирканам!

Хәлисә *(чигенеп)*. Алла... Ходаем!

Регина. Тагын сезгә шуны да әйтәсем килә, мин сезне кайтканнан бирле күзәтеп торам. Сезнең ни өчен кайтканыгызны да яхшы беләм. Сез мәрхүм туганыгызны искә алырга түгел, ә авыру карчыкны таларга кайттыгыз. Мал кайгысы сезнең чыраегызга чыккан! *(Хәлисә йөзен каплый.)* Әйе, әйе, әнә оятсыз йөзегезне көзгедән барып карагыз!

Хәлисә. Әстәгъфирулла! Мондый киленең булса—өйдән чыгып качарсың, билләһи!

*(Сабир, Сария, Тәүфыйк көлешәләр... Әмир керә.)*

Әмир. Тә-ә-әк! Исәнмесез! *(Сабирга)* Сабир кода сез буласызмы?

Сабир. Кодасын белмим. Сабир абзаң мин булам.

Әмир. Бир!

Сабир. Нәрсә?

Әмир. Бир, давай!

Сабир. Нәрсә бирим? Мин сиңа берни дә тиеш түгел!

Әмир. Тиеш. Акча минеке. Акча минем исемгә язылган.

Сабир. Ялгышасың, энекәш. Акчага тәтән хуҗа... закон буенча да, намус буенча да.

Әмир. Бир! Бир книжканы! Син—карак! Минем акчамны урладың, мин сине судка бирәм. Авылыңа кайтып йортыңны яндырачакмын, бир!

Сабир. Яхшы. *(Кесәсеннән книжка чыгарып.)* Бирәм мин сиңа бу книжканы, бирәм. Мә!

Әмир. Бир...

Сабир. Ал! *(Книжканы югары күтәрә.)*

Әмир *(сикергәләп)*. Бир, уйнама!

Сабир. Бирәм. Тик бер шарт белән.

Әмир. Хәлисә. Нинди шарт?

Сабир. Шарты болай. Әгәр дә син тәтәңне үзеңә карарга дип алып кайтсаң—акча тулысы белән синеке булачак. Йә, ничек?

Әмир *(аптырап)*. Китәм, алып китәм...

Сабир. Алып китсәң, карчыкны яхшылап карарга инде, шәләй-вәләй йөртергә түгел.

Сария. Авыру карчыкны каравы, ай-яй, бер дә җиңел түгел шул.

Тәүфыйк. Утыз мең генә түгел, йөз мең дә күзгә күренмәскә мөмкин.

Әмир. Карыйм, карыйм, алып китәм... Тик хәзер үк түгел!

Сабир. Ә кайчан?

Әмир. Минем хәзер машинам юк, авылга да попутный белән генә кайттым.

Сабир. Табам мин сиңа машина, тик алып кына кит. Үзем үк илтеп бирәм. *(Тынлык.)* Тик син башта әбиеңнән сора: риза микән ул сиңа кайтырга?!

Хәлисә. Ниемә безгә ул карчык, ул гына җитмәгән иде -өйнең ямен җибәрергә!

Мәүлия. Сария! Сария, кая син?

Сария. Монда, апа, монда, ни бар? *(Мәүлия янына килә.)*

Мәүлия. Бернәрсә искә төште. Кияүгә чыкканда Яруллам миңа бик шәп мамык шәл алып биргән иде. Ул чоланда гардеробта эленеп тора. Бабаң истәле-

ге. Алып кер әле шуны. Сезгә кайтырга туры килсә, аягымны шул мамык шәл белән төреп кайтырмын.

Сабир *(Халисә белән Әмиргә)*. Ишеттегезме инде, сезгә кайтырга уенда да юк аның.

Халисә. Ул сезнең туганыгыз, сез аны карагыз да инде. Җаныгызга төшәчәк әле ул сезнең, төшәчәк, әйтте диярсез!

Сария. Карганма, Халисә. Олы була бел. Авыру кешене карау ул изге гамәл.

Карт керә. Култык таягына таянган. Килеш-килбәте белән Ярулланы хәтерләтә.

Карт. Әссәләмәгаләйкүм!

Сабир. Вәгаләйкем!

Карт утырып дога кыла.

Сабир. Ни йомыш?

Карт. Мин күрше авылда яшим, шуннан килдем. Хәйбулла абзагыз булам мин. Йомышым шундый: минем карчыгым өч ел авырып урын өстендә ятты. Карчыгым терелә калса, муллага биш йөз тәнкә акчалата сәдака бирермен дип нәзер кылган идем. Аллаһының рәхмәте, хатыным терелеп китте... Ә ни... мулла үзе кая соң әле?

Сабир. Мулла—мәрхүм. Өченче көн генә җирләдек.

Карт. Әй, шулаймыни, кызганыч, бик кызганыч. *(Акчасын сузып.)* Кемгә бирим соң инде?

Сабир. Карчыгы исән—аңа бир.

Халисә. Монда бир! *(Акчаны тартып ала.)* Абый акчасы бу!

Сабир. Имансыз да икәнсең!

Халисә. Улым! Киттек, әйдә! Безгә монда көн калмады. Киттек! Төргәкләр чоланда... пароходка соңга калмыйк! *(Сабирга усал.)* Хуш! *(Чыгып китә.)*

Әмир. Карагыз аны, мин әле моны болай гына калдырачак түгел! Күрерсез! Акча минеке булачак! *(Ишекне каты ябып чыга.)*

Карт. Ярар... китим инде...

Сабир *(картка)*. Кара әле, кайсы авылдан килдем дип әйттең?

Карт. Моннан гына... мин... Ярый, оланнар, сау булып торыгыз, талашмагыз. Аллаһы Тәгалә беребезгә дә артыгын бирмәгән—һәр барчабызны теге дөнья... ахирәт көтә... *(Китә.)*

Сария. Бигрәк сәер карт булды әле бу.

Тәүфыйк. Гел җизнигә охшаган, чат җизни!

Сабир. Мин дә сизендем. Күрше авылдан килдем ди. Шушы яңгырда... җәяү... Ә бәлкем ул үзедер?!

Сария. Кем?

Сабир. Ярулла, Ярулланың өрәге.

Сария. Әстәгефирулла! Син бигрәк инде!

Сабир. Ә нәрсә, бик мөмкин. Сәер, сәер... Тагын яңгырга чыгып китте... Тәүфыйк!

Тәүфыйк. Нәрсә?

Сабир. Бар әле, картны кире бор! Безнең белән машинада кайтыр.

Тәүфыйк чыгып китә.

Регина. Әти, кайтабызмы?

Сабир. Кайтабыз. Мин инде күптән китәсе идем, Халисәләрнең киткәнен генә көтеп тордым.

Регина. Әти, ә мин пьесамны яза башладым инде, ул болай башлана...

Сабир. Тәмамларга вакыт, кызым, спектакль тәмамланып килә.

Тәүфыйк керә.

Тәүфыйк. Юк.

Сабир. Нәрсә юк?

Тәүфыйк. Карт юк. Җир уптымыни—беркайда да юк.

Сабир. Сәер.

Сария. Бу йортка җеннәр ияләшмәгәннәрдер ич?

Сабир. Ярар, житәр, безгә дә җыенырга кирәк.

Сария. Апаны нишләтәбез?

Сабир. Шәленә төрәбез дә машинага чыгарып салабыз.

Сария. Ярар алайса, мин шәлен карап керим әле! *(Чыга.)*

Тәүфыйк. Бәрәңгеләр, утыннарны нишләтәбез?

Сабир. Бәрәңгеләр, утыннар калып торырлар. Икенче вакыт. *(Утыра.)* Уф, эт булып ардым. *(Мәүлия чаршауны ачып карый.)* Китәбез, апа, әйберләренне җыйнарга кирәк.

Мәүлия. Үзем кая—әйберләрем дә шунда булыр инде.

Сабир *(көлеп)*. Әйбер! Нинди әйберең булсын инде синең?! Кара син бу

хәерчелеккә! Үрмәкүч оясы! Берәр ай килмичә торсам, бөтенләй пәрәвез каплап китә иде бит!

Сария керә.

Сария. Юк. Апаның шәле юк!

Сабир. Кая киткән соң?

Сария. Халисә алып киткән. Бөтен гардеробны актарып бетергән.

Сабир *(торып)*. Карак! *(Тынлык.)* Бөтен ил караклар белән тулды.

Күрше хатыны керә.

Күрше. Исәнмесез! Китмисездер бит?

Сабир. Китәбез. Хәзер үк!

Күрше. И-и! Әби дәме?

Сабир. Әби дә китә.

Күрше. Алайса саубуллашып калыйм инде, гомер буе күршеләр булып яшәдек, әле тагын кайчан күрермен. Мәүлия әби! Мәүлия әби! *(Янына килә.)*

Мәүлия *(танып)*. И, жаным, күршекәем, син икән!

Күрше. Синең белән саубуллашырга дип кердем, исән-имин генә яңа урыннарга кайтып жит инде. Яңа жирдә янача булыр -безне дә онытма! *(Күз яшен сөртеп ала.)*

Мәүлия *(елап)*. Онытмам, жаным, онытмам. Без бит күрше, синең белән бик тату яшәдек. Бик рәхмәт инде сиңа, авыр чакларымда бик булыштың, рәхмәт!

Күрше. Хужалар, китәбез, диләр.

Мәүлия. Шулайдыр шул... тик мин китмим әле!

Тәүфыйк. Нишләп?

Мәүлия. Мин болай уйладым: бер көнгә монда калам. Йоласы шундый. Иртән иртүк авыл карчыклары киләрләр, һәрберсе белән сөйләшеп, саубуллашып алырга телим.

Сабир. Син нәрсә, апа, юләрләнмә.

Сария. Сине кем ашатыр да, кем эчертер?!

Мәүлия. Күрше бар бит...

Сария. Алай да дуамал инде син!

Күрше. Калсын, калсын... Бер көндә генә берни булмас, мин янында булырмын.

Мәүлия. Бер көнгә калдырыгыз инде, иртәгә килеп алырсыз. Укымаган намазларым калды.

Сария. Апа, нигә инде алай итәсең?

Сабир. Ярар, ялынмагыз, бала-чага түгел, үзе белә торгандыр. Бүген безнең болай да кешеләр күп, әйберләр дә шактый. Калсын, иртәгә килеп алырбыз!

Сария. Күршегә бик зур рәхмәт инде! Без апа янына килми торганда да мунчасын ягып, чәен куя торды...

Сабир. Шунар күр апаның биш казын мин аңа бирәм.

Күрше. И, кирәкмәс иде инде!

Сабир. Ал, ал.

Күрше. Рәхмәт, шундый изге кешеләр булып чыктыгыз инде сез, бөтен авыл халкы сезнең изгелеккә мөккибән киткән.

Сабир. Әйдәгез, жыеныйк! *(Тәүфыйкка)* Син машинаны жылыта тор! Мә, ачкычны ал! *(Ачкычны бирә.)*

Тәүфыйк чыгып китә.

Күрше. Мин казларны карап керим әле, ашарларына салыйм. *(Чыга.)*

Сабир *(Сариягә)*. Кирәген генә ал—машинага сыярлык булсын.

Сария. Менә бу матрацны алырга кирәк.

Сабир *(Регинага)*. Кызым, әниеңә булыш!

Регина *(Коръән китабын алып)*. Әти, әни, «Коръән»не үзем белән алыйм әле!

Сабир. Нишлисең аның белән? Син аны барыбер укый алмассың!

Регина. Әти, ә нишләп без әбине ялгызын гына калдырабыз?

Сабир. Иртәгә килеп алабыз, дидек түгелме соң?!

Регина. Аның ялгызын гына калдырып китү әйбәт гамәл түгел инде.

Сабир. Әйбәт булмаса, кал әбиең белән, йә инде үзең белән алып кит.

Регина. Куркам мин бу өйдә.

Сабир. Шулай булгач!

Урам ягында казлар кангылдашкан тавышлар килә.

Сария *(тәрәзәгә ташланып)*. Күрше хатыны казларны үзләренә куып алып чыгып бара.

Сабир. Яна! Без киткәнне дә көтеп тормый! Хәзерге халык гел биргәнне генә ярата шул.

Сария. Беребез дә өметсез түгел инде, барыбыз да өмет итә.

Сабир. Чукынып китсеннәр!

Сария. Сабир!

Сабир. Нәрсә?

Сария. Әйт әле... син бу карчыкның акчасына гына кызыгып асрамага алмыйсың микән?

Сабир. Ә нәрсәсенә кызыгасың анын! Кызыгыр вакытлар үткән инде, үземнеке үземә җитә. Тик апаны мин дә карамагач, кем карар соң?!

Сария. Авыр булачак, тик шулай да түзәргә туры килә. Аның бөтен авырлыгы мина төшәр инде.

Сабир. Беләм. Үзем исән чагында мин аны ташлый алмыйм. Мин үлгәчтен карарсыз инде.

Сария. Баласы юк, баласы булса...

Сабир. Балаларга хәзер ышаныч юк, үзең исән йөргәнгә шатланып торырга кирәк.

Сария. Өч ел гомерем калды дип тора...

Сабир. Теге өч чияне әйтәсеңме?! Ул өч чияне дә төрлечә аңларга була, төрлечә... Бар курыкканым шул, авыру карчык аркасында туганнар арасында низаглар килеп чыкмасын инде, низаглар...

Урамда машина кабына.

Сария. Кара әле, Тәүфыйк бабасының биш мең акчасын алып торган булган. Шуның турында Тәүфыйк сиңа берни дә әйтмәдеме?

Сабир. Әйтер бар—аласын әйткән булыр иде.

Сария. Кара әле, Тәүфыйкка нәрсә бирәбез соң?

Сабир. Җизни бабасы биргән бит инде аңа. Башкасын өмет итмәсен. Мин монда байлык таратырга килмәдем. *(Тынлык.)*

Мәүлия *(Регинага).* Кызым!

Регина. Әү, әби?!

Мәүлия. Кил әле минем янга!

Регина *(килеп).* Тынлыйм, әби?!

Мәүлия *(елмаеп).* Сөбханалла! Кызым, синең егетең бармы?

Регина (көлеп). Бар инде...

Мәүлия. Әйбәтме?

Регина. Әйбәт.

Мәүлия. Мин әйткәнне тынла: яраткан кешенне кулыннан ычкындырма. Әнә без бабаң белән ничек яшәдек. Булды, булды анын да галәмәтләре. Хәлисә апаң аны миннән аертырга да дип тә йөрде. Аңа яңа хатын да тапты. Тик Ярулла мине аермады. Мәүлиянең нәселе яхшы, нәселе өчен генә булса да аерылмыйм дигән. Син дә кияүгә чыкканда иреңнен нәселен белеп чык, кызым, чыккач та аерылып, бозылышып йөрмә. *(Тынлык.)* Мә, менә бу нәстәне кесәңә тыгып куй әле! *(Бөти бирә.)*

Регина. Нәрсә бу?

Мәүлия. Бөти. Сөйдергеч бөтие. Мондый бөти белән йөргән кызларын яраткан егетләре беркайчан да ташламас.

Регина *(алып).* Рәхмәт, әби.

Мәүлия. Кызым!

Регина. Әү?

Мәүлия. Синең кузенә бабаңның Коръән китабы чалынмадымы?

Регина. Өстәл өстендә ята, әллә кирәкме?!

Мәүлия. Киткәндә яныма куеп китсәң ярар иде, укый алмасам да янымда торсын. Миңа хәзер берни дә кирәкми, миңа хәзер... Аллаһы Тәгалә белән очрашасы—алда...

Тәүфыйк керә.

Тәүфыйк. Булды. Машина әзер.

Сабир. Китәбез хәзер. Утырыгыз. Юлга чыгар алдыннан бер дога кылыйк. *(Утырышалар.)* Йәгез, бер дога! *(Дога кылып.)* Вакыт... китәргә кирәк.

Сария. Китәбез... Тәтәгез белән сабуллашыйм да... *(Мәүлия янына килә.)* Апа, апа дим! Бөтенләй калдырып китәләр дип уйлый күрмә тагын. Бер көннән Сабир килеп алыр. Үпкәләп ятма тагын! Апа! Нигә дәшмисең? *(Тынлап.)* Йокыга киткән... Уф! Үлгән дип торам, котым очты! Йоклый... пеф-пеф итеп...

Сабир. Йокыга талган... аргандыр...

Тәүфыйк. Йоклаган булып кына кыланмый микән?

Сария. Белмим инде. Аллага тапшырган... Их, бу гомерләр! Артык гомерләр... Берәүгә дә бәйрәм түгел. Аллаһы Тәгалә шул артык гомерләрдән сакласын иде инде, үз янына вакытында алсын... Үз көнеңне үзең күрәлми башлагач, яшәүдән ни мәгънә?!

Сабир. Киттек!

Регина. Әти! Ә бәлкем, бүген үк алып кайтырбыз?!

С а б и р. Кызым, сиңа күпме әйтергә була, бу турыда биш тапкыр сөйләшмиләр!

Р е г и н а. Әгәр...

С а б и р. Нәрсә әгәр?

Р е г и н а. Әгәр дә ул үлеп китсә?

С а б и р. Унөч ел үлмәгәнне бер көн дә генә үлмәс. Әйдә, җыен, киттек. Чыгыйк саф һавага тизрәк, чыгыйк!

С а р и я. Уф, минем дә башым әйләнә.

Сабир, Сария, Тәуфыйк чыгалар. Регина кулына Коръән китабын алып, уйланып тора. Мәүлия янына килеп китапны аның баш очына куя. Мәүлиянең баш очыннан үбеп ала.

Тәуфыйк керә.

Т ә у ф ы й к. Сария апа каядыр сумкасын калдырган дип әйтте, кая икән? *(Табып ала.)* Җен авырлыгы бу сумкада!

Регина чыгып китә.

Т ә у ф ы й к. Таш тутырганнармыни?! Картны әйтәм, абыйны, вәт хәйләкәр дә инде ә?! Тәтәнең акчасы булмаса, һич кенә дә алмас иде асрамага, юк, алмас иде! (Чыгып китә.)

Тынлык. Машина кузгалып киткән тавыш килә. Монсу көй агыла. Шыгырдап ишек ачыла.

М ә ү л и я *(монланып).* Йоклаган булып юри генә яткан иεм, йоклаганга санадылар, алдадым үзләрен. Ярар, Аллаһы бирсә, бар да рәтләнер әле. Күрше кереп житәр, хатыннар килерләр иртәгә... Сабир... Аллага шөкер, әлһәмдер иллаһи... *(Дога кыла.)* Йә, Алла... *(Йокыга тала.)*

Урамда гармунда уйнап узалар. Мәүлия, сискәнеп, уяна.

*(Елмая.)* Яшьләр... яшьләр клубка җыелалар... Ярулла исән чагында кергәлиләр иде, хәзер кермәсләр шул инде— өйдә яшәүче кеше калмаган дип уйлый торганнардыр... Бигрәк караңгы... Күрше кереп ут та кабызмый... ичмасам... *(Гармун тавышы ераклаша.)* Киттеләр... *(Дога укый.)* Амин! Амин! *(Кулына Коръән китабын ала, аны кинәт кулыннан төшерә, аның югалта.)*

Тынлык. Ябылмый калган чолан ишеге авызыннан көзге салкын җилнең хәвефле авазы гына ишетелеп тора.

*Пәрдә*



Гөлзадә
Бәйрәмова

# МИН БӘХЕТКӘ БАРАМ—ҖӘЯҮЛӘП

* * *

**Әллә соң бу еллар**
**Кирегә агалар?**
**Әйтәләр: яраны**
**Тик вакыт дәвалар…**

**Яралы йөрәгем**
**Кыстым да учыма.**
**Күзләрем яшьләнгән,**
**Кайда соң ашкынам?**

**Ишетәм тавышың—**
**Ул—җаннар әрнеше,**
**Яңгырый еракта**
**Кайтаваз агышы:**

**«Син әле сөюне**
**Ашыкма күмәргә.**
**Син мине алай да**
**Югалтып бетермә.**
**Әйтерсең, түзмәссең,**
**Өметең өзмәссең!**
**Мин сине чынлап та**
**Яратам икән бит,**
**Мин сине барыбер**
**Сагынам икән»,— дип.**

* * *

*«Багучыга барма—башыңа бәла алма».*
Халыктан.

**Алда ниләр көтә икән,**
**Аз булдымы күргәннәр?**
**Әллә ялган, әллә чынмы**
**Багучы сөйләгәннәр?**

**Тынычлыгым җуйсынгамы**
**Тагын сөю юрыйлар.**
**Яратмыйча гына яшәп**
**Булмас дипме уйлыйлар…**

**Мәхәббәттән ваз кичәргә**
**Әзер иде йөрәгем.**
**Алгысынмый, сабыр гына**
**Яшәү иде теләгем.**

---

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА—*журналист; шигырьләре, әдәбият-сәнгатькә караган мәкаләләре көндәлек матбугатта даими басылып килә. Казанда яши.*

«Ачы!» дип тә кычкырдылар,
Язмыш та булды ачы.
Хәзер менә бәгыремне
Телгәли үтмәс кайчы.

Күпме була соң югалтып,
Күпме була җан атып?
Юрамагыз миңа сөю,
Арыдым мин яратып!

* * *

Бәхет, бәхет!
Нинди төстә соң син,
Кайдан сине эзләп табасы,
Нинди кануннарга каршы килеп,
Кайсы юлдан сиңа барасы?

Йөгерепләр узасыңмы әллә
Сиздермичә яннан, хәйләләп?
Югыйсә бит сиңа таба китә
Тугач та ук балаң—җәяүләп.

* * *

Еллар—елга охшамый,
Күңелем уйдан бушамый.
Күңелем уйдан бушар иде,
Син юклыкка ышанмый.

Башта төрле исәпләр,
Көтмәгәндә, кисәктән,
Зыңлап куя телефон
Кулдан төшә бар эшем.

Ишетәм сулаганың
(Хәтта ни уйлаганың)...
«Бу—син!»—дидем, түзмәдем,
Беләм бит эзләгәнең.

Аһ бу йөрәк, бу йөрәк
(Бу йөрәк—сәер йөрәк!)
Азмы янды, ник соң аңа
Һаман да яну кирәк?!

...Син идең бит, син бит бу,
Ник дәшмисең? Мин бит бу!

* * *

Гомер узган саен бер уй килә:
Кайтарырга иде яртысын.
Башлап булса әгәр яңабаштан,
Кайсы елдан башлап карыйсы?

Тәпи киткән еллар? Мөмкин түгел,
Бик еракта, томан артында.
Соңгы сыйныф укучысы булып
Басып карыйм парта артына...

Студент чор. Иләс-миләс чаклар...
Хата ни дә сиңа, ялгышлар...
Үгетләүләр әле үтәмени,
Гел хыялдан торган ул башка.

Туй күлмәген кияргә дип йөргән
Чакларга соң кире кайтыйммы?
Атсыз бармагымны атлы иткән,
Туй балдагын суга атыйммы?

Эзе калыр. Буыннарга чаклы—
Тирән булып сызылып-уелып.
Нәселләрне тоташтырган җепләр
Бик еракка китә сузылып.

...Һәрбер елга вакыт мөһер суккан,
Чигенерлек урын калмаган...

* * *

Күп вакытлар узгач,
Туйлар инде тынгач,
Очрадың син янә
Урамның уртасында,
Яшәүнең уртасында,
Хисләрнең уртасында—
Онытыр-онытмас бер чакта,
Йөгерикме як-якка,
Ташланыйкмы кочакка?..
Күзләр—читкә карый,
Керфекләрең—түбән,
Иреннәрдә генә,
Нидән башланырга
Белми торган сүзләр.
Тик кирәкме алар,
Ничек, имеш, хәлләр?
Сер бирмәүдән генә
Һәркем «әйбәт» дияр.
Хикмәт сүздәмени!
Күзләр үзе сөйләр.
Бәлки соңгы кабат
Күрешүдер безнең...
Бүген очрашсак та,
Иртәгесен—нәрсә...
Һәм әйтербез шулчак:
«Әле кайчан гына
Исән иде, исән...»
...Дөрес аңларсыңмы,
Мин башымны исәм?

## Аерылгач

Һәммәсе үзенчә «тилерә»,
Гайбәткә азыкны мул бирә.
Ул, имеш, дөньяның явызы,
Бу, имеш, дөньяның азгыны.

Кемгәдер эш арта, сүз арта,
Табыла хуплаучы, яклаучы.
Дус-ишләр икегә бүленә,
Һәркайсы сүз ташып өлгерә.

Бу ике «гашыйктан» ил көлә,
Белмәскә тиешен «мир» белә.
Үзенә ягылган яладан,
Кайчандыр сөюдә яналган
Йөрәкләр илереп тилмерә.

Агартып булмаслык каралткач,
Дөньяны үзеңчә яңарткач,
Карыйсың борылып үткәнгә,
Сулкылдап йөрәгең типкәнгә,
Үткәндә син үзең икән лә!

• • •

«Ни әйтмәм», дип котылуы җиңел
Җавап тотмас өчен сүзеңә.
«Мин әйттем!»—дип нәгърә ору кирәк
Хакыйкатьнең төбәп күзенә.

• • •

*«Беренче ир (хатын) Ходайдан,*
*Икенчесе—кешеләрдән,*
*Өченчесе—шайтаннан».*
Халык сөйләме.

Нинди генә исемнәргә төреп,
Ничек кенә диеп атама,
Хәрам барыбер—хәрам!
Узган гомер—әрәм...

• • •

*Бер уенны ике уйнамыйлар,*
*Бер үк суга ике кермиләр.*

Бер тырмага ике басучыны
«Шыр тилегә» юкса тиңлибез.

Шул «тиле»нең хәленә үзебез калсак,
Ни эшләргә
Кирәклеген генә белмибез!

* * *

Сындырып ла сынаганда Язмыш
Сынатмасак иде ничек тә!

Аягүрә калу ай-һай авыр,
Тез астыннан капса көчекләр.

* * *

Синең яктан исми җилләр,
Килми хәтта сәламнәр.
Үпкәләмим. Исәнсең бит,
Исәнлегең зур хәбәр.

## Минем дөнья

Минем дөнья хәзер—үзгә дөнья,
Үзгәрешләр килде ерактан.
Урын даулап анда узып булмый,
Ярлыкаулар, гафу сорап та.

Дусларның да сыналганы анда—
«Гел минемчә» уйлый белгәне.
Мыскыл катыш сорау бирмәс алар:
«Әллә син дә яулык бәйләдең?»

Бутамаслар хәләл вә хәрамны,
Изгелектә булыр уйлары.
Сайлап алып булмый туганнарны,
Булмый сайлап ата-ананы.

Алар әйтмәс: «Динчә генә яшәү
Түгелме соң әле иртәрәк?»
Мәҗлестәшләр, гафу, сездән исә—
Мин беркадәр киттем читкәрәк.

Адаштырып йөртте «җан сөйгәннәр»,
Табынмастайларга табындык!
Ялгышларны хакка юрадык та,
Гел яшьлеккә сылтап—юандык.

Дөнья бер ул да бит, гамәл башка,
Һәркем яши үзе белгәнчә.
Кыйбла якның җиленә йөзем куям,
Ул иркәләр мине гүргәчә.

Габдрахман
Әпсәләмов

# САРЫ ЧЫПЧЫК

«Өйдә тавык кебек йомылып утырма, юләр... Бәхетеннән коры калырсың. Бәхет ачкычы юлда ята...»

Белмим, кайда, кайчан ишеткәнмендер мин бу хикмәтле сүзләрне. Мөгаен, малай чагымдадыр. Чөнки бала вакытта ук кыр уртасындагы тузанлы юлда ялтырап яткан әлеге серле көмеш ачкычны бик еш... төшемдә, ә кайчакта, уйга чумсам, хәтта өнемдә дә күрә торган идем. Дөрес, хәзер, илленең өстенә чыккач, малай чак хыяллары үтә беркатлы һәм көлке булып тоела. Ләкин бәхет ачкычының юлда ятуына бүген дә ышанам әле мин. Чөнки юлга чыксам, нәрсә дә булса тапмыйча кайтканым юк. Әлеге Сары чыпчыкны да юлда таптым. Шул турыда тәмле генә бер сөйләп биримче. Безнең авыл агайлары әкиятне башлап җибәрер алдыннан тыңлаучыларның колакларын торгызыр өчен шулай әйтә торганнар иде.

Узган ел бер шагыйрь иптәшем белән икебезне Чаллы мәктәбенә очрашуга чакырдылар. Пароходка утырдык та киттек.

Без еш кына үзебезне онытып җибәрәбез, хозур эзләп әллә кайларга, җылы якларга, диңгез буйларына, мәңге яшел магнолияләр, олеандрлар чәчәк атып, каштаннар, платаннар үсеп торган җирләргә омтылабыз. Хәлбуки, матурлыгы ягыннан көньяк белән ярыша алырдай гүзәл урыннар безнең үз тирәбездә дә җитәрлек. Идел-Кама буйлары сокланып туймас урыннарга бай. Җанга газиз тугайлары, әрәмәлекләре, таулары, урманнары, сулары, Сәйдәш музыкасы кебек, күңелеңә тула, сине сөендерә, ашкындыра, матурлый, пакьли, иркәли, олылый. Мондагы кебек тирән ләззәтне син бүтән беркайда да ала алмыйсың.

Кама тамагына килеп җиткәндә караңгы төшкән иде. Кама тамагы ул — кеше кулы ясаган диңгез, аның киңлеге кырык километрга якын. Бигрәк тә төнлә очсыз-кырыйсыз булып күренә ул. Уннарча пароходның, буксирларның, үзйөрешле баржаларның төрле төстәге утлары, бер сүнеп, бер кабынып торган маяк утлары, дулкыннар тибрәнүе, аларның өзлексез дәвам итеп торган серле тавышлары, су өсләрендә әллә кайсы пароходларның палубаларыннан төшеп калган сыман тоелган музыка тавышлары, җылы, тыгыз җил уйларны каядыр еракка, бала чакларга алып китә, күптән онытылган нәрсәләрне искә төшерә. Мин бигрәк тә су өстенә сузылган ай юлына карарга яратам, анда әлеге малай чактагы серле көмеш ачкычны да күргәндәй булам...

Иртән, без йокыдан торганда, су өстендә сыек кына томан йөзә иде. Кояш чыгып килә, ак томан, җинелчә алсулыкка манчылган кебек, тып-тын. Бер якта Чистайның ак-сары йортлары күренә, ахрысы, янарак кына пристаньнан кузгалып киткәнбез.

Каманың сөзәк ягында яшел утраулар, язгы ташудагы кебек су эчендә калып әле һаман үсеп торган агачлар, әрәмәлекләр күренә. Кайчак киек үрдәкләр очып килеп куна. Без шагыйрь иптәшем белән палубада йөрибез.

Палуба дымсу, әмма, җил булмаганлыктан, һава яңа сауган сөт сыман җылы һәм татлы. Пароход борынында яшь кенә, ябык кына бер кыз култыксага таянып басып тора—башка беркем юк. Кызның өстендә спортчылар кия торган молнияле кыска ак куртка, зәңгәр чалбар, инендә фестивальләрдә йөртелә торган бизәкле капчык. Үрмәгән, таралып төшкән сары чәче ябык иңнәрен каплаган. Муенында су өстендә йөзгән алсу-ак томан шикелле бик юка, үтә күренмәле косынка. Безгә кыз, рәхмәт төшкере, хәтта борылып та карамады, аның күз карашы гына түгел, бөтен торышы, бөтен уй-хыялы каядыр еракка, алга омтылган кебек иде.

Көндез, тамак туйдырырга дип, ресторанга кергәч, минем шагыйрь дус, гадәтенчә йомшак кына көлемсерәп, башы белән тәрәзәгә таба ишарә ясап алды да:

—Кара, Сары чыпчык һаман баягы урынында басып тора бит,—диде.

Әйтерсең үзе турында сүз барганын ишетеп, кыз артына борылып карады. Озынчарак йөз, кылычрак борын, нечкә ирен, күз карашында—шелтә. Җил чәчен тузгыта, ул аны әледән-әле бер кулы белән артка сыпыра.

—Мари кызына охшаган түгелме?—дип сорадым мин, шагыйрь дусның мари кызларына мәхәббәте барлыгын белгәнгә.

—Юк, мари кызлары болай усал карамый,—диде ул.—Ирене дә, колагы да башкачарак була аларның. Нечкә иренле, кечкенә колаклы кызлардан сакланырга кирәк.

—Ник?—дип сорадым мин, көлеп.

—О, юләр, алар өзеп алалар...

Яшьрәк чак булса, нечкә иренле, кечкенә колаклы дип тормас идек, билгеле, палубада берүзе басып торган кыз янына бармый калмас идек. Аннары кемгә ничек бит, миңа бу кыз ярыйсы сөйкемле булып тоелды. Аның нининдидер үзенә генә хас бер сыйфаты да бар иде кебек. Безнең пароходта яшь-җилкенчәк бик аз, ахрысы. Дөрес, берничә шома гына егет без ашаган арада кыз янына килеп кылын тартып карадылар. Ләкин, ул аларны бик коры тотты булса кирәк, куырылган кебек бик тиз китеп бардылар. Ә кыз һаман шул элекке урынында басып тора бирде.

—Билеты дүртенче классныкы, ләкин аның анда бөркүдә утырасы килми, шуңа күрә җил күзендә басып тора,—диде шагыйрь.

—Ник алай дип уйлыйсың?—дип сорадым.

—Юләр, шулай булмаса, бу кадәр басып торыр идемени, һич югында капчыгын каютада калдырыр иде. Аның бөтен байлыгы үзе белән.

Чаллыда без пароходтан төштек. Безне бер төркем мәктәп балалары, укытучылар чәчәкләр белән каршы алдылар. Тау башыннан артыбызга борылып карасак, кыз һаман баягы урынында басып тора.

Чаллыда без ике көн булдык. Мәктәп балалары, укытучылар, Чаллының китап сөючеләре белән очраштык. Якындагы Биклән авылына да барып кайттык. Анда да бик күңелле очрашу булды. Шуннан, күреп кайтыйк дип, Түбән Кама шәһәренә дә сугылдык. Асфальт юл, һәйбәт автобус—тирбәлеп кенә барасың.

Яңа салына торган шәһәрләрне минем байтак күргәнем бар. Ләкин шулай булса да, Түбән Каманы ерактан күргәч, кыр уртасында туктап, аңа байтак вакыт сокланып карап тордык. Ул кояш күзендә, әйтерсең Кама елгасы дулкыннарыннан әкияттәге ак сарай сыман күтәрелә. Зур-зур тәрәзәле кибетләре, кафелары әллә каян ялтырый. Болытсыз күктә әллә ничә кран салмак кына йөзә,—димәк, шәһәр салынуында дәвам итә. Юллар тәмам казылып беткән. Су, газ, җылыту, канализация торбалары үткәрәләр, экскаваторлар, тракторлар шаулап тора.

Гостиницага урнашып, горкомга барып сөйләшеп кайтканчы кич тә булды. Кайтышлый «Яшьлек» кафесына ашарга кердек. Яңа стильдә гел пыяладан гына диярлек салынган матур, җыйнак кафе ерактан ук үзенә тарта иде. Әмма, эченә кергәч, бераз аптырый төшеп калдык: егетләрнең дә, кызларның

да күбесе майга, цементка, акбурга буялып беткән эш киемнәреннән. Егетләр кай арададыр төшереп тә өлгергәннәр. Ничектер юри сыман тупас сөйләшәләр, өстәл янында киерелеп-сузылып утыралар, тәмәке тарталар. Аннары ашлары да шул дуңгыз ите дә, дуңгыз колбасасы. Сөт, катык, эремчек, тавык, манный боткасы кебек ашлар гына ашап яшәүче шагыйрь дус нибары бер стакан чәй алды. Ләкин без монда керүебезгә үкенмәдек, ник дисәгез... Сары чыпчыкны күрдек.

Ул почмакта, ясалма пальма күләгәсендә, алгарак чыгып торган бәләкәй ияген ике кулы белән терәп, өстәлгә текәлгән килеш берүзе утыра иде. Алдында бер стакан чәй, анысы да әллә кайчан суынып беткән булса кирәк.

—Бик күңелсез утыра, әллә сөйләшеп карыйбызмы?—дидем мин.—Чит шәһәргә килгәнлеге күренеп тора, бәлки, ярдәмгә мохтаҗдыр.

Әмма сөйләшә башлауга кыз кырт кисте.

—Мин сезнең ярдәмгә калмаган... Ялгыштыгыз,—диде ул.

Мондый җаваптан соң, билгеле инде, күп сөйләп торуның мәгънәсе юк.

—Дөрес әйткәнсең икән,—дидем мин шагыйрь дуска кафедан чыккач,—нечкә иренле, кечкенә колаклы кызлар чыннан да усал була икән.

—Мина калса, аны җәберсеткәннәр. Капчыгы да янында юк, курткасының култык асты да ертылган. Кайгырып түгел, гарьләнеп утыра ул.

Озакламыйча без мәктәпкә очрашуга барырга тиеш идек. Гостиницага безне алырга горкомның пропаганда секретаре Александр Павлович килде. Ул аксыл бөдрә чәчле, соры костюмлы, утызлар тирәсендәге чибәр генә бер кеше иде. Ачык чырайлы, сүзгә дә бик юмарт. Әдәбият, сәнгать турында беркадәр сөйләшеп утырганнан соң, без ана кафеда күргән күңелсез хәлләр турында да әйттек. Аның өчен бу, билгеле, яңалык түгел иде.

—Бараклардан яңа йортларга күчүчеләр иске әйберләрен ташлап калдыралар,—диде ул уйчан гына.—Хәзер бездә мебель кытлыгы, бар да яңа мебель сатып алырга тырыша. Ә менә иске гадәтләрне, кызганычка каршы, бик күпләре ташламый, менә дигән яңа йортларга, нәфис итеп салынган кафеларга алып керәләр. Шунысы үкенечле, яшьләр үзләре тудырган матурлыкны үзләре үк ямьсезлиләр... Билгеле, безнең дә, партия, комсомол оешмаларының да гаебе аз түгел. Яшьләрнең буш вакытын тиешенчә оештыра белмибез. Культура чараларына игътибар житенкерәп бетми. Күбрәк уңышларыбыз турында сөйлибез.

—Уңышларыгыз да кечкенә түгел,—дидем мин.

—Әлбәттә, Түбән Каманың салына башлавына нибары ике-өч ел. Монда ялан кыр иде, беренче төзүчеләр кыш көне дә палаткаларда тордылар. Хәзер әнә нихәтле яңа йортлар салдык. Урта мәктәбебез дә бар, балалар ясләре дә салынып ята, озакламыйча киң экранлы кинотеатрыбыз да, музыка мәктәбебез дә булачак. Безнең шәһәр торыр өчен бөтен уңайлыкларны күздә тотып салына. Бездә элекке кебек тар урамнар булмаячак. Бакча-шәһәр. Кешеләр бульварлардан гына йөриячәкләр, бөтен транспорт шәһәрдән читкә чыгарыла, производство предприятиеләре шәһәрдән җиде-сигез километр читтә салына. Казан химия-технология институтының филиалы да эшли башлады. Әлбәттә, бездәге төзелешнең колачын химкомбинат һәм ГЭС төзелешенә барып карамыйча күз алдына китерергә мөмкин түгел. Иртәгә барырбыз, күрерсез. Түбән Кама химкомбинаты комсомолның удар төзелеше булганлыктан, безгә эшләргә килергә теләүчеләрнең саны бик зур. Йөзләгән яшьләрдән көн саен хатлар килеп тора, кайберләре туп-туры үзләре килеп төшәләр. Әмма, шулай булса да, сез әйткәннәр дөрес. Яшьләрне тәрбияләү, аларда матурлык хисе үстерү—безнең беренче бурыч. Химкомбинатны салу кебек мөһим бурыч!

Сары чыпчык турында да ул кичне без секретарьга сөйләдек, ә икенче көнне горкомда, Александр Павлович өстәле янында кызның үзен дә күрдек.

—Оешмаган төстә булса ни,—диде ул, нечкә иренен тешләп.—Зоялар оешкан төстә генә сугышка киткәннәрмени?! Мин яңа шәһәр салырга, яңа завод

төзергә телим. Яшьлегебезгә лаеклы һәйкәл булсын дим. Бу, сезнеңчә, оешмаган эшмени, иптәш секретарь?!

Без шагыйрь дустым белән бер-беребезгә карашып алдык. Еламый, үтенми, ялынмый, таләп итә. Өзә!

—Мин барыбер моннан китмим. Иртәгә эшкә чыгам!—диде кыз, сүзен очлап.—Әйтегез, кемгә мөрәҗәгать итим?

—Хикмәт эштә түгел, эш бездә жаның теләгән хәтле,—диде Александр Павлович,—тик торак мәсьәләсе... Якын-тирәдәге авылларда да почмак табарга мөмкин түгел.

Кыз, нечкә ирене белән ачы гына көлемсерәп, башын артка таба чөеп алды. Зәңгәр күзләрендә очкын кабынды, һай, никадәр үзсүзле!

—Анысы өчен артык хафаланмагыз, иптәш секретарь,—диде ачы иттереп.—Җан биргәнгә юнь биргән ди, бер башыма кайда да урын табылыр әле.

Александр Павловичның йөзе бик җитди иде. Мондагы хәлләрне бу чая кыздан ул яхшырак белә. Нindидер Ваня белән телефоннан сөйләшеп алды да кызны аның янына җибәрде, аннары тагын телефон трубкасын алып ниндидер Чулпанны сорады.

—Үз янына булса да ал инде, Чулпан,—диде мәсьәләне аңлатканнан соң.—Әйбәт кыз кебек күренә. Менә язучы абыйларың да үтенәләр.

Трубканы куйгач, Александр Павлович тирән генә көрсенеп алды.

—Ничек әле, Сары чыпчык дидегезме? Бу кызый, минемчә, карчыга. Әйтүе оят... Монда килеп төшкән көнне төнлә кемнәрдер аның капчыгын, бар акчасын тартып алганнар. Ул бер тиенсез калган. Бер таныш кешесе юк, кунарга урыны юк, ләкин шулай да ул зарланмый, тизрәк китәргә ашыкмый. Юллык акча сорамый.

Без Александр Павловичка аның пароходта ничек килүен сөйләдек.

—Әйе, күренеп тора, характерлы кыз,—диде ул.

—Кемнәре бар соң? Кайдан килгән?

—Казанныкы, ди. Әнием, апаларым бар дигән була.

—Ә Чулпан дигәнегез кем?—дип сорадык ахырда.

—Алдынгы яшьләр бригадасының комсоргы. Ул сезнең Сары чыпчыкка ярдәм итү юлларын табар. Бездә кызлар бик булган... Торак мәсьәләсендә генә... Хәзергә Чулпан белән алмаш-тилмәш бер караватта йокларлар инде.

Икенче көнне Александр Павлович безне химкомбинат төзелешен карарга алып китте. Түбән Кама химкомбинаты заманыбызның иң зур төзелешләреннән берсе икәнен бөтен ил белә. Дөрес, хәзергә аерым корпуслары гына төзелеп беткән. Күбрәк җир һәм бетон эшләре бара. Шулай да гаять зур мәйданда җәелгән бу эшләргә карап, тагын берничә елдан монда гаҗәеп нәрсәләр буласын күз алдына китерүе кыен түгел. Менә шушы урман эчендәге гигант төзелеш белән танышып йөргәндә, инде түбәсе ябылып беткән, әмма эче әле буп-буш галәмәт зур корпусларның берсендә, эшче кызлар төркеме арасында, тагын үзебезнең Сары чыпчыкны очраттык. Ул ничектер бераз курка да төшкән кебек, аптыраган да сыман, тик күзләре генә елтырый. Аның янында кара тут йөзле, колак очында бөрлегән хәтле генә алка җем-җем итеп торган янә бер кыз, кулы белән күрсәтә-күрсәтә, Сары чыпчыкка нидер аңлата.

—Чулпаныбыз әнә шул кыз инде, ул монда төзелешнең беренче көненнән үк эшли. Коммунистик хезмәт ударнигы.

Казанга кайтып китәр алдыннан кич белән без тагын бер тапкыр яшьлек шәһәрен әйләнеп чыгарга булдык. Үз шәһәренең патриоты булган, аның һәр уңышы өчен сөенгән, һәр кимчелеге өчен көенгән Александр Павлович, шигырь укыган сыман илһамланып, Түбән Каманың бүгенгесе һәм киләчәге турында аңлатмалар биреп бара. Бүген бишәр катлы тагын ике йорт өлгереп дәүләт комиссиясенә тапшырылган икән. Уннарча бәхетле кешеләр машиналар белән дә, атлар белән дә яна квартираларга күченәләр. Секретарь, күбесенең кулларын кысып, яңа квартира алу белән котлады, тегеләре өй котлау мәҗлесенә чакырдылар.

Түбән Кама шәһәренең нәкъ үзәгендә тугызар катлы ике йорт сала башлаганнар (соныннан унар катлылары да булачак). Бу йортларны комсомоллар белән яшьләр җәмәгать тәртибендә салалар икән. Эшләгән өчен берәү дә акча алмый, йортларның берсенең нигезен өлгертеп куяләр, икенчесенең инде алты-җиде каты күтәрелгән. Без әнә шул йорт башында эшләүчеләр янына мендек һәм, хикмәти хода дигәндәй, биредә тагын Чулпан белән Сары чыпчыкны очраттык. Бу юлы инде Сары чыпчык безгә каш җыерып карамады, кул биреп исәнләште.

—Сез инде монда да килеп өлгергәнсез,—дип әйтүебезгә каршы ул, башын артка чөя төшеп, шаян гына елмайды да:

—Нигә вакытны әрәм итәргә?—дип, сорауга сорау белән җавап бирде.—Чулпан мина сезнең турыда сөйләде. Безнең бер үтенечебез бар сезгә. Без яшьлек шәһәре салабыз ич! Ул Кама буендагы иң матур шәһәрләрнең берсе булачак. Ә исеме... шигъри түгел. Бигрәк тә түбән дигәне ошамый мина. Юк, яшьлек шәһәренең исеме дә, ничек дип әйтим инде сезгә, нурлы, матур булырга, югары булырга тиеш.—Ул, муенындагы алсу косынкасын алып, берничә адым алга атлап, иң кырыйга килеп басты, көчле җил аның сары чәчен тузгытып, кулындагы яулыгын җилфердәтә башлады. Шулай еракта күренгән Камага бераз карап торды да тагын безгә таба борылды.—Сез безнең шәһәргә әнә шундый матур исем табып бирегез. Аннары аның турында яхшы җыр языгыз. Анда Кама дулкыннары, Кама җилләре, кояш, чын дуслык белән чын мәхәббәт булсын. Югыйсә безгә килеп тә йөрмәгез.

Бик каты әйтте әйтүен бу Сары чыпчык, ләкин нигә үпкәләргә, хак сүзгә үпкәләп буламыни.

—Таләбегез бик урынлы,—дидем мин.—Җырны менә шагыйрь иптәш рәхәтләнеп язар дип уйлыйм. Исем мәсьәләсендә... Нигә аны әллә кайдан ерактан эзләргә? Менә яныгызда яшьлек шәһәренең беренче нигез ташларын салучыларның берсе—Чулпан басып тора. Нигә аның исеме белән шәһәрегезне атамаска? Бик матур, сез әйткәнчә югары да, шигъри дә, нурлы да—Таң йолдызы.

—Ой!—дип кычкырып җибәрде Сары чыпчык.—Чыннан да... Чулпан! Таң йолдызы!—Ул оялып кызарынган дустын кочып алды.

Без кызларның исем-фамилияләрен дә язып алдык. Ләкин Сары чыпчыкны һаман да Сары чыпчык итеп калдырасым килә минем. Ул бит, әкияттәге сыман, юлдан табылды. Дөрес, моның өчен әкияттәгечә көмеш ачкыч белән тимер ишекләрне ачарга кирәк булмады. Безнең тормышыбыз үзенең серләрен һәм гүзәлләрен чит күзләрдән алай ерак яшерми. Ләкин күңелләрендә көмеш ачкычлары булмаганнар аларны күрә аламы икән соң?!

*1965*

## Искәрмә

Күренекле язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Габдрахман Әпсәләмовның «Сары чыпчык» хикәясендәге ике моментка игътибарны юнәлтик әле. Әдәбият сөючеләр белән очрашуга килгән ике әдип, Түбән Кама шәһәрендәге «Яшьлек» кафесына да сугылалар. Анда утыручы егетләр «кай арададыр төшереп тә өлгергәннәр. Ничектер юри сыман тупас сөйләшәләр, өстәл янында киерелеп-сузылып утыралар, тәмәке тарталар. Аннары ашлары да шул дуңгыз ите дә, дуңгыз колбасасы...»

Әйе, болар—якын-тирә авыллардан килгән авыл яшьләре. «Шәһәрләшеп» баралар әнә. Барысы да дип әйтмим, әмма нәкъ менә шулар арасыннан акрынлап туган телен, милли гореф-гадәтләрне оныткан маңкортлар, капрон яшьләр үсеп чыкты да инде. Автор менә шушы хәлне саран гына штрихлар белән укучыга сиздереп куя белгән.

Икенчесе. Хикәянең героинясы — Сары чыпчык, аның хәтта паспорттагы исеме дә бирелми. Бу исә әсәргә үзенчә бер серлелек өсти. Тәзелешкә дип килгән бу чая, яшь кызның үткенлеген кара син! Казаннан килгән кунакларга да үзенең сүзен һаваланмыйча, ихластан әнә ничек өздереп әйтә:

—Безнең бер үтенечебез бар сезгә. Без яшьлек шәһәре салабыз ич! Ул Кама буендагы иң матур шәһәрләрнең берсе булачак. Ә исеме... шигъри түгел. Бигрәк тә түбән дигәне ошамый миңа. Юк, яшьлек шәһәренең исеме дә... нурлы, матур булырга, югары булырга тиеш.

Шундыйрак фикерне шагыйрь Хәсән ага Туфанның да әйткәне мәгълүм. Чынлап та, яңа шәһәр яисә урамнарга исем кушуда, ай-һай, талымсызлык күрсәтеп караганбыз икән шул. Йәгез, Казан тимер юл вокзалы тирәсендәге Сакко-Ванцетти урамының асыл җисмен кем белә дә, кемнәр генә аңлатып бирер икән? Бәхәссез ки: милли республикабызда, һичшиксез, милли атамалар өстенлек итәргә тиеш!

Габдрахман Әпсәләмов — күпсанлы хикәяләр, публицистик язмалар өстенә, дистәгә якын романнар авторы. Исемнәре дә бик истә калучан: «Алтын йолдыз», «Газинур», «Сүнмәс утлар», «Ак чәчәкләр»... Һәр яңа романы әдәбиятта, киң катлам җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятыр иде. Аның шулай зур әдип булып китүендә биографиясе, һичшиксез, зур роль уйнаган.

Ул 1911 елның 28 декабрендә Пенза губернасы (хәзерге Мордовиянең Ковылкино районы) Иске Аллагол авылында крестьян гаиләсендә туа. Өч сыйныфны тәмамлагач, Мәскәүнең Н. Нәриманов исемендәге татар урта мәктәбендә (күрегезче: егерменче еллар башында ук Мәскәүдә саф татар мәктәбе эшләгән икән!) укуын дәвам итә. Шул вакытларда М. Җәлил җитәкләгән әдәби түгәрәккә йөри. Тора-бара Казандагы «Азат хатын» һәм «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналларына актив язышa.

Алга таба ФЗӨ мәктәбе, Мәскәү заводларында слесарь һәм токарь, М. Горький исемендәге Әдәбият институты. 1941 елда аның «Бәхет кояшы» дигән хикәяләр җыентыгы басылып чыга.

Сугышның беренче айларыннан ук Г. Әпсәләмов фронтка китә. Башта — Карелия фронты, аннары шул фронтта чыккан «Ватан өчен сугышка» дигән газетада эшли.

Ватан сугышы язучының иҗат эшчәнлегенә зур йогынты ясаган, билгеле. Моның шулай икәнлеген күпсанлы хикәя, повесть һәм романнары ачык раслап тора. Кешедәге иң күркәм сыйфатлар — Ватанга һәм халкына бирелгәнлек, патриотизм, сугыш кырындагы һәм хезмәттәге батырлык булсын, болар бар да сәнгати рәвештә, авторның язу стиленә хас күтәренке рух, романтик омтылыш белән, тормышчан геройлар язмышы аша сурәтләнә. 30-40 ел эчендә әдипнең татар, рус телләрендә, СССР һәм чит ил халыклары телләрендә йөзгә якын китабы дөнья күрә. Бу саннар артында никадәрле физик һәм рухи хезмәт ятканлыгын чамалау бер дә кыен түгел. Әле боларга тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеген өстәргә дә онытмыйк.

Г. Әпсәләмов озакка сузылган каты авырудан соң, 1979 елның 7 февралендә Казанда вафат була.

**Рашат НИЗАМИ.**

Солтан
Шәмси

# АДӘМНЕ КЕМ КОТКАРЫР?

ТАРИХИ–ЭЗОТЕРИК БӘЯН

## «Мин Адәмнән өстенрәк...»

Бу бүлекне без башкачарак төзергә булдык. Эш шунда ки, Елан символының нәрсәне аңлатканын һәм кешелек дөньясы тарихында нинди роль уйнавын күпмедер дәрәҗәдә ачыклап үткәннән соң безнең алга: «Елан ничек Иблискә әверелгән ?» дигән кызыклы сорау килеп баса. Аңа тулырак җавап бирү өчен кешелек дөньясының бик борынгы тарихына мөрәҗәгать итү, анда булып узган мөһим вакыйгаларга гомуми караш ташлап, аларның дини чыганакларда ни рәвештә һәм ни дәрәҗәдә чагылуына җентекләп тукталу сорала. Әмма җир йөзендә яшәүче адәм баласы бу вакыйгаларга андый биеклектән торып карау, алай фикер йөртүдән мәхрүм. Бәхеткә, бу эшне башкарып чыгарга безгә Остазларыбызның берсеннән ингән кыйммәтле мәгълүматлар ярдәм итә. Шуңа күрә, ул Затка олы рәхмәтләребезне белдереп, мәгълүматларны төкми-чәчми укучылар игътибарына тәкъдим итсәк, алдыбызда кешелек дөньясы тарихының күпләр өчен әлегә сер булып калган сәхифәләр манзарасы ачылыр һәм алар безгә глобаль рәвештә фикер йөртү мөмкинлеге ача төшәр дип ышанасы килә.

## Кешелек дөньясының борынгы тарихыннан сәхифәләр

«1. 150 мең ел элек җир йөзендә 100 мең ел буе дәвам иткән бозлык дәвере тәмамланды. Бу вакытта безнең Галактика Бөек Галәм Спираленең икенче божрасына күчү юлының яртысын инде үткән иде,—шулай яңа божрага күчәр өчен әзерлек башланды. Эволюциянең яңа божрасына аяк басар өчен, бөтен Галактика электән калган гөнаһлардан арыну, чистарыну-пакьләнү юлына чыкты. Бу процесс 2012 елда тәмам булачак.

Андый чистарынулар, кагыйдә буларак, Төп Циклның ахырында үткәрелә. Моны яңа эволюцион цикл башланыр алдыннан башкарылган «төп җыештыру» («генеральная уборка») дип атарга мөмкин. Хәзер бу процесс тәмамланырга тора.

2. Җир планетасының эволюция циклы 26 мең елга тиң. Соңгы 26 мең еллык цикл тәмамланган чакта Җирдә 2 миллиардка якын кеше яши иде. Әмма планета полюсларының урыныннан күчүе сәбәпле җир йөзендә яшәүчеләрнең саны 1,5 миллион гына калды, житмәсә алар әле бөтен планетага таралып беткән иде. Бу саннар ул вакыттагы катастрофаларның ни дәрәҗәдә көчле булуын ачык күрсәтә.

3. Җирдә халыклар саны кабат үсә төшкәч, Плеяда, Сириус һәм Андромедадагы Остазлар җир йөзендә физик тәндә гәүдәләнделәр һәм Мачу-Пикчу (Перу), Мисыр, хәтта Атлантида кебек цивилизацияләрне оештырырга ярдәм иттеләр. Ул вакытта Тын океанда урнашкан һәм хәзерге кешелек дөньясының бишеген тәшкил иткән Му (Лемурия) континентының байтак өлеше халкы белән бергә су төбенә киткән

*Ахыры. Башы журналыбызның 5 санында.*

иде. Шуна да карамастан исән-имин калган кайбер җирләрдә—Гавайя утрауларында һәм АКШтагы Шаста тавында (Калифорния) әүвәлге храмнар һәм рухи тәгълиматлар сакланып калды.

4. Шулай һәр төбәктә Остазлар җитәкчелегендә рухи мәктәпләр үсеп чыкты. Мәсәлән, Атлантидада Мельхиседек Ордены белән Алора (алиһә) храмнары барлыкка килде. Дәвалау һәм төрле дөньялар белән элемтә урнаштыру өчен кристаллардан файдалану сәнгате кабат үсеш алды. Тагын да борынгырак цивилизацияләрдә киң кулланышта булган бу сәнгать соңрак чорларда сүнде, онытылды. Тот исемле Остаз (аның икенче исеме Техути) Мисырда кояшка табыну дине кертте, аның әһелләрен әзерләүне, укытуны җайга салды, телепортация, телекинез кебек рухи практикаларны, Күкнең төрле үлчәмнәренә сәяхәт кылу ысулларыннан файдалануны гамәлгә ашырды. Шушы ук чорда Мисыр һәм бөтен планета кешеләре өчен кояш кодларын кабул итү, аларны тапшыру һәм рухи дәрәҗәләргә багышлау үткәрү (инициация) өчен Олуг Пирамида *(Хеопс пирамидасы—С.Ш.)* төзелде.

Бу дәвердә җир йөзендәге һәр культурада адәм балаларын рухи практикаларга, төрле үлчәмнәргә сәяхәт кылырга өйрәтү алып барыла иде.

5. Җир эволюциясенең хәзерге вакытта тәгәлләнеп килгән 26 мең еллык циклы башланган чакта, моннан 25 мең еллар элек, яшьрәк һәм үсеш ягыннан түбәнрәк баскычта торган җаннар Җирдә гәүдәләнә башладылар. Бу чорда Күкнең югары үлчәмнәрендә яшәүче Остазлар адәм балаларын өйрәтү белән шөгыльләнделәр һәм бу эш 250 еллап дәвам итте. Остазлар моны эволюциянең төрле баскычында торган җаннарны үзара берләштергән цивилизацияләргә көчү җинелрәк булсын өчен башкардылар, чөнки бу җаннар чыгышлары белән төрле Галактикалардан иделәр. Эволюцион үсешнең югарырак баскычына күтәрелү өчен алар рухи яктан югарырак торган гаиләдә туарга, үсеп җиткәч, үзләреннән рухирак кеше белән гаилә корырга һәм шулай үзләренең аң-белемен, рухи үсешен күтәрә төшәргә тиешләр иде. Мондый кушылулар башлангач, Плеяда йолдызлыгыннан килгән байтак Остазлар яшь җаннарны тәрбияләүне үз өсләренә алдылар. Плеяда йолдызлыгы вәкилләренең кайберләре хәтта адәми затның яшәү рәвешен кабул итте һәм кешеләр белән гаилә дә корды. Бу кеше тәненең генетик структурасын үзгәртү һәм анда рухи үсешкә омтылуны уяту өчен эшләнде. Бу процессны кайчакта «йолдыз чәчмәсе» («звездный посев») дип атау гадәткә кергән.

6. Югары үсешкә ирешкән кешеләр Җирдә рухи үсеш мәктәпләре оештыруны, шулай ук Күкләрнең югары үлчәмнәрендә эшләүче рухи үсеш мәктәпләре булдыруда үзләренә ярдәм итүебезне үтенделәр—моның өчен аларның бер өлеше, Җирдә үтәсе эволюция баскычларын тәгәлләп, изгелеккә ирешергә һәм, планетадашларына ярдәм итү өчен, Җир аурасында (тирәсендә) торып калырга тиешләр иде.

Планетаның эволюцион үсешен кайгыртучы Бөек Ак Туганлык (Великое Белое Братство) оешмасы инде 15 мең ел буе эш алып бара иде, һәм шушы вакыт эчендә Җирдәге төрле мәдәниятләрдән булган 1000 кешелек төркем рухи яктан нурлану-уянуга иреште. Шушы 1000 кешедән торган төркем монарчы Бөек Ак Нур Ордены (Орден Великого Белого Братства) дип йөртелгән оешманы Бөек Ак Туганлык оешмасы дип үзгәртеп корырга бертавыштан ризалык бирде. Җирдә рухи нурлану-уяну эшен алып бару мисалын булдыру өчен бу бик тә кирәк иде. Изгеләр җәмгыятен тәшкил иткән бу оешма әгъзаларыннан кайберәүләр, Күккә Ашкан Остаз (Вознесенный Учитель) дәрәҗәсендә булуларына карамастан, ара-тирә Җирдә гәүдәләнә башладылар. Алар рухиятка йөз тоткан гаиләләрдә физик яктан туып, егерме бер яшькә җиткәндә кабат рухи нурлану-уянуга ирешә иделәр. Бу яшьтә алар үзләренең бөтен үткән гәүдәләнешләрен, ничек Күккә ашуларын һәм шушы гәүдәләнештә аларга йөкләнгән рухи бурычны искә төшерәләр иде. Реинкарнация, ягъни кабат Җирдә гәүдәләнү кичергән бу изге затлар әйбәт һәм көчле Остазларга әверелделәр, чөнки аларда дуслык-иптәшлек хисләре моңарчы адәми зат булып Җирдә яшәмәгән затларныкыннан күпкә самимирәк һәм тирәнрәк иде. Шушы Күккә Ашкан Остазлар ара-тирә генетикалары төрле дәрәҗәдә бозылган, кармалары артык катлауланган яшь җаннар корган гаиләләрдә

тудылар—хәтта бүгенге көндә дә туа торалар. Бу изге затлар кешеләрдәге тупас энергияләрнең сыйфатын күтәрү, нечкәртү һәм илаһилаштыруны үз өсләренә алдылар, чөнки андый үрнәкләрне башкаларга күрсәтү мисаллары кирәк иде. Алар адәми затның эволюциясен әйдәп баручылар булдылар, бүген дә бу эшне дәвам иттерәләр.

7. Күктәге Идарәче Даирәләр, үзара килешеп, Бөек Ак Нур Орденын кинәйтергә карар кылдылар, аның сафларына, рухи нурлану-яктыру кичереп, Күккә Ашкан кешеләрне кабул итә башладылар. Бу кешеләр анда Гайсә пәйгамбәр ярдәмчесе вазыйфасын, Будда вазыйфасын , Мерлин Ордены әгъзалары вазыйфаларын башкару өчен билгеләнделәр, шулай ук Изге Ана (хәзер бу вазыйфаны Гуань-Инь белән Мәрьям-Ана башкара), җирле Остазлар вазыйфаларын башкару өчен әгъзалыкка кабул ителделәр. *(Гуань-Инь—Азия халыкларын тәрбия кылучы Күккә Ашкан Остаз (хатын-кыз); Мерлин—кельтлар мифологиясендә урын алган тылсым иясе-маг. Ул Британия халыкларының рухи Остазы санала, бер гәүдәләнешендә—безнең эраның 5 гасырында бритлар короле Артурның сарай кинәшчесе булган.—С.Ш.)*

Хәзер төгәлләнеп килүче 26 мең еллык цикл башланыр алдыннан Җир планетасының Күктәге Идарәчеләре, Остазлары, рухи лидерлары вазыйфаларын нигездә Плеяда, Сириус һәм Андромедадан килгән Нур Затлары (Существа Света) башкарып килде. Хәзер инде кешеләр арасында да нурлану-яктыру кичереп Күккә Ашкан затлар җитәрлек санда барлыкка килде, алар рухи үсеш мәктәпләре оештыруны, аларга җитәкчелек итүне үз өсләренә алдылар.

8. Хәзер тәмамланып килгән 26 мең еллык цикл башланган чакта Күктәге Идарәче Даирәләр тарафыннан шундый таләп куелды—эволюцион үсешнең хәтәр нокталарын исәпкә алмаганда, адәми затларга югары тәгълиматлар бирү һәм идарә итү мәсьәләләрен чишүне кеше булып Җирдә яшәү тәҗрибәсе алган затларның үзләренә йөкләргә. Җирдә яшәүчеләр, рухи үсешнең мәгълүм дәрәҗәсенә ирешеп, югары үлчәмнәр, төрле йолдыз системалары белән элемтә урнаштырырга мөстәкыйль рәвештә өйрәнергә тиешләр иде. Нәкъ шул вакытта «Ка» турында тәгълимат барлыкка килде. (Ка—кешенең физик тәнен югары үлчәмнәрдән ингән илаһи энергияләр белән тәэмин итүче, тоташтырып торучы арадашчы ролен башкара.—С.Ш.). Кешеләр рухи максатларына ирешү һәм Җирнең чын хуҗалары расасына әверелү юлларын үзләре табарга тиешләр иде. Плеяда йолдызлыгы вәкилләре кешеләрнең Күкләрдә яшәгән, аларның тәннәрендәге җаннарыннан күп тапкырга кодрәтлерәк һәм мөмкинлекләре гаҗәеп зур булган Олуг Җаны турында күп мәгълүмат бирделәр, Аның белән элемтәгә керү, аралашу хикмәтләренә өйрәттелер. Шулай югары үлчәмнәр, йолдыз системалары белән бәйләнешкә керү ысуллары кешеләргә җиткерелде.

9. Агымдагы 26 мең еллык цикл башланганнан соң үткән 5200 ел эчендә Мисыр һәм Атлантидада барлыкка килгән «Ка» гыйбадәтханәләрендә тәрбия алган, рухи нурлану-яктыруга ирешкән берничә мен кешенең бер өлеше рухи үсешнең тагын да югарырак баскычына—Гайсә пәйгамбәр аны дәрәҗәсенә күтәрелә алдылар. Аларның кайберләре Җирдә торып калырга теләк белдерде, кеше тәнендәге «Ка» каналларыннан файдалану һәм рухи практика белән шөгыльләнү аркасында алар бер үк тәндә 2 мең елга кадәр яши алдылар. Шушы 5200 еллык дәвердә рухи нурлану-яктыруга ирешүнең яңа ысуллары ачылды, Планетадагы әзерлекле җаннар өчен алар бик кулай булып чыктылар.

10. Алла телгә алынган 5200 еллык дәвер тәмамланып килгәндә Планетада киң масштаблы җир тетрәүләр булып узды, алар борынгы континент Лемуриянең сакланып калган гыйбадәтханәләрен һәм Атлантиданың ярты территориясен юкка чыгардылар. Җирдә сакланып калган Лемурия расасы (3 нче Раса) вәкилләре башка урыннарга күченергә карар кылдылар һәм Калифорниядәге (АКШ) Шаста тавы эчендә җир асты культурасына нигез салдылар. Лемурия расасының кайбер вәкилләре Америка, Гавай утраулары һәм Тибетның җирле кабиләләренә килеп кушылдылар. Соңрак алар майялар, буддистлар булып киттеләр. Лемуриялеләр бу мәдәниятләрдә рухи җитәкчеләр, Остазлар ролен башкардылар.

11. Бу катастрофалардан соң Атлантида халкы әле байтак сакланып калганга (бу әле беренче катастрофалар гына була—С.Ш.), алар үз мәдәниятләрен дәвам иттерә алдылар. Аларның коллектив аңы Жирдә исеме Тот булган Затның үз җәмгыятьләрендә кабат гәүдәләнүен һәм һәлакәтләр чорында онытылган борынгы рухи тәгълиматларның янә торгызылуын үтенде. Чыгышы белән Плеяда йолдызлыгының Ра атлы архангеллар ыруы вәкиле булган Тот аларның үтенечен кабул итте һәм Жирдә физик тәндә гәүдәләнде. Тиздән ул Атлантиданың бөек рухи җитәкчесенә әверелде.

## Атлантида һәлакәте, аның нәтиҗәләре

12. Тот Атлантидада гәүдәләнгәннән соң күпмедер вакыт үтүгә Жир атмосферасының аралык-вакыт сүрүендә зур ярык барлыкка килде. Шушы хәлдән файдаланып, элегрәк Лира йолдызлыгыннан Орион йолдызлыгына үтеп кергән бер төркем затлар Жир планетасына да бәреп керүгә ирештеләр. Аларның җитәкчесе Люцифер дигән зат булып, көтмәгәндә Жир сүрүендә барлыкка килгән әлеге ярык фәкать аның тырышлыгы белән барлыкка китерелгән иде. Шулай ул үз тарафдарлары белән сораусыз-нисез Жиргә үтеп керде. Әйтергә кирәк, әлеге ярык Кояш системасының тышкы ягыннан Жир атмосферасына таба төбәп җибәрелгән югары ешлыктагы тибрәнешләр нәтиҗәсендә барлыкка китерелде. Аннан соң шушы ярык аша тиз генә космик корабль үтеп керде. Орионнан, дөресрәге, Лира йолдызлыгыннан үтеп кергән шушы затлар, җитәкчеләре Люцифер ярдәме белән, вакыт-аралыклар аша сикереш ясау ысулын үзләштергән булып чыктылар. Шул сәбәпле алар берничә секунд эчендә әлеге ярыктан эчкә үтеп керделәр—беркем дә аларны туктата алмады. Алдан планлаштырылганча, алар Атлантидага килеп төштеләр, чөнки максатларына ирешү өчен бу иң кулай урын дип санадылар. Ә аларның максаты—Жирдә үз хакимиятләрен урнаштыру иде. Люцифер үзе Жиргә төшмәде, ул һәрвакыт Күкләрнең 4-5 үлчәмендә яшәде, эшчәнлеген шуннан торып алып барды.

Люцифер командасы, ягъни Лира йолдызлыгы вәкилләре, үзләрен кабул итүне һәм атлантлар җәмгыятендә урын бирүне үтенделәр. Атлантида халкының бер өлеше килмешәкләргә ышанмады һәм бу вакыйганың тора-бара рухи тозакка әверелү ихтималын күрде. Башкалар исә Люцифер командасына ышаныч күрсәттеләр, алар шөһрәт-дан һәм өстенлек турында хыялланды, шул сәбәпле лиралыларның килеп төшүен хуплады. Эш шунда ки, Атлантидага төшеп урнашу белән тегеләр җирле халыкны үзләренең «югары» галәми-технологик белемнәренә өйрәтә башладылар. Ул заманда атлантлар җир йөзендә иң югары үсеш алган раса булулары белән бик нык горурлана иделәр. Һәм җир йөзендә үз хакимиятләрен урнаштыру өчен яңадан-яңа җирләр эзләделәр. Килмешәк лиралылар аларга чикләнмәгән көч-куәт, яңа мөмкинлекләр, технологияләр һәм йогынты ясау ысуллары вәгъдә итеп, бу халык белән идарә итә башладылар, үзләренең галәми технология, психик контроль һәм интеллект ягыннан «өстен» икәнлекләрен гел күрсәтеп тордылар.

13. Люцифер командасы басып кергәннән соң үткән 10 мең ел вакыт эчендә Атлантида халкы икегә бүленде: бер лагерьда югары технологияләргә ия лиралылар һәм алар ягына чыгучылар булса, икенчесендә—рухи сафлыгын саклап калучылар тупланды. Атлантларның Мельхиседек храмнарына баскыннар һәм аларның йогынты ясаучы агентлары байтак үтеп керде, алар анда контроль урнаштырырга омтылдылар. Тора-бара «Соры рясалар» *(ряса—дин әһелләренең тышкы өс киеме—С.Ш.)* дип аталган махсус төркем барлыкка килде, соңрак ул «Кара рясалар» дигән исем алды. Бу төркем кешедә психик көчләрне үстерү һәм кара сихер белән шөгыльләнде. Мельхиседек храмнарының кайбер руханилары сафлыгын саклый алды, әмма күпчелек инде рухи сафлыгын югалткан иде.

*(Укучыларга тәкъдим ителгән текстта аңлашылмаган урын калмаска тиеш, дигән принципка тугры калып, безнең татар укучысына таныш булмаган Мельхиседек төшенчәсенә аңлатма биреп китү кирәктер дип уйлыйм.*

*Мельхиседеклар—үзләрендә Галәмдәге төрле дөньяларга иркен рәвештә үтеп керү, алар белән элемтә урнаштыру сәләте үстергән Затлар. Без радионы төрле дулкыннарга көйли алган кебек, Мельхиседек дәрәҗәсенә ирешкән Зат төрле дөньялар белән тоташа ала. Мельхиседек алдына рухи үсешенен бер баскычында һәрвакыт нинди юлдан китәргә дигән дилемма килеп баса: Галәмнен бу өлешендә калыргамы, әллә инде башка дөньяларга күчәргәме? Әмма Мельхиседек безнен дөньябызны ташлап китмәскә дә мөмкин. Ул еш кына Җирдә яшәп кала һәм биредә туып торган катлаулы мәсьәләләрне хәл итү белән шөгыльләнә, кешелек дөньясынын эволюциясенә ярдәм итә. Адәми зат үтәргә тиешле эволюция юлын тәмамлап Күккә Ашкан Остазлар да күп дәверләргә Җир аурасында кала һәм кешелек дөньясынын үсешенә ярдәм итү белән шөгыльләнә. Хәзерге вакытта АКШта яшәгән Мельхиседек дәрәҗәсендәге бер Затнын исеме Друнвало Мельхиседек. Ул күп хезмәтләр авторы, шул исәптән рус теленә тәрҗемә ителгән «Древняя тайна Цветка Жизни» (2 томнан тора) исемле фундаменталь хезмәте басылып чыкты. Шулай ук анын лекцияләре язылган видеокассеталар чыгарыла, төрле илләрдә семинарлары уздырыла. Атлантида заманында да Мельхиседеклар рухи үсеш мәктәпләрен житәкләгән, кагыйдә буларак, бу мәктәпләр храмгыйбадәтханәләрдә урнашкан булган. Кыскасы, кайчандыр исем булган Мельхиседек хәзер бик югары рухи дәрәҗәне анлата.—С.Ш.)*

Ул заманда Атлантидада алиһә Алора храмнары да бар иде. Анда бу алиһә Җәмгыятенен рухани хатын-кызлары яши, аларның дини тәгълиматы Күкләрнен тугызынчы үлчәменнән ингән тәгълимат иде. Лира йолдызлыгы вәкилләре һәм аларның житәкчесе Люцифер бу тәгълиматларны боза алмадылар, ә рухани хатын-кызлар аларга турыдан-туры каршылык, буйсынмау күрсәттеләр. Алар Кара Туганлык (Темное Братство) төркеменен арага үтеп керүенә гел комачаулап килделәр.

Элек, лиралылар басып кергәнче, магия һәм алхимия сәнгате белән шөгыльләнергә теләгән атлантлар, бу көчләрдән дөрес файдалану гарантияләнсен өчен, башта рухи әзерлек чорын үтәләр иде. Әмма тора-бара бу кагыйдә бозылды, үтәлми башлады, психик көчләр һәм сихер-магия белән шөгыльләнү теләсә кемгә рөхсәт ителде. Люцифер үзе һәрвакыт кешегә күренмәс халәттә яшәде, бер үк вакытта ул кешеләрнен анастына (подсознание) бик нык тәэсир итә иде. Ул Лира йолдызлыгы вәкилләренен Кара Туганлык оешмасы белән идарә итә һәм теләгән йогынтыны ясый ала иде. Анын максаты—Җир планетасы һәм Кояш системасы белән идарә итүче Нур Тарафдарларынын көченә ышанмау хисләре тәрбияләү иде. Ахыр чиктә ул, Җирдәге Ин Югары Зат сыйфатында, биредә чикләнмәгән хакимиятен урнаштырырга өметләнде. Ул Җирне Галәмдәге башка дөньялардан аерып алу, анда мөстәкыйль рәвештә идарә итү турында хыялланды.

14. Тора-бара Җирдәге бик күп ир-атларнын анына Люцифер һәм Кара Туганлык оешмасы йогынтысы үтеп керде, чөнки тирәндә яшеренеп яткан идарә итү теләге, бигрәк тә хатын-кызларга хуҗа булу омтылышы яшәү аркасында ир-атларнын психикасын контрольдә тотуга җирлек бар иде. Кара көчләр тырышлыгы аркасында җир астында астрал дөнья төзелде *(мәгънәне Ислам дине төшенчәләренә күчерсәк, җир астындагы астрал дөньяны Җәһәннәмнен Җир үзәгенә таба юнәлгән төрле катламнары дип атарга мөмкин.—С.Ш.)*. Анда төрле церемонияләр үткәрү мәйданнары, яшәү урыннары булдырылды, анда шулай ук Кара Туганлык оешмасынын коллектив аны урнашты. Җир катламнары аша өстә яшәүче адәми затларга энергетик дулкыннар, анастына, күнелләргә үтеп керә торган тискәре уй-фикерләр җибәрелеп торды. Шулай барлыкка килгән һәм бүгенге көндә дә әле кешеләргә йогынты ясап торган коллектив ан «Сатана» дип атала. *(Коръәндә бу коллектив көч «Иблис» исемен йөртә.—С.Ш.)*. Бу «коллектив ан» дигән нәрсә Кара Туганлык оешмасы әгъзаларынын түбән дәрәҗәдәге аннары берләшүдән барлыкка килде. Бу көч (Иблис) бер кодрәтле зат рәвешендә дә эш итә ала иде. Үзен Раббыбыздан, Җирдән, сезнен Кояш системасыннан һәм Илаһияттан өстен күрүче, һәртөрле манипуляцияләргә, алдашуларга сәләтле

шушы коллектив аң үсә, көчәя барган саен, әлеге кара көч тагын да күбрәк энергия туплады. Шулай Жирдә Караңгылык белән Яктылыкның бер-берсеннән аерылуы, полярлашуы гаять тизләнде. Ни өчен дигәндә, Раббыбызга ышанмауны, бар нәрсәнең Илаһи План нигезендә алып барылуын шик астына куюны даими кабатлап торган, хатын-кызга кимсетеп караган, салкын акылны хисси һәм рухи дөньялардан өстен санаган тискәре уй-образлар адәми затларның аңастына гел һөҗүм итеп торды.

Кыскасы, Атлантида җәмгыятендә технология һәм кара сихер белән мавыгу шул чиккә житте ки, кешеләр табигать көчләре, стихияләр белән идарә итә, Раббыбыз вәкаләтләренә тыкшына башладылар. Жирдә мондый хәлнең әле беркайчан да булганы юк иде. Бу чорда Яктылык тәгълиматына йөз тоткан гыйбадәтханәләр хатын-кызлар карамагында калса, Караңгылык храмнарында исә ир-атлар идарә итте. Әлбәттә, әлеге бүленеш абсолют рәвештә булды дип әйтүе кыен, әмма күпчелек халык өчен ул фәкать шулай иде.

Атлантида дәверенең ахырында, Тот исемле Остаз анда гәүдәләнгәннән соң 10 мең еллар вакыт үткәч, бу цивилизацияне хаос һәм буталчыклык, зур курку басып алды. Хакимият һәм шәхси өстенлек өчен көрәш Атлантида җәмгыятендә гадәти бер күренешкә әверелде, хәтта хатын-кызлар хуҗа булган алиһә Алора храмнарында да курку һәм чикләнгәнлек хөкем сөрде.

15. Атлантида һәлакәте алдыннан Яктылыкка йөз тоткан храм һәм рухи оешма җитәкчеләре үз тәгълиматларын бөтен Жир шарына тарату кирәклеге хакында Күктәге Идарәче Даирәләрдән кисәтү һәм киңәш алдылар. Люцифер һәм Кара Туганлык оешмасының җимергеч эшчәнлеге аркасында иң югары, вакыты җитмәү сәбәпле бирелмичә торган белемнәр бары бер урында—Атлантидада гына тупланды. Эш шунда ки, белемнәр жир йөзендә мөмкин кадәр тигез таралырга тиеш. Халыкларга андый белемнәр бирелгәнче әле байтак дәверләр үтәргә тиеш иде. Шуңа күрә зур рухи әзерлеге булган кешеләр, кечкенә төркемнәргә бүленеп, сиздермичә генә Атлантиданы ташлап китә башладылар. Алар үзләре белән Жир тарихы, аның эволюцион юлы турында мәгълүматлар тупланган бик күп кристаллар алып киттеләр. Бу мәгълүматлар кристалларга Хакыйкать Советы (Совет Истины) дип аталган махсус структура тарафыннан салынган иде. Алиһә Алора храмы руханилары Грециягә алып киткән шундый бер кристалл атлантларның рухи житәкчесе Тотның баш сөяге формасында ясалган иде. Ә Тот үзе моннан 9000 ел элек Атлантидадан китеп, рухи дөньяларга күчте. Баш сөяге рәвешендәге әлеге кристалл шушы төркем тарафыннан төзелгән Дельфы Күрәзәчесе храмы (Храм Дельфийского оракула) астына яшерелде һәм бу гыйбадәтханәне Иблис тарафыннан жир астыннан (Жәһәннәмнән) җибәрелә торган тискәре йогынтылардан, шуннан ук килгән энергетик дулкыннар үтеп керүдән саклады. Храмны психик яктан пычрату, эштән чыгару мөмкин булмаганга, борынгы грекларның «Зевс-алла гаскәриләре» дип аталган Кара Туганлык оешмасы әгъзалары, ахыр чиктә, рухани хатын-кызларны (жрицаларны) төрмәгә ябып куйдылар, аннан жаннарын кыйдылар, ә храмны үзләренең борынгы примитив илаһларына багышлап үзгәртеп кордылар.

16. Атлантидадан китеп өлгергән башка төркемнәр мәгълүмат банкы булып хезмәт иткән кристалларны һәм рухи тәгълиматларны Үзәк һәм Көньяк Америкага, Көнбатыш Ауропага, Көньяк Африкага, Һималайга, Көнчыгыш Азиягә, Австралиягә һәм Мисырга алып килделәр. (Төньяк Американың жирле ыру-кабиләләре ул чакта үз эволюцияләренең кызыклы бер баскычын үткәнгә, атлантларга анда үтеп керү кирәкле дип табылмады.). Ирләр һәм хатын-кызлардан торган иң зур төркем Мисырга килеп урнашты. Барлык төркемнәрдә дә Илаһи Хакыйкатьне саклау эшенә нык бирелгән затлар тупланган иде. Алар калган гомерләрен төрле илләрдә рухи үсеш алу храмнарына (инициация храмнары) нигез салу, анда үз тәгълиматларын тарату эше белән шөгыльләнеп үткәрделәр. Шулай итеп, иң зур төркем Мисырга килеп урнашты, чөнки анда Олуг Пирамида бар иде. Ул һәрвакыт Илаһи Хакыйкать белән Кояшның эволюцион кодлары тибрәнешләрен саклап килде, бүгенге көндә дә саклый.

Киләчәктә Мисырның үзендә һәм башка илләрдә-кыйтгаларда әле бик күп пирамидалар төзеләчәк иде. Алар Жир тарихы турында мәгълүматлар салынган кристаллар өстенә төзеләчәк иде. Ә бу кристаллар исә, челтәр сыман итеп эшләнгән махсус җайланмалар эченә урнаштырылып, пирамидада илаһи нурланышларны сакларга, түбән уй-фикернең үтеп керүен тоткарларга бурычлылар иде. Лира йолдызлыгы вәкилләре (Люцифер һәм аның тарафдарлары) Кояш колларын бозу, алар белән идарә итүгә ирешү өчен коллары ярдәмендә Атлантидада берничә пирамида төзеп карадылар. Тик Атлантиданың һәлакәте вакытында аларның барысы да шартлап бетте, яисә океан төбенә китте.

17. Атлантида утравының тулысынча һәлак булуының төп сәбәбе Люцифер һәм аның тарафдарларының жир астыннан ифрат көчле тавыш дулкыннары җибәрүенә бәйле. Бу дулкыннар анда җимергеч көчкә әверелде. Эш шунда ки, Кара Туганлык оешмасы планы буенча, атлантларның жир өстендәге храмнарында урнаштырылган югары ешлыкта (вибрациядә) эшләүче Нур Структуралары астан җибәрелгән тавыш дулкыннары тәэсирендә тәмам җимерелергә, юкка чыгарга тиешләр иде. Әгәр дә эшләр алар планы буенча барса, бу чаралар храмнарга кара сихер һәм Сатана (Иблис) контролендәге энергияләрнең иркен үтеп керүен тәэмин итәчәк иде. Әмма алар тавыш дулкыннарының тәэсир итү көчен дөрес исәпләмәделәр. Алар тарафыннан җибәрелгән дулкыннар шундый көчле булып чыкты ки, бу дулкыннар кайтаваз рәвешендә кире үз чыганагына әйләнеп кайтты һәм тегеләрнең жир астындагы тавыш генераторларын чәлпәрәмә китерде. Коточкыч шартлау булды, ул чылбырлы реакция барлыкка китерде, шулай жир астындагы башка генераторларга күчте. Шуның нәтиҗәсендә моңарчы Жирдә беркайчан да булмаган көчле тетрәнүләр башланды. Гомумән, андый көчле тетрәнүнең Жирдә башка кабатланганы юк. Бик күп пирамидалар шартлап вак таш өеменә әверелде, әмма кайберләренә берни булмады. Шулай Жирдә глобаль масштабтагы катаклизмнар башланып китте һәм алар ике ай буена сузылды. Нәтиҗәдә Атлантида утравы океан төбенә китте.

Атлантиданың рухи мирасын саклап калу, аны башка регионнарга тапшыру өчен алдан жир йөзенә таралып өлгергән рухи җитәкчеләр зыян күрмәделәр һәм үз вазыйфаларын башкарып чыга алдылар. Хәер, катастрофалардан котылып калыр өчен юлга чыгып та, әллә ни ерак китеп өлгермәгән берничә төркем генә шартлаулар вакытында күтәрелгән гигант дулкыннар эчендә һәлак булды. Бу континентның тулысынча җимерелүе якынча 10 мең 400 еллар элек булды.

18. Катастрофадан соң Люцифер (Иблис) Лира йолдызлыгы вәкилләрен Күкнең астрал катында туплады *(ягъни катастрофалар вакытында һәлак булып, алар теге дөньяга күчә—С.Ш.)* һәм алга таба нишләргә дигән мәсьәләне хәл итәргә керешге. Кешеләрнең аңастына (подсознание) даими рәвештә тәэсир итеп тору өчен, лиралылар Жир атмосферасының түбән астрал катында, шулай ук жир астындагы Сатана (Иблис) урнашкан катларда ныклап торып тормыш корырга булдылар һәм моны башкарып чыктылар. Шуннан тәэсир итеп тору нәтиҗәсендә жир йөзендәге халыклар, кавемнәр, кабиләләр арасында каршылыклар, сугыш-бәрелеш галәмәтләре ешаеп китте. Америка, Африка, Аурупаның жирле халыклары аерым кабиләләргә бүленде, ә бит моңарчы алар шул кабиләләрнең зур берлеген тәшкил итә иделәр. Әлеге аерылу-бүленүләрнең сәбәбе жир бүлешү, минераль ресурсларга һәм су чыганакларына хокук даулау, рухи үзгәлекләр һәм бер-береңә карата һич аңлатып булмаган шикчәнлек хисләре иде. Борынгыдан килгән ниндидер өстенлекне алга сөрүче тискәре фикерләр кеше психикасына торган саен күбрәк үтеп керә башлады. Әмма жир йөзенә таралган атлантлар һәм кайбер төркемнәр үз рухи җитәкчеләре ярдәмендә әлеге бозык һәм җимергеч уй-фикерләр басымына бирешмичә кала алдылар. Рухи җитәкчеләр тарафыннан төрле жирләрдә бүгенге көндә Стоунхенджда (Англия) сакланып калган түгәрәк корылмага охшаш «рәшәткәләр» төзелде, алар психикага тәэсир итүче бозык йогынтыларны тоткарлый, шушы йогынтыларга бирелмичә, кешеләргә төрле церемонияләр, җыелышлар үткәрү мөмкинлеге тудыра иде. *(Галимнәр күпме заманнан бирле*

*Стоунхенджның ни өчен төзелгәнлеген, нәрсәгә хезмәт иткәнлеген ачыклый алмыйча баш ваталар. Нинди генә гепотезалар юк! Остаз биргән мәгълуматта бу мәсьәләгә дә ачыклык кертелә.—С.Ш.)*

Яңа җирләргә күчеп утырган атлантлар арасында Алиһә Алора храмнары әле 5 мең елга якын көчле рухи үзәкләр булып хезмәт иттеләр. Хатын-кыз һәм ир-атлар храмнары Мельхиседек, Тот һәм Алиһә Алораның изге тәгълиматын алга сөрде, аны саклап килде. Бер үк вакытта бу тәгълиматларга җирле халыкларның аллалары, төрле инанулары һәм рухи практикалары өстәлә барды, шулай атлантлар үз тәгълиматларын киңрәк җәелдерүгә ирештеләр. Ир-ат һәм хатын-кызның роле турындагы тәгълиматлар, рухи дәрәҗәгә багышлау ысуллары, Ка храмнары, дәвалау чаралары һәм рухи үсешне тизләтүнең төрле алымнары Мисырда, Грециядә, Үзәк һәм Көньяк Американың төрле төбәкләрендә киң таралыш алды. Җир йөзендә Люцифер һәм Кара Туганлык оешмасы йогынтысына бирелмичә калган кабиләләр дә бар иде, алар рухи яктан саф һәм тыныч-юаш холыклы халыклар булып калдылар. Әмма гомумән алганда Җирдә Ак һәм Кара көчләрнең үзара бүленеше барыбер көчәя төште.

19. Моннан 5 мең еллар элек *(безнең эрага кадәр 3 нче меңьеллык башында—С.Ш.)* Кара Туганлык оешмасына тупланган Лира йолдызлыгы вәкилләре белән алар ягына чыккан адәм балалары планетаның төрле төбәкләрендә гәүдәләнә, аерым гаиләләрдә туа башладылар. Аларның төп максаты—рухи яктан алга киткән мәдәниятләргә үтеп керү, анда сугыш-һәлакәт, җимерүләр оештыру иде. Бу эш акрын гына алып барылуга карамастан, планетада кешеләр өстеннән хакимлек иткән идарәчеләрнең (патшалар, фиргавеннәр, ханнар, корольләр һ.б.—С.Ш.) рухи сыйфатында шактый үзгәрешләр булды. Шулай Мисырда, Грециядә, Аурупа һәм Америка тарихында Яктылык һәм Караңгылык дәверләре бер-берсен алыштырып килә башлады. Кара Туганлык оешмасы үтерү, җимерү, көчләү һәм һәр җирдә үз хакимиятен урнаштыру белән шөгыльләнде. Вакыт уза һәм бераздан Яктылык тарафдарлары кабат өстенлек ала һәм тегеләрне бәреп төшерә иде. Аннан цикл тагын кабатлана.

Тулаем алганда Җир планетасы һәрвакыт Яктылыкка, Югары Затка (Верховное Существо) һәм Югары Уникеле Советка (Высший Совет Двенадцати) йөз тотып яшәде. *(Югары Зат—Җир планетасындагы Иң Югары Зат, Ул Җирне һәм кешелек дөньясын эволюцион үсеш юлыннан алып бара. Дин китапларында Аны Раббыбыз дип атыйлар. Югары Уникеле Совет—Кояш системасының киңәшмә органы. Бу орган безнең Кояш системасына кергән планеталар һәм Үзәк Кояш арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләү белән шөгыльләнә, шулай ук һәр планетаны, анда барган процессларны күзәтеп-барлап тора.—С.Ш.)* Әмма барыбер Җирдәге Ак һәм Кара көчләр балансы байтак үзгәрешләр кичерде. Шунысы әһәмиятле, Җирдә яшәүчеләрнең күпчелеге һәрвакыт ярату һәм изгелек хисләренә ышанып яшәде, ләкин бу ышаныч зәгыйфь иде. Шул сәбәпле кешеләр үзләре өстеннән контроль урнаштыруны максат итеп куйган дәүләти һәм дини структураларга тиешенчә каршылык күрсәтә алмадылар. Җирдә яшәүчеләрнең күпчелеге шактый заманнар үзләрендә хөкем сөрүче сыйныфларга каршы торырдай көч таба алмады. Дөресен әйткәндә, безнең өчен мондый вәзгыять Җир тарихындагы иң сәер күренешне тәшкил итә. Әлеге курку һәм көчсезлекнең бер сәбәбе Күкләрнең 4 нче һәм 5 нче үлчәмнәреннән кешеләргә җибәрелеп торган астраль контроль йогынтысына бәйле. Бу эшне Люцифер (Иблис) үзе, Лира йолдызлыгы вәкилләре һәм Җир планетасы тарихында мәгълүм роль уйнаган Нибиру планетасы вәкилләре алып бара *(Нибиру планетасы вәкилләре Шумер цивилизациясенә нигез салучылар санала—С.Ш.)*. Хәзерге көндә безнең өчен иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе—сездә бу көчләрнең психик контроленә каршы торырлык дәрман бармы, әллә юкмы—шуны төгәл ачыклау.

...Хәзерге көндә Җирдә яшәүчеләрдән теләк-омтылышларының үтәлүен таләп итәрлек рухи кыюлык сорала. Әлбәттә, хәзерге вакытта җир йөзендәге изге күңелле кешеләрнең күпчелеге, көндәлек тормыш мәшәкатьләренә кереп чумып, рухи идеаллар турында уйлаудан мәхрүм булып яшиләр. Шулай да күпчелек кешеләр

әхлак нигезләрен аңлый һәм аларның күңеле изгелек ягында. Шуна күрә хәзер Жир кешеләре алдында рухи сикереш ясау өчен гаҗәеп мөмкинлекләр ачыла...»

(Өзек «Послания Старших Братьев Человечества». Изд-во «София», 1998, дип аталган контактёрлык материаллары җыентыгыннан алынды.)

* * *

Бу бүлекне без Коръәндәге: «Мин Адәмнән өстенрәк...»—дигән Иблис (Люцифер) сүзләре белән юкка гына атамадык. Остазларның берсе тарафыннан бирелгән глобаль тарих сәхифәләре безгә монарчы билгеле булмаган бик күп вакыйгаларны ачып сала. Бу мәгълүматлар бәяләп бетермәслек кыйммәткә ия, дип шикләнмичә әйтергә мөмкин.

Әйе, бүгенге көндә тарих фәне дип аталган рәсми фән Жирнең үткән тарихына 6 мең елдан да эчкәрәк керә алмый. Иң борынгы цивилизацияләрдән саналган Мисырның да тарихка кадәрге чоры (династияләр барлыкка килгәнче) безнең эрага кадәр 5 мең еллар тирәсендә генә башлана. Шумер тарихы исә безнең эрага кадәр 4 нче меңьеллыктан башлана. Һиндстан белән Кытайның ачыклана төшкән тарихы безгә тагын да якынрак, ә Борынгы Греция белән Рим тарихы исә, кичә булган вакыйгадай, күз алдыбызда тора. Бу хәл адәми затның үз тарихын әле бик начар белүе турында сөйли.

Ерак дәверләрдә ниләр булган, кешелек дөньясы ничек яшәгән, нинди чорлар кичергән, эволюциянең нинди баскычларын үткән—моны җир йөзендә санаулы кешеләр генә белә. Эзотерик чыганаклар белән таныш кешеләргә бүгенге кешелек дөньясының бишеге саналган Лемурия, аннан соң үсеп чыккан Атлантида цивилизацияләре хакында гына түгел, Жир тарихында мәгълүм роль уйнаган галәми цивилизацияләр йогынтысы турында да кайбер нәрсәләр билгеле. Әмма рәсми фән һәм аның басымы астында яшәүче күпчелек кешеләр эзотерик чыганакларга шикләнеп карый, аларны танымый, Галәмдә башка цивилизацияләр булу фактын шушы көнгә кадәр күрмәмешкә салына. Материалистик күзаллауга корылган рәсми фәннең хәле аңлашыла: эзотерика белән диалог башлап җибәргән очракта үзенең дәлилләре җитмәячәген, астына су керәчәген, гасырлар буе тырышып төзегән бинасының нигезе чатный, уала башлаячагын ул яхшы аңлый. Аннан соң бүгенге рәсми фәнне терәтеп торучы бик күп авторитетларның тиз арада пьедесталдан очып төшәчәге дә көн кебек ачык.

Ә бит Жир дип аталган гүзәл планетада кешелек дөньясы күп миллион еллар яшәп килә. Нинди генә цивилизацияләр булмаган да, илаһи эксперимент рәвешендә барлыкка китерелгән адәми затның нинди генә вариантлары булдырылмаган. Әгәр дә укучыларыбыз адәми затны үзенең яралтылу вакытыннан бирле һаман бүгенге без белгән кеше рәвешендә тереклек иткән дип уйласалар, бик нык ялгышкан булырлар иде. Борынгы чыганакларда җир йөзендә яшәгән гигантлар турында юкка гына телгә алынмый. Әгәр дә без шуна өстәп планетабыз үз гомерендә бернichә тапкыр күчәренең торышын үзгәрткән дисәк, бу тагын бер серне укучыларга җиткерү була. Әгәр дә без бүгенге көньяк һәм төньяк полюслар урынында кайчандыр җылы климат хөкем сөргән дисәк, тагын бер серне ачып салу булыр иде.Жир күчәре урыныннан күчкән саен планетаның климатик зоналары да үзгәреп торган. Боз асларыннан табылган мамонтларның ашказанында ямь-яшел үлән табылу фактлары шул хакта сөйләмимени?!

Ә Жирдә гел кабатланып торган 26 мең еллык эволюция циклы турындагы мәгълүмат үзе үк уйланырга күпме азык бирә *(кара: С.Шәмси. Күк капусы ачылса. Казан утлары, № 7, 2004)*.

Кешелек дөньясының Плеяда, Сириус, Андромеда, Венера, Җидегән йолдыз һ.б. күк җисемнәре, йолдызлыклар белән булган борынгы бәйләнешләре, эволюция барышында алардан алган ярдәме турында да кайбер хәбәрләр бар.

Әгәр дә без җир йөзендә яшәгән халыкларның тышкы кыяфәте, тән төсе, холкы-фигыле, этнографиясе бер-берсеннән бик нык аерылып торуын искә төшерсәк, расаларның генетик тамырлары Жирдән читтә яшәгән цивилизацияләргә

барып тоташканын бик тиз чамаларбыз. Яисә берничә цивилизациянең, үзара килешеп, геннарын уртаклашып, адәми затның мәгълүм бер тибын ялгау ихтималын да истән чыгармыйк. Һәм бу Жир тарихында булып кичкән күп дәверләрнең асылын ачып салыр.

Планетабыз һәм кешелек дөньясы Галәмдә ятим бала түгел. Аның даими Күзәтүчеләре һәм Тәрбиячеләре бар. Алда китерелгән глобаль тарих сәхифәләрендә бу хакта ап-ачык әйтелә. Шушы мәгълүматлар яктылыгында фикер йөрткәндә без диннәрнең, рухи тәгълиматларның да, очраклы рәвештә үсеп чыкмыйча, махсус кайгырту яисә йогынты ясау нәтиҗәсе икәнлегенә төшенербез.

Классик диннәр заманы инде узып бара. Алар тарихта үзләренә йөкләнгән житди вазыйфаны үтәделәр. Хәзер кешенең фикер сөреше планетар аң дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш. Алай гына да түгел, эзотерика фәне белән коралланган кеше хәзерге көндә аңы белән Галәм киңлекләренә чыгу, андагы рухи дөньялар белән элемтәгә керү ихтималын да уйларга бурычлы. Хәзер Тәрбиячеләребез тарафыннан бирелгән яңа белемнәргә таянган хәлдә фикри һәм рухи яктан яңа баскычка күтәрелү заманы килде.

Жир йөзендәге цивилизацияләр тарихында Тот (Техути) исемле Остазның роле турында да бер-ике сүз әйтеп үтү кирәктер, дип уйлыйм. Чыгышы белән Плеяда йолдызлыгыннан булган бу Зат байтак заманнар Атлантида җәмгыятендә рухи лидер була. Атлантида һәлакәтеннән соң Мисырга күчеп, бу мәдәниятне рухи яктан күтәрү өчен күп көч куя. Борынгы Мисыр мифологиясендә Тот бу илнең интеллектуаль тормышын оештыручы, вакыт төшенчәсе белән эш итүче, аны елларга, айларга, көннәргә бүлүче, аны санап баручы алла исәпләнә. Ул шулай ук кешеләрне укырга-язарга, санарга өйрәтүче санала. Илнең барлык архивлары һәм мәшһүр Гермополь шәһәре китапханәсе аның кайгыртуында булган, язу эшен башкаручылар (писецлар) аңа багышлап догалар кылганнар, корбан чалганнар, ул Мисырның Ра алла вәзире саналган. Тора-бара үзе дә аллаларның берсенә әверелгән. Мисырлыларның мәшһүр «Мәрхүмнәр китабы»нда Тот үлгән кешенең йөрәген үлчәгәндә аның изгелекләрен һәм гөнаһларын теркәп баручы Зат буларак сурәтләнә. Тот шулай ук мәрхүмнәрне теге дөньяга озатучы вазыйфасын башкаручы буларак та билгеле.

Бу Зат Борынгы Греция мифологиясендә дә зур урын алып тора. Ул анда Гермес исемен йөртә, аллаларга хәбәр китерүче, юлчыларның ярдәмчесе, Мисыр мифологиясендәге кебек үк, мәрхүмнәрне теге дөньяга озатучы санала. Дөрес, Мисырның чәчәк аткан чорын күрмәгән греклар Тот-Гермеска бигүк житди булмаган сыйфатлар да өстәгәннәр. Әмма антик чорның азагында ул кабат Гермес Трисмегист (тәрҗемәсе—Гермес Триждывеличайший—Өч Тапкыр Бөек Гермес) исеме белән рухият тарихында кабат житди урын ала, яшерен гыйлемнәр тупланган кырыкка якын хезмәт авторы буларак олылана, адәми затларга бирелгән илаһи гыйлемнәр атасы дип санала.

Жирнең глобаль тарихы сәхифәләрендә Күкләрнең кешелек дөньясы белән эш итү алымнарын ачып салган мисаллар безнең өчен аеруча кыйммәтле һәм зур әһәмияткә ия. Китерелгән мәгълүматлар безгә Күктәге Идарәче Даирәләрнең (Иерархияләрнең), ягъни төрле дәрәҗәдәге Тәрбиячеләребезнең ничек итеп жир йөзендә Нур, Рухи Тәгълиматлар тарату белән шөгыльләнүен, бу эшкә рухи әзерлеге житәрлек дәрәҗәдә булган адәм балаларын да тартуын, тора-бара алар өстенә төрле җаваплы вазыйфалар йөкләнүен, шулай Жирнең үзендә туып үскән затлардан Галәм хезмәткәрләре, Раббыбыз Планын тормышка ашыручылар тәрбияләнүен аңларга, бу процессны ачык итеп күз алдына китерергә ярдәм итә. Бүгенге көндә шундый белемнәр белән коралланып, аң дәрәҗәңне мөмкин кадәр үстереп һәм киңәйтеп кенә рухи үсешкә ирешергә мөмкин.

Мәгълүматларның Атлантида тарихына багышланганнары шулай ук зур әһәмияткә ия. Эш шунда ки, Атлантида һәлакәте белән кешелек дөньясының 700 мең ел дәвам иткән 4 нче Раса тарихы тәмам була. Аны еш кына Атлантлар Расасы яки 4 нче Кешелек Дөньясы дип тә йөртәләр. Бу очракта «раса» сүзе тән төсен билгеләгән тар мәгънәне аңлатмый, ә кешелек дөньясы тарихының зур

бер дәверен күздә тота. Атлантлардан соң жир йөзендә үсеп чыккан раса шартлы рәвештә Арийлар Расасы, яки 5 нче Кешелек Дөньясы дип йөртелә. Монысы инде хәзерге кешелек дөньясы, ягъни без белгән дөнья булып чыга. Кызганычка, безгә шушы 5 нче Раса тарихы да житәрлек дәрәжәдә мәгълүм түгел. Ә инде атлантлар турында әйтеп тә торасы юк. Бүгенге көндә дә рәсми тарих фәне Атлантиданың яшәвен танымый, төрле сәбәпләр табып, аны шик астына куя, гәрчә эзотерика белән житди шөгыльләнүче һәркем өчен бу аксиома булып тора.

Бәхеткә, бүгенге көндә Остазларыбыз тарафыннан Атлантида тарихына кагылган мәгълүматлар да бирелә һәм бу цивилизациянең тарихын ачыграк күз алдына китерү мөмкинлеге туа. Бирелгән мәгълүматлар Люцифер (Иблис) һәм аның командасы эшчәнлегенең 4 нче һәм 5 нче Кешелек Дөньялары тарихына ничек тәэсир итүен ачып сала. Беренче чиратта, без Атлантлар Расасының ни сәбәпле тарих мәйданыннан төшеп калуы турында төп-төгәл җавап алабыз. Юкса дини текстларда очраган ишарәләр мәсьәләне берничек тә хәл итми.

Атлантида җәмгыятенең фаҗигасы—аның тормышына Галәмнән килгән затларның дорфа рәвештә тыкшынуыннан башлана. Шул сәбәпле анда зур каршылыклар үсеп чыга, әхлак бозыла, рухият бик түбән төшә, кара сихер чәчәк ата. Рухи яктан әзерлексез адәм балалары, вакытыннан алда галәми белемнәргә, технологияләргә ия булып, алардан явыз максатларда файдаланырга тотыналар. Шулай Раббыбыз вәкаләтләренә тыкшыну башлана. Нәтиҗәдә Атлантида һәлак була.

Люцифер эшчәнлегенә кагылышлы мәгълүматлар яктылыгында без шулай ук ни өчен Атлантлар Расасының шундый авыр тарихи юлга кереп китүен, ни сәбәпле жир йөзендә туктаусыз сугышлар, халыкларның даими бәрелешләре булып торуын да ачыклыйбыз, глобаль тарихның эчке пружиналарын, яшерен механизмнарын күрә башлыйбыз. Шулай безгә жир йөзендә үсеп чыккан цивилизацияләр тарихына Ак һәм Кара көчләрнең үзара бәрелеше жәһәтеннән күз ташлау мөмкинлеге ачыла. Бу хәл безгә тарихтагы күп күренешләрнең асылын аңларга ярдәм итә. Моны бары тик адәм балаларының күзләрен ачу, Күкләрдән ингән рухи ярдәм дип кенә бәяләргә мөмкин.

Аннан соң безгә 5 нче Раса тарихындагы бер бик сәер күренеш ачыла. Ул да булса, без белгән борынгы цивилизацияләрнең глобаль тарих биеклегеннән торып караганда «кинәт» үсеп чыгуы һәм тиз арада югары рухиятка ирешүе; аларның без бүгенге көндә дә һич ирешә алмаган илаһи белемнәрдән файдалануы, гаҗәеп храмнар, архитектура ядкарьләре, пирамидалар, зиккуратлар, дини һәм спорт комплекслары төзүе һ.б. Бирелгән мәгълүматлар безгә бу мәсьәләгә дә ачыклык кертергә ярдәм итә.

Эш шунда ки, ничек кенә мактансак та, безнең 5 нче Раса казанышлары күп очракта Атлантида мирасына барып тоташа, шул нигездә үсеп чыга. Бер өзекне кабат хәтердә яңартыйк: «Атлантидадан китеп өлгергән башка төркемнәр мәгълүмат банкы булып хезмәт иткән андый кристалларны һәм рухи тәгълиматларны Үзәк һәм Көньяк Америкага, Көнбатыш Аурупага, Көньяк Африкага, Һималай тауларына, Көнчыгыш Азиягә, Австралиягә һәм Мисырга алып килделәр... Ирләр һәм хатын-кызлардан торган иң зур төркем Мисырга килеп урнашты. Барлык төркемнәрдә дә Илаһи Хакыйкатьне (Божественная Истина) саклау эшенә нык бирелгән затлар тупланган иде. Алар калган гомерләрен төрле илләрдә рухи үсеш алу храмнарына (инициация храмнары) нигез салу, анда үз тәгълиматларын тарату эше белән шөгыльләнеп үткәрделәр».

Бу өзек безнең 5 нче Кешелек Дөньясы тарихын тирәнтен аңлау өчен ТЫЛСЫМЛЫ АЧКЫЧ булып тора. Чыннан да, планетабыздагы күп халыклар Атлантида һәлакәтен дөньякүләм масштабта узган коточкыч катаклизм дип кабул итә, бигрәк тә Атлантик океан яр буйларында урнашкан халыклар. Бу Остаз тарафыннан тапшырылган хәбәрдә дә раслана, анда: «Коточкыч шартлау булды, ул чылбырлы реакция барлыкка китерде—жир астындагы башка генераторларга күчте. Шуның нәтиҗәсендә моңарчы Жирдә беркайчан да күзәтелмәгән көчле тетрәнүләр башланды. Гомумән, андый тетрәнүләрнең Жирдә башка кабатланганы

юк»,—диелә. Димәк, Жир шарында яшәүче халыклар хәтерендә бу һәлакәтләр гаҗәеп тирән эз калдырган, шуңа күрә алар мифологиядә дә урын алган. Шушы дөньякүләм катастрофадан соң без яшәгән дөньяны Атлантида мирасын саклап калган рухи житәкчеләр күтәрә, үсеп чыккан цивилизацияләргә нигезне алар сала, гыйлемнәрне алар бирә, мәшһүр храмнар, рухият үзәкләре алар ярдәмендә калкып чыга. Алар халыкларны Люциферның (Иблиснең) тискәре йогынтысыннан саклап, диннәр, рухи тәгълиматлар белән тәэмин итә, адәми затка үзенең илаһилыгын онытмыйча тереклек итү мөмкинлеге бирә.

Шушы урында укучыларыма авыр сорау бирәсем килә. Бүгенге көндә классик диннәрдән саналган, миллион адәм балаларын үз канаты астына алган борынгы тәгълиматлар кешенең аңын киңәйтә, үстерә аламы? Адәми заттан бары тик инануны гына таләп иткән, информацион цивилизациягә аяк баскан бүгенге кешегә мәгълүматны бик аз биргән бу искергән тәгълиматлар үткән юлыбызның глобаль манзарасын ачып салырга сәләтлеме? Кызганычка, «юк» дип әйтергә туры килә. Бу тәгълиматлар кешелек дөньясына бирелгәндә жир йөзендә бөтенләй башка заман һәм башка вәзгыять булып, алар алдында бөтенләй башка бурычлар һәм максатлар торган түгелме? Раббыбыз белән адәми зат арасында элемтәне саклау, үзләренең илаһилыгын адәм балаларының исләренә төшереп тору һәм Күкләрдәге Тәрбиячеләребезгә догаларыбыз аша рәхмәтләребезне житкерү һ.б.

Әйе, әгәр дә шушы диннәр, рухи тәгълиматлар булмаса, Люцифер һәм аның тарафдарлары алып барган юлдан яздыру сәясәте тагын да җимергеч йогынты ясамас идемени? Шуңа күрә без борынгы диннәргә хөрмәт белән карарга бурычлы. Кешелек дөньясының караңгы дәверләрендә адәми затның рухиятын саклап калу юлында алар фидакарь эшчәнлек алып барды. Әмма дөньяда бер нәрсә дә мәңгегә килмәгән, һәр нәрсә үзгәрә, күпмедер вакыттан соң искерә, тормыштан артта кала башлый. Аның урынын яңалары алмаштыра. Бу хакыйкать рухи тәгълиматларга да кагыла. Күпмедер вакыттан соң алар да үзгәргән тормыш таләпләренә җавап бирә алмый башлый. Алар урынына яңа тәгълиматлар иңә, туа, дөньяга тарала. Яңалары инде үзгәрә барган дөньяны яңача—тирәнрәк һәм киңрәк аңлата.

Без хәзер фәкать шундый заманны—дөньяның тамырдан үзгәрә бару заманын кичерәбез. Иске классик тәгълиматлар урынына адәми затны Галәм масштабында фикер йөртергә өйрәтүче югарырак баскычта торган тәгълиматлар килә, алар инде ишегебезне шакый. Адәм балаларын, халыкларны бүлгәләп торган региональ тәгълиматларга ябышып ятмыйча, тарлыктан, аң-фикер чикләнгәнлегеннән арынырга чакыра. Бу яңа тәгълиматлар инде без белгән классик диннәр рәвешендә булмаячак, гомумән, алар диннәр булмаячак, ә Галәмдәге закончалыкларны, яшәү тәртибен, анда хөкем сөргән әхлак кодексын бәян итүче тәгълиматлар булачак. Булачак дип әйтү дөрес түгел, алар инде бар! Алар һәрвакыт булган, Галәмдәге Нур Тарафдарлары (Силы Света) һәрвакыт шул кануннарга таянып эш алып барган. Бары тик эволюция баскычларының түбәнрәк басмасында торган кешелек дөньясы гына аларны белмәгән, белә алмаган. Чөнки аң-белемнәрнең, дини тәгълиматларның, әхлак өлгеләренең югарырак баскычта торганнары Күкләрдән кешелек дөньясы аларны кабул итәргә әзер булгач кына иңә. Башлангыч сыйныф баласына югары математика укытылмаган кебек, кешелек дөньясына да Илаһи Гакыл (Божественная Мудрость) өлешләп, аның өлгерү дәрәҗәсенә карап кына бирелә. Һич тә башкача түгел! Шуңа күрә рухи тәгълиматларның тормыш таләпләренә җавап бирми башлавы, искерүе, дөньядан артта калуы табигый хәл. Без бит буыннар алмашынуны табигый нәрсә дип саныйбыз. Бу эволюция кануны, диалектика. Үсеш фәкать шулай дәвам итә. Яңа искене алмаштыра. Ниндидер заманда кешеләрне канәгатьләндергән күзаллаулар тора-бара чикләнгән бер карашка әверелә. Әгәр дә кеше дигәнең үҗәтләнеп шуңа ябышып ятса, аның рухи үсеше бөтенләй туктала.

Әйе, бүгенге көндә диннәр әле адәми затның әхлакый сафлыгын саклау юнәлешендә файдалы эш башкаруларын дәвам иттерәләр, әмма алар инде яңа рухи офыклар ачу мөмкинлегенә ия түгел. Әлбәттә, бозыклык юлында йөргән

кешенең, дин юлына басып, яшәү рәвешен үзгәртүе, Раббыбызны искә төшереп, рухи һәм пакь тормыш белән яши башлавы, кешеләргә карата мөнәсәбәтен үзгәртүе һичшиксез унай күренеш, бу аның шәхси эволюциясендә алга китеш булып тора. Хәзерге вакытта жан авазына колак сала белгән берише кешеләр, чыннан да, шундый юлны сайлый. Тик бүген инде дин юлына аяк басу гына канәгатьләнерлек таләп була алмый. Хәзер адәми зат алдында, дини йолалар үтәү белән генә чикләнмичә, ан үсеше ягыннан югарырак баскычка күтәрелү бурычы тора. Дин ул рухи үсеш юлында беренче адым гына.

Тормыш шуны күрсәтә, дин юлына аяк баскан кайбер кешеләр караш, фикер йөртү ягыннан гаҗәеп тар кысаларда яши башлый, фанатикларга әверелә. Бу инде рухи үсешнең тукталуы турында сөйли. Шундый тозакка кереп капмас өчен адәми зат хәзер галәми тәгълиматларны, Илаһи Гакыл тарафыннан бирелгән белемнәрне үзләштерергә бурычлы. Адәм баласы, ана рәсми диннәр тарафыннан кушылган «Раббы колы» билгеләмәсенә риза булмыйча (шулай Раббыбызга колбиләүче исеме тагыла), Иң Югары Затның Җирдәге чын ярдәмчесенә әверелү юлына басарга бурычлы. Мона исә аңны киңәйтеп кенә ирешергә мөмкин. Остазлар тарафыннан бирелгән мәгълүматлар шушы максатны күздә тота.

## «Син каргалганнар сафында...»

Бу бүлектә безгә кабат Библия белән Коръән текстларына мөрәҗәгать итәргә, кешелек дөньясы тарихында булып узган ерак вакыйгаларның бу чыганакларда ничек, ни рәвештә чагылуын җентекләп күздән кичерергә туры киләчәк. Бу очракта Тәрбиячеләребез тарафыннан бирелгән мәгълүматлар безгә ярдәм итәр.

Чыннан да, шушы текстларга таянып без инде дини чыганакларга бөтенләй башкача карый алабыз. Әйтик, Библиядәге Змей-Еланның 4 нче һәм 5 нче Расалар тарихына зур йогынты ясаган Люцифер (Иблис) икәнлеге безгә инде билгеле. Шуны белү дини текстны безгә бөтенләй башкача ача.

Библиядә: «Змей был хитрее всех зверей полевых, которых создал Господь Бог...»,—диелә. (Бытие, 3 :1). Чынында исә Елан-Люцифер кайчандыр Раббыбызның дәрәҗәле, зур кодрәткә ия Архангелы була, икенче төрле итеп әйткәндә, ул Галәмдә эш итүче Затларның берсе була. Исеменә игътибар итик: Люцифер—нур сибүче, нур таратучы дигән мәгънәгә ия. Әмма Люцифер тора-бара Раббыбыз белән тиң булырга, Аның рәхмәтен-мәрхәмәтен кире кагып, үзенә аерым бер дөнья (планета) яулап алып, шунда беркем белән хисаплашмыйча идарә итү турында хыяллана башлый. Хыялы тормышка ашкан очракта ул Галәмдә кабул ителгән кануннарга буйсынмыйча яшәргә уйлый. Шушы максатын тормышка ашыру өчен Җирне сайлый һәм үз тарафдарлары белән анда үтеп керә.

Болар бик ерак дәверләрдә булып узган вакыйгалар. Люцифер үз тарафдарлары белән Җиргә үтеп кергәннән соң булган хәлләр Остаздан ингән мәгълүматларда бик ачык яктыртыла. Әлбәттә, планетабыз тарихында урын алган мондый зур вакыйга дини чыганакларда ничек тә булса чагылыш табарга тиеш иде. Чөнки ул Җир һәм кешелек дөньясы тарихында бик зур фаҗигага әверелгән, аның эволюциясен үзгә юнәлешкә алып кереп киткән үзәк вакыйгаларның берсе булып тора. Аның асылын ачып салмыйча, Җирдә озак дәверләр дәвам иткән көрәшләрнең мәгънәсен кешеләргә аңлатып бирү гомумән мөмкин түгел. Кеше дигәнең нинди көчләрнең ана даими рәвештә тәэсир итеп торуын аңлап яшәгәндә генә үзендә бу көчләргә каршы торырлык көч-куәт таба алачак. Күзгә күренмәгән затларның нинди лагерьдан икәнен чамалау өчен адәмнән зур сизгерлек, рухият, белем һәм акыл көче таләп ителә. Сер түгел, кеше еш кына, шушы көчләрнең уенчыгына әверелеп, үзе дә сизмәстән алар программасын башкаручы бер кемсәгә әйләнә дә куя.

Атлантида һәлакәтеннән соң күп заманнар үткәч тупланган Библиядә Люциферның «хитрый змей», хәтта «красный дракон» дип аталуы табигый хәл. Әлбәттә, Библия китап рәвешендә тупланган заманнарда элегрәк җир йөзендә булып узган һәлакәтләр, Атлантида һәм аның фаҗигалы язмышы турында сөйләү,

бу хакта мәгълүмат бирү тыелган булгандыр. Кабат күтәрелеп килүче яшь 5 нче Раса вәкилләре, Атлантида үткән юлны кабатламыйча, үз дөньяларын үзләре төзәргә, Атлантида казанышларын да, аның хаталарын да белмичә, үз көчләренә таянып самими рәвештә үсәргә тиеш булгандыр. Әлбәттә, яңа цивилизацияләрне торгызучы рухи житәкчеләр, илаһи падишаһлар, дин башында торучы руханилар күбесен белеп, җимерелгән дөнья мирасына таянып эш иткән. Алар сакланып калган кристаллардан, язма чыганакларга теркәлгән яшерен белемнәрдән файдаланган, тик бу белемнәр санаулы затларга гына билгеле булган. Алар бик тирән яшерелгән.

Шундый шартларда рухи лидерлар алдына кыен мәсьәлә килеп баса. Ничек итеп Җир тарихында булып узган вакыйгаларның чын йөзен ачып салмыйча, аларның асылын халыкларга җиткерергә? Әлбәттә инде, бу очракта да алар борынгы сынау үткән ысулга мөрәҗәгать итәләр. Рухи җитәкчеләр вакыйгаларны халыкларга мифлар, риваятьләр рәвешендә җиткерәләр, шулай мәгълүматларны теркәп калдыралар. Аларның кайберләре дин китапларында да урын ала. Хәзерге көндә Библияне кулына алган кеше андагы Еланның кем икәнен белүдән ерак торса да, Адәм белән Хәуваның яралтылуы турындагы мифтан ул Еланның Раббыбызга каршы баручы, Адәм белән Хәуваны (димәк, кешелек дөньясын) юлдан яздыручы тискәре лагерь житәкчесе икәнен яхшы белә. Шулай итеп, Люцифер тарихы, Атлантида һәлакәте, җир йөзендә булып узган фаҗигаларның берсе дә сөйләнми, ә менә вакыйгаларның асылы миф аша адәми затка җиткерелә. Шулай Еланның тискәре зат булуы кешенең хәтерендә уелып кала. Һәм инде ничә мең ел буе адәм балалары нигезендә нинди вакыйгалар ятканы билгесез булган шушы миф белән канәгатьләнеп яши.

Ә Елан үзе нинди зат? Алдагы бүлекләрдә без инде күрдек, Елан—кешелек дөньясы хәтерендә гакыл, зирәклек, рухи кодрәт символы буларак та урын алган. Дөрестән дә, Люцифер, Раббыбызга каршы баш күтәргәнче, Галәмдә мөһим эшләр башкаручы Гакыл Еланы (Змей Мудрости) булмаганмыни? Гакыл Еланы дәрәҗәсенә борынгы цивилизацияләрдә сирәк затлар гына лаек булган. Еланга карата булган тискәре мөнәсәбәт Атлантида вакыйгалары, аннан соңгы дәверләрдә Люцифер һәм аның командасы тарафыннан алып барылган яман эшләр нәтиҗәсендә дә ныгый төшкән, эволюция кичергән булса кирәк. Ул адәм балаларының дошманына, тискәре затка әверелгән.

Без инде күрдек, Библия белән Коръәнгә дә ул тискәре зат буларак кереп калган. Библиядә:

«И сказал Господь Бог змею: за то, что ты сделал это, проклят ты...»,—диелә. *(Бытие, 3: 14)*

Ягъни Адәм белән Хәувага (кешелек дөньясына) галәми белемнәрне вакытыннан алда биргәне, шул сәбәпле атлантларны бозыклык юлына кертеп җибәргәне өчен Елан-Люцифер Раббыбыз каргышына дучар була.

Библиядәге «Исайя пәйгамбәр китабы»нда Люциферның ничек итеп Раббыбызга каршы көрәш башлавы хакында туп-туры әйтелә:

«А говорил (Люцифер) в сердце своем: взойду на небо, выше звезд Божиих вознесу престол мой, и сяду на горе в сонме богов, на краю севера. Взойду на высоты облачные, буду подобен Всевышнему». *(Исайя, 14: 13—14)*

Әмма аның чиксез зур амбициягә корылган хыяллары тормышка ашмый, Күкләрдә барган көрәшләр нәтиҗәсендә ул, күрәсең, нәфесен тыя төшәргә, Җиргә үтеп кереп, аны тулысынча үзенә буйсындырып, анда үз патшалыгын кору турындагы карарга килә.

Аның Күкләрдән Җир планетасына үтеп керүен дә Библия билгеләп үтә:

«Как упал ты с неба, денница, сын зари! Разбился о землю, попиравший народы»,—ди. *(Исайя, 14: 12)*

Бу өзектә китерелгән «денница» һәм «сын зари» гыйбарәләре дә Люцифер исеменә туры килеп тора (без алдарак Люцифер сүзенең—«нур сибүче», «нур таратучы» дигән мәгънәгә ия булуын әйтеп үткән идек)—денница—таң атуны, сын зари—таң угылы, дигәнне аңлаталар. Һәм шушы кара юлга баскан зат Җиргә

бәреп керә. Атлатиданы үз йогынтысына буйсындыра. Атлантида һәлакәтенә кадәр ул Күкләрнең мәгълүм катламыннан торып идарә итә, бу хакта без инде беләбез. А бу утрау су астына киткәннән соң ул инде үз тарафдарлары белән яшәү урынын җир астындагы астрал катламнарга күчерергә мәҗбүр була. Бу вакыйганы да Библия билгеләп үтә. Анда:

«Но ты низвержен в Ад, в глубины преисподней»,—диелә. *(Исайя, 14:15)*

Әйтергә кирәк, глобаль тарихтан хәбәрдар булмасаң, Библиядәге бу юлларны аңлап бетерү һич мөмкин түгел. Барысы да кат-кат яшерелгән, ишарә рәвешендә генә сиздереп кителә.

Кабат Библия текстына күз салыйк:

«Адаму же (Господь Бог) сказал: за то, что ты послушал голоса жены твоей и ел от дерева, о котором Я заповедал тебе, сказав: «не ешь от него», проклята земля за тебя...» *(Бытие, 3: 17)*

Әйе, Җир-Анабыз һәм анда тереклек итүче кешелек дөньясының меңнәрчә елларга авыр хәлгә төшүендә бер Люцифер гына гаепле түгел, өстенлек бирүче гыйлемнәргә ымсынып, башкалар өстеннән хакимлек итү турында хыялланган атлантларның да монда гаебе зур. Тарихтан билгеле, алар Люцифер биргән технологияләрдән файдаланып, җир йөзендә үз хакимиятен урнаштырырга керешәләр, башка халыкларны яулап алу белән мавыгып китәләр, ягъни чын мәгънәсендә Җирдә Люцифер йогынтысын, аның программасын җәелдерүгә үзләреннән шактый зур өлеш кертәләр, үзләре дә сизмичә, Люцифер корган тозакка килеп эләгәләр. Шул сәбәпле Җир-Анабыз кара көчләрнең көчәеп китүеннән сыкрап яши башлый.

Безгә якынрак торган дәвердә барлыкка килгән Коръәнгә исә Библиядәге шушы сюжет үзгәртебрәк кертелә. Анда Елан дигән затны без инде очратмыйбыз. Библиядәге Елан-Люцифер анда инде Иблискә әверелгән, Иблис сүзе христиан динендәге латинча—«диаволис» сүзеннән килеп чыккан. Аның тарафдарлары исә җен-шайтаннар сыйфатында сурәтләнә.

Коръән текстына мөрәҗәгать итик:

«Аллаһ әйтте: «Без сезне җир йөзенә урнаштырдык һәм яшәү шартлары бирдек. (Моның өчен) шул кадәр аз шөкер иттегез. Хактыр ки, сезне яралттык, соңра сезгә рәвеш бирдек, аннан соң фәрештәләргә: «Адәмгә сәҗдә итегез»,—дип боердык. Иблистән башкалар сәҗдә итте. Ул (Адәмгә) баш оручылардан булмады.

Аллаһ аннан: «Мин кушканны үтәмәскә ни сәбәп булды?»,—дип сорады.

Иблис әйтте: «Мин аннан өстенрәк, чөнки мине уттан яралттың, аны балчыктан гына,—диде». *(Коръән, 7 : 10—13)*

Безгә Люцифер-Иблиснең ни сәбәпле Адәмгә баш ормавы һәм ни өчен тәкәбберләнеп: «Мине уттан яралттың»,—дип җавап бирүе ачык. Галәмнән килгән затның адәми затка баш ияргә теләмәве табигый. Коръән ул чорда җир йөзендә барлыкка килгән вәзгыятьне бик дөрес чагылдыра, ә менә бу вәзгыятьнең чын сәбәбе турында ләм-мим. Аныс тирән яшерелә. Аллаһ белән Иблис арасында үсеп чыккан конфликтның сәбәбе дә бик гадиләштерелеп, Иблиснең, Аллаһ сүзен тыңламыйча, Адәмгә баш ормавы, аның алдында сәҗдә кылмавына кайтарып калдырыла. Шуңа күрә Аллаһ Иблисне каргый, аның белән арасын өзә.

Иблис исә Аллаһның карарын гаделсезлек дип кабул итә: «Син мине азгынлык юлына этәрдең»,—ди. Һәм Хисап көненә (Кыямәт көне) чаклы Аллаһка каршы эш алып барачагын ачыктан-ачык белдерә:

«Шуңа күрә мин дә Синә омтылучыларны юлдан яздыру өчен зур тырышлык куячакмын. Ант итеп әйтәм ки, аларныаздыру өчен бер алларына, бер артларына төшәчәкмен, уңнан да, сулдан да котыртып торачакмын. Ахыр чиктә Син аларның күбесендә шөкер итү күрмәссең»,—ди. *(Коръән, 7 : 16—17)*

Чыннан да, Атлантида һәм ул җимерелгәннән соң аякка баскан 5 нче Раса тарихына күз салсак, Коръәндә китерелгән бу сүзләр Люцифер-Иблиснең адәм балаларын юлдан яздыру өчен алып барган кара эшчәнлеген гаҗәеп төгәл чагылдыруын күрербез. Әмма Планетабызның глобаль тарихыннан кайбер дәверләрне күз алдына ачык китермәсәң, Коръәндәге Иблис тә, ул әйткән сүзләр

дә реаль вакыйгалардан ерак торган әкияти-мифологик бер сюжет булып кына кабул ителәчәк. Мифологиядә без ул вакыйгаларның гадиләштерелгән кайтавазын гына күрәбез. Шуңа күрә дини чыганакларда китерелгән мифларның асылын аңлау гаять кыен мәсьәлә булып кала. Дөресен генә әйткәндә, алар еш кына чишеп булмаслык табышмакка әверелә. Ни кызганыч, кешелек дөньясы күпме заманнар, үзенең чын тарихын белә алмыйча, шушы мифларны чын вакыйгалар дип кабул итеп яшәде һәм әле бүгенге көндә дә андый кешеләр бар.

Шушы уңайдан дини текстларны акыл һәм мантыйк бизмәненә салып караудан курыккан, моны гөнаһ дип санаган, язылган һәр сүзгә сәҗдә кылып яшәгән кайбер кешеләрнең исләренә «Хакыйкатьтән өстен дин юк!» дигән борынгы гыйбарәне төшерәсем килә. Җирдә барлыкка килгән һәр нәрсә адәми зат кулы аша уза, шул исәптән изге саналган дин китаплары да.

Күктәге Затлар белән элемтәгә керү аша яки башкача язылган ул өйрәтмәләр кеше тарафыннан башкарыла, соңрак кеше тарафыннан ук туплана, төзәтелә, редакцияләнә, кайбер очракта кулланышта йөргән төрле вариантлары ярдәмендә тулыландырыла, нидер өстәлә, нидер төшереп калдырыла һәм ахыр чиктә ТӨП КАНУНИ ТЕКСТ барлыкка килә. Халык арасында төрле бәхәсләргә урын калмасын өчен башка текстлар юкка чыгарыла. Шулай бердәнбер кануни текст билгеле бер рухи тәгълиматның нигезенә әверелә. Әмма бу принцип сакланмаска да мөмкин. Мисал өчен христиан диненең нигезен тәшкил иткән Евангелиене (Инҗил) алыйк. Евангелие—Гайсә пәйгамбәрнең тормыш юлын һәм эшчәнлеген сурәтләгән изге чыганак санала. Аның рәсми дин таныган дүрт варианты бар, шуңа өстәп рәсми дин танымаган башка вариантлары да яши, аларны апокрифлар дип атыйлар.

Диннәр бирелгән борынгы заманнарда беркем дә рухи житәкчеләрнең, пәйгамбәрләрнең һәр әйткән сүзен, без диктофонга яздырып алган кебек, төп-тәгәл итеп язып бармаган, диннең башлангыч чорында вәгазьләр хәтта теркәлеп тә куелмаган, алар ирекле әңгәмә рәвешендә сөйләнгән. Сөйләнгән сүзләр кешеләрнең хәтерендә генә сакланган. Ә адәми затның хәтере бик тә ышанычсыз нәрсә. Шуңа күрә без дини текстлар белән эш иткәндә һәрвакыт үз акылыбызга таянырга тиешбез. Бу җәһәттән Пәйгамбәребез тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган хәдисләрне иң күп туплаган мәшһүр исламият галиме Әл-Бохари (810—870) тарихы аеруча гыйбрәтле. Ул күп еллар дәвамында Гарәп хәлифәлеге җирләрендә сәяхәттә йөри һәм Мөхәммәт пәйгамбәр турында хәдисләр туплау белән шөгыльләнә, шул заманның күренекле Ислам галимнәре белән аралаша. Шул эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, «Әл-җәмигъ әс-Сахих» исемле хәдисләр җыелмасын туплауга ирешә. Ул үз гомерендә 600 мең хәдисне тикшерә, үзе төрле кешеләрдән 200 мең хәдис язып ала, шулар арасыннан үзе дөрес дип ышанган 7397 хәдисне сайлап ала һәм аларны китабына кертә.

Әл-Бохариның хәдисләр туплау тәҗрибәсе китап булып тупланган дини чыганакларның ничек барлыкка килүен бик ачык күрсәтә. Күреп торабыз, монда шәхси зәвык һәм очраклылыкка зур урын кала. Әгәр дә хәдисләрне икенче бер шәхес туплаган булса, аларның составы, эчтәлеге башкачарак төзелмәс иде дип кем кистереп әйтә ала? Китерелгән мисал һәрбер дини чыганакка кагыла. Мәгълүм булганча, Коръән дә Пәйгамбәребез вафатыннан соң егерме ел вакыт үткәч кенә туплана. Госман хәлифә идарә иткән елларда яшәгән Зәйд ибне Сабит исемле кеше житәкчелегендә махсус комиссия төзелә һәм ана Коръәннең кануни текстын туплау бурычы йөкләнә. Бу эшкә шулай ук Пәйгамбәребезне шәхсән белгән, аның белән аралашу бәхетенә ирешкән бик күп сәхәбәләр дә тартыла. Шулай итеп, Коръәннең безгә килеп житкән кануни тексты 650—652 нче елларда гына барлыкка килә.

Инде кабат төп сүзебезгә әйләнеп кайтыйк. Коръәндә чагылыш тапкан реаль вакыйгаларга мөрәҗәгать итик. Әйтелгәнчә, Люцифер-Иблис һәм аның тарафдарлары атлантларны югары галәми белемнәр, технологияләр белән кызыктырып, анда үзенең тискәре эшчәнлеген башлап җибәрә. Бу вакыйгаларның кайтавазы Коръәндә менә ничек чагылыш таба:

«Каплаулы гаурәтләрен күрсәтер өчен, шайтан аларны, пышылдап, котыртырга керешге: «Раббыгыз сез фәрештә булмасын яки үлемсезгә әверелмәсен дип, бу агачтан файдалануны тыйды»,—диде. Һәм аларга (Адәм белән Хәувага): «Мин сезгә яхшы нәсихәт бирүчедер»,—дип ант итте. Күңелләренә вәсвәсә салып, ул аларны хәйлә белән алдады. Агач җимешләрен татып караганнан соң аларның күзләренә оят җирләре чалынды». *(Коръән, 7 : 20–22)*

Дөресен әйтергә кирәк, бу аятьләрне аңлавы җинел түгел, гаять нечкә урын. Әлбәттә, бередә сүз Адәм белән Хәуваның Җәннәт бакчасы уртасындагы агач җимешләрен татып караганнан соң, кинәт күзләре ачылып китеп, бер-берсенең гаурәтләрен, ягъни җенес әгъзаларын күрә башлавы турында бармый. Тыелган җимешләр—адәми зат әле үзендә ачмаган илаһи һәм яшерен сәләтләр—рухи көч-кодрәт, мөмкинлекләр турында бара. Алдагы бүлекләрнең берсендә без бу мәсьәләгә бераз тукталып узган идек.

Шулай итеп, үзенең умыртка баганасы буйлап тезелешкән чакраларның тулы көченә эшли башлавы аркасында адәми зат «теге дөнья» дип аталган Нәфис дөньяны, андагы тормышны, рухи дөньялардагы затларны, чакраларның ничек эшләвен, кеше аурасындагы төрле төсләрнең ни аңлатканын белә башлый. Ул шулай бик күп өстәмә мәгълүмат ала, аның рухи мөмкинлекләре гаять көчәя. Адәмгә бик күп яна нәрсәләр ачыла. Икенче төрле итеп әйтсәк, ул Нәфис дөньяга үтеп керә. Шуна күрә Иблис ана: «Раббыгыз сез фәрештә булмасын яки үлемсезгә әверелмәсен дип, бу агачтан файдалануны тыйды»,—дип хәбәр итә. Шулай ул вакытыннан алда Адәм белән Хәувага Раббыбызның зур серен ача. Һәм бу вакыйганы Библия дә, Коръән дә гади генә сюжет аша киләчәк буыннарга тапшыра. Бу чорда Люцифер-Иблис ягына чыккан атлантлар моннан тыш та бик күп белемнәргә, техник мөмкинлекләргә ия булалар. Әйтик, кайбер эзотерик чыганакларда аларның һавада оча торган очкычлары булуы хакында әйтелә. Шундый казанышлардан файдаланып, алар зур өстенлекләргә ирешәләр. Рухи яктан җитлекмәгән һәм җавапсыз кешеләр кулына килеп кергән шушы югары белемнәрдән файдалану аркасында бу җәмгыять рухи сафлыгын югалта, бозыклык юлына баса. Һәлакәт якынлашып илгән чорда атлантлар чын мәгънәсендә агрессорга, сугыш чукмарларына әверелә, планетаның башка төбәкләрен яулау, анда үз хакимиятен урнаштыру белән бик актив шөгыльләнәләр. Атлантиданың үзендә исә бу вакытта хакимлек итү, өстенлек һәм байлык туплау өчен көрәш бара, беркем беркемгә ышанмый, җәмгыятьтә имансызлар арта, кара сихер ысулларын үзләштергән кешеләр үз амбицияләрен канәгатьләндерү өчен аннан явызларча файдалана, кеше психикасына тәэсир итү, ана карата манипуляция чаралары үткәрү анда гадәти бер күренешкә әверелә.

Чыннан да, бу шартларда атлантларның, Коръәндә әйтелгәнчә, «күзләренә оят җирләре чалына», ягъни алар эволюциянең ул этабында адәми зат өчен тыелган гамәлләр белән мавыгалар, табигатьнең күп серләре алар өчен инде сер булудан туктый. Коръәндә Аллаһның мондый хәлләргә карата булган мөнәсәбәте ап-ачык белдерелә:

«Аллаһ аларны: «Мин сезгә ул агачка кагылырга ярамый димәдеммени?—дип орышты»,—диелә. *(Коръән, 7 : 22)*

Шулай ук Адәм белән Хәуваның гөнаһлар кылган өчен үкенүе дә китерелә:

«(Адәм белән Хәува) әйттеләр: «Йа Раббыбыз, үзебезне харап иттек. Әгәр безне кичермәсәң, ярлыкамасаң, һичшиксез, зыян күрүчеләрдән булачакбыз,—диделәр». *(Коръән, 7 : 24 )*

Кылган гөнаһлары өчен Атлантлар Расасы, ягъни 4 нче Кешелек Дөньясы каты җәза ала. Атлантида тулысынча Атлантик океан төбенә китә.

Шушы коточкыч һәлакәт аркасында кешелек дөньясы эволюциясе нык тоткарланса да, аның яшәеше өзелми, күпмедер вакыттан соң җимерелгән дөнья хәрабәләре өстендә 5 нче Раса калкып чыга. Коръәндә Аллаһның кабат күтәрелеп килгән кешелек дөньясына атап әйткән кисәтү сүзләре дә чагылыш тапкан:

«Әй, Адәм балалары! Атагыз белән анагызны Җәннәттән кудырыр өчен, Иблис аларның киемнәрен салдырып, оят җирләрен күрсәтте. Ул сезне дә шулай алдый

күрмәсен. Чөнки ул (Иблис) һәм аның яраннары сезне күреп тора, ә сез аларны күрмисез. Хактыр ки, без шайтаннарны имансызларның дусты иттек».

*(Коръән, 7 : 27 )*

«Иблис аларның киемнәрен салдырып, оят җирләрен күрсәтте» дигән гыйбарәгә игътибар итик. Нинди киемнәр турында сүз бара соң? Әлбәттә, биредә сүз өскә кия торган кием турында бармый. Бу киемнәр—кешене кара көчләр тәэсире үтеп керүдән саклый торган энергетик сүрү—Аура булып тора. Әгәр дә кеше тискәре хисләргә, начар теләк-омтылышларга бирелмичә, якты уй-хисләр, күтәренке күңел, изге омтылышлар белән яшәсә, аның тәнен саклап торган энергетик сүрүе дә нык була. Тынычлыгын саклый белгән кешегә йогынты ясау, зыян салу мөмкин түгел, аны Аурасы саклый. Һәм киресенчә, әгәр дә кеше берәр төрле түбән хиskә бирелеп, нык дулкынланса, ярсый, нәфрәтләнә башласа, шулай үз-үзенә контрольне югалтса, шул минутта ук кара көчләр кулында бер уенчыкка әйләнә дә куя. Алай гына да түгел, чамадан тыш көчәеп киткән ярсу, көчле нәфрәт һәм башка тискәре хисләр аркасында аны саклап торган берничә кат сүрү зыян күрергә, ертылып китәргә дә мөмкин. Әлбәттә, Аурасы зарарланган кешегә тәэсир итүе күпкә җиңелрәк, хәтта кайбер очракта теге дөньяда яшәүче күзгә күренмәгән берәр нәмәрсәкәй кешенең тәненә үтеп керергә, аның белән идарә итә башларга да мөмкин. Андый очракларны халыкта «эченә җен кереп оялаган» дип аңлаталар.

Коръәннең бер аятендә кешене саклап торган шушы «киемнәр»—аның Аурасы турында да ап-ачык әйтелә:

«Тәкъвалык (саф әхлак, изге ниятләр белән яшәү)—явызлыктан саклаучы иң әйбәт киемдер. Болар Аллаһның галәмәтләредер»,—диелә. *(Коръән, 7 : 26)*

Әйтелгәнчә, Атлантида җәмгыятендә Люцифер-Иблис йогынтысында яшәүчеләр артык ишәеп китә, алар «киемнәре салдырылган», кара көчләр кулында марионеткага әверелгән, алар программасын үтәүчегә әверелә. Фәкать шуны күздә тотып, Аллаһ: «Ул (Иблис) сезне дә шулай алдый күрмәсен »,—дип, кешелек дөньясын, ягъни безне—5 нче Раса вәкилләрен андый афәттән сакланырга, уяу булырга чакыра.

Уяу булып кала алдыкмы, Атлантлар Расасы хаталарын кабатлау юлына басмадыкмы?!

## Адәмне кем коткарыр?

Бүгенге көндә кешелек дөньясының зур сынаулар чорына килеп керүе, аның КҮЧЕШ ДӘВЕРЕ кичерүе инде беркемдә дә шик уятмый шикелле. Моны аңлау өчен, телевизорны кабызып, соңгы хәбәрләрне карау-тыңлау да җитә. Җир йөзендә кызу темплар белән үзгәртеп кору бара. Хәзерге вакытта уртак йортыбыз Җир һәм анда яшәүчеләр система кризисы кичерә. Тормышның нинди генә өлкәсенә күз салма, һәркайсына зур үзгәрешләр кертү кирәклеге ап-ачык күренә. Дөньяның элеккечә бара алмаячагы көн кебек ачык. Һәм тиз үзгәрә торган тормыш шартларында искечә яшәү, уйлау, гамәл кылу мөмкин түгел икәнне һәркем аңлый. Аңлавын аңлый, тик ничек яшәргә, яңа шартларга ничек күнегергә, ничек итеп үз-үзеңне, сәламәтлегеңне, иминлегеңне саклап калырга—болары әлегә күпләребез өчен зур мәсьәлә булып кала бирә.

Әйтелгәнчә, хәзерге көндә җир йөзендә яшәүче кешелек дөньясы 5 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ булып тора, ягъни без белгән, чал тарихка кереп калган, алты мең еллык язма тарихы булган, планетабызның теге яки бу тарафында төрле ядкарьләре сакланып калган дөнья 5 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ дип атала.

Планетабыз Тәрбиячеләре сүзләренә караганда, без атлап кергән өченче меңьеллыкның беренче елларыннан Җирдә шартлы рәвештә 6 НЧЫ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ яши башлады дип исәпләргә мөмкин икән. Моны хәзер туган балаларның нинди акыллы-зирәк булуы да күрсәтеп тора. Алар сөйләшә башлау белән ата-аналарын өйрәтергә тотына, чөнки хәзер Җирдә 6 НЧЫ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫНА йөкләнгән вазыйфаларны үтәргә әзерлекле зирәк һәм зур рухи мөмкинлекләргә ия җаннар туа. Бу җаннар үзләренең башка гомерләрендә бик

зур акыл, тәҗрибә туплаган. Балаларның акыллы булып тууы шуның белән бәйле.

Хәзерге көндә жир йөзендә һәм җәмгыятьтә барган кискен үзгәрешләрне Җирнең һәм кешелек дөньясының яна үсеш баскычына, яна рухи халәткә күчәргә әзерләнүе дип анларга кирәк.

Егерменче гасырны, ике мең ел буе дәвам иткән Балык йолдызлыгы дәверенең соңгы гасырын, чын мәгънәсендә хәзер жир йөзендә барган глобаль үзгәрешләргә әзерлек алып бару гасыры булды дип атарга мөмкин. Хәзерге көндә без инде Сукояр йолдызлыгы дәверенә аяк бастык. Ул да ике мең ел буе дәвам итәчәк. Шушы ике мең еллык вакыт аралыгында жир йөзендәге тормыш тамырдан үзгәртеп корылачак. Бүгенге көндә без башланып киткән шушы процессның беренче чаткыларын гына күрәбез, аның шаһитлары булып торабыз.

Дөнья күләмендә башланып киткән шушы үзгәрешләрне безнең ил мисалында барлап чыгу отышлырак булыр шикелле. Ни өчен дигәндә, вакыйгалар һәркемнең күз алдында барды һәм бара, күбебез аларда үзе катнаша, йөрәге аша уздыра.

Әйе, егерменче гасыр—хәзерге көндә барган глобаль үзгәрешләргә әзерлек чоры булды. Әүвәл Россия тарихында булып узган бер гаҗәеп хәлгә игътибар итик. 1917 елдан бездә дин җәмгыятьнең рухи нигезе булудан туктады, гамәлдән төшеп калды. Россия Раббыбыздан баш тартты, алмашка коммунистик идеология килде. Шулай ил 70-80 еллап динсез яшәде, дәһри-атеистлар иле булды. Шуна да карамастан коммунистик җәмгыять төзү идеаллары югары әхлакны алга сөрде, кешеләрне туганнарча яшәргә, бер-берсенә ярдәм итәргә чакырды, яшь буынны намуслы итеп тәрбияләүгә зур игътибар бирелде, картлык көнендә кеше кайгыртусыз калмады,—бер сүз белән әйткәндә, илдә дәһрилек чәчәк атса да, аның рәсми идеологиясе гуманистик нигезгә корылган иде.

Югары идеаллар белән рухланган халыклар Гражданнар сугышыннан соң илне торгызуда, Бөек Ватан сугышы елларында аны дошманнан саклауда, соңыннан кабат аякка бастыруда, сәнәгать гигантлары төзүдә, чирәм җирләрне үзләштерүдә гаҗәеп тырышлык, фидакарьлек, батырлык үрнәкләре күрсәттеләр. Халыкларның бер идея тирәсенә туплануы илне көчле һәм абруйлы итеп бөтен дөньяга танытты. Сәясәттә гаять катлаулы моментлар булуга карамастан, ил һаман алга таба бара кебек иде. Әмма нигездә матди-техник һәм хәрби яктан ныгуга йөз тоткан СССР дип аталган дәүләтнең бераздан үсеше тукталды, ул бер урында таптана башлады—торгынлыкка дучар булды.

Ни сәбәпле шулай килеп чыкты соң? Сәбәбе бик гади—рухи үсеш кануннарын белмәү, барысын да матди як хәл итә дип уйлау, планнарны шул нигездә кору иде килеп туган торгынлыкның төп сәбәбе. Коммунистик идеология нигезендә: «Материя—беренчел, аң-рух—икенчел»—дигән ялган принцип ята. Ә Җиһанда бит барысы да киресенчә корылган, анда аң-рух һәрвакыт беренчел, материя исә икенчел. Раббыбыз аңында Галәм идеясе барлыкка килмичә ул төзелә алмый. Сызымын сызмыйча хәтта гап-гади урындыкны да ясап булмый. Иоанн Инҗиленең беренче юллары юкка гына шундый сүзләрдән башланмый: «В начале было Слово, и Слово было у Бога, и Слово было Бог». Биредә «Слово-Сүз»не—беренче этәргеч, хәрәкәт, Җиһанны барлыкка китерү идеясе дип кабул итәргә дә мөмкин.

Шулай коммунистик идеология үзе утырган ботакка балта чапты, иң алдынгы идеяләр капма-каршысына үзгәртелде, җәмгыятькә һәм кешегә каршы эшли башлады. СССР дип аталган илдә ахмаклыклар күп булды. Мисал өчен 70 нче елларда илдә зур шау-шу, тавыш кубарган, кайнар көрәшләр китереп чыгарган төньякка аккан елгаларны көньякка таба бору проектын гына искә төшерик. Үзенең мәгънәсезлеге, илгә китерәчәк зыяны, рухиятсызлыгы белән аерылып торган шушы проект, абруйлы дәүләт оешмалары тарафыннан эшләнеп, гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителмәдемени?! Ярый әле илнең патриотик зыялылары бу ахмаклыкка кискен каршы чыкты, зур тавыш күтәрде. Бу афәттән бары шулай гына котылып булды. Моңа өстәп тыныч кына агып яткан елгаларда ( мәсәлән, Идел ) электр станцияләре каскады төзү һәм шуның аркасында иң уңдырышлы күпме кара туфраклы җирләрне су астында калдыруны да әйтергә мөмкин. Шушы

акылсызлык аркасында күпме өстәмә проблемалар туды, кətелмәгән күпме чыгымнар тотарга туры килде.

Бер сүз белән әйткәндә, 70 нче елларны рухиятсызлыкның иң түбән төшкән чагы дип әйтергә мөмкиндер. Ул елларда уйлый белгән һәр кеше өчен андый режимның киләчәге булмавы ап-ачык иде. Рух һәрвакыт беренчел, ә материя, гамәл—икенче урында тора. Җиһанның төп канунын киресенә алмаштырып яшәгән дәүләт ничек итеп озын гомерле була алсын. Ул бит Раббыбыз кануны белән санашмыйча яшәргә омтылды. Моннан ни килеп чыкканын без инде күрдек.

Аннан 80 нче еллар килде, илдә «үзгәртеп кору» дигән хәрәкәт башланды. Шулай без кискен үзгәрешләр чорына килеп кердек. Алар дәүләтнең генә түгел, һәр кешенең язмышына кагылды. Тормышта бар нәрсә җимерелә, сүтелә башлады. Халыкта: искегә тисәң исең китәр, дигән әйтем бар. Бу очракта искене ямаштырып, аннан-моннан сипләп кенә котылу мөмкин түгел икәнне күпчелек күрә, аңлый иде. Дөрес, элекке тәртипләрне үзгәрткәләп, яңалыклар керткәләп иске тормышны саклап калырга тырышучылар да булды. Әмма күпчелек элеккечә яшәү мөмкин түгел икәнне аңлый, тормышны тамырдан үзгәртеп кору ягында иде. Һәм СССР халыкларының бу омтылышында заман таләбе бик ачык чагылды.

Инде вакыйгаларга тагын да өстәнрәк торып күз салырга тырышыйк. Әйтелгәнчә, егерменче гасыр—Балык йолдызлыгы дәверенең ахыргы гасырын тәшкил итә. Бу нәрсәне аңлата соң? Хикмәт шунда ки, ике мең елга сузылган шушы дәвер эчендә без, адәм балалары, Балык йолдызлыгы дәверенә хас нурланышлар (аны Илаһи План, яки Яшәү Программасы дип тә атарга мөмкин) йогынтысында яшәдек. Шушы нурланышлар адәм балаларына мәгълүм бер йогынты ясады, тормышны билгеле бер тәртиптә алып барды. Инде менә шушы зур дәвер тәгамәлләнеп килгәндә һәр җанның, мәктәп баласы имтихан тоткан кебек, Раббыбыз алдында өлгергәнлеккә имтихан бирер чагы җитте. Шулай рухи үсеш өчен бирелгән вакыт тәгамәлләнгәндә җаннар имтихан тапшыра, бу «җаннарны җыеп алу» дип атала. Һәр җан Күкләр алдында хисап бирә. Имтиханны уңышлы тапшырсаң, сиңа эволюциянең, рухи үсешнең яңа баскычына күтәрелергә мөмкинлек ачыла, тапшыра алмасаң, вафатыңнан соң сине Галәмдәге авыррак, кырысрак шартлар хөкем сөргән башка дөньяга озатачаклар, яисә Коръәндә тәмуг дип аталган аскы дөньяда авыр шартларда яшәячәксең—тиешле тырышлык күрсәтмәгән, рухи үсеш юлына басмаган өчен!

Безнең илдә «үзгәртеп кору» дигән нәрсә тиктомалдан гына барлыкка килмәде. Гадәттә, кешеләр аны сәяси, икътисади сәбәпләр белән аңлатырга тырышалар. Әмма һәр күренешнең күзгә күренми торган сәбәпләре дә була. Уйлап карыйк әле, СССР дип аталган катып калган илдә кешегә рухи үсеш өчен тиешле шартлар бар идеме? Идеология—коммунистлар партиясе идеологиясе, фикер кысылган, матбугатны цензура буып тора, иркле рәвештә фикер йөртү, әйтәсе килгән сүзенне әйтү, язып чыгу, шул хакта ачыктан-ачык сөйләшү мөмкинлеге юк. Чит илдә чыккан китаплар илгә кертелми, бары тик безнең идеологиягә каршы килмәгәннәре генә тәрҗемә ителә. Бу хәл аң, фикер үсешенә киртәләр куя, шәхеснең үсешен тоткарлый, аны тарлыкта яшәргә мәҗбүр итә иде.

Кешенең рухын буып торган мондый режимның яшәргә хакы бар идеме? Әлбәттә, юк иде. Шуңа күрә ул бик тиз җимерелеп төште дә. Чөнки ул эволюция кануныа каршы барды. Тагын да түзеп тору мөмкинлеге калмагач, Күкләр аңа үз хөкемен чыгарды.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар—бу режим кешене динсез, Алласыз итеп тәрбияләргә тырышты, төп игътибар матди якны кайгыртуга юнәлтелде. Шуңа күрә дәһрилек-атеизм рухында тәрбияләнгән кешене тиз генә дингә, Раббыбызга кайтару мөмкин түгел иде. Андый кешегә Күктәге Тәрбиячеләребезнең планетабыз һәм кешелек дөньясы үсешен җитәкләвен, адәм балаларын рухи үсеш, эволюция юлыннан алып баруын сөйли башласаң—ул моңа ышанмаячак, көлеп кенә караячак. Шул сәбәпле адәм балаларын кабат Раббыбызга кайтару эше төрле могҗизалар күрсәтүдән башланды. Төрле төбәкләрдә ниндидер шаккатыргыч сәләтләре ачылган кешеләр пәйда булды. Алар кешегә, үзеннән берни

сорашмыйча, тормыш хәлләрен, авыруларын, киләчәктә ниләр буласын сөйләп бирә, житди проблемаларын хәл итәргә булыша, теге яки бу очракта ничегрәк эш итү кирәклеген аңлатып бирә иделәр. Шулай телгә тылсым ияләре—сукыр Ванга, экстрасенслар Джуна, Кашпировский, Чумак кебекләрнең исемнәре килеп керде. Шаккаткыч хәл—аларның дәвалау сеансларын хәтта үзәк телевидениедән күрсәтә башладылар. Кешеләр су тутырылган банкалар тотып телетапшырулар карый, экраннан агылган энергетика ярдәмендә суны «заряжать» итәргә тотындылар. Шулай илдә экстрасенслар, күрәзәчеләр дәвере башланды.

Безнең ил өчен көтелмәгән бу күренешнең кешегә ярдәм итүдән тыш тагын бер әһәмиятле ягы бар иде. Кешеләргә андый сәләтләр кайдан килә, башкалар булдыра алмаганны алар кем ярдәмендә башкара? Мондый сораулар кешенең фикерен ирексездән Күкләргә тарта, аны тәрбия кылучы Затлар барлыгын, Раббыбыз һәм Аның күп санлы ярдәмчеләре булуына ишарәли, күңелдә бик күп сораулар уята иде. Өстәвенә шул ук елларда кешеләр оча торган тәлинкәләр (НЛО) күрә башладылар, чит планетадан килгән ниндидер затлар белән очрашу очраклары газета-журналларда басыла, кайчакта алар, аерым кешеләрне корабларына алып кереп, Галәм буйлап сәяхәт кылдыра һәм кире өйләренә кайтарып куя иделәр. Аерым йортларда «полтергейст» дип аталган «йорт иясенең» әллә ниләр кылануы, күзгә күренмәгән шушы затның савыт-саба ватуы, шкафларны ачуы, люстраны селкетүе, стеналарны шакып йөреп, хужаларга төне буе йокы бирмәве турында газеталар язып чыга, телевидение андый кешеләрдән интервью ала, андый йортка хәтта милиция наряды билгеләнә, тик беркемне ни күрә, ни тота алмыйча буш кул белән әйләнеп кайта иде. Шушы елларда күзгә күренмәгән затларны өйрәнүче уфология фәне чәчәк атты, галимнәр оча торган тәлинкәләр еш күренгән төбәкләргә фәнни экспедицияләр оештырды. Бер сүз белән әйткәндә, кеше өстенә күзгә күренмәгән «теге дөнья» барлыгын, параллель дөньяда кемнәрнеңдер яшәвен, хәрәкәт итүен исбатлый торган фактлар яңгыры ява башлады. Бу фактлар кешегә бик нык басым ясый, аңны тетрәтә, элекке дәһрилек күзаллауларын акрынлап какшата иделәр. Алар дөньяның, син уйлаганча, бер каптырмалы гына булмавын, яшәешнең күп катламнардан торуын, адәми затның күзгә күренмәгән реаль энергияләр, затлар, төрле көчләр камалышында яшәвен даими сиздереп тордылар.

Шул ук елларда дин әһелләре дә хәрәкәткә килде, аларга да ирекләр ачылды, яңа гыйбадәтханәләр төзелә башлады. Күпләр дин юлына басты. Әмма берничә дистә ел дини белем бирү өзелеп торганга, бу хәрәкәтне житәкләрдәй әзерлекле кешеләр санаулы гына иде. Шул сәбәпле дин өлкәсенә очраклы кешеләр дә килеп керде. Ләкин барыбер халыктагы дингә табигый тартылу күпмедер дәрәжәдә канәгатьләндерелә, кеше үзен Күкләр тәрбиясендә яшәүче зат итеп тоя, шуның белән юанып яши башлады.

Бу еллардагы тагын бер гажәеп күренешкә аерым тукталып үтәсе килә. Аны арадашчылык хәрәкәте дип билгеләргә мөмкин. Монарчы мөселманнар бер генә арадашчыны—рәсүлебез Мөхәммәт пәйгамбәрне генә белә иде. Бу очракта «арадашчы» төшенчәсе Күкләрдәге Затлар белән элемтәгә керү бәхетенә ирешкән, контакт аша аннан илаһи сүз ишеткән, хәбәр алган кешене аңлата. Мөхәммәт пәйгамбәргә вәхи килүне, аңа Коръән аятьләре иңә башлауны да асылда шул ук арадашчылык дип исәпләргә мөмкин. Әлбәттә, арадашчылык белән арадашчылык арасында зур аерма бар. Кем белән аралашасың бит. Күкләрдә кемнәр генә булмас...Ләкин бу күренешнең нигезендә бер үк процесс ята.

Ни хикмәт, борынгы заманнарда санаулы гына булган арадашчылар егерменче гасыр ахырында кинәт күбәеп киттеләр. Алар аша төрле мәгълүматлар, киңәшләр, өйрәтмәләр бирелә башлады. Бу текстлар хәтта аерым җыентыклар рәвешендә (Ченнелинг-контактёрлык җыентыклары) басылып та чыктылар. Нинди хикмәтле күренеш иде соң әле бу арадашчылык дигән нәрсә? Аның беренче максаты, әлбәттә, кешеләргә өр-яңа мәгълүмат бирү, кешелек дөньясының зур сынаулар чорына килеп керүен тәфсилләп аңлату, бу елларда рухи үсеш юлына басуның иң дөрес һәм имин юл икәнен төшендерү иде. Планетабыз һәм без, адәм

балалары, сынау чорын кичерәбез. Күкләр алдында Имтихан тотабыз—Яңа Дәвергә күчәргә әзерлек бара. Мондый Хисап бирү чорына килеп кергәндә адәм балаларына Күкләрдән һәрвакыт кисәтүләр ингән. Библия белән Коръәндә *(7:59–64)* Нух (Ной ) пәйгамбәр тарихы юкка гына бәян ителми, ул заманда да җир йөзен су басар, Туфан килер алдыннан адәм балаларына пәйгамбәрләр, изге затлар аша кисәтүләр килгән. Тик аларга колак салучы гына аз булган. Без дә хәзер шундый дәвергә аяк бастык.

Әмма әлеге арадашчы–контактёрлар һәм экстрасенслар, кайсы белеп, күбесе үзе дә белмичә, тагын бер зур эш башкардылар. Эш шунда ки, дәверләр алмашынган вакытта (Планетабызның Балык йолдызлыгыннан Сукояр йолдызлыгына күчүе) Җирнең һәм анда яшәүчеләрнең энергетик халәтен-тибрәнешләрен югарырак дәрәҗәгә күтәрү ихтыяҗы туа. Арадашчы-контактёрлар һәм экстрасенслар энергияләрне Күктән кабул итү һәм җир йөзенә тарату белән шөгыльләнделәр һәм шөгыльләнә. Раббыбыздан килгән энергияләр алар аша Җиргә дә үтеп керә, җир йөзендә яшәүчеләрнең энергетикасын арттыра иде. Андый кешеләрнең күбәеп китүе шуның белән дә аңлатыла. Әлбәттә, сынаулар чорында авыручылар да арта һәм көн тәртибенә аларны дәвалау, саклап калу ихтыяҗы килеп баса. Кыскасы, бу күренешләрнең берсе дә үзеннән-үзе килеп чыккан очраклы хәлләр түгел, ә Раббыбыз Планы буенча планета күләмендә алып барыла торган олуг эшләр.

Җирнең яңа энергетик халәткә күчүе өчен анда яшәүчеләрнең рухи яктан югарырак баскычка күтәрелүе таләп ителә. Әйтелгәнчә, кеше Галәмнән килгән энергияләрне тәне аша уздыра, ул аларны, якорь корабны тотып торган кебек, Җиргә беркетүче ролен башкара. Әгәр дә кешенең рухи үсеше түбән булса, ул үз тәне аша үткән энергияләрне түбән сыйфатлы итеп үзгәртә. Әгәр дә әлеге энергияләр югары рухиятка ия кеше тәне аша узса, аларның сыйфаты да югары була һәм бу хәл планетабызның (Җир-Анабызның) алга китешенә зур ярдәм була, аның эволюциясен тизләтә. Менә нинди хикмәтле зат бит ул кеше дигәнең! Ул үзенең җир йөзендә нинди вазыйфа башкаруын белми диярлек. Менә ни өчен контактёрлар аша алынган мәгълүматларда Тәрбиячеләребез кешене рухи үсеш юлына басарга чакыра, чөнки бары шушы таләп үтәлгән очракта гына Күкләр, Җир-Анабыз һәм без—адәм балалары арасында барган энергия алмашу процессы тиешенчә барачак. Ә моның өчен без рухият һәм әхлак ягыннан гаять югары баскычта торырга тиеш.

Егерменче гасырда, бигрәк тә аның ахырында, безнең илдә булып узган үзгәрешләр, сәяси системаның зур тетрәнүләр кичерүе, рухият өлкәсендә ачылган мөмкинлекләр һәм ирекләр—барысы да шушы процесска әзерлек чаралары булды. Кешегә дин, рухият юлына басуда бик күп юллар күрсәтелде, җаның теләгән китапны уку, рухи тәгълиматлар белән танышу, белем алу, аңыңны үстерү өчен зур мөмкинлекләр тудырылды. Шушы нигездә хәзерге көндә Иске Илаһилыктан Яңа Илаһилыкка күчү бара.

Иске Илаһилык дигәндә без нәрсәне күз алдында тотабыз? Иске Илаһилыкны борынгы заманнарда бирелгән диннәр, рухи тәгълиматлар дип аңларга кирәк. Алар тарихи дәверләрдә үз вазыйфаларын үтәде, хәзерге көндә дә билгеле бер катлам кешеләр өчен рухи таяныч булып хезмәт итә. Әмма зур белемнәр белән коралланган, акылга таянып конкрет эш итә торган, компьютер аша теләсә нинди мәгълүматны ала белгән замана баласын борынгы дәверләрдә бирелгән, искерә дә төшкән диннәр, тәгълиматлар инде канәгатьләндерә алмый. Хәзер рухи тәгълиматлар әчтәлеге һәм бирелү рәвеше белән заманча булса гына кешене җәлеп итә ала. Шуңа күрә хәзерге вакытта Күктәге Даирәләрдән бирелгән мәгълүматларда заман кешесенең фикерләү рәвеше һәм психологиясе һәрвакыт искә алына. Яңа Илаһилыкны чагылдырган бу материаллар эчтәлеге ягыннан бай, формасы ягыннан фәнни яки фәнни-популяр, иң мөһиме—төгәл һәм аңлаешлы була. Аларда борынгы диннәрдә чагылыш тапкан хакыйкать һәм идеяләр бик нык кинәйтелә, баетыла һәм бүгенге заманда барган процессларны тирәнтен аңларга ярдәм итә. Аларда кешелек дөньясының алга бару юлларын күрсәткән бик күп

закончалыклар ачып салына. Әлбәттә инде, дөньяның үсеш юлларын чагылдырган шушы закончалыклар белән танышкан, аларны үзләштергән кеше Яна Дәвергә әзерлекле һәм анлы рәвештә аяк басар дип өмет ителә. Адәми зат үзенең рухи үсешендә югарырак баскычка күтәрелгән саен аңа карата таләпләр дә югарырак куела.

Әмма Рәсәй, көтелмәгәндә бер салулап алмаса, Рәсәй буламыни!? Бу мәсьәләдә дә бездә туры юлдан читкә тайпылу кебек күренеш барлыкка килде. Бирелгән белемнәр, кешеләрдә кинәт ачылып киткән сәләтләр, монарчы тыелып килгән эзотерик әдәбият, төрле төркемнәрдә гамәлгә кергән рухи практикалар еш кына Яна Дәвергә күчү өчен түгел, күбрәк матди якны ныгытуга, күбрәк акча эшләүгә, тормыш-көнкүреш мәсьәләләрен хәл итүгә файдаланылды: кемдер күрәзәче ярдәмендә үзенә кияү эзләде, бизнесын көйләде, сихер-магия ярдәмендә кешегә тәэсир итү белән шөгыльләнде һ.б. Кыскасы, кеше дигәнең кабат матдиятчылык тозагына килеп эләкте, бирелгән мөмкинлекләрне дөрес кулланмады. Артык баеп китүчеләр, гомумән, Раббыбыз барлыгын онытты, чөнки матди көч-куәт аларга рухият юлына баскан өчен түгел, киресенчә, әхлак кануннары белән санашмыйча яшәгән, аларны инкарь иткән өчен агыла иде. Андый кеше өчен Раббыбызның булмавы файдалырак, Аны искә алмыйча яшәү уңайлырак, чөнки күңелдә шикшөбһә дә, шомлы уйлар да тумый. Кыскасы, хәлләр: әйбәт ният белән тотынган идек тә, гадәттәгечә килеп чыкты,—дигән кебегрәк булды.

Форсаттан файдаланып, дин өлкәсенә караган бер күренеш турында да берике сүз әйтеп узасы килә. Әйе, хәзер күпләр дин юлына басты, халык дингә сусаган иде. Әмма кайберәүләр динилекне, тәкъвалыкны үз шәхесләрен раслау өчен файдалана. Алар тышкы кыяфәткә бик нык игътибар итә, шәрекъ фасонына охшатып, нинди генә баш киеме, күлмәк, кофта, костюм кебек нәрсәләр кими һәм шуның белән даими рәвештә үзләренең нинди дини һәм тәкъва икәнлекләрен исбатларга омтылалар. Хәтта моның белән башка кешеләргә басым ясап торырга яраталар. Дини мәсьәләләр хакында ирекләрәк фикер йөртүче булса, нәфрәтләнәләр, ул кеше аларның кан дошманына әверелә. Әлбәттә, бу күренешнең асылында бик нык чикләнгәнлек, рухиятның чамалы булуы ята. Югары рухиятка ия кеше үзенең динилеген, тәкъвалыгын, ни дәрәҗәдә Раббыбызга бирелгәнлеген исбатлап йөрүдән ерак тора, динилек аның күңелендә, уенда, сүзендә, гамәлендә, кешеләргә карата булган мөнәсәбәтендә чагыла. Динилекне болай демонстрацияләүче кеше белән сөйләшә башласаң, бик тиз аның аңы әле урта гасырлар томаны эчендә яшәвен ачыклыйсың. Ул Коръәнне дә юньләп аңламый, бары тик аның кәлимәләрен генә кабатлый, Изге Китапның рухына түгел, хәрефенә табына, шуны чын динилек дип саный. Тагын шунысы да бар—мондый кешеләр, үз диненне тирәнрәк аңлау өчен, диннәрне чагыштырып өйрәнүдән бик нык куркалар, кешелек дөньясына бирелгән башка дини тәгълиматлар белән кызыксыну, шулай аң-белемеңне үстерүне алар үз диненә хыянәт итү дип саный, чикләнгәнлек читлегендә яшәүне кулайрак күрәләр.

Дин өлкәсендәге бу күренешне мин «үз-үзеңне сукырайту» дип бәяләр идем. Әлбәттә, мондый сыйфат кешенең рухи яктан бик түбән баскычта торуы турында сөйли. Кеше нәрсәнең өскә, нәрсәнең аска тартканын чамаламый икән, димәк, аның аңында төшенчәләр буталышкан, дөньяны дөрес аңлау әле юк дигән сүз. Югары аң, югары рухият ул һәрвакыт куркусыз була, ул үзе өчен яңа офыклар ачарга омтыла, шул юлдан барып кына үсешкә ирешү мөмкин икәнне яхшы белә. Ясалма динилекне, тәкъвалыкны байрак итеп йөрткән кешеләр белән бәхәсләшмәскә, аларга көчеңне сарыф итмәскә кирәк, заманнары узып бара…

Заманыбызның бер глобаль күренешенә игътибар итик. Соңгы елларда җир йөзендә фаҗигалар аеруча күбәеп китте: планетаның әле бер, әле икенче тарафында катастрофалар, аварияләр, табигать көчләренең чыгырдан чыгып шашынуы күзәтелә, шул сәбәпле бик күп нәрсә юкка чыга, җимерелә, меңәрләгән кеше һәлак була. Әлбәттә, моны очраклы хәлләр дип тә уйларга мөмкин, күпчелек кешеләр аны шулай «дөньяларның көе китте» дип кабул да итә. Әмма бу күренешләрнең асылын планетабызда барган глобаль чистарыну процессы тәшкил итә.

Әйтелгәнчә, Жирдә 5нче Кешелек Дөньясының яшәү вакыты тәгәлләнеп килә. Хәзерге вакытта Галәм тарафыннан «игеннәрне урып алу», «ашлыкны кибәктән аеру» эше алып барыла. Яңа Дәвергә күчәр алдыннан планетабыз да, кешелек дөньясы да үз эволюциясен, рухи үсешен тоткарлап торган барлык искедән, чүп-чардан, балласттан арынырга, пакьләнеп калырга тиеш. Шуңа күрә бүгенге көндә төрле катастрофалар, аварияләр, стихияләрнең көйсезләнүе күзәтелә, шундый чаралар аша Жирдән китәргә тиешле кешеләр китеп бара, теге дөньяга күчерелә, кешелек дөньясы үз үсешен тоткарлап торучылардан акрынлап арына бара.

Әмма монда бер мөһим мәсьәләгә ачыклык кертеп үтү кирәк. Эш шунда ки, төрле һәлакәтләр, катастрофалар булган андый төбәкләрдә бары тик Раббыбыз сынавын үтмәгән, Ул күрсәткән юлдан бармаган, бүгенге көндә Күкләр куйган таләпләргә җавап бирмәгән кешеләр генә һәлак була. Ә һәлакәтләр зонасына эләккән саф кешеләрне Раббыбызның күп санлы ярдәмчеләре исән-имин килеш саклап кала. Моның шулай икәненә ышану өчен һәр кешенең аны саклый торган фәрештәсе булуын искә төшерү дә җитә.

Сорау туа: ни өчен бу эш катастрофалар, төрле һәлакәтләр белән алып барыла? Тыныч кына, зур фаҗигаларсыз гына булмый микәнни? Әйтергә кирәк, әгәр дә хәзерге көндә кешеләр Раббыбыз тарафыннан бирелгән яңа мәгълүматны, дөньяны яңача аңлауны, эволюцион үсеш закончалыкларын китап кибетләрен басып киткән рухи-эзотерик әдәбият аша үзләштерә барган булсалар, әхлак, фикер һәм аң үсеше ягыннан Күкләр куйган таләпләргә җавап бирсәләр, җир йөзендә мондый һәлакәтләрнең, фаҗигаларның, стихияләрнең чыгырдан чыгуы кирәк тә булмас иде. Әмма бик күп кешенең әле әхлагы түбән, Күкләр тарафыннан тәкъдим ителгән әлеге белемнәрне, өйрәтмәләрне кабул итми, кайберәүләр гомумән андый китапларны кулга алырга курка, моны гөнаһлы эш дип саный. Шулай үзенең үсешен тоткарлый, иске күзаллаулар дөньясында яшәүне кулайрак күрә. Ә вакыт инде тәгәлләнеп килә, тәгәлләнде дип әйтергә дә мөмкин. Шуңа күрә кешеләрне йокыдан уяту, уйланырга мәҗбүр итү өчен Күкләр кискен чаралар кулланмыйча булдыра алмый. Кешене тагын ничек уятырга!? Кыскасы, яхшылык белән уянырга, тыныч шартларда аңын, яшәү рәвешен үзгәртергә теләмәгән кешелек дөньясын Күкләргә кискен һәм кырыс чаралар кулланып уятырга, аңга китерергә туры килә. Шуңа игътибар итик: кайда югары әхлак, рухият, пакьлек, чисталык, тату эшчәнлек—анда һәлакәтләр, катастрофалар һәм үлем-китем юк диярлек. Кайда түбән хисләр, ниятләр, бозыклык, кайда нәфрәт, сугышлар, ярсулык, дошманлык—анда һәлакәтләр, аварияләр, катастрофалар. Моның шулай икәнен һәр көнне телевидение аша килеп торган дөнья хәбәрләреннән дә күреп була. Барысы да күз алдыбызда бара, бу бик реаль процесс һәм аны күрмәмешкә салышу инде мөмкин түгел. Шуңа күрә хәзер планетаның һәм гомумән кешелек дөньясының язмышы адәм балаларының үзләреннән дә тора. Кеше үзен ничек тота, ничек яши, ул үзгәрергә әзерме, үзгәрәме, Раббыбыз тарафыннан бирелә торган яңа мәгълүмат, дөньяны яңача аңлау, Яңа Илаһилык һәм югары әхлак кеше тарафыннан кабул ителәме???

Бу очракта кешегә: «Адәм баласы, иҗтиһад ит, үз-үзеңне коткар!»—дип кенә әйтергә кала.

# ҮТКӘН ЕЛГА ЙОМГАК

*Шушы елның 12 апрелендә Татарстан язучылары үткән 2005 әдәби ел йомгакларына багышланган гомуми җыелышларын уздырдылар. Башка еллардан аермалы буларак, быел эшлекле сөйләшү остаханәләрдә башланып китте. Ә төштән соң пленар утырышта иҗади берлек идарәсе рәисе* ***И. Ибраһимов*** *докладын тыңланды һәм фикер алышулар булды. Утырышта Татарстанның Премьер-министр урынбасары—Мәдәният министры* ***З. Вәлиева*** *катнашты һәм чыгыш ясады.*

*Бу санда укучыларыбызга Язучылар берлеге рәисе* ***И. Ибраһимов****, проза буенча чыгыш ясаган язучы* ***К. Кәримов****, шигърият турында сөйләгән шагыйрь* ***Р. Зәйдулла*** *чыгышларын тәкъдим итәбез.*

Илфак
Ибраһимов

## Әдәби сүзнең көче

Без бүген 2005 әдәби ел йомгакларына җыйналдык. Алдагы еллардагы тәҗрибә һәм язучыларыбызның теләкләреннән чыгып, без быелгы әдәби ел йомгакларын иң әүвәл һәр жанр буенча секцияләрдә тикшерергә һәм гомуми пленар утырышта анализлап үтәргә дигән фикергә тукталдык. Белгәнебезчә, бүген 6 секциягә бүленеп әдәби жанрлар буенча зур кимәлдәге сөйләшүләр булды.

Секцияләрдә тирән анализлы докладларны каләмдәшләребез: Ркаил Зәйдулла, Дания Гыймранова, Камил Кәримов, Лилия Газизова, Рафис Корбан, Мансур Вәлиевлар ясадылар. Секцияләрдә үз фикерләре белән 30дан артык язучыбыз чыгыш ясады (жанрлар буенча төп докладларның тезислары алдан бастырылып сезнең кулларыгызга таратылды). Секцияләрдә әйтелгән тәкъдим-киңәшләр, таләпләр пленар утырышта да үзенең чагылышын табар дип уйлыйм.

2005 ел халкыбыз тормышында тирән эз калдырган, тарихи яктан зур әһәмияткә ия ел булды. Казаныбызның 1000 еллыгын үткәрергә әзерлек барышында да, аны билгеләп үтү көннәрендә дә татар халкының—тарихта эзле халык булуын, аның кешелек дөньясының рухи камиллеген тотып торуда саллы өлеш керткән затлы, зыязатлы халык булуын бөтен дөнья җәмәгатьчелегеннән бигрәк, үз халкыбызга ышандырырлык итеп күрсәтә алу мөмкинлеге туды. Ышандыра алу сүзенә аеруча басым ясыйсы килә. Хәтта үз дәүләтчелеген югалткан биш гасыр дәвамында да, үз йөзен югалтмаган халык, бүген, бөтен дөньяны колачлый башлаган глобальләшү дәверендә, үзенең милли йөзен югалтырга бик тә мөмкин. Моннан йөз ел элек бөекләребез Гаяз Исхакый һәм Габдулла Тукайлар җан ачысы белән кисәткән инкыйразның сәбәбе асылы да шуллыр мөгаен. Г.Тукайның: "Халык үлмәгән дә, йокламаган да, мәрткә киткән"—дип әйтүе шуны кисәтү булгандыр.

Үзенең: "Инде ул мәрткә киткән милләт белән нишлик, аны ничек үз гакылына кайтарыйк?"—дигән соравына, Г. Тукай: "Милләткә—җанына хуш килердәй милли музыкаларыбызны тынлатыйк, аңа ерак бабаларыбызның бик тәрәккыятле булуларын рәсем-сурәтләрдә, әдәби әсәрләр аша үзенең йөзен—күзгедән күрсәткән кебек күрсәтик—анарда ышаныч уятыйк",—дигән чакыруы—бүген 100 елдан соң да бик актуаль яңгырый. Илбашының 2006 елны "Әдәбият һәм сәнгать елы" дип

игълан итүе дә, халкыбызның үз-үзенә ышануына ирешүне, милли идея дәрәҗәсенә күтәрүе, ә моңа фәкать, Г.Тукай әйткәнчә, әдәбият һәм сәнгать аша гына ирешеп булуын танудадыр!

Әйе, киләчәккә ышаныч уяту акыл һәм күңел аша гына булырга мөмкин. Һәр алдынгы карашны милли идея дәрәҗәсенә күтәрүдә әдәбият һәм сәнгать үзе үк вәкаләтле һәм җаваплыдыр. Чөнки идея—ул үзе дә иҗат, иҗат җимеше.

Казанның 1000 еллыгы! Халкыбыз никадәрле сынаулардан соң да, канга батып кыйналганнан соң да, көлгә калдырып яндырылганнан соң да, дөньяның дүрт тарафына таралганнан соң да, Казанның әлегәчә шул халыкның башкаласы-мәркәзе булып торуы—чыннан да бүген халкыбыз өчен фаразланган, инкыйразга киртә булырдай фал. Халыкка үз киләчәгенә ышаныч тәрбияләү—бу сәяси лозунгмы, әллә милли идеяме? Бу сәяси лозунг та, милли идея дә була ала.

2005 ел халкыбыз өчен шулай ук Бөек Ватан сугышында җиңүнең 60 еллыгы белән дә билгеле. Коточкыч корбаннар бәрабәренә яуланган җиңү! Җиңү—бар халыкларның бердәмлеге, максатлар уртаклыгы белән яуланды. Тынычлык өчен көрәш, халыклар дуслыгы бердәмлеге—бу сәяси лозунгмы, әллә бүгенге көндә үзара имин яшәүнең асылы булган милли идеяме? Бу, һичшиксез, сәяси лозунг та, милли идея дип тә бәяләнә ала.

Әлбәттә, узган әдәби ел йомгакларына анализ ясарга алынсак, без әлеге дөньякүләм тарихи әһәмиятле вакыйгаларның матур әдәбиятта ничек чагылыш табуына тукталмый булдыра алмыйбыз.

Татарстан китап нәшриятында, "Казан утлары" журналында, башка нәшриятларда һәм әдәби басмаларда китап булып нәшер ителгән һәм аерым әсәрләр булып бастырып чыгарылган дистәләрчә авторларыбыз—шул исәптән халык язучылары һәм шагыйрьләр—Гаяз Исхакый, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллиннарның 5—6 томлыклары, Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллинның "Утырып уйлар уйладым", Мөсәгыйт Хәбибуллинның "Хан кызы һәм Шәһри Казан турында риваят", Вахит Имамовның "Казан дастаны", Равил Вәлиевнең "Бөек хан әмере", Рабит Батулланың "Елантау", Зиннур Хөсниярның "Терсәк сугышы", Марсель Галиевнең "Рух", Айдар Хәлимнең "Кыйбла", Камил Кәримовның "Сакау күке", Фәүзия Бәйрәмованың "Кырык сырт", Тәлгат Галиуллинның "Сәид Сакманов", Мәдинә Маликованың "Кызыл гөл", Фоат Садриевның "Бәхетле бәхетсезләр", Искәндәр Гыйләҗевның "Идел-Урал легионы" кебек күләмле проза, публицистик әсәрләре; Роберт Әхмәтҗановның "Таш аргамак", Ркаил Зәйдулланың "Мәгарә", Газинур Моратның "Төнге әверелеш", Харрас Әюповның "Йөз яктысы", Лена Шагыйрьҗанның "Сагынмаклык", Рәниф Шәриповның "Мәңгелек сер", Флера Тархpraнованың "Яшьлек эзем калган сукмаклар", Габделнур Сәлимнең "Итагать" һәм башка шигъри китаплары, "Казан утлары"нда басылып чыккан Роберт Миңнуллин, Фәнис Яруллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Флера Гыйззәтуллина, Лена Шагыйрьҗан, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ һәм башкаларның шигъри әсәрләрен без узган әдәбият елының билгеле бер казанышлары дип әйтә алабыз.

Секция утырышларында ел прозасы һәм ел поэзиясенең һәм башка жанрлар үрнәкләре докладларда һәм язучыларыбызның чыгышларында чагылыш тапкандыр дип беләбез. Шуның белән беррәттән халкыбызның хак тарихын чагылдыручы, халык язмышының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында гыйбрәтле тарихи вакыйгалар, тарихи шәхесләрнең образларына бәйле рәвештә яңадан-яңа әдәби фаразлар, әдәби модульләрне күрергә ихтыяҗы бар.

Әдәби процессның кан әйләнешен, аның пульс ешлыгын язучыларыбызның вакытлы әдәби басмаларда дөнья күргән әдәби әсәрләре билгели дисәк ялгыш булмас.

"Казан утлары", "Идел", "Мәйдан" журналлары, "Мәдәни җомга" газетасы бүген чын мәгънәсендә язучыларыбызның иҗат остаханәсе булып әверелде. Әлеге әдәби журнал-газеталарыбызның баш мөхәррирләре үзләре күренекле каләм ияләре буларак әлеге редакцияләрдә гамәли хезмәткә егермедән артык профессиональ язучыны туплап, аларны бер яктан эш белән тәэмин итеп, икенче яктан чын әдәби

процессны оештыручылар булып торалар. Үзенең 1000 саны белән дөньяга чыккан "Казан утлары" әдәби иҗат коллективының хезмәте аерым игътибарга лаек.

Һәр елдагыча әдәби мирасны һәм бүгенге язучыларыбызның иҗат үрнәкләрен киң катлау укучыларына җиткерүдә республикабызда нәшер ителүче башка газета-журналларыбыздан "Мирас", "Салават күпере", "Сөембикә", "Татарстан", "Казан", "Ватаным Татарстан", "Шәһри Казан", "Татарстан яшьләре", "Республика Татарстан", "Казанские ведомости" газета-журнал редакцияләренә дә без бүген үзебезнең рәхмәтләребезне җиткерәбез һәм аларны алдагы чорда тагы да кинрәк хезмәттәшлеккә чакырабыз.

Хөрмәтле каләмдәшләр! Әдәби газета-журналларыбыз үзләренең барлыкка килүенә бәйле рәвештә үз вакытында дәүләт тарафыннан тулысынча әдәбиятка хезмәт итү өчен булдырылган да. Шунардан чыгып аларны гамәлгә куючылар булып, иҗат берлеге һәм Мәдәният министрлыгы торды. Россия күләмендә базар икътисады шартларында—дистәләрчә әдәби журналлар—дәүләтнең төрле структура органнарыннан чыкты яки чыгарылды, ә массакүләм чаралар коммуникацияләре агентлыгында калганнарының уставлары үзгәртелә башлады. Һәм дәүләт органнары бу басма нәшриятләрнең уставына иҗат берлекләренең гамәлгә куючылар булуны танымый башладылар. Шуңа ияреп безнең "Татмедиа" агентлыгы да, "Казан утлары", "Идел", "Мәйдан" журналларының уставына үзгәрешләр кертеп һәм бу журналларны туа-туганнан бирле гамәлгә куючыларның берсе булган Язучылар берлеген төшереп калдыруны күздә тота. Без инде бу хакта "Татмедиа" белән сөйләшүләр алып барабыз. Бердәнбер көнне—бу журналларны "табыш китермәве" сәбәпле ябылган очракта, без—язучылар—үз әсәрләребезне кайда, ничек бастыру турында уйларга тиеш булабыз. Әдәбият һәм сәнгать елында безгә бу мәсьәләне хәл итүдә дә Мәдәният министрлыгы бер эшлекле адым ясар дип ышанабыз.

Язучыларның иҗатларын пропагандалау шулай ук әдәби иҗат процессының аерылгысыз бер өлеше. Ел дәвамында үткәрелгән әдипләребезнең юбилей, иҗат кичәләре, алар белән очрашу кичәләре район, шәһәрләрдә үткәрелгән татар әдәбияты көннәре, радио-телевидение аша алып барылган чараларның һәркайсына тукталып тормыйм. Җыйнап шуны гына әйтәсем килә: киләчәктә бу юнәлештә башкарасы эшләребез бихисап... Өстәп шуны да әйтү зарур: язучының иҗатын һәм гомумән әдәбиятны—язучы үзе, аның китабы һәм башка әдәби басмалардан да үтемле итеп һичкем һәм һичнәрсә пропагандалый алмый.

Әдәби журналларыбыз, газеталарыбыз һәр укучыга, һәр өйгә ничек барып житә? Һәр каләм иясен һәм Язучылар берлеген иң беренче чиратта шул мәсьәлә борчый. Язучылар берлеге идарәсе газета-журналларга язылу чорында район, шәһәр җитәкчеләренә, мәгариф идарәләренә, зур предприятие җитәкчеләренә хатлар белән мөрәҗәгать итеп тә карадык, әмма ана карап кына тиражыбыз үсмәде. Димәк, эзләнергә, яңадан-яңа хезмәттәшлек формаларын табарга кирәк.

Һәр хезмәт тиешенчә бәяләнергә һәм хакы түләнергә тиеш.

Без—язучыларны—базар шартларына яраклашмауда урынлы тәнкыйть итәләр. Үзенең иҗат җимешен һәр очрашуда бушка өләшеп йөрүе дә, китабы басылып чыкканнан соң ел ярым гонорарын ала алмый йөрүе дә, аның үзеннән башка һәркемне гаҗәпләндерә—фәкать аның үзен генә түгел. Язучылар берлеге идарәсе октябрь-ноябрь айларында китап сәүдәсе һәм гонорар түләүнең торышын җентекләп анализлады.

2005 елның азагында Татарстан китап нәшриятында 2004 елда язучыларыбызның басылып чыккан китаплары өчен гонорар бурычы 1 млн 900 мең сум иде. 2004 елгы бу бурыч хәзер инде түләнеп бетеп килә. Ә 2005 елда басылган китаплар өчен түләнмәгән хезмәт хакы бурычы исә тагы да миллион сумнар белән бәяләнә.

Нәшрият җитәкчелеге, бу хакта мәсьәләне күтәрүгә, үзләренең складларының сатылмый яткан китаплар белән тулганын әйтеп җавап бирә. Һәм монда фәкать язучының үзенең пассивлыгын сәбәп итә.

Язучылар берлеге идарәсе, әйткәнемчә, республикабызда китап сәүдәсенең торышын бик кызыксынып өйрәнде. Идарә әгъзалары республикабызның 26 район-шәһәрләренә барып, мәсьәләне урынында тикшерделәр. Баксаң—китап сату буенча

дәүләт һәм кооператив сәүдә челтәре гел бетерелгән. Дөрес, шәхси китап кибетләрендә дә татар теле дәреслекләре һәм берничә җирле авторның китапларын очратып була, әмма алар китапка: "акча—товар—акча" формуласы белән генә карыйлар. Җирле үзидарә җитәкчеләре коммуналь һәм мәктәп китапханәләренең тузган фондын янартуга тиешле әһәмият бирмиләр. Без моны 22 март көнне Әлки районының 12 мәктәбендә булып, күреп тагын бер инандык. Мәдәният министрлыгы, Мәгариф министрлыгы биргән 1-2 миллион сум акчага алып, бүлеп биреләсе китапларны көтеп яталар. Бу хакта без Республикабызның Дәүләт Советына һәм хөкүмәтенә мөрәҗәгать иттек. Ни кызганыч, әлегәчә китапка, татар китабына мөнәсәбәт әдәбият һәм сәнгать елында да бик начар булып кала бирә.

Базар шартларын яхшы "аңлаган һәм аңа яраклашкан" менеджментларның хезмәт хаклары язучының китабы сатылуга корылса һәм язучы гонорарының бер өлеше китабы сатылу дәрәҗәсенә корылса нәшрият һәм язучы арасында мөнәсәбәтләр бер-берсен эшлексезлектә гаепләүдән ярдәмләшү, хезмәттәшлеккә күчәр иде.

"Казан утлары" журналыннан кала башка газета-журналлар шулай ук гонорар түләүне изге вазыйфалары дип танымыйлар. Ә бит гонорарның түбәнлеге турында сүз алып бармыйбыз, вакытында түләү турында сүз алып барабыз. Язучылар берлеге идарәсендә бу мәсьәләне тикшерүдә катнашкан "Татмедиа" агентлыгы директоры урынбасары Фәрит Шәһиәхмәтов барлык редакцияләрнең һәм нәшриятләрнең гонорар түләү фондлары дәүләт тарафыннан тоткарлыксыз финанслануын белдергән иде югыйсә.

Язучының иҗатын стимуллаштыруда республикабыз күләмендәге һәм Язучылар берлегенең исемле премияләре зур әһәмияткә ия. Узган ел башында Илбашыбызның Указы нигезендә Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең яңа Положениесе эшләнде һәм премиянең матди кыйммәте күп мәртәбәләр күтәрелде. Илбашыбызның тәкъдиме буенча Язучылар берлегенең аерым жанрлар буенча исемле премияләрнең дә матди кыйммәте 10-12 мәртәбә күтәрелде. Бу максаттан республикабызның эре предприятиеләре һәм спонсорлары ярдәмендә Язучылар берлегендә грандлар һәм премияләр фонды булдыру тагы да нәтиҗәле булачак. Шулай ук "Татнефть" ачык акционерлык җәмгыяте һәм Язучылар берлегенең Саҗидә Сөләйманова исемендәге премияләрен, стипендияләрен булдыру үрнәкләрендә хезмәттәшлекнең башка төр формаларын эзләү зарур.

Язучы иҗатын стимуллаштыруда аның чын-чынлап бөтендөнья әдәби пространствосына чыгуы әһәмияткә ия. Бу максатта талантлы әдәби әсәрләрне дөнья телләренә тәрҗемә итү кебек шактый "каты чикләвек"не ватасыбыз бар әле.

Хәтта рус теленә әдәби тәрҗемә, бигрәк тә татар поэзиясен русчага тәрҗемә итү буенча, шактый еллар йоклап калганбыз. Бүген Мәскәүнең профессионал тәрҗемәчеләре бер строфа шигырь тәрҗемәсенә 3-4 доллар акча сорыйлар—бу якынча 100 сум дигән сүз, татар шагыйренең үз телендә язып, бастырып та андый бәһане күргәне юк. Шуңа күрә Язучылар берлеге идарәсе каршында кичекмәстән тәрҗемә секциясе оештыруны күздә тоттык.

Моннан берничә еллар элек татар язучыларының әсәрләрен төрек теленә һәм төрки телләр группасына кергән башка телләргә тәрҗемә итү буенча җитди фикерләр күтәрелгән иде. Ни кызганыч, бу эш тә туктап калган.

Күргәнебезчә, үз-үзебезгә бикләнеп яту—ул безнең әдәбият файдасына түгел. Әдәби тәрҗемә—дәүләт дәрәҗәсендәге әһәмиятле мәсьәлә. Һәм әдәбият, сәнгать елы дип игълан ителгән быелгы елда без бу юнәлештә билгеле бер эшлекле адым ясарга, әзерләнергә тиешбез.

Әдәби иҗат процессын оештыруда, бигрәк тә яшь авторлар белән эшләүдә, Язучылар берлеге идарәсе каршында оештырылган аерым жанрлар буенча иҗат секцияләре зур әһәмияткә ия.

Соңгы съездан соң иҗат секцияләренең эшчәнлеге сизелерлек яхшырды дип билгеләп үтәр идем. "Проза" һәм "Публицистика" секциясе җитәкчеләре Марсель Галиев һәм Рабит Батулланың үз эшләренә иҗади карауларын билгеләп үтәсем килә. Әйтик, Рабит Батулланың тәкъдиме һәм үзенең башлап йөрүе буенча август—сентябрь айларында язучыларыбыз 2005 ел урагына, авыл хезмәтчәннәре белән

очрашуга чыктылар, 31 язучыбыз 7 районга чыгып, бүгенге авыл тормышын үз күзләре белән күреп гыйбрәтләнеп кайттылар. Марсель Галиев октябрь аенда проза секциясенең киңәйтелгән утырышына Нурлат шәһәре һәм районы җитәкчесе Фатих Сибагатуллинны чакырып, аның белән очрашу оештырды.

Балалар әдәбияты секциясе җитәкчесе Рафис Корбан һәм "Салават күпере" газетасы редакциясе инициативасы белән "Балалар китабы атналыгы" үткәрелеп, Казанның 48 мәктәбендә язучыларыбызның очрашуы оештырылды. Шигърият секциясе җитәкчесе Зиннур Мансуровның инициативасы белән "Бүгенге эстрадада җыр текстлары" турында шагыйрьләр, җырчылар һәм композиторларның кызыклы иҗади бәхәсле очрашулары булып узды. Яшь шагыйрьләрнең әсәрләре тикшерелде.

Шул ук вакытта, әле иҗат секцияләре чын-чынлап яшь авторлар белән эшләү буенча иҗат лабораториясенә әверелде дип әйтеп булмый. Без иҗат секцияләренең эшен менә бүгенге пленар утырышларда булган рәвештә дә күрергә теләр идек. Һәрхәлдә алдагы чорда шунар омтылу кирәк тә.

Язучылар берлеге идарәсе узган әдәби иҗат елында дәүләт органнары һәм киң җәмәгатьчелек белән элемтәләрен ныгытырга омтылды. Мәдәният министрлыгы белән көндәлек хезмәттәшлек шартларында һәм бердәм үткәрелгән чараларның матди нигезен Мәдәният министрлыгы чыгымнары тәшкил итә. Идарәнең Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты белән элемтәләрнең ныгуын аеруча басым ясап әйтәсем килә. Узган ел Удмуртия Язучылар берлегендә татар язучылары секциясен оештыру буенча беренче адымнар ясалды. Бу эштә Бөтендөнья татар конгрессының Удмуртиядәге оешмалары бик тә инициатива күрсәтте. Милли мәдәниятебезне, телебезне үстерү буенча һәркайда милли мәдәни автономияләр нәтиҗәле эш алып баралар. Бөтендөнья татар конгрессы һәм Федераль милли автономия үзеге шул мөхтәриятләрне координацияләп торучы буларак—татар әдәбиятын пропагандалауда һәм сатуда безгә таяныч була алыр иде. Бер сүз белән әйткәндә, без алар белән берлектә үз эшчәнлегебезнең географиясен генә түгел, ә эчтәлеген дә тагын да баета алачакбыз. Кызганычка каршы, узган иҗат елында Казан шәһәре хакимияте, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Балалар һәм яшьләр белән эшләү министрлыклары, Казан югары уку йортлары белән белән элемтәләребез теләктә генә калды. Бу юнәлештә идарәнең ныклап уйланылган программасын эшлисе бар.

Идарә ел дәвамында язучыларыбызның яшәү-көнкүреш шартларына кагылышлы мәсьәләләр буенча да берникадәр эш башкарды. Бу максатта идарә составында социаль-көнкүреш мәсьәләләре буенча комиссия төзелүне үзвакытында күрелгән чара дип беләбез. Әлегә комиссиянең зурдан сөйләрлек нәтиҗәләре булмаса да, Язучылар берлегенең социаль паспортын эшләве, авыру язучыларыбызга адреслы медицина ярдәме күрсәтү буенча берникадәр эшләр башкара алдык. Хәзер Язучылар берлегендә торучыларга пенсия билгеләү буенча кайбер проблемаларны хәл итү юлларын эзлибез.

Язучылар берлеге идарәсе яшь каләм ияләре белән эшләү юнәлешендә дә хәрәкәт итә. Күз күне Мәдәният министрлыгының ярдәме белән республикабызның 28 районыннан әдәби берләшмә җитәкчеләрен Казанга 4 көнлек семинарга җыйный алдык. Алар аша дистәләрчә өметле яшь язучыларыбызны барладык. Саба районының үзәк китапханәсе каршындагы "Саба таңнары", Актаныш районының район газетасы каршындагы "Агыйдел дулкыннары", Түбән Каманың "Кама таңнары", Сарман районы Җәлил эшчеләр поселогы, Чаллыда "Ләйсән", Минзәлә район балалар китапханәсе каршындагы һәм башка әдәби берләшмәләрнең чын мәгънәсендә иҗади оешма булуы безне сөендерде. Киләчәктә Язучылар берлеге идарәсе Казан уку йортлары һәм район, шәһәрләр әдәби берләшмәләре белән иҗади элемтәләрне һичшиксез ныгытырга бурычлы.

Хөрмәтле каләмдәшләр!

Әдәби ел йомгаклары, дип зур кимәлдә сөйләшүебез, ул, әлбәттә, шартлы рәвештәге вакыт бүленеше... Һәр язучы—ул үзе бер иҗади күренеш. Һәр язучының иҗат календаре—гомуми ел календаре һәм аның фасылларына буйсынмаска да

мөмкин. Шагыйрь әйтмешли, иҗат кешесе өчен күзләрдә дә язлар кабатланырга һәм киресенчә язларда да моң, сагыш төпсезлегенә чумарга мөмкин. Шуңа да карамастан, безнең әсәрләребезгә ихтыяҗ барлыгын, аларның җәмгыятьтә берләштерү, туплау, тәрбияви мәгънәдәге әһәмияте барлыгын бүген беркем инкарь итә алмый.

Илбашыбыз М.Ш.Шәймиев үзенең Дәүләт Советында бәян иткән юлламасында Әдәбият һәм сәнгать елы буларак игълан ителгән 2006 елның бөтен Татарстан халкының киләчәккә ышанычны ныгытуда, рухи дөньяның, рухи сфераның барлык өстенлекле социаль проблемалардан да өстенлекле булуны ассызыклады... Һәм агымдагы елга билгеләнгән барлык чаралар—алар киләчәктә һәрберебез юнәлеш тотачак тарафны һәм иҗади-рухи потенциалны куллану, файдалану, нәтиҗәгә ирешү юлларын эзләү-билгеләү булып та торырга тиеш.

Инде якын көннәрдә үткәрелгән һәм үтәчәк шундый чараларга да тукталып үтик. 2006 елда—Җәлил һәм Тукайның олуг юбилейлары гына түгел, исән һәм дөньядан киткән 109 язучының да төрле дәрәҗәдәге искә алу даталары билгеләп үтелә. Алардан тыш, музыка, сынлы сәнгать буенча күренекле шәхесләрнең күркәм юбилейлары да бар.

Ә бүген Җәлил һәм Тукай—Россия һәм дөнья буйлап сибелгән халкыбызны барлау, берләштерүдә илче рольләрен үтиләр. Хәтта, читтә яшәүче йөзләрчә мең татар яшьләренә Ана телендә сөйләшү, язу, яттан шигырь уку өчен укытучы булып хезмәт итәләр... Әдәбиятның—әдәби сүзнең мәгънәви багланышын, аның тәэсир көчен арттыру—иң бөек максатыбыз,—дип авыз тутырып әйтә алабыз! Шул изге эшебездә һәркайсыбызга саулык-сәламәтлек, рухи иҗат күтәренкелеге, бәхет-шатлыклар телим!

---

Камил
Кәримов

## Прозаның киштәдәге урыны

*(2005 елда басылып чыккан кайбер чәчмә әсәрләр турында)*

Өч нульле XXI гасыр капкасыннан килеп кергәч, иҗтимагый, әдәби һәм мәдәни тормышыбызда өч урынлы саннар белән бәяләрлек вакыйгалар артты. Мең еллык әдәби мирасы киштәгә куелган бөек татар халкы, ниһаять, Мәркәзебез Казанның мең еллыгын бөтен дөньяга шаулатып исбат итә алды, сыйнфый көрәшләрне, дәһшәтле елларны каһарманнарча кичеп, бүгенге көнгә кадәр аягында нык басып тора алган төп әдәби журналыбыз—«Казан утлары»ның меңенче саны дөнья күрде...

Меңнәрдән соң «мең дә бер кичә» башлана. Базар юлыннан исән-имин килеп җитсәк безне әкияти киләчәк көтә.

Узган 2005 әдәби ел, басылып чыккан китаплар, роман, повестьлар, хикәяләр саны белән чагыштырганда, башка еллардан һич кайтыш түгел. Татарстан китап нәшрияты Халык язучыларының күп томлыкларын чыгаруга ирешә, «Мәгариф» нәшрияты дәреслекләр белән бер букчада йөрерлек тарихи китаплар, библиографик белешмәләр, балалар өчен проза үрнәкләре чыгарды.

Вакыт-вакыт нәшриятларыбызның оперативлыгына, дөресрәге язучыларыбызның активлыгына шаклар катасың. Роман «Казан утлары»ның, әйтик, август санына планлаштырыла, ә сентябрь аенда ул инде нәшриятта басылып та чыккан була. Объектив сәбәпләр аркасында журналда планлаштырылган әсәр бер-ике айга чигерелеп куйса, ул инде китап булып чыгып өлгерә һәм кызганыч ки, журналдан төшеп кала. Мин бу очракта Галимҗан Гыйльмановның «Албастылар»ын (II кисәк), Мәдинә Маликованың «Кызыл гөл» романын һәм Равил Вәлиевнең «Олуг хан ярлыгы» китабын күздә тотып әйтәм.

«Казан утлары» журналы һәр тарихи датага игътибар итеп өлгерергә тырыша.

Узган 2005 елда, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 60 еллыгына багышлап басылган әсәрләр арасында Шамил Маннаповның «Янгыннан калган баганалар» дигән хикәятләре бар. Үз биографиясенә кагылышлы вакыйгалар булгач, автор бу хикәяләрне бөтен көчен һәм сәләтен кызганмыйча язган. Сугыштан соң тернәкләнгән яна буынның сабырлыгын, гаделлеген, кешелеклеген һәм тырышлыгын күрәсең дә: «Их, капма-каршы якка үзгәрдек бит без!» дип авыр сулап куясың. Бүгенге көрлектә үскән яшьләргә мәҗбүри укытыр өчен Шамил Маннаповның әлеге хикәятләрен дәреслекләргә кертәсе иде...

Җиңү залплары ерагайган саен батырлар күбәя, ләкин фронтовик язучыларыбыз кими бара. Мөҗип Имамовның фронтовик язмалары тере истәлек буларак макталса, Маннур Саттаровның документаль повесте татар солдатының чын интернационалистик рухын яктырта. Сиксән яшенә житеп тә юмористик шигырьләр язудан туктый алмаган Маннур Саттаров бик җитди эшкә алынган. Ул фронтовик дусты, дәресрәге окопташ дусты Юлдашның туганнарын эзләп Үзбәкстанга изге сәяхәткә чыга. Партия һәм комсомол бюрократлары белән көрәшеп окопташ дусты Юлдашны аклап чыга, үзбәк егетенең батырлыгын исбат итеп исемен күтәрә. Шуның белән автор үзе дә батыр совет солдатына әверелә.

Тарихи дата дигәннән, узган 2005 ел татар халкы тарихында иң гүзәл вакыйга— Казанның 1000 еллыгы белән хәтердә калыр. Мәркәзебезнең туган елы Казан Кремле нигезендәге таш сандыклардан табылган хәзинәләр белән генә түгел, ә язучыларыбыз тудырган тарихи романнар, эсселар белән дә расланып тора. Мөсәгыйт Хәбибуллин, Батулла, Марат Әмирхан, Флүс Латыйфи, Вахит Имамов, Равил Вәлиев кебек каләм осталарының тарихи әсәрләр язарга алынуы әдәбиятыбызның әкияти офыкларын киңәйтте. Үзенең бөтен иҗатын татарның мең еллык шәҗәрәсен әдәбиләштерүгә багышлаган халык язучысы Нурихан Фәттах бар иде. Ул барында татар тарихын янадан язарга башкалар бик үк җөрьәт итмиләр иде. Хәзер исә, редакция папкасына тарихи роман керсә, рецензиягә бирергә кеше табуы кыен. Тагын да җетерәк итеп әйткәндә—Нурихан Фәттахның үзе исән чагында тәгәлләнеп бетмәгән «Аклан» романын кемгә укытып алырга икән, дип, икеләнебрәк торабыз.

Репрессия елларын тасвирлап, сталинизмны фаш итеп язылган романнар белән дә шул ук хәл. «ГУЛАГ» тәмугыннан исән-имин котылып, кичергәннәрен матур әдәбиятка әверелдергән изге шаһитләребез бар иде—безнең буынның остазлары Хәсән Туфан, Ибраһим Салахов, Гурий Тавлин... Алар юк инде. Әдәби намус сагында торырлык классикларыбыз ерагайган саен алар башлап җибәргән темага тотынучыларыбыз күбәя. Нәтиҗәдә, ерак яки якын тарихка кагылышлы бәхәсле романнар авторның үз намусында һәм редакция хезмәткәрләре җаваплылыгында кала. Әлбәттә, иҗаттагы хөррият шушы рәвештә сакланса, әдәби процесс үзенең яңа рецензентларын, яңа белгечләрен булдырыр әле.

Вахит Имамовның «Казан дастаны» романы, Казанның мең еллыгын үткәргән айда чыксын өчен, журнал өстәлендә махсус запас булып торды. Өч йөз утыз битлек романда Габдулла хан, Талиб хан, Мөхәммәт хан һәм Ибраһим хан идарә иткән чорлар тәфсилләп сурәтләнә. Укучылар өчен күңелсез булмагандыр: романда ызгышлар да, сугышлар да,уйнашлар да җитәрлек. «Казанның мең еллыгына багышлыйм» дигән төгәл адрес белән башлангач, Казан каласына нигез салу күренешләрен түземсезлек белән көтәсең. Ниһаять, алтмышынчы бүлеккә җиткәч, Владимир кенәз алдында Ибраһим хан: «Монда яңа кала салам!»—дип бер казык кага. Әсәрдә Казан каласы бер казык булып кына кала. «Казан дастаны» дастаныбызга әверелерме-юкмы—белмим, әмма Вахит Имамов бүгенге көндә тарихи әсәрләр язучы иң актив автор. Каян килә торгандыр аңа шулкадәр энергия һәм тәвәккәллек?! Нурихан Фәттах булып ул да җиде-сигез елга бер генә роман яза ала иде. Ә Вахит Имамовны тыебрак тормасаң ел саен берәр роман яза ала. Безгә Вахит дустыбыздан активлыкка өйрәнәсе бар әле.

«Казан утлары» журналында узган ел чәчмә әсәрләрдән өч роман һәм сигез повесть, ун хикәя басылды.

«Иманыннан бер язсаң» дигән романына артык тукталмыйча Рауль Мирхәйдәровның журналда басылган иҗаты хакында берничә сүз әйтергә телим. Мәскәүдә яшәп рус телендә иҗат итүче татар җанлы Рауль Мирхәйдәровның романнары бөтен дөньяга билгеле. Ләкин аны татар укучысына нәкъ менә «Казан

утлары» журналы алып килде. Аның һәр романы кызу бәхәс тудыра, бигрәк тә язучылар арасында... Югары эшелон даирәләре кереп чумган коррупция, элеккеге СССР киңлекләрен колачлаган мафия турындагы детектив романнар кирәкме безгә? Әлбәттә кирәк! Беренчедән, Рауль Мирхәйдәров үзен: «Мин татар малае»,— дип әйтә икән, ник әле без Мәскәү язучылары арасындагы шундый авторитет белән горурланмаска тиеш ди. Икенчедән, бүгенге укучыга рус әдәбиятының, чит ил классикларының кызыклы үрнәкләрен тәрҗемә итеп күрсәтү хәзинәбезне баетыр иде. Юкса без хәзер «любовный треугольник»лар белән мавыгып, охшаш өчпочмаклар ясый башласак; шәхес культы корбаннары дип һәр колхоз бригадирының көндәлеген күчерә торсак; «тарихи» дигән вакуумны борынгы ханнарыбызның байлыктан нишләргә белмичә кызлар һәм малайлар белән шаярышып күңел ачуын, үзара талашып ятуын гына тасвирлаган компилятив әсәрләр белән тутырсак—татар әдәбияты үз сазлыгына үзе кереп батачак. Ерак бабаларыбызның ояты безгә булачак, рус теленә тәрҗемә ителгән романнарыбызны укыгач йөз утыз миллионлы күршебез безгә бармак төртеп күрсәтәчәк.

Бүгенге укучыбыз ниндиерәк әсәрләр ярата соң, дигән сорауга җавап табасыгыз килсә, сез Мәдинә Маликованың роман-повестьларын укыгыз дияр идем мин. Алар күтәрелгән теманың актуальлеге, вакыйгаларның тыгызлыгы, каршы як мөнәсәбәтләрнең киеренкелеге, гадел чишелеше белән укучы күңелен бик тиз җәлеп итә. «Чәчкә балы» повесте, беренче карашка наркоманиягә каршы көрәшкә чакыру булып яңгырый. Гамилне кыйнап киткән малайларның берсе—аның үз улы булып чыга, бала тудыру йортында ук буталып, ул бала чит кеше кулында үсә. Макар Харитоновка әверелгән татар малае марҗа кулында юньсез тәрбия алып наркоман булган. Повестьның ахырында һәр ике малай да Гамил белән Сәгъдия кулында кала. Авыл тормышы, чәчкә балы наркоман малайны савыктыра. Малайларның икенчесе дә үз әнисе, марҗа кулында тәрбияләнгән булса—аны да Макар Харитонов язмышы көткән булыр иде дип нәтиҗә ясыйсы килә.

Бүгенге чыгышка бирелгән ярты сәгать вакытны бары тик Фәүзия Бәйрәмованың «Караболак» романы турында гына да сөйләшеп үткәрергә мөмкин булыр иде. Ниһаять! Ниһаять, туксан ел буе шымчылар күзәтүе астында иҗат итеп, язылмаган әсәрләре өчен дә сагаеп яшәргә өйрәнгән татар язучысы әкренләп «сүз иреге» дигән татлы канунга ышана башлады. Фәүзия Бәйрәмова «Казан утлары»на китергәнче «Караболак» романының өзекләрен анда-монда бастырып өлгергән иде. Шуңа күрә ул киң катлам укучыларга таныш, эчтәлеген иркенләп сөйләп торасы юк. Роман көрәшче Фәүзия каләме белән язылган. Чиләбе өлкәсендәге татар авыллары өстенә «Маяк» оешмасы атом реакторлары төзеп сынаулар үткәрә. Сынау дигәне шул—төрле шартлатулар, күпсанлы аварияләр, радиактив калдыклары белән мөлдерәмә тулган күлләр. Халык зур газаплар белән ярты гасыр буе кырыла. Ә Мәскәү аларның ыңгырашуын ишетми. Чиләбе өлкәсендәге авылларның фаҗигасе—татар халкына каршы үткәрелгән сәясәтнең эзлекле дәвамы дип әйтергә кыюлыгы житә авторның. Кыю язарлык хөррият килде, егетләр!

Хөррият ул—көрәш дигән сүз.

Проза—сугышчан жанр. Безнең язучылар берлегендә бер рота прозаик бар. Әбүнәчеләребез дә берәр дивизия чамасы булыр. Кыскасы, яңа үрләр яуларлык мөмкинлекләребез бар әле.

Талантлы язучылар талантлы укучылар кулына калсын, дигән догалы юллар белән Марсель Галиевнең 2005 елда чыккан «Рух» китабын кулга алдым. Депутат язучыларыбыз арасында гел кайнаша торгач Марсель Галиев тә чәчәкле-чуклы, калын-калын том-том китаплар чыгарырга өйрәнеп житте. Инжил форматында төпләнсә дә «Рух»—чын татар китабы. Аны бер утыруда гына укып чыгу һич мөмкин түгел, «Рух» еллар буе, кайтып-кайтып укый торган китап. Марсель Галиев кулына каләм алса—шундук рәсем ясый башлый. Аның «Рух»ын кулыңа алгач үзеңне сынлы сәнгать музееның портретлар экспозициясенә эләккән кебек хис итәсең. Шәхесләрне тасвирлаганда ул җете бизәкләр, урыны-урыны белән сарказмга әверелгән лирик юмор, бай мәгълүмат һәм сурәтләү чараларын кызганмыйча, тыгыз фикер туплап яза. «Рух»ның киштәдәге урыны Ибн Фазланның Иделгә сәяхәте турында язылган китап белән Татар энциклопедик сүзлеге уртасында булыр. Марсель Галиевнең «Рух»ына багышлап монографияләр язылыр әле, боерган булса.

Ярты сәгать эчендә сынар китап та укып булмаган кебек, ярты сәгатьлек чыгышка 2005 елда басылган чәчмә әсәрләр турында тулаем сөйләп өлгерү мөмкин түгел. М. Хуҗин, Т. Галиуллин, Р. Фәизов, Ә. Сәләх, Р. Вәлиев, Ф. Яхин, Рифә Рахман, К. Кәримов, Ә. Гаффарлар мине берүк гафу итсен... Вакыт ягы кысан. Аларның повесть һәм хикәяләре кайсы яктан килсәң дә камил. Чибәр кешегә шарж ясавы читен булган кебек, төзек әсәрләрнең дә уртага салып сөйләрлек проблемаларын табуы кыен.

Янарыш чорында, бер-бер артлы яңа матбагалар ачыла торгач, язучыларга эш артты, кызыклы язмаларны көтеп кенә торалар, кешесенә күрә, язганчы—алдан ук планлаштырып та куялар. Эшкә урнашасың килсә дә—хөррият, сәләтле авторны редакция колачын җәеп көтеп ала. Совет әдәбияты чорында газета йә журналга эшкә килгәнче синең биографияңне җиз иләк аркылы үткәрәләр, күрше-тирәңнән, элеккеге тормыш иптәшләреңнән белешмәләр алалар, теге-бу оешмалардан раслаталар, шуннан соң гына сина бирәр задание биреп карыйлар иде. Ифрат дәрәҗәдә кимсетә торган чаралар иде бу. Ә хәзер... һәр редакция, кирәкле авторларны читкә җибәрмичә, үзенә штатка алырга тырыша. Һәм контракт төзегән мөхәррир газета йә журналның «никахлы» авторына әверелә, бары тик ана гына тугры хезмәт итә. Ләкин проза жанры бер генә матбага рамкаларына сыешмый. «Идел» журналы мөхәррирләре Ркаил Зәйдулла белән Хәбир Ибраһим, «Салават күпере»нен Зиннур Хөснияр, Ләбиб Лерон, Вакыйф Нуриевлары, «Мәйдан»дагы Вахит Имамов белән Фирүзә Җамалетдинова, «Сөембикә»нен Марат Әмирханы һәм башка бик күп кенә авторлар «Казан утлары» журналының штаттан тыш авторы... Ә менә Нәбирә Гыйматдинова, унбиш ел инде, чын мәгънәсендә «Идел» кызына әверелде. Иң актив автор—үз хезмәткәрең дигәндәй, утыз еллык иҗади тәҗрибәсе булган Нәбирә Гыйматдинова яшьләр журналы укучылары белән бик җинел генә уртак тел тапты, ел саен повесть-хикәяләре, очерклары рәт араларын санга сукмыйча гына басыла килә. Кайвакыт ул: «Менә, яңа повесть тәгәлләп утырам, әбиз «Казан утлары»на була монысы!»—дип вәгъдә биреп өлгерә. Ләкин бер ай үтми, ул повесть «Идел»дә дөнья күреп өлгерә. Әйе, «Идел» төпсез, ул да юка журнал түгел. Читтән торып эшләүче көйсез авторларга заказ биреп, кыстый-кыстый яздырган арада, типографиягә бәйле график көне килеп җитә. Журнал үз вакытында чыксын өчен Нәбирә—«Идел»гә, «Идел» Нәбирәгә таяна.

2005 елның 10-11 саннарында басылып чыккан «Ачкыч» повесте белән Н. Гыйматдинова үзенең утыз еллык темасына тугры кала—үзәктә бәхет турында хыялланып, төрле мәҗараларга юлыккан көчле, әрсез һәм шул ук вакытта романтик рухлы хатын-кыз язмышы. Н. Гыйматдинованың һәр яңа әсәрендә нинди дә булса бердәр яңа рецепт ачыла һәм ул рецепт әсәр ахырына таба бәхет модуленә әверелә. Өч кешедән торган мәхәббәт башваткычын чишәр өчен (русчалатып әйтсәк «любовный треугольник») авторның героинялары кирәксә җинә, җинә алмаса җинелеп җинә һәм максатына ирешә. Н. Гыйматдинова үзенең укучыларын куллан ычкындырмый, аның әсәрләрен хатын-кызлар егылып укый һәм бәхетсез хатыннар автордан киңәш өметләнә, ә бәхетле ханымнар кулларындагы песнәкне очырып җибәрмәскә өйрәнә. Күпчелек укучыбыз, тамашачыбыз, әбүнәчебез һәм хәтта авторларыбыз да—хатын-кызлар. Нәбирә алар белән уртак тел тапты, бу—язучының төп уңышы, популярлык китергән кредосы. «Ачкыч» повестен автор «бәян» дип куя, чөнки анда тасвирланган вакыйгалар чынбарлыкка бик якын, әсәргә карата кызыксынуны көчәйтә. Матур киләчәкне ашыктырыр өчен бер генә көнгә татар буржуена сатылырга ниһаять ризалашкан Илсөяр язмышы шул тиклем җәлеп итә ки, укып чыкканда текстта очраган күпсанлы орфографик хаталар да кәефне генә күтәрә. Кыскасы, Н. Гыйматдинованың «Ачкыч»ы—уңышлы әсәр. Озакламас, әле моның буенча телевизион фильм да төшерерләр, чөнки бәян нигездә диалогларга корылган, мизансценалары да бер өй тирәсенә бәйләнгән.

Узган ел «Сөембикә» журналы хатын-кызлар гына булдыра алырлык зур батырлык эшләде: яңа хикәяләргә биш призлы конкурс игълан итте. Батырлык—призлар санында түгел, батырлык—әлеге конкурста ирләргә дә катнашырга рөхсәт ителде...

Нигездә, үз хезмәткәрләре кулыннан гына чыгарылып, күптәннән бирле «натураль хуҗалыкка» әверелгән Сөембикә журналына яңа исемнәр, яңа образлар

килеп керде. Конкурс—үзенә күрә бер уен инде ул. «Заман һәм шәхес» конкурсының уен кагыйдәсен «Сөембикә» кызлары үзләре төзеде. Нәтиҗә көтмәгәнчә уңышлы булып чыкты, егермеләп яңа хикәя дөнья күрде. Сер түгел, хикәя жанры һәрвакыт кытлык кичерде. «Казан утлары» журналының да хикәясез чыккан саннары байтак. Заман язучысы сюжетны хикәягә әрәм иткәнче—ул аны повесть итеп күпертә. Повестьның укучысы да, мәһере дә күбрәк, китапларга кертүе дә кызык.

Борынгы әдәби чыганаклар исбатлавынча, элек хатын-кыз Алыплар да сугышчылар сафында йөргән икән. Аларны без «Амазонкалар» дип тә беләбез... Әйтергә теләгәнем шул—Рәмзия Габделхакова, Фирүзә Жамалетдинова, Рифә Рахман кебек Алып бикәләребез «Заман һәм шәхес» конкурсына килгән мин-минле Марсель Галиевне, бурильщик Камил Кәримовны, һәм шкафтай Зиннур Хөсниярны алып кына аттылар! Хәер, хатын-кыз Алыпларыбыз барыбер дуамал Ркаил Зәйдулланы җинә алмадылар, ирләр үпкәли күрмәсен дигәндәй, пьедесталның өченче баскычына бастырдылар.

Сөембикә журналы искиткеч матур яңалык белән чыкты. 70-80 еллар дәвамында «Казан утлары» журналы «Ялкын» һәм «Яшь ленинчы» редакцияләре хикәяләр конкурсын бик еш үткәрә торган иде. Ниһаять бу онытылган традицияне хатын-кызлар журналы яңадан башлап җибәрде. Бәлкем инде әлеге башлангычка башка матбагалар да кушылыр, соңгы елларда очерклашып зәгыйфьләнә һәм юморлашып хәлсезләнә барган хикәяләр жанры яңадан терноәкләнеп китәр.

2005 елда басылып чыккан чәчмә әсәрләр турындагы вәгаземне түгәрәкләп шуны әйтергә телим: мин инде соңгы утыз ел эчендә Татарстан Язучылар союзы үткәргән әдәби чараларның барысында да диярлек катнашкан кеше. Иҗади ел йомгакларында, ачык һәм ябык партия җыелышларында, съездларыбызда элек-электән ачык сүз белән эчкерсез сөйләшү традицияләре бар иде. Чыгышымдагы җайсыз урыннарны гаеп эзләү дип түгел, ә иҗат лабораториябезнең көндәлек эше итеп кенә бәяләгез. Инде, әйтелгәннәрне йомгаклап, нәтиҗә ясарга да була:

Егерме ел буе гамәлгә кергән сүз иреге, фикер кыюлыгы, үткәнебезне яңача бәяләү—ниһаять татар язучысының иҗат рәвешенә әверелде.

Хроника, мәгълүмат, документальлек, вакыйгаларның төгәл географиясе һәм оперативлык белән мавыга торгач, чәчмә әсәрләр күп очракта публицистикага якынайды.

Проза әсәрләрендә тасвирлау дигән төп канун бозылып, ситуацияләрне сөйләп бирү өстенлек алды. Көндәлек тормышның кырыслыгы алгы планга чыкты, шуңа күрәдерме—сурәтләү чаралары көннән-көн ярлылана бара. Ә бу Матур әдәбиятның матурлыгын примитивлаштыра.

Чәчмә әсәрләр тирәсендә актив эшләүче әдибәләребез артканнан-арта. Монарчы ирләр профессиясе булып саналган прозабыз әкренләп кызлар кулына кала. Бу күренеш әдәби типлар, персонажлар һәм характерлар палитрасына яңа төсләр өстәрме, юкмы—анысын укый-укый күрербез...

Үткәнебезгә карата кызыксынуны киметмичә, архивларда күмелгән чынбарлыкны өйрәнеп, монарчы матбугатта күренмәгән чыганакларга таянып язылган тарихи әсәрләр күрәсе килә.

---

Ркаил
Зәйдулла

## Саркылган эңгернең шәүләсе

Былтыр матбугатта дөнья күргән шигырьләрне барлап чыкканда янә бер мәртәбә иске, күнегелгән хакыйкатькә ышанасың—татар шигъриятенең дилбегәсе һаман да әле өлкән шагыйрьләребез кулында икән! М. Әгъләм, Р. Әхмәтҗанов, Ш. Галиев, Р. Гаташ, Ф. Гыйззәтуллина, Зөлфәт, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, А. Хәлим, Б. Рәхимова,

Л. Шагыйрьҗан, Ф. Яруллиннарның шигъри бәйләмнәрен укыганда күңелдә сөенеч белән бергә сагыш та уяна. Бәлки бу хисне гомумиләштереп «якты сагыш» дип атарга кирәктер. Ярый әле алар бар! Шигырь дәртен җуймаган, галиҗәнаб шигъриятнең көченә ышанычларын яңа гасыр укучысына күчерергә тырышучы өлкәннәр... Матди, маргиналь мәнфәгатьләр алга чыккан заманда әлеге омтылыш үзе үк батырлыкка тиң ләбаса. Һәм алар үзләре дә бу хакта уйланалар, үз иҗатларының серенә төшенергә талпыналар булса кирәк. Нинди генә халәттә калса да, шагыйрь үзенчә өн салырга, үз авазын кешеләргә ишеттерергә тырыша. Хәтта тыңлаучы юкта да, кайберәүләр аркаларын борса да...

Юк, күңелне иҗат ялкыны ялмаганда эндәшми калып булмый! Чөнки, Фәнис ага Яруллин сүзләре белән әйткәндә:

*Йөрәкләргә килеп бәрелә дә*
*Әрнүләрдән туган бу тавыш—*
*Һич көтмәстән кайнар бөҗра булып*
*Тынны буа башлый бер сагыш.*

Ана Роберт абый Әхмәтҗановның җан авазы кушыла:

*Инде ачылып китсә дә Иҗатның офыклары,*
*Чүмечләп эчсә дә гөрләгән суларны,*
*Ятып чөмерергәдер болытлары белән—дәрьясын,—*
*Басалмыйдыр сусынын дөнья ярсулары?!*

Әлеге юлларны укыгач, Алла биргән сәләтнең һичнинди шартларда югалмавын уйлап куанасың. Р. Әхмәтҗанга хас колач киңлеге һаман шундый икән! Ялган, ясалма шигырьләрне укып арганда менә шундый шагыйрьләрнең әсәрләрен кулга алырга кирәк. Равил ага Фәйзуллин хак валлаһи!

*Туксанда да ялганның ул*
*суга ала яңагына.*
*Шагыйрьләр пыскый алмыйлар.*
*Шагыйрьләр—яна гына.*

Без—шагыйрьләр, шигырь язучылар—әлбәттә, поэзиянең һәм шагыйрьнең җәмгыятьтәге ролен кайвакытта кирәгеннән артык купайтырга да яратабыз. Шулай да милләтнең рухи халәтен, аның хис-омтылышларын, гамен белер өчен шигърияткә мөрәҗәгать итүдән дә кулай юл юк. Билгеле, әдәбиятның көчен, куәтен проза билгели, әмма поэзия, җиңел кавалерия кебек, «халык күңеле» дигән мәйданга алдан килеп керә, барасы юлны ачыклый. Дөрес, Мөдәррис Әгъләм дә хаклы:

*Шагыйрь шулай язган диеп кенә*
*Кыймылдамас кыл да.*
*Ахмак баш та кием киеп кенә*
*Килмәс ул акылга.*

Шуңа күрә, элеккерәк заманнардагы сыман, ниндидер роль, вазифа-фәләннәр турында сөйләп тору да кирәкмидер. Шигъриятнең халыкка ниндидер тәэсир итү көче турында да телгә аласы килми, безгә андый ялган иллюзияләрдән арынырга вакыт, мина калса. Поэзиянең ниндидер магистраль юллардан җилеп үткән чаклары узды. Хәзер шигырь кешенең күңел катламнарына үтеп кереп андагы төпкелләрдән хыял-өметләрне, үкенеч, сөенечләрне, сурәтле чаралар ярдәмендә көн күзенә чыгаруы белән кадерле. Ә кеше дигәнебез—иң беренче нәүбәттә автор үзе инде. Үзен-үзе таный алмаган, үз күңелен актара алмаган шагыйрь беркемгә дә кызыклы түгел.

Һәм гаҗәеп бер пародокс—үткән ел дөнья күргән шигырьләр, замананың бер төрле, соры булуына карамастан—форма ягыннан да, эчтәлеге җәһәтеннән дә

төрлеләр, кызыклылар. Биредә мин әлбәттә, узган ел татар поэзиясе яңа бер баскычка күтәрелде, дип әйтергә җыенмыйм. Әмма камиллек ягыннан, аерата сурәтләү чараларының җителеге ягыннан, шигъриятебезнең уңай якка үзгәрүе бәхәссез. Укып карагыз сез әдәбият мәйданына яңа гына аяк баскан кызларыбызның шигырьләрен—профессиональ югарылыкта язалар!

Шигырь укучылар кимегән саен оста шагыйрьләрнең күбәюе үзе үк тагын бер пародокс түгелме?

Хәер, шигырь үзе дә пародокслар җимеше инде ул.

Ләкин... Ләкин... Испан шагыйре Леон Фелипеның бер кыска шигыре күңелгә килә:

*Шигырьне сүзләргә таркатыгыз.*
*Кафия кыңгырауларын ташлагыз,*
*Ритмнан һәм вәзеннән,*
*Хәтта фикердән арыныгыз.*
*Һәм җилгә чәчегез сүзләрне.*
*Ни булса да калса шуннан соң,*
*Шул булыр менә*
*Шигърият.*

Кыскасы, шигырьне укыганнан соң күңелдә ниндидер халәт туарга тиеш. Шигъриятнең аңлатып булмас сере дә нәкъ менә шунда. Шул булмаса, әллә нинди катлаулы метафоралар да, искиткеч эпитетлар, ассонанс, аллитерацияләр дә шигырьне коткарып кала алмый.

Шул җәһәттән миңа, мәсәлән, Җ. Сөләйманның гап-гади бер шигыре тәэсир итте:

*Аллы-гөлле*
*Чигү чигә сылу—*
*...Күңелдә*
*чәчкә-гөлле болын.*

*Әби-карчык*
*Салмак кына*
*Йон эрли—*
*ә орчыкка*
*күңелдәге*
*эңгер урли.*

Шигырь ул, күрәсең, шат мәхәббәт чаткыларын чәчрәткәндә дә күңелдәге эңгернең дөньяга саркылган шәүләседер...

Ара-тирә гүзәл шигырьләргә очрыйм да, юләр кебек сөенәм. Ул гынамы—шушы ләззәттән коры калган акыллыларны кызганып көенәм әле. Әлбәттә, ул кызгануны үз эчемә яшерергә туры килә. Чөнки бер-беребезне дөрес аңламавыбыз бар. Чынлап «юләр» тамгасы ябыштырып куярга мөмкиннәр, билләһи. Хәер, алар болай да шигырь белән җенләнгән кешеләрне бик үк акыллыга санамыйлар инде. Безнең көннәрнең иң актуаль әйтеме колакта һаман чыңлап тора әле: «Если ты такой умный—почему бедный?»

Ләкин дөньяга карыйсың да аптырыйсың—ул акыллы байлар ил-көнне ни дәрәҗәгә төшерделәр соң? Ир балалар бандит булырга, кыз балалар элитный фахишә булырга хыяллана.

Элегрәк без әдәбиятыбызның чишмәләрен сугарып торучы авыл бар, дип куана идек. Кайтып карагыз авылга! Әби-бабайлар авызыннан бер канатлы сүз, борынгы әйтем ишетә алырсызмы? Иске көйгә көйләүче берәр картны очратырсызмы? Юк, алар телевизордан авыз суларын агызып, тәһарәт бозып, бетмәс-төкәнмәс сериаллар карыйлар. Бүген телевидение патша заманыннан да, советның, ялган интернационализм идеяләреннән дә көчлерәк булып чыкты. Ул иманы какшаган халкыбызны күз алдыбызда уптым-илаһи үз җәтмәсенә эләктерде.

Авылларда да татар теленен сафлыгы җуелды. Андый мохиттән яшь шагыйрьләрнең чыкмавы табигый хәл. Милләт деградациядә. Туксанынчы еллардагы өметләрнең юкка чыгуы, хыялларның пыран-заран килүен күрү шагыйрьнең йөрәген ничек әрнетмәсен! Йөрәк әрнегәндә нишлисең? Йә елыйсың, йә көләсең... Рөстәм Мингалим тикмәгә генә болай язмый: «Үкенү дә һәм елау да файдасыз инде, беләм. Шуна бүген мин—үземнән һәм... миндәйләрдән көләм».

Шигырь укучыларның кимүе турында без еш сөйләргә яратабыз. Ничек аларның саны артсын? Безнең мәктәпләрдә матур әдәбиятка мәхәббәт бөтенләй тәрбияләнми. Укытучыларның әзерлек мәсьәләсенә кагылып тормыйм, мәктәп дәреслекләренә генә игътибарны юнәлтәсем килә. Аларны төзүчеләрне кемнәр билгели икән? Нигә бу эштән язучыларның үзләрен читләштерәләр? Ул дәреслекләрне актарып чыгыгыз, алар бит әдәбиятка мәхәббәт уятмау гына түгел, анардан күңелне биздерәләр.

Мин әлбәттә, бөтен кеше дә әдәбиятка, шигъриятькә гашыйк булырга тиеш, дигән фикердән ерак торам. Беркайчан да халык шигырьне ябырылып укымаган, һәр кешедән шигырь укуны таләп итү ахмаклык булыр иде. Хәер, бу безгә янамый да—бездә шигырь укучыга караганда шигырь язучы күбрәк.

Шигъриятнең укылмавында, китапларның таралмавында, бәлки, шагыйрьләр үзләре гаепледер? Бәлки, без, Тукай әйткәнчә, искә «такмак» дигән сүз килеп төшүгә, абына-сөртенә шакмак эзләргә йөгерәбездер? Юк, алда әйткәнемчә, бүгенге шигъриятебез, Аллага шөкер, йөз кызартырлык түгел. Шигърият—әдәбиятның йөзек кашы ул. Бары шигъри атрибутлар гына—чагыштырулар, метафоралар, киная һәм, иң мөhиме, сыгылмалы тел—бүтән барлык жанрларның да әдәби кыйммәтен билгели.

Шигырь гүзәллеген күрергә сәләтсез, шигъри сүзгә битараф кеше бүтән жанрларда да уңышка ирешә алмый.

Әдәбият мәйданында үз сүзен әйтә алган зур шагыйрьнең пәйда булуы, күк йөзендә якты йолдыз калыкканы кебек үк, илаһи могҗиза ул. Узган елны без, минемчә, шундый могҗизаның шаһиты булдык. Габделнур Сәлимнең былтыр Татарстан китап нәшриятында «Итагать» дигән шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Әлбәттә, биредә аның турында җәелеп сөйләргә мөмкинлек юк, тик:

*Җир йөзе... бәй... зөбәрҗәт ич*
*сирпелгән ай яктысыннан!—*
*Ничек узыйм гүзәллектән?!—*
*юк, узарга яхшысынмам:*
*Кар—бер яшел, кар—бер зәңгәр;*
*бер тына, бер алышына...—*

дигән шигырь юлларын искә төшереп, әлеге гүзәл китапны читләтеп узарга яхшысынмасак иде. Шигърият күгендә балкыган барлык төсләр дә бар анда!

Турысын әйтергә кирәк, шигъриятнең дәрәҗәсен, кимәлен бик аз шагыйрьләр генә билгели. Тик әле бу дистәләгән шагыйрьләрнең хезмәтен инкарь итү түгел. Нәкъ менә алар озын-озак еллар дәвамында, энә белән кое казыгандай, салына торган шигърият сараена акрынлап таш ташыйлар.

Сарай өскә күтәрелә, ә кое төбендә гүя шигъри энҗеләр җемелдәп ала...

Шигъриятебезнең үзенчәлегенә әверелгән бер сыйфат узган ел дөнья күргән шигъри әсәрләргә дә хас. Милләтнең тарихын барларга омтылу, ачы язмышыбызга ишарәләр ул. Мондый төр шигырьләр укучының милли үзаңын уятуда шактый зур роль уйный. Әлбәттә, алар арасында декларатив характердагылар да күп очрый. Әмма А. Хәлим, Зөлфәт, М. Әгъләм, З. Мансуров, Г. Морат, И. Гыйләҗевләргә хас югары шигъри техника, шигъри сүзне бер төенгә бәйләп торган сагышлы моң, буыннан буынга кан аша күчеп килгән югалту ачысы, гыйбарәләрне бер организмга җыеп торган нәзберек кабырчык аша нечкә тамырлар тибешен тою сөенече, шигырь тәмен тоя белгән беркемне дә битараф калдыра алмыйлыр. Керфеккә эленгән тамчыга дөнья сыя... Шагыйрьнең кодрәте нәкъ шунда түгелмени?

Соңгы елларда шагыйрьләребезнең шәрекъ шигъриятe биләмәләренә кайтуы

сөендерә. Югыйсә, Кандалыйларның, Тукайларның җан сыкравыннан тернәкләнгән татар шигърияте төрле төсләргә кереп балкыган шәрекъ дөньясының аерылгысыз өлеше бит. Һәм әлеге күренмәс җепләрнең беркайчан да өзелгәне юк.

Менә, ниһаять, хәзерге шагыйрьләрнең дә газәлләрен, робагыйларын уку бәхетенә ирештек. Бу җәһәттән Рәдиф Гаташның исемен аерып әйтәсем килә. Дөрес, аның иҗатыннан хәбәрдар кеше, Р. Гаташның шәрекъ әдәбиятына беркайчан да битараф булмавын искәрер. Ләкин татар кояшының чыгышын гел көнбатыш яктан гына көткән заманда, ә шәрекънең томаналыгын көн саен сүгеп торганда, әлбәттә, татар шагыйрьләренең күзе Аурупага, Америкага төбәлгән булуын анларга мөмкин. Р. Фәйзуллиннарга, Р. Харисларга йогынты ясаган Назыйм Хикмәтне, мөгаен, чын шәрекъ шагыйре дип атап булмыйдыр.

Хәер, шигъриятне Көнчыгышныкына яки Көнбатышныкына бүлү миңа бераз урынсызрак та булып тоела. Есенин шәрекъ шагыйреме, гарепнекеме? Ә Гете? Гомәр Хәйям әлегә кадәр Көнбатышта иң күп укыла торган шагыйрь түгелмени!

Бөтен шагыйрьләр дә бер кавемнән. Хыял иленнән! Шагыйрьнең кояшы Көнбатышта калкып, Көнчыгышта баерга да мөмкин.

Соңгы елларда Мөхәммәт Мирзаның да газәл, робагыйлары шигырь сөючеләрнең дикъкатен җәлеп итте. Мең еллар сыналган вәзендә иҗат итәргә омтылу үзе үк хуплауга лаек гамәл. Ләкин биредә традицион алымнарны гына кулланырга кирәк түгелдер. Югыйсә, кайчакта Мирза әсәрләрендә дидактик төсмерләр өстенлек алып куя.

Бу җәһәттән Туфан Миңнуллин робагыйлары бөтенләй аерылып тора. Борынгы кысалардан чыкмый гына ул юморны да мул куллана, аз гына хулиганлык та бар аңарда... Күңелгә кайчак көфер уй да килә: әллә Туфан агай шушы робагыйлары белән татар әдәбияты тарихына кереп калырмы? Беләм, ул иҗатының бу ягын бик җитдигә дә санап бетерми бугай, «хобби» гына дип күрсәтергә тырыша. Хәер, Г. Хәйям да үзенең үлмәс робагыйларын шаярып кына гыйльми трактатларының читенә язган бит.

> *Карале син, күр син теге Сылузатны—*
> *Түш киереп атлаулары ничек татлы...*
> *Хуш, картлыгым! Мин ияреп киттем аңа,*
> *Без бит әле, ни әйтсәң дә, Туфан атлы.*

Нигәдер әлеге робагыйда телгә алынган Сылузатны мин Шигърият итеп күз алдына китердем. Туфан агайның, мәшһүр адашы: «Әнкәбез Әдәбият, һәрберебезнең сөйгән яры Поэзия»,—дип әйтергә ярата иде бит. Икенче Туфанны да, картлыгын оныттырып, үз артыннан ияртә алган икән, Сылузат дими ни дисең инде аңа?

Әлбәттә, ир-ат шагыйрьләрнең Поэзияне сөйгән ярга охшатуын хатын-кызларыбыз гаеп итмәсен. Шагыйрәләр бөтенләй яңа образны, яңа сурәтне күзалларга мөмкин. Мөмкин генә түгел, тиеш тә. Чөнки шагыйрә поэзиягә Сылузат дип мөрәҗәгать итсә, бөтенләй бүтән ассоциацияләрнең тууы бар...

Хәлбуки, хатын-кыз шагыйрьләребезнең авазы татар шигъриятендә үзләренә генә хас аһәңнәр белән яңгырый. Л. Шагыйрьҗан, Э. Шәрифуллина, Н. Сафина, Б. Рәхимова, Х. Мөдәррисова, Иделбикә, Ф. Зыятдинова, Ш. Җиһангирова, Ф. Мөслимова, Ф. Тарханова, Р. Рахман, И. Иксанова, Р. Вәлиеваларның шигырьләрен бер-берсе белән дә, ир-атлар иҗаты белән дә бутау мөмкин түгел.

Соңгы елларда каләм тибрәтүче яшьләрнең барысы да диярлек кызлар. Моңа кайберәүләр кайчак борчылып та куя. Миңа калса, моңа борчылырга түгел, сөенергә генә кирәк. Дөнья әдәби тарихыннан беләбез—шигърият тирәсендә һәр заманда да алар күп булган. Беренче мәхәббәт очкыннары, табигый ки, шигырь учагын кабызучан. Урыс шагыйре Юрий Кузнецовның гыйбрәтле сүзләре бар: «Женщина, когда пишет, смотрит на мужчину, а мужчина—на Бога».

Әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр һәм шагыйрьләр үзләре дә хатын-кыз язучыларның иҗатына туры бәяне бирүдән тайчаналар. Җыелышларда, телмәрләрдә, мәкаләләрдә хатын-кызлар шигъриятенә аерым тукталу, бәя биргәндә «Хатын-

кызларга хас нәфислек белән» дигән гыйбарәне даими куллану, аларның иҗатына, әлбәттә, ташлама ясау билгесе. Беркемгә дә сер түгел, Гете, Пушкин, Блок кебек шагыйрьләр хатын-кыз шигъриятенә көлемсерәп караганнар.

Мин фәкыйрь дә, моннан унбиш еллар элгәре, бер җыелышта: «Табигатьтә ата сандугачлар гына сайрый»,—дип белдереп, хатын-кызларыбызның ачуын китергән идем.

Табигать белән бәхәскә керү җүнлегә илтми. Ин әүвәл шигърият тә, сандугач сайравы кебек үк, сөйгән кызның йөрәген яулау өчен янгыраган. Ләкин бүген кем генә шигырь белән хатын-кызның күнелен аулый икән? Сөйгәненең балкон төбендә төннәр буе серенада җырлап торган кавалерны кайда күргәнегез бар? Шигърияткә хәзер егетләрнең килмәвен йәисә аз килүен, бәлки, шул үзгәрешләр белән аңлатып буладыр?

Хатын-кыз сандугачларның сайрый башлавы табигый.

Л. Янсуар, Л. Гыйбадуллина, Г. Корбанова, Г. Вәлиева, Ф. Солтан һәм башка кызларыбызның шигырьләрен укыгач, сөенми мөмкин түгел. Нәкъ Рәдиф Гаташ язганча: «Табигатьнең үзе тудырган эчкерсез, саф сулышлы, курай тавышы кебек садә, ә кайчакта заманыбыз кебек көтелмәгән борылышлар, аһәннәр белән сискәндерүче ихлас, якты авазлар».

Күрәсең, татарның Ватанын, сабыйларның телен һәм шигъриятне бары тик хатын-кызлар гына коткарып калачак заманалар тагын житте...

Шигърият турында сөйләгәндә кайчандыр аның алтын баганасы булган поэманы читләтеп үтәргә ярамастыр. Поэманың нинди булырга тиешлеге турында, әлбәттә, күп язылган. Әмма шигърият тарихына, монарчы иҗат ителгән күпсанлы поэмаларга күз салсаң, бер нәрсәгә ышанасың—аларның яшәеш куәте әдәби образларда, чор сулышын әдәби персонажлар аша әсәрнең тукымасына сеңдерүдә. Чыннан да, үткән гасырда иҗат ителгән билгеле поэмаларны искә төшерүгә үк күз алдына үзләренең кабатланмас холыклары, йөз чалымнары белән Карәхмәтләр, Алсулар, Мокамайлар, Хабуллар, Минаплар килмимени? Билгеле, нинлидер сюжет сызыгын алып, берәр вакыйганы шигъри калыпта сөйләп чыгу турында сүз бармый. Прозада яисә мәкаләдә әйтәсе фикерне, сөйләнәсе вакыйганы тезмәдә калыплап чыгу—ул поэзиядә гайре табигый эш. Гомумән, монда төгәл рецептлар юк, һәр әсәрнең бәһасе, мәгълүм ки, аны язган кешенең күңел биеклегенә тәңгәл.

Былтыр «Казан утлары»нда ике поэма дөнья күргән. Ә. Рәшитовның «Казан» һәм Р. Гарифуллинаның «Ак сарайда серләр бар» поэмалары. Икесе дә тарих белән бәйле, тарихи экскурсларга бай. Әхмәт абзыйның әсәре, башкалабызның 1000 еллыгына багышланган. Өлкән шагыйрьнең әлеге тантанага үз өлешен кертергә омтылуы хуплауга лаек, әлбәттә. Аңарчы да ул тарихи поэмалар язды. Әлеге әсәре дә шул сериалны дәвам итә, дип әйтергә мөмкин. Әмма, гадәттәгечә, сериалны дәвам иткәндә, соңгы серияләр гел сыеклана бара. «Казан» поэмасында автор бик тапталган юлдан киткән. Шул ук Мөхәммәдьярлар, Кол Шәрифләрне сагыну, Шаһгалиләрне сүгү... Урыс белән үзара мөнәсәбәтләргә кагылганда исә автор бик наив сентенцияләр чыгара:

*Тигезли замана һәммәсен—*
*Ул кая барасын белгәндер;*
*Буталып, болганып бетсәк тә,*
*Канунда син дә бер, мин дә бер—*
*Язмышлар уртак һәм бердәнбер.*

Һәм, әлбәттә, поэма бик пафослы язылган. Хәер, шундый зур бәйрәмгә арналган әсәрдә пафоссыз булмыйдыр инде:

*Ә без бар...*
*Булырбыз...*
*Барабыз*
*Төз атлап Сәйдәшев маршына,*
*Өченче мең еллык каршына.*

Әхмәт абзыйга, 70 яшен тутырган көннәрдә, исәнлек-саулык теләп, тагын байтак еллар шул маршка төз атлавын телисе генә кала.

Р.Гарифуллинаның әсәре шактый уңышлы язылган. Бүгенге көнне ул тарих белән бәйле белә. Хәер, бу табигый дә, поэманың кереш сүзенә ышансаң, Рәсимәнең нәселе Бирдебәк ханга барып тоташа икән, торган йортлары да хан сарае нигезендә, имеш. Шундый затлы токымнан булуына карамастан, Рәсимәгә, барыбер шигырь техникасына игътибар итәсе бар әле. Һәм, әлбәттә, ана поэма язарга омтылучыларга хас бер сыйфат, дөресрәге, сыйфатсызлык хас, ул сөйләп чыгу, ягъни урысча әйткәндә, пересказ белән мавыга, шуңа да аңарда фигыльләр бик еш рифмалаша.

Елның иң уңышлы поэмасы, дип, мин Рәниф Шәриповның «Азатлык көне» әсәрен атар идем. Ул «Идел» журналында дөнья күрде. Бередә дә, Әхмәт абзый әсәрендәге кебек, барасы юллар турында уйланыла. Әмма ул юлны фаразлау нинди!

*Балкыш булып бер күренде безгә*
*Дәүләт нуры әллә кайдагы.*
*Юлда булыйк.*
*Юл үтелә, барсаң,*
*Көтә безне Ирек мәйданы.*

Яисә:

*Ә без бәйдә... Инде нишләсе?*
*Без бәйләнгән бауның бер очында*
*Көйрәп ята дары мичкәсе.*

Гомумән, Р. Шәриповның иҗаты елдан-ел ныгый, камилләшә бара. Быелтыр аның «Мәңгелек сер» дигән китабы да чыкты. Әмма мин биредә китапларга бәһа бирергә җыенмыйм. Чөнки, гадәттә, китаплар күп еллык хезмәтне хасил итәләр. Аларның кайберләре турында зур итеп аерым язарга кирәк. Шундыйлар рәтенә мин Г. Моратның «Төнге әверелеш», Х.Әюпнең «Йөз яктысы" җыентыкларын кертер идем.

Шактый оптимистик чыгышымны Франц Кафканың бер фикере белән тәмамлыйсым килә: «Аз санлы милләтнең хәтере бөек милләтнекеннән сайрак түгел,—дип яза ул.—Шуңа күрә ул булган рухи байлыкны җинелрәк үзләштерә. Дөрес, аларда әдәбият тарихчылары азрак, әмма әдәбият—әдәбият тарихы булудан бигрәк, бөтен халык эше һәм шуңа күрә ул, камил рәвештә үк булмаса да, биредә ышанычлы саклана. Чөнки аз санлы халыкның милли аңы һәр кешедә әдәбиятның аңа тигән өлешен белүне, яклауны таләп итә. Ул гына да түгел, хәтта әдәбиятны белмәгән һәм аннан ерак кеше дә кирәк очракта аны якларга мәҗбүр була».

Бөек язучының әлеге фикерен Президентыбызның бу елны «Әдәбият һәм сәнгать елы» дип игълан итүе дә раслап тора шикелле.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Алпар

Атамаларына «алпар» берәмлеге катнашкан авыллар Әлки районында урнашкан. Иске Алпар район үзәге Әлкидән 19, Яңа Алпар — 18 чакрымда урнашкан.

Е. И. Чернышев мәгълүматларына күрә, Алпар авылының Казан ханлыгы чорында ук булганлыгы мәгълүм. Атама шулай ук башка тарихи хезмәтләрдә һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш очрый.

1859 елга Иске Алпарның 108 йортында 389 ир-ат һәм 401 хатын-кыз яшәгән, мәчет булган. Яңа Алпар авылының 96 хуҗалыгында 326 ир-ат һәм 308 хатын-кыз исәпләнгән, мәчет эшләгән. 1878 елның 4 ноябрендә Казан губернаторы Н. Я. Скарятин эчке эшләр министры А. Е. Тимашевка Иске Алпар, Яңа Алпар, Иске Үргәгар, Яңа Үргәгар авылларында чыккан чуалышлар турында хәбәр итә. Авыл халкы янгыннан саклану максатыннан авыл корылмаларын страховать итү өчен төзелгән исемлекне тыңлагач, тавышлана башлый. Халык аны чукындыру өчен төзелгән исемлек дип кабул итә.

Алпар атамасы ни аңлата соң?

Күренекле тюрколог С. Е. Малов үзенең бер хезмәтендә alp «батыр, герой» сүзенә Күл Тәгин истәлегендә ныгып калган Alpar исемен мисал итеп ала. Борынгы төрки телдә ar (ер-ир) сүзе «ир» төшенчәсен аңлаткан. Алпар исеме «батыр ир» мәгънәсенә ия.

Әлки районындагы әлеге авылны батыр ир — Алпар исемле кеше нигезләгән.

Төрки халыкларның шактыенда, шул исәптән татарларда да дастан яки әкият герое сыйфатында очраган Алпамыш исеме дә шушы ук ояга керә. Татар теленең Минзәлә сөйләшендә алпамыш сүзе әле бүген дә «алап, зур гәүдәле кеше, көчле, батыр», алапа- «зур, таза гәүдәле кеше, озын буйлы кеше» төшенчәсен аңлата.

Алпар белән Алпамыш исемнәренә борынгы хикәятләр каһарманы Алып тамырдаш. Алып гаять зур гәүдәле, көчле шәхес итеп күрсәтелә. Татарлар арасында кечерәк тауҗыкларны, калку җирләрне «Алып бабай чабатасын каккан җир» дип йөртәләр. Алып шулкадәр зур гәүдәле һәм көчле булган ки, ул ял итәргә утырып чабатасын какканда, хәтта кечерәк таулар да барлыкка килгән, имеш. Мондый тауҗыклар борынгырак дип исәпләнгән шактый күп татар авыллары янында бар. Татар фольклорында Алыпка мөнәсәбәтле легенда һәм риваятьләр дә шактый. Мәсәлән, «Зур гәүдәле кеше», «Дәфгый һәм аның сеңлесе», «Болгар пәһлеваны» h. б.

«Болгар пәһлеваны» дип аталган риваятьтә мондый вакыйга сурәтләнә. Дәхи Болгар җирендә мин бер зур кеше күрдем. Ул кеше һуд (легендар пәйгамбәрләр) нәселеннән, имеш. Бу кешенең буе җиде зираг (терсәк кадәрле, ягъни 58 см. чамасы) кадәрле иде. Үзе Болгар патшасының хезмәтендә иде.

Патша аны үзенә якын кылган һәм аңа сугыш киеме вә олут казан мисалында сугыш бүреге ясаткан. Аны сугышка арба белән алып баралар, чөнки аны йөкләргә тәвәнең көче җитмидер. Җәяү йөреп мәшәкатьләнмәс өчен, ул сугышта да арба белән

йөри. Җәяүле кешеләрне ул кулындагы озын таягы белән үтерә. Ул таякны күтәрергә һич кешенең көче җитмидер. Әмма аның кулында ул безнең кулыбыздагы бер кечкенә таяк мисалында гынадыр. Төрекләр аны күргәч һәм, ул каршы килсә, җиңеләләр. Үзе, шулай булса да, күркәм сыйфатлы, холкы вә фигыле дә яхшы».

Хәкимҗан Халиковның «Ялгыз нарат» исемле шигырендә ялгыз нарат Алып батыр белән чагыштырыла:

*Калку кырда бер нарат бар,*
*Ямь-яшел чатыр сыман.*
*Давылга да бирешми ул,*
*Нәкъ Алып батыр сыман.*

Татар теленең кайбер сөйләмнәрендә, аерым алганда урта диалектның Дөбьяз урынчалыгында зур гәүдәле, зур аяклы кешене алап кебек зур дип йөртәләр. Буе, аягы зур булса «бу кеше алап кебек», «бу кешенең аягы алап аяк икән» дип чагыштыралар.

Алпар авылы кайчан оешкан?

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, ул XV гасыр ахырында – XVI йөз башында оешкан булырга тиеш. Аны Алпар исемле кеше нигезләгән. Алпарны морза булган дип тә әйтәләр. Безгә күп мәгълүматлар биргән Гаязетдин улы Исмәгыйль абый үз нәсел шәҗәрәсенең Алпар бабайга барып тоташуын күрсәтте: Алпар – Әмири – Мөслим – Мөрсәлим – Мөстәкыйм – Зәйнабит – Абит – Камалетдин – Гаязетдин – Исмәгыйль.

Алпар авылында тагын мөкән нәселе дә бар. Аның вәкиле – Сибаев Кадыйр. Моннан башка авылда тагын татарлашкан мукшы, мари һәм чуваш нәселләре дә яши. Мукшыдан татарга чыгучылар калкурак гәүдәле, нигездә алар Яңа Алпарда урнашкан. Маридан татарлашучылар ваграк, карсаграк, ач яңаклы, кечерәк күзле. Татарлашкан чувашлар да гәүдәгә артык зур түгел. Чуваш, мари һәм мукшылар бирегә Тау ягыннан килгәннәр.

Авылдагы һәм аның тирә-юнендәге географик берәмлек атамалары әлеге фикерне раслый.

Авылда бер урам Чуваш урамы дип йөртелә. Ул урамда элек чуваш, мари (чирмеш), мордва (мукшы) халыклары яшәгән.

Алпар бабай килеп утырганда, бу тирәләр шау урман булган. Анда каен, имән, талтирәк агачлары үскән. Агачлар арасында төрле җанварлар, киек кошлар яшәгән. Кайчандыр бу урында калын кара урман үсүен Каенсар, Имәнсар сазлыклары, Азанча, Пәҗи, Кәсәми, Олы алан, Кече алан һ. б. атамалары күрсәтеп тора. Ике тирәк дип йөртелгән урын да бар. Анда элекке урманнан ике зур тирәк кенә утырып калган. Ялгыз яки куш тирәкле урыннар халык тарафыннан изге урыннар дип таныла. Моның шулай икәнлеген халык хәтерендә сакланып калган легенда-риваятьләр раслый. Тирәк агачлары белән бәйләнешле изгеләр турындагы легенданы Казан шәһәрендә Нәгыймә Мәһдиевадан 1977 елда Марсель Әхмәтҗанов язып алган. «Иван Грозный Казанны алган вакытта җиде кыз, шәһәр кырыена килеп, һөҗүм итүчеләрне каргап торганнар. Шәһәрне ала алмый торуларына ачулары чыккан сугышчылар аларны куа башлаганнар. Кызлар хәзерге татар зираты кырындагы Өч Тирәк (Казанның Яңа бистә зиратында үсеп утырган өч тирәк агачлары янында җиде кыз каберлеге бар. Халык арасында ул изге исәпләнә) дигән җиргә җиткәч, җир ачылып, аларны үзенә алган. Шуңа күрә бу урын халык арасында изге дип санала.

Иске Алпар авылы янында Иске йорт дигән урын бар. Авыл беренче башлап шушында оешкан, ләкин соңыннан аерым сәбәпләр аркасында хәзерге урынына күченгән. Бу урында табигать бай. Авыл тирәсендә елга-күлләр, тау-калкулыклар, сазлыклар шактый. Бәгыйль, Бирге баткалак, Аргы баткалак, Каршы каенлык, Акчарлак, Кабак, Фидыр (рус исеме Федор), Болан, Мүкле сазлар авылны чолгап алганнар. Мәүләшә, Кизләү, Утар, Әлмүшкә инешләренең суы әлләни мул булмаса да, халыкка хуҗалык алып бару өчен ифрат дәрәҗәдә кирәкле. Түгәрәк, Кара, Яслә күле буйлары – халыкның яраткан урыннары. Иске йорт тау башы, Кизләү, Көрән таулары – Алпар халкына табигать биргән бүләк.

Иске Алпар авылында 300 ләп хуҗалык бар. Иске Алпар белән Яңа Алпар арасында 3 катлы урта мәктәп урнашкан. Анда тагын тарих музее, мәдәният йорты, китапханә, мәчет, кибет эшли.

## Әлдермеш

Әлдермеш авылы Биектау районында, район үзәге (тимер юл станциясе) Биектаудан – 12, Казаннан 22 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы Казан ханлыгы чоры авыллары исемендә күрсәтелгән. Казан өязенең теркәү кенәгәсендә (1602 – 1603 еллар) авыл еш телгә алына, анда йомышлы һәм ясаклы татарлар яшәгәнлеге әйтелә. Эпиграфист – галим Һарун Йосыпов Әлдермеш авылы зиратында XVI йөзнең беренче яртысында куелган кабер ташлары таба. 1646 ел 30 май числосы белән авыл атамасы И. П. Ермолаев төзегән тарихи хезмәттә күрсәтелә. XVIII йөзгә нисбәтле тарихи чыганактан күренгәнчә, Әлдермеш авылында 137 йомышлы, 46 ясаклы татар яшәгән. А. Артемьев Әлдермеш турында мондый мәгълүмат бирә. «Авылдагы 139 хуҗалыкта 581 ир-ат һәм 580 хатын-кыз көн иткән, бер мәчет эшләгән. Мишаевка (Кече Әлдермеш) авылындагы 30 йортта 44 ир-ат һәм 46 хатын-кыз яшәгән». Олы Әлдермеш һәм Кече Әлдермеш авыллары турында Н. Н. Вечеслав түбәндәгеләрне яза: «Олы Әлдермеш авылындагы 153 хуҗалыкта 507 ир-ат һәм 474 хатын-кыз яшәгән, алар Олы Әлдермеш авылы җәмгыятенә кергәннәр. Авылда бер агач мәчет, мәктәп, су тегермәне, кабак һәм 3 җил тегермәне булган. Кече Әлдермеш авылындагы 50 хуҗалыкта 187 ир-ат һәм 174 хатын-кыз көн иткән, алар Кече Әлдермеш авылы җәмгыятен төзегәннәр. Авылда бер агач мәчет булган». Олы Әлдермеш һәм Кече Әлдермеш авыллары турында И. А. Износков хезмәтендә түбәндәге мәгълүматлар бар. «Сая суы янына, Уржум сәүдә юлына урнашкан Олы Әлдермеш авылының икенче исеме – Әлдермеш-Казаклы (Лашман). Андагы 155 хуҗалыкта ислам дине тотучы 498 ир-ат һәм 537 хатын-кыз яшәгән, алар Олы Әлдермеш авылы җәмгыятенә кергәннәр. Тормыш-көнкүрешләре уртача булган, тегермәнчелек, тимерчелек, умартачылык белән шөгыльләнгәннәр. Кече Әлдермешнең Әлдермеш – Ясаклы дип аталуы искәртелә. Авылдагы 53 хуҗалыкта ислам дине тотып яшәүче 190 ир-ат һәм 186 хатын-кыз исәпләнгән, алар Кече Әлдермеш авылы җәмгыятенә кергәннәр. Тормыш-көнкүрешләре уртача булган, тегү теккәннәр, чабата үргәннәр, пыяла куйганнар һәм умартачылык белән шөгыльләнгәннәр.

Авыл атамасы Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мостәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән китабында, Мелла Хәмид бине Мортаза бине Нурмөхәммәд әл-Казани әл-Әлдермеши исемле кешене сыйфатлаганда искә алына. Бу шәхес заманының укымышлы кешеләреннән белем ала. Уйлап эш итүе, уйлап сөйләшә белүе белән мәшһүр була. Руслар хакимлеге чорында Казан шәһәрендә мөселманнарга башлангыч белем бирү һәм мәдрәсәләр ачу турында беренче булып шушы кеше сорап йөргән дигән фикер бар. Ул Казан шәһәренең Яңа Бистәсендәге Урта мәчеттә мелла Мәхмүдкә ярдәмче имам була.

Әлдермеш авылында мәдрәсә XVIII йөздә ачыла. Әлегә кадәр сакланып калган мәчет 1899 елда салынган. Ул 1832 елда салынган мәчетне алыштырган. Мәхәлләдә 533 ир-ат исәпләнгән.

1896 елның 10 маеннан дини эшләрне алып бару Габдулла Габдрахман улы Сәлимовка йөкләнә (1872 елда туган). Ул мәхәллә мәдрәсәсе җитәкчесе дә була. Мәдрәсәдә XX йөз башында 72 ир бала һәм 57 кыз бала укыган.

Әлдермеш халкы Дөбъяз, Зур Солабаш, Кече Солабаш, Чыршы, Тарышна, Суксу, Кондырлы, Өбрә, Абла авыллары халкы белән бергәләшеп Биектау җыенын бәйрәм иткән.

Әлдермеш атамасы ни аңлата?

Авыл атамасының килеп чыгышы Казан феодалы Галидәрвиш исеме белән бәйләнешле. Хәзер Дәрвишләр бистәсе (русча Дербышки) дип йөртелгән бистә исеме дә шушы феодал исеменә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән.

Әлдермеш авылы Сая суы буена утырган. Авыл янынннан олы юл уза. Шунда автобус,

машина көтә торган урынны Лашман дип атыйлар. Сугышка кадәр һәм сугыштан соң да берничә ел буена авылның ике ягы арасында, елга буенда Мишавка дигән рус авылы булган. Сугыштан соңгы авыр елларда руслар күчеп киткәннәр. Ул авыл урынын халык хәзер Мишәүкә дип йөри. Мишәүкә авылының бер очында, тау башында Сидор исемле рус торган. Тау итәгеннән чыккан чишмәне Сидеркә чишмәсе дип йөртәләр (русча Сидор сүзеннән). Авылдан 1 чакрым тирәсе ераклыкта Мишәүкә авылының зираты бар (рус зираты).

Авыл белән янәшә генә печән чаба торган урын бар. Аны Дегетле баз дип атыйлар. Олылар әйтүе буенча, элек анда дегет кайнатканнар. Авылдан чыгып күрше Кавал авылына барган юлда Каенлы саз дигән урын кала.

Авылның табигате матур. Куян оясы, Тора, Сидеркә, Дегетле баз һәм башка ермакелгалар суларын (аз гына булса да) Сая инешенә коялар. Басуда Каенлы саз күле, Раскалан, Күперле тау, Караңгылык, Бакалы, Үрмәт һ. б. болыннар бар. Әлдермештә Чирмеш зираты, Әүлия кабере, Изгеләр зираты, Изгеләр чишмәсе, Әкәй алачыгы дип аталган урыннар билгеле. Алар авылның тарихын искә төшереп торалар.

Авылда урта мәктәп, китапханә, балалар бакчасы, мәдәният йорты, медпункт, кибетләр эшли.

Халык үзәкләштерелгән газ яга, юллар асфальтланган.

Авылда мәчет торгызылган. Халык авыл янындагы зиратны карап, тәрбияләп тора. Зираттагы хәлне, тәртипне күзәтеп тору өчен махсус кешеләр билгеләнгән. Елга бер көн (җәй көнендә) бөтен авыл ирләре зират чистартырга баралар.

Авылдагы караучысыз олы кешеләр халыкның игътибар үзәгендә.

Халык авыл урамнарының элекке исемнәрен куллана. Югары урам, Түбән урам, Дамба урамы, Арт урам. Авылның кече ягын Аръяк, Ясаклы дип йөртәләр.

Авыл халкының тормышы җитү. Йортлары һәм башка каралты-куралары яңа һәм матур. Яшьләр авылда калырга тырыша. Авылда иманлы, мәгънәле, эшчән һәм булган халык яши.

Халык арасында кулланылган кушаматларның иң үзенчәлекләре: кебәш, кертеки, әпәс, очлы, бокый, кумерче, галдый, пәпә, мамаш, бәйтән, кытыкый, кәлкә, кәчәм, пети, абатый, һава, төпи, касан, кәтән, күкерт, нәтешкән, таракан, чәлти, дәүбаш.

*Дәвамы киләсе саннарда*



***—Иң элек Сезне, Татарстаннан бер вәкил буларак, Россия Федерациясенең җәмәгать Палатасына сайлануыгыз белән котлыйбыз! Иҗтимагый яктан дәрәҗәсе югары булган андый оешмалар тарихта билгеле. Бүгенге Россия өчен яңа күренеш. Әлеге Палата нинди рәк эшчәнлек белән шөгыльләнә яки шөгыльләнәчәк? Аерым алганда, әлеге зур трибунадан Татарстаныбыз мәнфәгатьләрен яклау, милли мәсьәләләрне гадел хәл итү мөмкинлекләре бармы?***

**Роза Рәхмәтулла кызы ТУФИТУЛОВА,** *РФның Җәмәгать Палатасы әгъзасы:*

—Бүгенге Франциядә вәкаләтле андый палата инде утыз еллап диярлек эшләп килә. Мондый иҗтимагый эшчәнлек кайбер Европа илләрендә дә әйбәт үсеш алган. Оештыру эшләрен башлаганда Россиянең әнә шулар тәҗрибәсенә таянуы бер дә гаҗәп түгел.

Җәмгыять сулышын тоеп яшәү, гомумкешелек кыйммәтләре өчен көрәш, законнарны камилләштерү— Палатаның тоткан юлын, мәслəген берничә сүз белән әнә шулай аңлатырга мөмкин. Мин аны хакимиятнең халыкчан бер тармагы дияр идем. Законнар халыкка хезмәт итәме, әллә чиновникларгамы? Без әйтәбез: халыкка хезмәт итсен, халык мәнфәгатьләрен кайгыртсын! Дәүләт исә законнарны тайпылышсыз үтәргә бурычлы.

Безнең төп эшчәнлек (функция)—Россия Дәүләт Думасында каралачак закон проектларын өйрәнү, анализлау, бәя бирү, кабул ителгәннән соң аларның үтәлешен тикшерү. Палата составында барлыгы 17 комиссия эшли. Шәхсән, мин үзем мәдәни һәм рухи мирасны саклау комиссиясен сайладым. Россия Федерациясендә яшәүче халыкларның мәдәни-рухи мирасын саклап калу турындагы федераль законнарга үзгәрешләр, өстәмәләр кертүне игътибар үзәгенә куябыз. Байтак кына тәкъдимнәрне без инде эшләп тә тапшырдык.

Палатаның һәм безнең комиссиянең эшчәнлеге Татарстаныбызга ни файда китерер икән дисезме? Тамчыдан күл җыела, диләр. Күпмилләтле Россиядә безнең киңәш-тәкъдимнәрне, һичшиксез, ишетергә һәм колак салырга тиешләр. Әйтик, Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәт Концепциясе проекты бездә канәгатьсезлек хисләре калдырды. Анда акка кара белән: «Концепсия Россиянең бер бөтенлеген тәэмин итүгә һәм аның дәүләтчелеген ныгытуга юнәлтелгән…»—диелә. Мондый билгеләмә, соңгы еллардагы милләтара мөнәсәбәтләрне истә тотканда, чынбарлыктан шактый ерак тора. Юкса бәхәссез ич инде: милли сәясәтне дөрес корып, аны тормышка ашырганда гына дәүләт бөтенлегенә чынлап торып ирешү мөмкин. Чөнки дәүләт—үзе өчен түгел, барыннан да элек халык ихтыяҗларын кайгыртып яшәгәндә генә чын мәгънәсендә ныклы, тотрыклы була ала, җимерелүгә дучар ителми.

«Гомумгражданлык тәңгәллеге формалаштыру» дигән юллар нәрсә аңлата соң?

Әлеге тезисның хәтта 1996 елда, Ельцин вакытында кабул ителгән элгәрге Концепсиядән дә кайтышрак икәнлеге күзгә бәрелеп тора. Рус телен генә дәүләт теле буларак ныгытырга, хөрмәтләргә, дигән чакырулар да күңелдә гаҗәпләнү уята. Йомшак кына әйткәндә, «державачыл» очкыннар һаман күзгә ташланып тора. Күпләрнең аңында башка милләтләрнең, аз санлы халыкларның телен, гореф-гадәтләрен саклау дигән нәрсә юк диярлек. Аңлашылса кирәк, мондый шартларда эшләү һәм көрәшү җиңелләрдән түгел. Концепсиядә балалар бакчасыннан алып мәктәпкәчә туган телдә белем бирү системасын булдыру һәм аны финанслау, һичшиксез, иң төп мәсьәләләрнең берсе итеп кертелергә тиеш. Безнең комиссия бу хакта үзенең сүзен әйтә белде.

Җөмләдән, «Идел белән Урал арасында» («Между Волгой и Уралом») дигән телевизион канал торгызуны, яңартуны да без тәкъдим иттек. Ул татар, башкорт, мари, чуваш һ. б. телләрдә алып барылачак дип өметләнәбез. Безнең комиссиягә Татарстанны гына түгел, Идел буе төбәкләренең мәнфәгатьләрен кайгырту да йөкләтелгән.

Күптән түгел миңа Җәмәгать палатасының пленар утырышында «Россия җәмгыятендәге ксенофобия һәм экстремизмга каршы көрәшү» дигән мәсьәләдә фикер алышуда катнашырга туры килде. Үземне һәм күпләрне борчый торган әлеге актуаль мәсьәлә хакында фикерләремне ачыктан-ачык әйттем. Фашизмны себереп түккән илдә фашистик идеология баш калкыта икән, моны берничек тә аклап булмый. Моның сәбәбе дә билгеле: чөнки дистә еллар инде күпмилләтле гигант шушы илнең ныклы милли сәясәте, берләштерү идеясе юк. Миңа калса, шулай да төп сәбәпләрнең берсе—базар мөнәсәбәтләре белән мавыгып, без дәүләтчелекнең төп принцибын, ягъни «Россия—күпмилләтле халык...» дигән иң мөһим сүзләрне арткы планга этеп чыгардык.

100 дән артык милләт вәкилләре яшәгән Татарстандагы дуслык, үзара аңлашып яшәү тәҗрибәсе хакында да әйтми калу мөмкин түгел. Бер көн белән яшәмибез. Әйтик, бездәге Халыклар дуслыгы йорты төзелү һәм аның эшчәнлеге—кеше хокукларын саклауның күркәм бер тәҗрибәсе ләбаса...

Әйткәнемчә, иҗтимагый Палатада эшләү—катлаулы, четрекле, шул ук вакытта мактаулы да эш. Җәмгыятебезнең рухи тазалыгы, аның матур киләчәге өчен безгә бергәләшеп эшләргә, көрәшергә кирәк. Менә шуның өчен дә мин Палата эшчәнлегендә катнашырга ризалык бирдем. Милли матбугатта озак еллар эшләү, Бөтендөнья Татар Конгрессында рәис урынбасары булу, халык депутаты буларак, Татарстан Дәүләт советы эшчәнлегендә актив катнашу—әнә шул еллар тәҗрибәсе миңа көч һәм таяныч бирә.

*Әңгәмәдәш*—**Рашат НИЗАМИ.**

*Татар театрына 100 ел*

# СӘХНӘБЕЗ КАҺАРМАННАРЫ

## Зәкия Туишева

Татар театры сәхифәләренә күз салсак, аның тарихында өч хатын-кызның сәхнә эшчәнлеге аерым урын алып торганлыгын күрербез. Беренче карашка алар бер-берсенә охшамаганнар да сыман. Тик аларны берләштерә торган ниндидер уртаклык бар: алар артист булу белән бергә, һәркайсы театрның иң киеренке, хәлиткеч мизгелендә дилбегәне үз кулларына алып, кирәкле юнәлештә театр сәнгатен үстерүдә зур көч сарыф иткән шәхесләр. Алар—Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Рәшидә Җиһаншина, Зәкия Туишева. Беренчесе «Нур» труппасын төзегән, татар сәхнә сәнгатендә романтик юнәлешне барлыкка китергән, икенчесе—әйдәп баручы актриса булу белән генә чикләнмичә, Г.Камал театрының иң авыр көннәрендә житәкчелек вазифаларын үз җилкәсенә күтәргән, андагы буыннар арасындагы эзлеклелекне үзара ялгап, коллективны ил күләмендә танытуга үзеннән өлеш керткән оештыручы, өченчесе исә—Әлмәт театрын киң җәмагатьчелеккә таныткан актриса һәм режиссер, шулай ук коллективның җилкәнсез калган мизгелендә, олы яшьтә булуына карамастан, аның җанын кире кайтарган, берсеннән-берсе кызыклы спектакльләр тудырган Зәкия ханым. Сүзебез аның турында.



Бер язмасында ул үз биографиясен болай дип башлый:

«Мин элекке Самар губернасы Чаллы башы авылында 1919 елда туганмын. Әтием мулла буларак, 1925 елны Татарстанга Яңа-Әлмәт авылына күчеп килгән, 1928 елда, әтием үлеп, ятим калганмын. Ул чорга хас булганча, әтиемнең мулла булуы балачак һәм үсмер гомеремә бик күп һәм зур күңелсезлекләр тудырган. Шуларның берсе—беренче класста укыганда мәктәптән кудылар. Шунысы кызык: күңелемдә никадәрле генә кимсенүләр, сызланулар булуга да карамастан, кара тап урнашмаган, һаман яктылыкка омтылыш, эзләнү булган! Театр сәнгатенә мәхәббәтем, яхшы хәтерлим, бик иртә, мәктәптән чыгарылгач уянды. Мәктәпкә кергәнче үк инде мин яхшы укый һәм яза, ул вакытта ук Тукайның шактый шигырьләрен яттан белә идем. Авылда «Нардом» бар—шунда авылның алдынгы яшьләре катнашы белән театрлар куя башладылар. Әлбәттә, анда балаларны кертмиләр иде, тәрәзә төпләреннән кыш булса, муенга кар тутырып, җәй булса—кычыткан белән куалар иде. Әле дә хәтеремдә: көз көне иде, ничек күренмичә «Нардом»га үтеп керә алганмындыр, ләкин мин эскәмияләр астында ята идем. Бистә белән авыл арасындагы күпер җимерелгәч, суфлерның килә алмавын әйттеләр, репетициядән таралырга куштылар. Шулай чыгып барганда, мине тотып алдылар бит! Җилдерәтеп куып чыгарганда, күрше Сәмигулла абзый: «Җәмәгать, бу кыз яхшы укый, әйдәгез карап карыйк, берәр нәрсә чыкмасмы?»—ди. Куллан күчерелгән китап тоттырдылар, мин исә куркудан «су кебек эчәм». Шуннан мин бу түгәрәкнең суфлеры булып китәм, репетицияләр барганда кесәгә ипи тыгам, аякка чабата бәйлим дә кош кебек очам! Менә «театр» көне килеп житте! Мине суфлер будкасы эчenә ящик куеп утырттылар: югыйсә буй житми! Алдыма лампа куйдылар, зал шыгрым тулы, башланды «театр»! Пьесаны яттан беләм, әйтеп тә торам, уенны да карыйм,

кемгә эләккән бу бәхет!–«Сүнгән йолдызлар» спектакле бара. Ах-ух килеп, елый-елый карыйлар. Аннан соң «Зәңгәр шәл»не әзерли башладылар. Мин бу абый-апалар өчен бик кирәкле кеше булып киттем, үзеннең кемгәдер, нәрсәгәдер кирәк булуыңны белү нинди бәхет! Ул Сәмигулла абыйлар, Бәдәр, Җиһан апаларга шул вакытта театр сәнгатенә сүнмәс мәхәббәт уятулары өчен, алай гына да түгел, ятимлек суккан бала күңеленә шифалы дулкын бөркүләре өчен мең-мең рәхмәтләр укыйм! Мәктәпнең 7 классын тәмамлагач, 1937 елда Казанга укырга дип киттем, театр мәктәбе булмаганлыктан, ФЗОга укырга кердем.

Ә 1938 елны Академия театры каршында студия ачылгач, имтихан тотып, шунда укый башладым, гомерлек теләгемә ирештем».

1941 елда шушы студияне тәмамлаганнан соң, Зәкияне театрның ярдәмче составында актриса буларак эшкә калдыралар. Ләкин анда аңа уйнарга насыйп булмый–илдә Бөек Ватан сугышы башлана һәм аның өчен тәүге сәхнә мәйданы туган иленең бомба һәм гранаталар шартлавыннан теткәләнеп беткән фронт кыры була. Кичәге студенткалар–җан дусты Бикә Шакирова белән бергә алар үзләре теләп фронтка китәләр, дивизион клубта эшли башлыйлар. Анда алар сугышчылар алдында җыр-бию, сәхнә әсәрләреннән алынган әдәби өзекләр белән чыгыш ясыйлар. Ә фронт һөҗүмгә күчкәч, Зәкия дә вазыйфасын үзгәртә–сугыш беткәнче медсанбатта шәфкать туташы булып эшли. Бөтен йөрәк җылысын яралы сугышчыларга багышлый, иптәшләрен үлемнән саклап калу өчен үз канын да җәлләми.



*З. Туишева «Гөлмәрфуга» ролендә. 1954 ел.*

I Украина һәм Көнбатыш фронтлар составында шәфкать туташы буларак Калугадан алып Берлинга һәм Прагага кадәр сугыш юлы үза. 13 енче Армиянең 121 нче Кызыл байраклы Армия дивизиясенең шәфкать туташы Зәкия Туишева Кызыл йолдыз ордены һәм «Сугышчан батырлыклары өчен», «Праганы азат иткән өчен», «Берлинны алган өчен», «Германияне җиңгән өчен», «1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышындагы Җиңүгә 20 ел» һ.б. медальләр белән бүләкләнә.

Шулай итеп, олы сәнгать дөньясына ул, меңнәрчә чакрым фронт юлларын узып, бик авыр һәм озак якынлаша. Аннан соң да, сәхнәгә кире кайткач та, аның язмышы тәгәрмәч өстендәге күчмә театр тормышы белән бәйле. Янәдән Әлмәт театрында куелган спектакльләрдә бихисап рольләр уйнап, Зәкия Туишева әле тагы да меңләгән чакрым газаплы һәм мавыктыргыч юллар уза.

Шулай итеп, җиңү шатлыгы һәм тантанасы Зәкиянең элеккеге театр турындагы хыялларын уятып җибәрә: кыз кабат сәхнәгә әйләнеп кайта. Башта ул Республика күчмә һәм Мамадыш колхоз-совхоз театрларында чыгыш ясый, ә 1951-1976 елларда Әлмәт дәүләт драма театрында–артистка һәм режиссер. Театрга килгән көннәреннән үк ул үзен төптән уйлаучы сәхнә остасы итеп таныта.

З.Туишеваның иҗат чалымнары ачык һәм якты. Сәхнә алымнарының төп сыйфаты–лирик башлангычның тормышчан дөреслек белән үрелеп баруы. Ул тудырган образлар һәрвакыт төптән уйланылган. Моннан тыш, Зәкиядә режиссерлык эшчәнлегенә дә хирыслык сизелә башлый.

Иң әүвәл ул халыкка артистка буларак танылa, драматик пландагы берсеннән-берсе катлаулы образлар иҗат итә. Мәсәлән, аның беренче каһарманнары–М.Фәйзинең «Яшьләр алдатмыйлар»ында Мәгъруфә, А. Корнейчукның «Украина далаларында» спектаклендә Катерина. Актриса алар турында үзе болай сөйли: «Бу

яшь-яшь кызлар, икесе ике чорныкы, икесе ике милләт вәкилләре булсалар да, аларның шуклыгы, яшьлек ташкыны һәм максатларына ирешүгә күйган көрәш алымнары берләштерә. Менә бу образлар, иң беренчеләрдән булганлыктан, минем өчен аеруча кадерлеләр. Ә инде артистлык хезмәтемдә үзем өчен, рухымда тирән эз калдырган, тамашачыда зур кызыксыну, театр сәнгатенә мәхәббәт тудырган һәм минем иҗат юлымда борылыш ясаган каһарманнарның берничәсен атап китәргә туры килер. Алар–Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ендә Сәрби, А.Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр»ендә Кручинина, И.Франконың «Урланган бәхет»ендә Анна, А.Гыйләҗевнең «Яланаяклы кыз»ында Әлфинур, Ч.Айтматовның «Анам кыры»нда Тулганай, М.Кәримнең «Ай тотылган төнендә»–Тәнкәбикә... Саный китсәң, болар бик күпкә җыйналыр иде.»

Актрисаның иҗат биографиясендә тәүге елларда аеруча тирән эз калдырган, образны калку итеп сурәтләгән рольләр арасында А.Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр»ендә Кручинина һәм И.Франконың «Урланган бәхет»ендә Анна образлары. Характер бөтенлеге, максатчанлыгы ягыннан бу ике образ актрисаның холык-фигыленә аерата да туры киләләр сыман, хатын-кызның бәхетне ничек аңлавын рәвешлиләр. Актрисаның каһарманнары көчле рухлы, тәвәккәлләр. Күктән ингән мәхәббәт хисенә тугрылык саклаган хәлдә, алар гаделсезлек белән очрашкач, үзләрендә аңа каршы торырлык көч табалар. Беренче чиратта З.Туишева үз героиняларының әхлакый нигезен эзли. Катлаулы драматик халәт, куәт таләп иткән әлеге образлар яшь актрисаны яхшы ук чыныктыра, тиз арада үзен халыкка танытып, Әлмәт театрының әйдәп баручы артисткалары рәтенә бастыра.



*Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар»ында Зәмзәмбану ролендә. Сулдан беренче З. Туишева.*

Ә менә З.Афиногеновның «Машенька» пьесасындагы төп героиня образын З.Туишева бөтенләй үзгә калыпта хәл итә. Әлеге характерлы рольне башкарудагы сәхнә үзенчәлекләре алдагылардан бик нык аерылып тора. Машенька образы эчке җыйнаклыкны, интонацион төсмерләрнең нәфислеген, нечкәлеген сорый. Ул әле укучы кыз бала гына. Сафлык, пакълык һәм күтәренке рухның тулы гәүдәләнеше булган Машенька башкалардан да шундый ук халәтне таләп итә. З.Туишева, бу рольне башкарганда, мәктәп баласы булып кыланырга тырышмый. Бу риясыз җан иясе яшүсмер кызның ихтыяр көчен ничек үзендә барлый алуын ачарга тырышты, кеше холкының мөмкинлекләрен һәм үзенчәлекләрен күрсәтте. Бу роль артистка өчен шул ягы белән кыйммәтле дә, ул аңа тәҗрибә, сабак өсти, акыл бирә.

Әлмәт театры ирешкән уңышларда З.Туишеваның да өлеше гаять зур. Әйткәнебезчә, күп еллар буена ул төп рольләрдә чыгыш ясый. Алар арасында Мәрзия («Ул кайтты»), Зәмзәмбану һәм Гайнавал («Ташкыннар»), Әлфинур («Яланаяклы кыз»), Таня («Икенче фронт артында»), Тәнкәбикә («Ай тотылган төндә»), Васса («Васса Железнова»), Тулганай («Анам кыры») һәм башка бик күп образлар бар. Тулаем алганда, 100 дән артык роль уйналган. Мисал өчен шуларның берсе А.Гыйләҗевнең «Яланаяклы кыз» драмасындагы Әлфинур образын гына искә төшерик. 60 ынчы еллар башында психологик драма жанрында язылган бу пьесада шушы чорга хас үзеннән-үзе калкып чыккан низагларның асылына төшенергә омтылу һәм аларның ничек хәл ителүе татар сәхнәсе өчен үзенә күрә бер яңалык

иде. Кешенең үзенә һәм гаиләсенә карата таләпчәнлеге, аның башкалар һәм үз алдына куйган әхлакый бурычларның ничек үтәлеше, уңышсызлык сәбәпләренең бары тик үзебезгә генә бәйле булуы турында тамашачы белән житди сөйләшү иде бу. Туишеваның Әлфинуры иң четерекле хәлләрдә дә үз мәсләгенә хыянәт итми, аңа тугъры кала. Бу образ аша актриса Кеше булып калу өчен киң күңелле булу гына житми әле, аның өчен көрәшергә дә кирәк, дигән фикерне аерым ассызыклый.

З.Туишеваның ижади алымына рольне тирәнгә кереп психологик анализлау һәм әдәби материалга таяну, аның үзенчәлекләрен үз роленең партитурасын мөстәкыйль ача алу сәләте хас. Аның ижат халәтендәге шушы сыйфат профессиональ режиссурага таба борылыш ясарга мөмкинлек тудырды. Шул сәбәпле дә ул үзенең тәүге постановкалары аша ук тиз арада кызыклы режиссер буларак таныла.

Әйткәнебезчә, Зәкия Туишева табигате белән эзләнүчән, аналитик фикерләүгә сәләтле кеше. Мөстәкыйль фикер йөртүгә сәләте, үз рольләренең партитурасына җентекле анализ ясавы режиссер һөнәренең дә асылына төшенергә ярдәм итә. Аның бәхетенә 1963 елда Әлмәт театрына баш режиссер булып сәхнә сәнгате буенча бай тәҗрибәгә ия сәнгаткяр Габдулла ага Йосыпов билгеләнә. Бу еллар—коллективның, нык аякка басып, киң җәмәгатьчелеккә үзен таныта башлаган чагы. Габдулла абый бу артистканың тынгысыз җанын, сәхнәне режиссерларча тоемлавын тиз сиземләп, жае чыккан саен аны спектакльләр куйган чагында үзенең ассистенты итеп чакыргалый. Тора-бара спектакльләрне ул инде үзе генә мөстәкыйль генә куя башлый. Зәкия апа театрда 1976 елга кадәр эшли. 10 ел эчендә 21 спектакль куярга өлгерә.

Билгеле инде, эш санда гына түгел. Һәр спектакльне дөньяга китерү, аны күрсәтү ул—һәрчак җәмгыятебезнең ижтимагый халәте дә. Вакыт төшенчәсе һәм коллективтагы эчке атмосфера, кешеләр язмышы белән дә бик нык бәйле. Шунысы да бар бит әле: гадәттә, режиссерлык һөнәренә хатын-кызлар бик атлыгып тормыйлар, театр тарихында аларны бармак белән генә санарлык. (Татарларда бер Кәшифә Тумашевадан башка берәүне дә атап булмый).

З.Туишева үзенә генә хас житезлек белән бу өлкәдә өлгерлек күрсәтә, чын-чынлап мавыгып китеп, тулысы белән шушы эшкә чума. Соңыннан ул Мәскәүдә режиссерлык курсларын да тәмамлый. Яшь режиссерның иң беренче мөстәкыйль рәвештә куйган спектакле—Америка язучылары Д.Гоу белән А.Дюссонның «Тирән тамырлар» драмасы Октябрь революциясенең 50 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә Бөтенсоюз драмтеатрлары смотрында күрсәтелә һәм икенче дәрәҗә диплом белән бүләкләнә. Режиссер буларак, З.Туишеваны нигездә әдәп-әхлак башлангычларына багышланган, шулай ук сугыш темасына кагылган әсәрләр күбрәк кызыксындыра. Алар, гадәти тормыш-көнкүреш режиссура кысаларында хәл ителгән булуларына карамастан, аның спектакльләре гадәттә якты, самими, мажор һәм лирик тоннарда чишеләләр. Аның өстәвенә Зәкия Туишеваның гаять бай, гаҗәеп кызыклы режиссерлык ижаты сугыштан соңгы чорда Әлмәт театрында эшләгән тулы бер буын сәхнә осталарының катлаулы, гаять үзенчәлекле язмышлары белән дә бәйле. Аның спектакльләрендә шул заман кешеләренә хас, үзең сайлаган шөгыленә, гомумән, хезмәткә зур хөрмәт белән карау, үзеңнең барлыгыңны шуңа багышлау өстенлек ала. Шунлыктан ул олы сәнгать дөньясында үз хасияте булган, чынбарлыкны үзенчә кабул иткән сәхнә остазы итеп таныла. Аның «күңел кыңгыраулары» аңа яхшы таныш гади һәм эчкерсез образлар системасына корылган пьесаларда шәбрәк, яхшырак яңгырый. Бу чорда З.Туишева тарафыннан куелган спектакльләр түбәндәгеләр: «Законлы никах белән» (Ә.Атнабаев), «Чаткылар» (Т.Гыйззәт), «Их, Уфа кызлары», «Тиле яшьлек» (И.Абдуллин), «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т.Миңнуллин), «Хажи әфәнде өйләнә» (Ш.Камал), «Трибунал» (Д.Макаенок), «Сөюләрең хак булса» (Х.Вахит), «Барабанчы кыз» (А.Салынский). Соңгысы, башта режиссерлар, ә аннары «Корчагинчылар—70» дип аталган Бөтенсоюз драмалар конкурсында жинүче булды.

Шулай уңышлы гына эшләвенә карамастан, Зәкия Туишева 1976 елда «лаеклы ялга» китәргә карар кыла. Аның «лаеклы ялга» китүе бу очракта бик күпләрне аптыраšта да калдырды. Ләкин, билгеле булганча, һәр нәрсәнең үз сәбәбе була. 1969 елда Әлмәт театрына аның сәнгать житәкчесе итеп гаять тә тынгысыз

табигатьле режиссер Гали Хөсәенов билгеләнә. Заман сулышын иркен тоючы талант иясе һәм шул ук вакытта хезмәттә, оештыру эшендә ныклы тәртип ратучан бу шәхес коллективны тиз арада «кулга ала» һәм үзенең ихтыяр көченә буйсындыра. Әлмәт театрының «күккә күтәрелгән» чоры, мөгаен, ул хакимлек иткән вакытлардыр. Тик, ни хикмәт, шәхсән шундый ук сыйфатларга ия режиссер Зәкия Туишева белән алар уртак тел таба алмыйлар (билгеле инде, аның үз сәбәпләре булгандыр, монда ул турыда язу кирәк микән?). Җыеп кына әйткәндә, ике талантлы шәхескә бер сәхнәгә сыешу шактый кыенлаша башлый. Өстәвенә, Гали Хөсәенов үзенең төп игътибарын яшьрәк буынга—үсеп килүче, шулай ук режиссура белән кызыксынучы театрның яшь артисты Рөстәм Абдуллаевка юнәлтә, ана күбрәк ышана, аны якынрак күрә. Бу сүзләр кемнедер гаепләү ниятеннән әйтелми, һәркем дөньяны үзенчә аңлый, үзенчә фикер йөртә, гомумән, һәркемнең үз ирке бар. Зәкия апа, горур табигатьле кеше буларак һәм үз кадерен яхшы аңлаганга күрә, пенсия яшен сылтау итеп, «матур» гына итеп театрдан китәргә карар кыла. Театр белән арасын өзми, һәрвакыт театр өчен кирәк, аның мактаулы кунагы—«туй генералы» булып кала. Үз-үзен чикләү аңа җиңел бирелми, билгеле. Күңеле кителсә дә, зарланмый. Тәвәккәл кеше буларак, югалып калмый, үзе әйткәнчә: «Мин тик кенә утыра торган кеше түгел. Лаеклы ялга чыккач, үзешчәннәр сәнгате дөньясына чумдым. Бу чорда мине театрга чакырып тордылар. «Тиле яшьлек», «Шундый-шундый эшләр» спектакльләрен мин шул вакытта сәхнәгә куйдым!»—ди. Тынгысыз җанына «хуш» килгән эш табыла, яраткан шөгыленнән аерылмый: Әлмәт район мәдәният йорты каршында оешкан халык театрында сәнгать җитәкчесе булып 10 елдан артык эшли. Монда ул баштарак, бәлкем, үзенең шул тынгысыз җанына урын таба алмыйча килеп кергән булса, бераздан баш-аягы белән эшкә чума—чын йөрәктән бирелеп иҗат итә башлый. Монда аның беренче спектакле Ш.Шагалинең «Бала бәхете—ана бәхете» әсәре «Театр язы-78» конкурсында лауреат исемен яулый. Икенче эше—Ш.Хөсәеновның «Зөбәйдә—адәм баласы» шулай ук лауреат исеменә лаек була. Бу спектакльләрне халыкка күрсәткәннән соң коллективка «Халык театры» дигән мактаулы исем бирелә. Бирелә дә ул 12 спектакль куя. Бу четерекле өлкәдә Татарстанның халык артисты, Бөек Ватан сугышы ветераны, Әлмәт шәһәренең мактаулы гражданины Зәкия Туишеваның фидакарь хезмәтенә сокланасы гына кала.

Вакыт дигәнең уза, тәгәри генә тора бит. Һәм, менә кем уйлаган, коллектив үзенең иң авыр көннәрендә, Зәкия апаларын терәктәй күреп, ярдәм сорап янадан аның янына килергә мәҗбүр булыр дип. 72 яшьлек Зәкия апа, баш режиссер буларак, театрны сәнгати яктан җитәкләү вазифасын янә үз өстенә ала һәм максатына ирешә—бербөтен иҗат коллективы буларак уңышларга ирешә, театрга килгән яшьләр дә үзләрен күрсәтә, үз сүзен әйтә башлый—янадан иҗат биеклекләренә таба старт алына.

Зәкия апа, дөресен генә әйткәндә, холкы белән шактый катлаулы шәхес. Ул үз эшенә нык бирелгән, иҗат утында кайнап яши, башкалардан да хезмәткә карата шундый ук мөнәсәбәтне таләп итә һәм бернинди икеләнүләрсез куйган максатына ирешергә омтыла.

Ул, коллективны иҗади яктан бергә туплау җәһәтеннән чыгып булса кирәк, репертуарга халык тормышын киң яктырткан әсәрләргә йөз тота. Аның бу очракта маһирлыгы масса күренешләренә бай, халыкчан әсәрләргә йөз тотуында чагыла. Беренче эш итеп ул Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр» әсәренә туктала һәм гаять тә тормышчан, милләтебезнең гореф-гадәтләрен шигъри югарылыкка күтәргән, гаять тә халыкчан спектакль тудыруга алына. Шулай ук Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрен дә ул киң социаль манзара рәвешендә сәхнәләштерде. Гаилә таркала икән, димәк, ата-бабаларның яшәгән нигезе, җире дә таркала дигән сүз. Режиссер буларак, ул иң әүвәл шушы фикерне расларга омтыла. Гади кешенең уй-тойгыларын, рух-халәтен шигърият югарылыгына күтәреп, романтик юнәлештәге спектакльләр куя. Ләкин—иң мөһиме—бу спектакльләр Әлмәт театрының эчке иҗат потенциалын ачалар, аның абруйлы, сәләтле, үсештәге артистларын халыкка таныталар, яңа үрләр өчен киңлек барлыгын күрсәтәләр.

Театрга җитәкче булып кайткан Зәкия Туишева янәдән 4-5 ел эчендә 10 лап

спектакль куярга өлгерә. Тик сәламәтлеге аңа иҗатын дәвам итәргә мөмкинлек бирми, ул янәдән «лаеклы ялга» китә. Монда шуны әйтергә кирәк, Зәкия Туишева—үзенең кешелекле холкы белән «баш бирмәс», актив көрәшчеләр сафындагы ханым. Ул җәмәгать эшендә дә алгы рәтләрдә баручылардан. Әле менә узган елның декабрь ахырында Кама аръягы театрларының фестивале булды—атнадан артык вакыт эчендә бер көнен дә калдырмыйча, монда катнашкан һәр театрның спектакльләрен карарга дип кич белән Зәкия апа да килә иде. Аңа инде 86 яшь тулганлыгын искә төшерсәк, аның төшенкелеккә бирелмичә, тайгакта кич белән урамга чыгып, театрга юл тотуын күзалласак, бу батыр ханымның ихтыяр көченә сокланмыйча кала алмыйсың. Аның өстәвенә ул һәрвакыт «форма»да булыр—мәһабәт кыяфәтле, ап-пак чәчләр матур һәм килешле рәвештә өелеп куелган, гаҗәеп зиннәтле, пөхтә итеп киенгән, аягында «модный» туфли, төз буын, акыллы, ихтирамлы караш. Мин аның белән 40 елдан артык таныш—ул һәрвакыт тантаналы бәйрәм көннәрендә дә, болытлар куерып, йокылары качкан, тынгысыз, чарасызлыктан гаҗиз калган борчулы чакларында да үзен кулда тотып, җилкәсен төшерми, туры тотты. Бу шәхеснең театрның ишеген ачып, аның бусагасын атлап керүе үк яшьләргә ток йөгерткәндәй тәэсир ясый. Дөньяның аяусызлыгына ул бөгелмәс рухы белән җавап бирергә әзер иде. Белгәннәр белә, аның күңелендә әле бүген дә җил-бураннар уйный—менә инде шактый еллар аның җанын телгәләгән бер сорау аңа тынгылык бирми—«Кайларда гына югалды икән соң, аның 50 яшьлек газиз улы Альберт?» Менә инде алты еллап, ул җир упкандай тик торганда юкка чыкты. Хатын-кыз өчен Ана кайгысыннан, Ана борчуыннан да зур нәрсә бар микән? Кем уйлаган, бүгенге замана чире—тик торганда кеше югалу зары аңа да кагылыр дип. Ләкин Зәкия апа улының исәнлегенә ышана, ул инде телевидениенең «Көт мине» тапшыруына да мөрәҗәгать иткән, анда аңа өметен өзмәскә киңәш иткәннәр һәм ул улының исән-сау булуына ышанып, аны көтә, өзелеп көтә... Зәкия Туишева тормышында көрәш әле һаман да дәвам итә...

## Рауза Хәйретдинова

Тиздән татар театрының йөз еллык юбилее, дибез. Менә шушы Вакыт берәмлеге эчендә театрыбыз сәхнәсендә нинди генә талантларыбыз якты йолдыз булып кабынмадылар да, нинди генә шәхесләребезнең язмышлары илебез тормышы белән бәйләнештә хәл ителмәде. Югары гүзәллеккә омтылучан артист халкы тамашачысы белән һәрвакыт тыгыз элемтәдә тора һәм, аларның рухи ихтыяҗларын күңелендә барлап, хис-тойгыларын көчле дулкынлану аша сәхнәдә чагылдыра. Артист халкының талпынышы, аның ирешкән уңышлары әнә шул тамашачының эмоциональ шифалы йогынтысы нәтиҗәсендә туа. Ул аның сулышын үзенә сендерә, аңа юаныч бирә. Исемлеккә күз йөртсәк, татар театры белән үз язмышларын тыгыз бәйләгән артистларыбызның саны берничә йөзгә туладыр. Аларның һәркайсының үз сәләт югарылыгы, изге эшләре, илаһи биеклекләре бар. Алар арасында театрның тарих битләрен бизәгән Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Рауза Хәйретдинованың иҗаты да аерым бер урын алып тора. Ул да аерым игътибарга һәм тирән ихтирамга лаек. Аның турында да, башка бик күп артистларыбыз хакындагы кебек, ул безнең сәхнәбезнең бер үк вакытта ханбикәсе дә, колы да дип әйтәсе килә. Ник дисәң, аның өчен сәхнә гомер-гомергә иң изге урын булып калды. Ул—аның тормышы, гомер агышы, сулый торган һавасы, яшәү чыганагы. Шул ук вакытта сәхнә безгә аны халык күңелендә моң, җыр булып яшәгән Галиябану, Гөлбану образларының җанлы гәүдәләнеше, рәвеше итеп тә танытты, аның үзенә дә, театрга да дан алып килде.

Рауза ханым 1928 елда Балык Бистәсе районының Яңа Ырга авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Раузага 13 яшь чагында әтисе сугышка китә. Озак та үтми, әнисе дә якты дөнья белән саубуллаша.

Рауза сеңлесе һәм энесе белән ялгыз кала. Тик авылдашлары аларны үзләренең ярдәмнәреннән ташламыйлар, аякка басарга булышалар.

Моңлы бала буларак, ул бик иртә үзешчән сәнгатькә катнаша башлый, ә инде

1946 елда Г.Камал театры каршындагы драма студиясенә укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң театрның үзендә эшкә калдырыла. Шулай итеп, менә ярты гасыр буена, шул сәхнәнең тылсымлы көченә буйсынып, ул театрның ишеген хуҗаларча киң итеп ачып керә, пәрдә ачылганын зарыгып көтеп ала. Дөрес, 1991 елдан ул пенсиядә исәпләнә, тик театр каршындагы «Инсаният» фонды труппасында ул үзенең иҗатын һаман да дәвам иттерә. Сәхнә тылсымы аны бүген дә кичәге сыман ук сихерли, үзенә тарта.

Рауза Хәйретдинова сәхнәгә 40 нчы еллар ахырында аяк атлады. Бу чор илебез өчен дә, театрыбыз өчен дә иң авыр, шул ук вакытта, куанычлы еллар булдылар. Ачлык, ялангачлык, хәерчелек баштан ашкан бер вакытта алда өмет йолдызы балкый башлый—сугыштан соң михнәтле, сагышлы көннәр алдагы яктылыкка омтылу белән алышына. Һәр нәрсә бик тиз җайга салынып да, тормыш тантана итәр сыман тоела. Рауза апа исә үзенең табигате, холкы белән дә бу ышанычның җанлы рәвеше—зәңгәр күзләрен тутырып карап, бер елмаеп, көлеп җибәрсә, тирә-юнь нурга төрелә, аның янында үзеннән-үзе матур гамь хасыйл була. Шунадырмы театрда аны бик тиз арада үз итәләр, роль артыннан роль бирә башладылар.



Шуны да истә тотыйк: илленче еллар башында театрга шул чорда ук талантлары гөрләп чәчәк аткан Фатыйма Ильская, Галия Булатова, Галимә Ибраһимова, Мәрзия Миңлебаева, Рәшидә Җиһаншина кебек татар сәхнәсендә каһарман рухлы шәхесләрне оста итеп уйный торган артисткалар янына Мәскәү каласыннан, ГИТИСны тәмамлап бер төркем искиткеч сәләтле яшь артистлар—Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Рауза Уральская, Асия Галиева, Гәүһәр Камалова кебек яшь ханым-туташлар кайта. Менә шушы чолганыш һәм әйләнештә, күз ямен ала торган талантлар арасында Хәйретдиновага югалып калмыйча, үзен тамашачыга күрсәтү һәм таныту, мөгаен, җиңел булмагандыр. Яшь Рауза үзенең җырга-моңга булган сәләте белән алдыра. Андый пландагы артистларга кытлык театрда һәрвакыт зур.

Татар тамашачысы ул аерым халык, ул музыкаль әсәрләргә битараф түгел, дип кенә әйтү аз. Ул җырлы әсәрләргә җанын фида кылырга әзер. Спектакльдә музыка яңгырамаса, аның кәефе кырыла, ул үзен алдангандай хис итә. Режиссерлар яшь Раузаның мондый музыкаль рольләргә артистлык чаткыларын тойганнан соң, аның сәләтен тулысынча ачу ниятеннән халыкның иң сөекле образларын ана бер дә икеләнмичә тапшыралар һәм ялгышмыйлар. Шуннан башлана аның җырлы гомере. Бу турыда журналист М.Хөснимәрдәнов болай дип искә ала: «Г.Камал исемендәге ТДАТ сәхнәсендә үлмәс Галиябануны ун елга якын Рауза башкарды. Табигать биргән сәләте, яшьлек чибәрлеге, моңлы тавышы белән әсәрләндерә иде ул безне. Үзең залда утырасың, ә күңелең анда, сәхнәдә, аның янында. Һәр чорның үз Галиябануы була. Һәр егет үз Галиябануын эзли. Һәр кызның күңелендә үз Хәлиле яши. Ул чордагы Галиябануның саф мәхәббәте безне Рауза уйнавы, аның өздереп җырлавы аша рухландыра, тетрәтә иде. Без шул чор кешеләре үз Галиябануыбызны-Раузабызны сагынабыз. Ул гына да түгел, унбиш ел буена К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендәге Мәйсәрәне дә сагынабыз».

Бәхетебезгә илленче еллар уртасында 20 ел сәхнәдән көчләп аерылдыртылган «Зәңгәр шәл» мелодрамасы яңадан кайта. Анда да төп рольне—Мәйсәрәне ул башкара һәм 15 ел буена һәр чыгышында тамашачыга бәйрәм хисе бүләк итә.

Нинди яклары белән Р.Хәйретдинова тамашачының игътибарын җәлеп итә соң?

Вокаль мөмкинлекләре киң булу өстенә, ул—халыкның гореф-гадәтләренең бөтен нечкәлекләрен дә бик яхшы белә, аларны ул күз-карашларыннан ук тоемлый торган халыкчан актриса. Рауза ханым кыланмый, ә бәлки алар булып яши. Ул тудырган образларда самимилек, табигыйлек, хәтта авылчанлык (гыйбатлык белән бутый күрмәгез), характер ачыклыгы, ачыклыгы ярылып ята. Алар татар халык авыз иҗатында җырланган туган илнең урман-кырларында, су-болыннарында үскән чибәр, сылу кызларны хәтердә яңарталар. Алар аша халкыбызның рухын тоясың. Шушы уңайдан олуг язучыбыз Әмирхан Еникинең 1956 елда К.Тинчуринның «Казан сөлгесе»н кую уңае белән язылган бер рецензияне мисал итеп китерәсе килә:

«Казан сөлгесе»—музыкаль комедия. Ләкин музыкаль әйберләрне күптәннән куймаганга күрә, театрның билгеле бер авырлыклар кичерүе дә мөмкин иде. Бер үк дәрәҗәдә уйнарга да, җырларга да сәләтле көчләрне табу җиңел эш түгел бит. Спектакльнең үзендә бу хәл ачык күренде дә. Мәсәлән, Ильяс шәкерт ролендә И.Гафуров уйнау җәһәтеннән бик әйбәт, җылы, сөйкемле образ тудыра алды. Әмма җырлауга килгәндә—тавыш зәгыйфь, «Казан сөлгесе» аның башкаруында бөтен көче һәм матурлыгы белән яңгырый алмады. Моның өчен театрны да, артистларны да гаепләп булмый, билгеле. Шул ук сүзне Бариев, Камская, Минская, Нигъмәтуллиналарга карата да әйтергә туры килә. Болар берсе дә оперетта артистлары түгелләр, җырлау сәләте аларда бик чамалы. Дөрес, аларның һәркайсы бу кимчелекне оста уйнау белән капларга тырышты. Бигрәк тә Минкина мөәзиннең олы кызы Сажидәне нечкә тоеп, аның кичерешләрен—көнчелеген, үпкәсен, үзенчә хәсрәтләнүен—дөрес чагылдыра алды диясе килә...


*«Зәңгәр шәл» спектаклендә Мәйсәрә ролендә.*

Ихтимал, бу спектакльдә һәр ике таләпкә җавап бирә алган артистка Р.Хәйретдинова булгандыр. Уйнавы да, җырлавы да аның бер үк дәрәҗәдә яхшы иде. Ягымлы, матур тавышы аның, ничектер, хәтергә сеңеп калды. Сөйкемле, иркә, зирәк Мөршидә һаман әле күз алдында басып торган кебек...»

Озынрак тоелса да, бу өзекне шул чорның атмосферасын чагылдыру өчен махсус китердек. Менә шулай Әшрәф Синяева, Галия Кайбицкая, Оркыя Кушловскаяларның уен традицияләрен матур дәвам итү Рауза Хәйретдинова җилкәсенә төшә. Гомумән, Рауза апаның уйнаган рольләрен күздән кичергәч, үзенең сәхнә гомерендә бик күп яшь кызларны уйнап, карчыклар образына якын да килмәве, аларга күчмәве ачыклана. Күрәсезме, нинди хәйләкәр! Халык күңелендә мәңге шулай яшь, матур, чибәр, сылу булып калуыдыр ахырсы. Аны аңлап та, аклап та була: музыкаль рольләрдә уйнау аны үзеннән-үзе лирик дулкынга көйләгән булырга тиеш. Татар хатын-кызының язмышы ул иҗат иткән образларда төрле вариантларда үз чагылышларын тапты. Һәм, ни хикмәт, ана яшьрәк чагында күбрәк уңай образларны гәүдәләндерергә туры килде. Шундыйлардан М.Әблиевнын «Шәмсекамәр»ендә Разия, Т.Гыйззәтнең «Шомлы көннәр»ендә Гөлчирә, Ш.Шаһгалинең «Таң атканда»сында Гөлбикә, Н.Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу»ында Айсылу, Г.Әпсәләмовның «Яшьлек иртәсе»ндә Һаҗәр, Г.Насыйриның «Кадерле минутлар»ында Айсылу, Р.Ишморатның «Серле моң»ында Дилбәр, И.Юзеевнең «Янар чәчәк»ендә Фәүзия, Х.Вахитның «Бергә—гомергә»сендә Шакирә рольләрен атыйсы килә. Бу образлар үзләренең кешелек сыйфатлары ягыннан гаять үзенчәлекле, бер-берсен кабатламыйлар. Аларның кайсы монсу һәм уйчан, кайсы саф һәм шат күңелле. Кайсы юмарт, кайсы чая, беркатлы, артын-алдын уйламыйча гашыйк булучан, гомумән, төрледән-төрлеләр. Аларны берләштергән

бер сыйфат—аларда фаҗигале төсләр юк. Бер вакытта да мескен, елак, мыштым түгелләр, шыңшымыйлар. Аның сәхнә алымында якты буяулар гына өстенлек итә. Арадан, дөрес, берсе—Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» дигән әсәрендәге Гөлбану образы аерылып тора. Моны инде трагедия жанры үзе таләп итә торгандыр. Олы тәнкыйтьчебез Гази Кашшаф сүзләре белән әйтсәк, «Дөньяда һичбер ямь, шатлык тапмаган һәм алдагы көненең яктылыгына һичбер өмете булмаган Гөлбануга суга ташлану «бәхете» генә кала. Спектакль әнә шундый фаҗига турында сәхнә теле белән сөйли».

Һәр артистның үз тылсымы, үз сере була. Рауза апаның уен манерасына ачык, җанлы төсләр хас. Ул җил сыман сәхнәгә атылып килеп керә, үз «партиясен» башкара да ут уйнатып чыгып та китә. Тормышта да ул шундыйрак, театрның ишеген кыю һәм киң итеп ачып керә, җил-җилдәй яныңнан узып китәр, яңгыратып көләр, сәхнәгә чыгуны изге бер эш итеп күтәп алыр, чыккач, төгәл итеп уйнап бирер—аңардан һәрвакыт энергия бөркелеп торыр. Мөгаен, бу очракта артистның гаять актив табигате аның уенына да тәэсир итәдер. Бигрәк тә тискәрерәк пландагы рольләрне уйнаганда бу аерата сизелә. Шушы уңайдан Ш.Хөсәеновның «Әни килде» драмасындагы Расиха образын искә төшерик. Ул—үзенең килеш-килбәте белән безнең тормышта бик еш очрый торган гадәти бер хатын. Беренче карашка үзе чибәр, тере табигатьле сыман. Азмыни андый холыклы кешеләр! Тик, вакыйгалар куерган саен, аның холкының асылы ачыла. Битлеге ертыла: күз алдына ире Исламга охшаган, аның кебек үк комсыз һәм намуссыз, тәүбә итә белми торган, бер тиен акча өчен җанын фида кылучы затсыз бер җан иясе килеп баса. Расиха сатира жанрында гына уйнала торган образ түгел, ә бәлки, (аның күчтәнәчкә килгән йомыркаларны сайлау моменты үзе ни тора!) тормыш-көнкүрешебездән алынган тормышчан бер образ. Шуның өчен җәнҗалчы, усал хатыннарны Р.Хәйретдиновага шактый күп уйнарга туры килде. Аларны ул үзенә генә хас җанлылык һәм җиңеллек белән башкара. Бу кешеләргә хас комсызлыкны, намуссызлыкны, вак җанлылыкны фаш итә. Әйтик, Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар»ында байбикә булырга омтылучы Мөршидә образы үзенең оста һәм төгәл тасвирлануы белән күпләрнең хәтерендәдер. Яисә Н.Исәнбәтнең «Зифа»дагы Кәләмзәсе дә бар бит әле. Ул бу рольдән шулай ук зур ләззәт табып, аны бик тә яратып уйнады. Театрның искиткеч шәп артисткасы Гөлсем Камская башкаруыннан соң әлеге рольдә чыгыш ясау—зур кыюлык һәм тәвәккәллек иде. Рауза апаның театрыбызга хас традицион уен алымнарының камиллеген, җанлылыгын, образлылыгын үз иҗатында чагылдыра алуы өчен без аңа бик рәхмәтлебез. Аның уен осталыгы яшьрәк буын артистларының уенында кабатлана икән, димәк, беренче буын артистларының фидакарь тырышлыклары югалмаган дигән сүз.

«Халык артистлары» дигән китапта Җәмилә Кумысникова Рауза Хәйретдинованы «иң бәхетле язмышлы артистка» дип атый. Бу, чыннан да, шулай. Роза апа сәхнәдә бер вакытта да рольләргә кытлык кичермәде, эшсез тормады, сүнмәс дәрт белән яшәде. Шәхси тормышында да Рауза апа, миңа калса, иң бәхетле хатын-кызларның берсе. Ире Нуретдин—Нури абый белән инде күптән аларның кызыл туйлары узды. Аларныкы кебек тигез, матур, бер-берсен нык ихтирам итеп, аңлап яшәгән гаиләне бик сирәк очратасың. Нури абыйның «Рауза» димәгән сулышы бар микән, ул Рауза апаның тормышта да, театрда да алыштырып булмый торган терәге сыман. Рауза апа Нури абыйны Галиябануны уйнаган көннән үзенең Хәлиле итеп кабул итте. Алар гомер бакый бер-берсенә терәк булып, бер-берсенең күзләренә генә карап торучы сокландыгыч пар канатлар. Тормышта да, сәхнәдә дә шулай мәхәббәт дәрьясында иркен йөзгән хатын-кызны иң бәхетле кеше димичә, ничек атыйсың?

**Дания ГЫЙМРАНОВА,**
*театр белгече*

♣

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

**СӘМРУГ КОШ** — Фарсыча *си-мург* — утыз кош сүзеннән. Гарәптә — *Зумруд*, төректа-*зумран*. Р.Әхмәтьянов сүзнең татарча *сәмрәү* язылышын төрки һәм аны фарсыча "*сиәһмург* — кара кош" сүзеннән дип аңлата. Ләкин борынгы фарсылар уйлаганча, бу хыялый кош дөньяның бер читендә ("Каф тау артында" яки борынгы Эльбрус тауларында, торак җирләрдән еракта) яшәгән. Аның оясы фил сөягеннән яки сандал агачыннан ясалган баганалар өстендә була имеш. Сәмруг кош очып килгәндә күк йөзен караңгылык баса. Ул сөйләшә белә, халык әкиятләрендә еш кына адәми затны саклаучы фәрештә буларак сурәтләнә.

*Ике башлы сәмруг кош* — Романовлар империясенең символы, ул Русия гербында, дәүләт мөһерендә сурәтләнә. Хәзерге (1998) Русия акчаларында да, Дәүләт банкы күрсәтмәсе буенча, шушы ике башлы сәмруг кош төшерелгәнен ("Двуглавый орел"ны) күрәбез. Йөзләрчә халыкны кыерсытып, изеп, кимсетеп килгән империянең символы буларак, без аны икеләтә чукый торган, икеләтә ерткыч кошка тиңлибез. Чуку һәм чукындыру сүзләре бер тамырдан.

Шулай да гайре табигый гарип-гораба гербны кабул иткәндә, урысларның оригиналь булмавы, башкаларныкын күчереп эш итүе бу мәсьәләдә дә ачык чагыла. Ике башлы сәмруг кош сурәтенең Мәскәү патшалыгы гербына кадәр күп элек Алтын Урда акчаларында очравын искә төшерик. Мәс., Үзбәк хан (1313-1341) чорында сугылган бер тәңкәдә ике башлы кош сурәтенең трактовкасы Византия гербындагы шундый ук мотивларга якын. Әгәр Кыпчакның Византия белән киң элемтәләре булганлыгын һәм Үзбәк ханның Византия императоры кызына өйләнүен искә алсак, татар пулларын Византиянең ике башлы бөркете белән бизәү ихтималы да бар. Хәер, тарих тирәнлекләренә төшеп, тагы да эчкәрәк керсәк, II гасырда Алтай төркиләренең бер символы ике башлы бөркет булганлыгын күрәбез. Алтай төркиләре Кытайга басып кергәндә аларның байрагында шушы ике башлы бөркет сурәте кәбирләнеп торган (Морад Аджи).

Ләкин Византиянекенә охшаган ике башлы бөркетнең калку сурәтләре бакыр акчаларның бик аз өлешендә генә очрый. Акчаларның күпчелегендә ике башлы бөркетнең стильләштерелгән шартлы сурәте, ягъни монголларга кадәрге чорда ук Идел буе халкы арасында киң таралган һәм аңа аңлаешлы булган сурәт төшерелгән.

Канатларын җәйгән схематик кош мотивы хәзәр сәнгатенә үк хас булган. Ике башлы схематик кош сурәте X-XI гасырларга караган Түбән Идел бәҗәнәк истәлекләрендә дә еш очрый.

Идел буе халыклары сәнгатендә канатларын җәйгән кош сурәте, тотрыклы сакланып, буыннан-буынга күчә килгән. XIII гасырга нисбәтле көмеш болгар тәңкәләрендә һәм кабер ташлары бизәлешендә дә шундый ук мотив очрый.

Акчада ике башлы бөркетнең татарча исеме — сәмруг, бу хыялый кош күп кенә фольклор әсәрләрендә катнаша. Ике башлы кош сурәтенең баш (илаһи) хөкемдар мәгънәсен белдерүе әлеге бакыр акчаларның арткы ягындагы язуда да ачыла: "Сарай әл-Җәдидта сугылды. Уналты-дәник". (Билгеле булганча, Үзбәк хан заманында башкала Сарай әл-Мәхрусадан Сарай әл-Җәдидкә күчерелә.)

Тагын шуңа игътибар иткәннәр: үз эмблемалары итеп ике башлы каракошны алган илләр (Византия, Изге Рим империясе, Австро-Венгрия, Россия империясе, Серблар, хорватлар һәм словеннар Корольлеге) барысы да һәлак булганнар.

---

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санында басылып килә.*

**СӘРАВИЛ** *г.* — Чалбар, ыштан, шаровар (соңгысы этимология ягыннан *сәравил* сүзенә барып тоташа). //*Вә һәм йәлбису әл-кафтан, тәгамеһү шалкан, кәлямеһү ялган вә сәравилеһү ыштан...* — кигәне — кафтан, ашаганы — шалкан, сөйләгәне — ялган һәм чалбары — ыштан... (Иске мәдрәсәләрдә шәкертләрнең мәгърәкә, ягъни күңел ачу кичәләрендә әйтелгән шаян сүз. Г.Исхакый буенча.)

**СӘРЛӘҮХӘ** *фг.* — **1**.Китап-журналның исеме күрсәтелгән титул бите; мәкаләнең исеме, башы. //*Гаяз әфәнде "Сүз"нең 18 нче номерында "Йолдыз"ның миллилеге" сәрләүхәсе белән дәхи озын бер мәкалә язып, безнең "Таңчы"га җавап" дигән мәкаләмезгә җавап бирергә теле.* (Авторы билгеле түгел.) **2**.Эпиграф.

**СӘҮЧИ** *бор.* — Пәйгамбәр, рәсүл, илче. //*Сәүчи Йосыф* — Йосыф пәйгамбәр (Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасында очрый; шушы ук әсәрдә Йагкуб та *сәүчи* дип аталган һәм Фазыл Фасеев аны русча "патриарх Йагкуб" дип аңлата). *Җиһан эчрә кубмыш иде Йусеф нәби, Атасы Йагкуб нәби, хак хәбибе, Дәдәсе Исхак сәүчи, дин табибе — Хәлиуллаһ Ибраһимның углы имди.* "Кыйсса-и Йосыф". "Рисаләи Газизә" китабында, мәсәлән, Зәкәрия һәм Шәмгун пәйгамбәрләр гади *йалавычлар* (апостоллар) исәбенә кертелә, ә Идрис, Шис һәм Муса пәйгамбәрләр — зурлар, аларны *сәүчи* дип олылаганнар. "Древнетюркский словарь"да "сәүче-илче, пәйгамбәр": "*Йалавачларда өдрүнтүсе улуг сабчысы*" — илчеләрдән сайланган олуг пәйгамбәр. Шушы ук сүзлектә теркәлгән *тыңчы сәүче* кушсүзе исә "әләкче шымчы" мәгънәсендә.

Себер татарлары диалектында *саучы*/*сауцы* — яучы.

**СӘХАБӘ** *г.* — Мөхәммәд Пәйгамбәрнең фикердәшләре, көрәштәшләре. Аларның саны барысы 114 меңгә җиткән. //*Сәхабәи кәрам (разыйаллаһу ганһүм)* — хөрмәтле сәхабәләр (Аллаһы алардан риза булсын). "Рисаләи Газизә"дә хөрмәтле һәм оҗмах сөенече бирелмеш сәхабәләр унау дип күрсәтелә, болар: Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали (изге хәлифәләр-хөләфаи әр-рәшидун), Талхә, Габдеррәхман бине Гаваф, Габидә, Сәгыйд бине Ваккас, Сәгъд бине Зәйд һәм Зәбир. Сәхабәләрдән соң *табигыйннар* һәм *тәбге табигыйннар* аерып карала.

*Сахабә* язылышы да очрый.

**СӘХНӘ** *г.* — **1**.Театр сәхнәсе (сцена); йорт эче. Мисырдагы солтан Хәсән (хакимлеге 1356-1363 елларга карый) мәдрәсәсендә Исламдагы дүрт мәзһәб аерым-аерым укытыла торган дүрт бүлек үзәктәге *сәхен* яки *сәхнә* дип атала торган бер мәйданга чыкканнар. Шул рәвешле, *сәхнә* сүзе көнбатыш "сцена" сүзеннән алынмаган, бәлки гарәпчәдән кергән дип әйтә алабыз. **2**.Савыт-саба, тәлинкә.

**СИГА, МӨТГА** *г.* — Вакытлы(ча) никах (*никахен мөтга*); вакытлы хәләл җефет. Хәзерге вакытта шигыйлар арасында гына таралган, ләкин аерым шигый җәмәгаләре дә аңа каршы чыгалар, чөнки мондый никах Иранда фахишәлек индустриясендә киң кулланыла башлаган.

Мондый никах балигъ булганнар белән дә, балигъ булмаганнар белән дә һәм алар арасында да төзелә. Ул 1 сәгатьтән алып 99 елга кадәр дәвам итәргә мөмкин. Аерым очракларда якынлык мөнәсәбәтләре күздә тотылмый, ягъни никах фиктив була (чит хатынның йортта авыру яки карт кешене каравы чорында, озаклап кунак булганда, укытуга бәйле вазифалар үтәгән вакытта). Вакытлы хатынның хокуклары һәм бурычлары даими хатынның хокук һәм вазифаларыннан беркадәр аерыла. Беренчесенең шәхси ирекләре киңрәк, ләкин аның иҗтимагый дәрәҗәсе (статусы) түбәнрәк. Сига никахында торучылар бер-берсенең милегенә варис булалар. Вакытлы никахта туган балалар гадәти никахтан туган балалар хокукына ия. Мондый традиция Исламга кадәрге Гарәбстанда яшәп килгән. Сига никахын Гомәр хәлифә тыя һәм шуннан бирле ул сөнниләр арасында кануннан тыш, *нашәргый никах* дип санала.

**СИҖҖИЛ** *г.* — **1**.Тәмуг утында кыздырылган таш (*әхҗаре мин сиҗҗил*). Газап ителергә тиешле кешеләрнең исемнәре шушы ташка язылган була икән. **2**.Яндырылмаган кирпеч.

***СИҖҖИН*** *г.* — Җәһәннәмнең иң түбәнге каты. Кайбер чыганакларда ул җирнең җиденче каты дип күрсәтелә, кяфирләрнең гамәл дәфтәрләре шунда саклана икән. Фәрид хәзрәт Сәлман аны "Иблис һәм аның токымнарының җыелган урыннары" дип аңлата. // *Юк, үлчәүдә хыянәт итмәгез, тәхкыйк хыянәтчеләрнең гамәл дәфтәрләре сиҗҗиндәдер.* "Коръән тәфсире", 83:7.

***СИЛСИЛӘ*** *г.* — Чылбыр; тезмә; рәт, бер-берсенә бәйләнеп килгән әйберләр җыелмасы; сөяләлә. Кайчагында *шәҗәрә* мәгънәсендә дә йөри. Мәс., *"тарикать силсиләсе"* — тарикатьләрнең нәсел шәҗәрәсе дигән сүз. Бу шәҗәрә йә Мөхәммәд Пәйгамбәргә, йә аның берәр сәхабәсенә барып тоташа. Ясәвия тарикатенең силсиләсе Мөхәммәд галәйһиссәламнән, нәкыш- бәндия исә Әбүбәкердән килә. Кайбер чыганакларда "Силсилә дүрттер: әүвәл — Хуҗа Әхмәт Ясәви, икенче — Габделхалик Гаҗдәвәни (Гиждувани), өченче — шәйх Нәҗметдин Кибры, дүртенче — Әбүлхәсән Гыйшык силсиләседер" дип аңлатыла. // *Сәбәпләр силсиләсе* — сәбәпләр эзлеклелеге. *Рухи силсилә.*

***СИЛСИЛӘНАМӘ*** *гф.* — Эзлекле тәртиптә ата-баба исемнәре язылган язма, шәҗәрә, нәсел агачы; суфичылыкта остазлык чылбыры (тарикать силсиләсе).

***СИМСИМ МАЕ*** — Киндер мае. // Ибне Фазлан әйтәдер: "Болгарларда балык маеннан башка май юк. Алар аны зәйтүн мае вә симсим мае урынына тоталар, алар шул сәбәпле исле булалар", дип. Г.Әхмәров.

"Мең дә бер кичә"дәге "Гали баба һәм кырык юлбасар" әкиятендә юлбасарларның хәзинәсе саклана торган мәгарә "Симсим, ач ишекне!" дигәч ачылып китә торган булган. Ихтимал, бу әкиятне киндер чәчәгеннән алынган наркотик тәэсирендә "зиһене ачылып", матур галлюцинацияләр күргән кеше беренче булып сөйләгән булгандыр.

***СИНӘЗАННАР*** *ф.* — Шигыйларда имам Хөсәенне искә алу вакытында (тәгъзийә йоласы) күкрәкләрен йодрык белән төюче актерлар.

***СИРАТ КҮПЕРЕ*** *г.* — Оҗмахка алып бара торган күпер, җәһәннәм уты өстенә корылган. Аның озынлыгы өч йөз еллык юл кадәр булып, беренче йөзе өскә таба менә, икенчесе тигез генә бара, өченче йөзе түбән таба була икән. Күпер ут өстендә торса да, монда караңгы булыр, әмма мөэминнәргә иман нурына таяну мөмкинлеге бирелер, ә кяфирләрдә андый таяныч булмас һәм алар күпердән егылып төшәчәкләр. Сират күперенең җиде чаты бар, чат саен үткен сөңгеләр калкышып тора. Беренче чатта фәрештәләр бәндәдән иманын сорарлар, ышаныч белән дин тотмаган булса, ул сөңгегә кадалып, җәһәннәм утына егылып төшәчәк. Икенче чатта намазын сорарлар, өченчесендә — уразасын, дүртенчесендә — зәкятне ничек бирүен, бишенче чатта-хаҗга ничек баруын, алтынчы чатта — кешенең тәһарәт вә госеле турында, ниһаять, җиденче чатта адәмнең ата-анасына, туганнарына, кардәшләренә китергән яхшылыклары хакында сорарлар. Чыганакларда сират күперен кичә алмаган гөнаһкярлар башта *Гаййә коесына*, аннары җәһәннәмгә егылып төшәрләр дип күрсәтелә.

Сират күпере туктаусыз чайкалып торганга, таянычлары булмаса, бәндәләр котыла алмаслар. Хак мөэминнәрне күпердән Мөхәммәд галәйһиссәлам үзе алып барыр. Колларны Йосыф пәйгамбәр ияртер, байларга — Сөләйман пәйгамбәр, дәрвишләргә — Гайсә пәйгамбәр, гарипләргә — Әйүп хәзрәтләре, сукырларга — Гозәер галәйһиссәлам билгеләнгән булыр һ.б.

Гомумән, сират күперен үткәндә бәндәләргә дөньялыкта кылган изге эшләре таяныч бирерләр.

Мөселманнарны сынау өчен сират күпере аша үткәрү идеясе зәрдәшт дине йогынтысында килеп кергән дип уйлыйлар Зәрдәштләрдә аларны яклаучы Вай исемле алла вафат булганнарның җаннарын, Чинват күпере аша алып чыгып, тиешле урынга илтә.

Сират күпере кылдан нечкә, кылычтан үткен дигән сүз бар.

Кайбер сөйләшләрдә (Пенза өлкәсе Кузнецк сөйләше, Нижгар өлкәсе Сергач сөйләше) *салават күперен* сират күпере дип тә атыйлар.

***СИРӘТ*** *г.* – Гарәпчә биография (тормыш юлы), яшәү рәвеше. Сөннәнең системага салынган материаллары һәм аерым биографияләр. "Сирәте Рәсүлуллаһ" – VIII гасырның икенче яртысында Багдадта Пәйгамбәрнең Ибн Исхак (704-767) төзегән һәм IX гасырда Ибн Һишам (вафаты 834 елда) тарафыннан әдәби эшкәртелән биографиясе. Тарихи чыганак буларак мөһим хезмәтләрнең берсе. Ибн Исхак Ислам йәһүди һәм нәсраниларның изге тарихын дәвам иттерә һәм тәмамлый дигән фикер үткәрә. Ибн Исхакның хезмәте төгәл схема буенча төзелгән һәм өч кисәктән тора: *әл-Мөбтәда* – дөнья яратылганнан алып борынгы пәйгамбәрләрнең тарихы; *әл-Мәбгас* – Мөхәммәд Пәйгамбәрнең тормыш юлы (һиҗрәгә кадәр); *әл-Мәгази* – Мөхәммәд Пәйгамбәрнең яулары (вафатына кадәр).

Гарәп әдәбиятында башка затларның-мөселман хакимнәренең һәм мәшһүр галимнәрнең сирәтләре дә билгеле.

Сирәт сүзе "гореф-гадәт, кешенең үз-үзен тотышы" мәгънәсенә дә ия. // *Казан халкы ... татар мулласының кыланышын, сирәтен күрергә зарыгып тора иде.* Фатих Әмирхан.

Тагын кара: ***СИЯРӘТ.***

***СИХЕР, СИХЫР*** *г.* – Бозу, күз бәйләү; гайре табигый булып тоелган ысуллар кулланып, гадәттән тыш күренешләрне булдыру.

Ислам диненең сихергә һәм сихерчеләргә карашы "Бәкарә" сүрәсенең 102 нче аятендә аеруча ачык чагыла. "Тәфсир Ногмани"да сихер китабын шайтаннар язганлыгы әйтелә. Бабил шәһәрендәге ике фәрештәгә (*Һарут* белән *Марутка*) сихер гыйлеме иңдерелә, шул сихерне шайтаннар кешеләргә дә өйрәткәннәр. Шуңа да Һарут белән Марут сихерчеләрнең һәм багучыларның химаячесе булып исәпләнә.

Сөләйман пәйгамбәр сихернең хуп күрелә торган төре *"әт-тарика әл-мәхмүдә"* не белгән дип сөйлиләр. Сихернең бу төре Адәм галәйһиссәламнән һәм аның кызы Анактан ук килә дип исәпләнелә. Фарси мифлардагы тылсымлы җамаяк иясе Җәмшид патша да андый сихерне белгән диләр. Мондый "кануни" сихерне *әр-рухани* дип атаганнар һәм аны да ике төргә – югары, илаһи, *рахмани* төргә һәм түбән, *шайтани* төргә бүлеп караганнар.

Ә сихернең тыелган *"әт-тарика әл-мәзмума"* дигән төре Иблиснең үзенә үк барып тоташа. Иблис бу белемен кызы (яки улының кызы) Байдаһага тапшырган имеш.

Мөселман дөньясында алхимия һәм астрология дә мәгълүм урын тотканнар. Көнкүрештә төрле юраулар, тылсымлы бөтиләр еш кулланылган.

Бозу кылучылар үзләренең явыз гамәлләрендә җеннәр белән бәйләнешкә кереп, төрле агулар, тоз, аю, бүре, дуңгыз, кәҗә сөтләре, адәм сөте, күрем каны һәм үсемлекләрдән абага, арыслан тырнагы, аю колагы, аю табаны, аю тәмәкесе, бака гөле, бизгәк үләне, бүре бөресе, бүре җиләге, бүсер үләне, давыл чәчәге, кара тамыр, карга күзе, кытай кычытканы, лыбырдык үләне, таштишәр үләне, убыр табагачы, шайтан таягы, эт үләне, әрнеткеч үлән, үги ана яфрагы, шулай ук алма, борыч, дөге ярмасы, ачы камыр, кавын-карбыз, нәхуд орлыгы, җитен орлыгы кулланганнар. Сихерне яшел, кызыл, сары ташлар белән, җиде гүр яки җиде мәчет туфрагы белән, ике, өч, дүрт юл туфрагы белән, эт сөяге яки этнең тиресе белән, дуңгыз сөяге, тиресе, төге белән яки дуңгызның дүрт аягы белән, дуңгызның үте белән, ишәкнең корыган башы яисә ишәкнең баш мие белән, куй сөяге, киек сөяге, төге һәм тиресе белән дә кылганнар.

*Кырык төен төйдерү* һәм *ашка катып бирү* дә – кешене сөйдерү яки биздерү өчен эшләнә торган сихер төрләреннән. Беренчесендә сихер догасын укып, бау яки җепкә төеннәр ясаганнар, ә икенчесендә дога укып әфсенләнгән тоз-борыч кебек тәмләткечләрне яки башка бер ризыкны кешенең ашына кушып биргәннәр.

Сихерләү вакытына килгәндә, аны *Зөхәл* йолдызы (Сатурн планетасы) сәгатендә, *Мәрих* йолдызы (Марс планетасы) сәгатендә, *Гыйтар* йолдызы (Меркурий планетасы), *Мөштәри* йолдызы (Юпитер планетасы) сәгатьләрендә кылганнар. *Кояш* һәм *Айны* да ярдәмгә чакырганнар.

Сихернең тәэсир итү сере нигездә кеше психикасына, аның акылына да, күңеленә дә йогынты ясауга кайтып кала, ягъни сихергә дучар булган кеше моны ишетеп белергә, хәтта шикләнгән шәхес турында да хәбәрдар булырга тиеш. Ә психик тәэсир бик

көчле була. Мәс., кыргый халыклар арасында гаебе ачылып үлемгә хөкем ителгән кешегә берәү дә кул якмый, чөнки бер-ике көннән ул үзе үлә. Асылда ул үзенең яшәү көчен, яшәү теләген һәм ихтыярын җуя.

Әлбәттә, электә халык "сихерне кире кайтару" өчен төрле алымнарга һәм чараларга мөрәҗәгать иткән.

Сихерне рәд кылу (кире кайтару), бетерү, батыйль кылу (яраксызга чыгару) өчен якты көнне сайлаганнар яки Ай яктысында, йолдызлар янганда, Коръән сүрәләре һәм кирәкле догалар укып, чын күңелдән ышанып эш иткәннәр. Психологлар монда нәкъ менә ышануның, инануның хәлиткеч урын тотканлыгын әйтәләр. Бу вакытта укыган догалар һәм теләгән теләкләр, инану белән бергәләп, организмның барлык тән һәм рухны саклагыч көчләрен авыруга яки күңелгә утырган шикләнүләргә каршы туплыйлар.

Электә сихерне кире кайтару алымнары һәм ысуллары бәян ителгән китаплар татар телендә дә чыккалаган. Аларны "Рәднамә", ягъни "Кире кайтару китабы" дип атаганнар. Бу китапларны хорафатчыллыкта гаепләү бик ансат, әмма аларда иҗаби (позитив, кулай) мәгълүматлар да җитәрлек. Асылда андагы алымнар бүгенге психотерапевтлар "аутоген тренинг" (тренировка) дип атаган нәрсәдән әлләни аерылмыйлар.

Шундый рәднамәләрнең берсеннән өзек китерәбез:

"Бисмилләһи-р-рахмәни-р-рахим.

Аллаһы Тәгаләнең исеме белән сыенамын сихерче хатыннар сихереннән.

Сихерне кылырга теләсәләр йә кылсалар—һәммәсен үзләренә кире кайтарырмын, сихерләрен батыйль кылырмын.

Сихерне минем алдымда кылсалар да, артымда кылсалар да, кайчан гына кылмасыннар—үз башларына булсын, үзләренә кире кайтсын. Аллаһы Тәгаләнең шушы аятенең хакы-хөрмәте өчен һәммәсен рәд кылырмын.

Бисмилләһи-р-рахмәни-р-рахим.

Куль әгүүзү бирабби-л-фәләкъ миң шәрри мә халәкъ үә миң шәрри-н-нәффасәти фил-гукад. Үә миң шәрри хәмдин изә хәсәд.

Шушы аять хакында рәд кылырмын һәм батыйль кылырмын."

Аятьнең мәгънәсе: "Әйт: саклаучыны сорыймын Алладан—таңны яратучыдан, шул нәрсәләрнең явызлыгыннан (ул барлыкка китергән сары еланнардан, чаяннардан, дию-пәриләрдән), төн караңгылыгы җәелгәндәге явызлыктан, сихерчеләрнең явызлыкларыннан (унике төенгә укып өргән сихерче хатыннардан, көнчеләрнең хөсетлегеннән).

Бисмиләһи-р-рахмәни-р-рахим.

Куль әгүзү бәрабби-н-нәс мәләки-н-нәс илаһи-н-нәс миң шәрри-л-үәсүүәси-л хәннәс әллази үәсүисү фи судури-н-нәс мин-әл-җиннәти үә-н-нәс.

Шушы аять хакында рәд кылырмын һәм батыйль кылырмын.

Аятьнең мәгънәсе: "Әйт: саклаучыны сорыймын Алладан—адәмнәрнең, пәриләрнең, фәрештәләрнең Раббысыннан, пәриләрнең һәм барча хайваннарның патшасыннан, барчаларының илаһысыннан. Күңелне аздыручы шайтанның явызлыгыннан, кешеләрнең һәм җеннәрнең йөрәкләренә вәсвәсә салучы шайтаннан сакла.

Һәр сихергә, нәрсә белән кылсалар да, һәммәсен рәд кылырмын һәм батыйль кылырмын."

Сихерне кайтару догалары еш кына шактый озын, аларны күп тапкырлар кабатларга туры килә, шуңа күрә рәд кылу гамәле берничә сәгатькә сузыла, ягъни аның өчен тыныч һәм уңайлы шартлар кирәк дип саныйлар.

Ләкин Исламда күрәзәләргә һәм багучыларга, имләүче вә сихер кайтаручыларга йөрү һәлак булу вә һәлак итүдән башка нәрсә түгел дип каралганлыгын истә тоту лязим.

Иске әдәбиятта сихерче, күз буучы, күрәзә мәгънәсендә фарсы теленнән кергән *җаду* сүзе дә очрый.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Миркасыйм
Госманов

# ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

*Була шундый кешеләр: бер карагандa, алар синең тормышыңа, язмышыңа әлләни тәэсир дә итмәгән кебек. Гади танышларың сыман гына шунда.*

*Ләкин син, нигәдер, аларны бер дә онытмыйсың, оныта алмыйсың. Вакыт-вакыт булса да, аларның гадәт-холыклары, әйткән сүзләре хакында уйланасың. Фәлсәфәләрен, тормышка карашларын, эш нәтиҗәләрен тулысынча үз итмәгән, кабул кылмаган хәлдә дә исеңнән һич тә чыгармыйсың аларны. Кылган гамәлләрен, әйткән сүзләрен үз вакытында әлләни җитди кабул итмәгән, хәтта үзләреннән бераз көлгәләп йөргән булсаң да, аларны гел истә тотасың.*

*Димәк, элегрәк үзең әлләни сизмәсәң дә, тәэсирләрен татыган булып чыгасың.*

*Андый, үзләренә күрә кызыклы дип әйтимме, гыйбрәтле дип бәялимме икән, «җитди һәм сәеррәк» кешеләр, бу очракта дөресрәге картлар, гадәттә күп тә түгелдер, аз да булмастыр. Ихтимал, һәрвакытта да җитәрлек буладыр андыйлар. Минем үз тормышымда шундыйрак булып тоелган берничә картның хатирәсе һаман да күңелдә саклана. Үз вакытында көлкелерәк тоелсалар да, хәзер төптәнрәк уйласаң, алар матур кешеләр, хәтта матур картлар, гыйбрәтле шәхесләр рәвешендә һаман хәтердә яшиләр икән.*

*Шулардан, әйткәнемчә, ике картны мин аерата истә тотам. Аларның берсе университетның татар бүлегендә эшләгән укытучыларымнан доцент Якуб ага Агишев (1899-1972) иде. Икенчесе—Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми хезмәткәре Хәй, дөресрәге, Габделхәй ага Хисмәтуллин (1895-1977).*

*Икесе ике төрле, бер-берсенә бөтенләй диярлек охшамаган кешеләр. Буй-сыннары, бит-кыяфәтләре буенча да бөтенләй башка. Ләкин аларны бер үк вакытта нәрсәдер үзара якынайта да, охшашрак итә дә иде. Нәрсәләре белән шулай бер-берсенә охшаганнардыр алар, анысын хәзер дә төгәл әзеп әйтә алмыйм.*

*Уйлануларым һаман дәвам итә.*

*Алар белән аралашуы, сөйләшүе дә күңелле һәм җиңел була иде. Яшь араларыбызда зур аерма барлыгына карамастан, кордашлар кебегрәк шаярышып алгалаган вакытлар да булгалый иде.*

*Бәлки, истәлекләремне бераз тәртипкә салып, кәгазьгә төшерсәм, үзем өчен дә аңлаешлырак булыр. Башкаларны да, ихтимал, уйландырыр.*

*Болардан Хәй Хисмәтуллин белән элегрәк, үзен күргәнче үк, танышырга туры килгән иде.*

## Хикмәтле карт

1956-1957 елларда, әле Казакъстанда яшәгән чакта ук, Казан университетына укырга керергә ниятләнгәч, миңа татар теле һәм әдәбияты буенча мәктәп программалары нигезендә әзерләнә башлау кирәк иде. Казаннан, «Книга—почтой» хезмәте аркылы соратып, татар мәктәпләре өчен чыгарылган дәреслекләр алдырдым. Чөнки, үз сөйләшемдә жирле, ягъни диалекталь үзенчәлекләр һәм шул яклардагы кардәш төрки телләрнең тәэсире шактый булуын белгәнгә, миңа үз телемне бераз «үтүкләү», арулландыру зарур иде. Шуңа күрә әдәбият һәм грамматика дәреслекләрен жентекләп өйрәнергә тотындым.

Дәреслекләрнең икесе дә миндә, дөресен әйткәндә, шактый сәер хисләр уятты. Мәсәлән, татар әдәбияты буенча төзелгән китаплардагы татар язучыларына карата бирелә торган билгеләмәләрдә аларны рус әдипләре белән чагыштырып бәяләү

очраклары бар иде. Әйтик, «татар Пушкины», «татар Островские», «татар Горькие» ише. Димәк, татар тормышындагы әдәби күренешләргә, аерым иҗатларга шулай рус культурасы күзлегеннән бәя бирерлек дәрәҗәдә булгач, татар мәктәпләренә кергәнче, ягъни балалар бакчасыннан ук безнең халык балалары рус әдәбиятын шулай шәп беләләр булып чыга?!

Төрле яклап уйланырга туры килде, һәрхәлдә. Уйлануларның нәтиҗәсе генә күңелле түгел иде, әлбәттә... Шулай да урта мәктәпне русча тәмамлаган, гомумән классик рус әдәбиятыннан бераз хәбәрдар булган минем өчен әлеге алым файдалы да булып чыкты—күп баш ватып торасы юк...



Грамматика дәреслекләрендә исә икенче төрдәге сәерлекләр игътибарны җәлеп итте. Һәрбер кагыйдәдән соң мисал рәвешендә китерелә торган сүз тезмәләренең, җөмләләрнең һәр өченче-дүртенчесендә диярлек «матур» дигән сүз очрый иде. «Тормыш матур», «хезмәт матур», «колхоз матур», «көн матур» ише. Катлаулырак җөмләләрдә дә шул ук бер бәя—«матур» сүзе гел «сакта торган» булыр.

Мондый алымның еш кулланылуы тәшвикать (пропаганда) тәэсиреме, әллә китап язучыларның дөньяны шулай гел матур итеп күрергә теләүләре нәтиҗәсеме—болар минем өчен ачык түгел иде ул чакта. Ләкин бер сүзнең шулай адым саен кабатланып торуы тешкә тия бит. Өстәвенә, эчке Русиягә караганда тормыш шартлары күпкә яхшырак булган Казакъстандагы чынбарлыкны үз күзләрең белән күреп торгач... Шулай да миндә ул чакта бер шаян кызыксыну да барлыкка килгән иде. Һәр ясалма тел мисалын шулай эзлекле рәвештә «матурлаган» авторларның үз төс-кыяфәтләре нindирәк икән соң? Матурмы икән?!

Авторлар дигәч тә, әлеге дәреслекләр нигездә ике кеше тарафыннан язылган иде. Ләкин мин алардан, нигәдер, Хәй Хисмәтуллинны гына хәтерлим. Күрәсе килә иде матурлыкка сусаган шул кешеләрнең үзләрен! Һәм, күп тә узмый, аларның берсен мина еш күрергә, хәтта соңрак аның белән беркадәре аралашырга да насыйп булды.

Университетта укый башлауга ук без, беркадәре хезмәт стажы белән укуга кергән олырак яшьтәге студентлар, шул елларда яңадан активрак оештырыла башлаган төрле әдәби, музыкаль кичәләргә йөрергә тырыша идек. Кызыксынучанлык, иҗтимагый активлык безне хәтта гыйльми конференцияләргә дә кертеп утырта иде. Шундый конференцияләрнең берсендә сүз филология фәннәре кандидаты Хәй Хисмәтуллинга биреләчәге игълан ителгәч, мин сагаеп көтә башладым.

Трибунага тәбәнәк кенә буйлы, әгәр тагын бераз тазара төшсә, квадрат ук дип әйтерлек базык гәүдәле бер карт килеп басты. Ул, биек трибуна артыннан бөтенләй күренми каласын үзе дә сизгән сыман, трибунаның янына басып сөйли башлады. Түгәрәк йөзен калын пыялалы күзлек бизәгән. Чәчләре чак кына агара башлаган, кыска итеп кыркылган мыеклы. Буе кечкенә булуга карамастан, йөз-чырае эре гәүдәле кешенеке кебегрәк иде. Пөхтә ак күлмәге, карарак төскә якын кәстүм-чалбары аның кыяфәтенә җитдилек өстәгән шикелле. Җыеп әйткәндә, зур яшьтәге кешеләргә хас матур гына кыяфәтле иде ул. Яшьрәк чагында, күрәсең, тагын да чибәррәк булгандыр. Дөрес, шактый олы яшьтә булгангадыр, бераз башы селкенгәләп ала иде. Селкенгән саен күзлек пыялалары да ялтырап куйгалый. Мин үземнең Казакъстанда чактагы ирония катыш кичергән уйларымны искә төшереп, үз алдыма елмаеп куйдым.

Конференция әдәбият тарихы мәсьәләләренә багышланган иде бугай. Һәрхәлдә, Хәй агай борынгы текстларны өйрәнү, гыйльми хәрәкәткә яңа истәлекләр кертү хакында сүз башлап, «Дастаны Бабахан» дигән бер әсәрне телгә алды. Аның татар җирлеге истәлеге икәнлеген раслый торган дәлилләр китерде. Мин, дөресен

әйткәндә, ул мәлне Хәй агай фикерләренә сокланып утырдым, үземнен элегрәк, аны күрмәгән килеш, анардан көләргә теләвемнән уңайсызланып та куйдым. Ләкин сонрак нәкъ шул истәлек хакында аның белән кызу бәхәскә керәсемне, дастанның татар җирлеге әсәре булмавын әйтеп, аның кәефен кырасымны ул мизгелдә әле белми идем, әлбәттә.

Бу очрашудан соң да Хәй ага Хисмәтуллинны тагын берничә кат тыңларга туры килде. Бер яктан карасаң, ул—заманча фикер йөртә торган чын совет чоры галиме. Шул ук вакытта аның кайбер сүзләреннән, фикерләү үзенчәлегеннән элекке чор зыялыларына хас сыйфатларны да чамалап була иде. Моңа игътибар итүнең, бәлки, үз сәбәбе дә булгандыр. Мәсәлән, укытучыларыбыздан Якуб ага Агишев, бер әңгәмә вакытында болайрак әйтеп куйган иде: «Безнең хәзерге галимнәр арасында чын мәдрәсә белеме алган бер генә кеше калды, ул—Хәй Хисмәтуллин. Гомумән, күпне күргән тәҗрибәле кеше, үзенә күрә хикмәтле, мудрыйлыкка ия карт». Бу сүзләрне беркадәре раслый торган очракларга соңрак үзем дә якыннан шаһит булдым. Чөнки яшьләребез арасында аерма зур булса да, Хәй ага белән әкренләп якынлаша башлау барлыкка килде. Моңа, ихтимал, мәнфәгатьләребезнең бер тирәдәрәк йөрүе, мәсәлән, язма истәлекләр белән кызыксыну да сәбәп булгангадыр.

1964 елның җәе иде. Касыйм ягына археографик экспедициягә җыенып йөргән көннәрем. Университет капкасы каршындагы кечкенә генә Лобачевский бакчасы янында озын буйлы Әбрар Кәримуллин белән тәбәнәк сынлы Хәй ага Хисмәтуллин, «Кәтүк белән багана» дигән артистлар образын хәтерләтеп, кыза-кыза сөйләшеп торалар иде. Яннарына килеп исәнләшкәч, бәхәснең ни хакында баруы белән кызыксындым.

—Менә Әбрар,—диде Хәй ага бераз дулкынланып,—беткә ачуланып туңны ягарга җыена. Үзен эштән куганы өчен үпкәләп, шәхси китапханәсен, архивын университетка түгел, безнең институтка калдырырга тели. Үзе үлгәч. Мин исә университет китапханәсенә бирү дөресрәк булыр иде дим. Чөнки университетны император хәзрәтләре нигезләгән. Ул яши, тагын да яшәячәк. Унҗиденче елдан соң да исән кала алды. Ә безнең институтны сәвит ясаган, сәвит бетүгә ул да бетәчәк. Яки үзебез үк бетерәчәк без аны!

Университет китапханәсендә директор урынбасары булып эшләгән Әбрар Кәримуллин үзе төзегән бер библиографик күрсәткечкә Сталинга багышланган китапларның исемнәрен кертә. Шуның өчен өлкә комитеты бюросының карары белән эштән чыгарыла. Ул көннәрдә эшсез йөргән, үз хезмәткәрен якламавы өчен университетка, бигрәк тә аның проректоры Мансур Абдрахмановка нык үпкәләгән Әбрар агай Х.Хисмәтуллинның әлеге сүзләрен дә, башка дәлилләрне дә колагына элмәде. Аның үз фикерендә нык торуын күргән Хәй ага селкенгәләп тора торган башын бераз чалшайта төшеп, биегрәк буйлы Әбрарга астан өскә таба карап, соңгы хөкемен чыгарды:

—Кызма әле син, Әбрар энем, архивны биргәнгә хәтле әле яшисе дә, үләсе дә бар бит! Үлгәнчегә кадәр фикерең дә үзгәрер, бәлкем. Ничек диләр әле урыслар: «челавек предполагает, бух располагает», диләрме?..

Лобачевский бакчасы янындагы бу сөйләшү искә төшсә, хәзер дә елмаеп куям. Хәй аганың совет дәүләте, Тел, әдәбият һәм тарих институты бетү хакында әйткәннәре ул чакта миңа тормышка ашуы катгый рәвештә мөмкин булмаган дуамал, мәгънәсез сүзләр сыманрак ишетелгән иде. Әмма утыз ел да үтмәде, совет хакимияте дә җимерелде, башка үзгәрешләр дә барлыкка килде. Дөрес, элек СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы составында булган Тел, әдәбият һәм тарих институты яңа оешкан Татарстан Фәннәр академиясенә алынды. Ул хәзер нигездән үзгәреп, ике институтка бүленде. Ягъни «үзебез үк» үзгәрттек.

Ә.Кәримуллинның шәхси китапханәсенең язмышы да башкача хәл кылынды: китапларның бер өлеше Төркиягә китте, акчасы хуҗасының дәвалануына тотылды. Икенче өлеше һәм архивы Татарстан Милли китапханәсендә саклана хәзер.

Шулай итеп, Хәй аганың «үлгәнчегә кадәр үзгәрү», «предполагает, располагает» хакындагы сүзләре тулысынча диярлек расланды...

Әлеге очрашуның тагын бер истәлеге калды: шул әңгәмә бетүгә эшсез интегеп

йөргән Әбрарны бергә-бергә кульязмалар эзләр өчен Касыйм ягына сәфәргә чакырдым. Ул сөенеп риза булды...

* * *

Хәй Хисмәтуллин белән икенче бер сөйләшү дә онытылмый. Аның «Азат хатын» журналында басылган бер мәкаләсендә әллә ни тәфсилләмичә, дөресрәге, совет чорында кабул ителгәнчә, махсус тәнкыйтьләп, ягъни гаепләп, сүгеп тормыйча, Йосыф Акчура телгә алынган була. Кемдер, әләкләп, партиянең өлкә комитетына хәбәр итә. Анда исә ду кубалар: ничек инде ак эмигрант, Русия һәм русларның явыз дошманы булган «буржуаз милләтче», пантюркист хакында язып торырга? Кайда соң монда «партиячел принципиальлек»?!

Журнал редакторларына шелтә белдерү белән бергә өлкә комитетында мәкалә авторының да «кирәген бирергә» дигән карарга киләләр. Шул юнәлештә кайбер әзерлекләр дә башлана сыман. Әлбәттә, күнелсез имеш-мимешләр хакындагы хәбәрне Хәй агага да ирештерәләр. Ул исә шул төнне үк үзенең «зур ялгышлар» җибәрүе хакында тәүбәләр укый-укый өлкә комитеты секретаре исеменә махсус хат яза, иртәгесен аны тиешле адрес буенча тапшыра. Бу хакта әдәпле карт редакциягә дә кереп сөйли һәм журналны уңайсыз хәлгә төшерүе өчен гафулар үтенә.

Х.Хисмәтуллинның болай эшләве кайберәүләргә, җөмләдән минә да, ошамаган иде. Мондый гамәлне куркаклык яки принципсызлык дип бәяләү ягында идек. Шуңа күрә бер очратуда мин аның әлеге эшеннән риза түгеллегемне белдердем, кыза-кыза үз дәлилләремне саный башладым:

—Сезнең мәкаләдә бернинди дә сәяси, тарихи хата, тәүбә итәрлек бер нәрсә дә юк бит! Йосыф Акчура да советлардан качкан ак эмигрант түгел ләбаса! Ул 1908 елда ук Русиядә башланган реакциягә протест йөзеннән Төркиягә һиҗрәт иткән, ягъни законлы рәвештә күченеп киткән кеше бит! Аннары Яңа Төркия белән ул вакытта күп илләр тарафыннан танылмаган СССР арасында дипломатик мөнәсәбәтләр, хезмәттәшлек урнашуга да зур өлеш керткән шәхес ул Акчура! Совет дипломаты Аралов истәлекләрендә моның хакта бик ачык әйтелә...—Калын пыялалы күзлеген ялтырата-ялтырата тынлап торган Хәй аганың башы ешрак селкенә башлады. Аннары «тукта!» дигән сыман кулын изәп алды да, бер-бер артлы тезеп китте:

—Син генә түгел, мин дә яхшы беләм боларны! Акчураның Бишенче елдан соң рус политиклары белән ихлас хезмәттәшлеккә омтылуын да. Җиденче елдан соң, Русиядә демократик үзгәрешләргә тәмам өмет өзелгәч, чын реформалар юлына баскан Яңа Төркиягә китүен дә шулай ук әйбәт беләм мин! Ә инде тәүбә хатына килгәндә, алай кырыс хөкем чыгарырга ашыкма син, энем. Ярар, шуны да уйлап кара: мин ул хатны язмаган, гаепне үз өстемә алмаган булсам, нәрсә килеп чыгар иде? Уйладыңмы шуны?! Иң киме рәсми гәзиттә бер редакцион тәнкыйть мәкаләсе басылыр, журнал редакторы эшеннән алыныр иде. «Совет әдәбияты»нда Әмир Нәҗипнең Алтын Урда хакындагы мәкаләсе, дөрес эчтәлекле мәкаләсе өчен Газый Кашшафны эштән алуларын, аның урынына әдәбиятка бөтенләй катнашы булмаган чиновник куелуын белмисеңмени?.. Алай гына түгел, «кайбер идеологик хаталар» дигән чираттагы карарның да чыгуы, тагын гомум эзәрлекләүләр башлануы да ихтимал иде бит, егетем. Редакция хезмәткәрләренә, шәхсән миңа да эләгүдән тыш, янә Йосыф Акчураның бүгын чәйнәү, пычрак төкерекне башкаларга да чәчү бик ихтимал иде бит! Үзең беләсең, обкомның бер ишарәсе булуга һаулый башларга әзер торучы кутыр кәнтәйләр җитәрлек бездә! Ә болай бер мин генә, бары бер кеше генә гаепле булып калды. Моннан гына тарихи дөреслек җимерелмәстер бит, шулай бит?!..

—Ул хатыгызны киләчәктә укырлар да...—дип, киная белән үз позициямне акларга тырышкан идем, Хәй ага тагын сүземне бүлдерде:

—Ярар, синеңише тормышны яхшы белмәгән бер сары авыз кызу башлысы укыр да, «Х.Хисмәтуллин дигән бер куркак бәндә булган икән», дип әйтер ди. Йә,

шуннан нәрсә үзгәрә?! Мин исә җәнҗалның хәзер чын-чынлап зурга китүеннән, башкаларга зыян килүдән курыктым. Тора-бара үзен дә аңларсың әле моны. Йосыф Акчура хакында да адәм рәтле итеп яза башларсыз. Вакыты житкәч, әлбәттә. Ә мин бераз ашыкканмын шул...

Бәхәсне дәвам итәрлек урын калмаган иде. Саубуллашып китә башлагач, Хәй ага тагын өстәп куйды:

—Әйтүләре дөрес булса, минем хатны укыгач, обком секретаре: «Вопрос не будем раздувать, старик пусть доживает»,—дип әйткән, имеш. Эткә бер сөяк тә житә икән!

Соңгы сүзләр мине тетрәндереп җибәрде. Хөкем сөргән идеологик, сәяси системага тугрылыклы булып тоелган, күп еллардан бирле шул системага хезмәт итеп килә торган, утызынчы еллар «сират күпереннән» дә ничектер исән-сау чыга алган кешенең әлеге системага нәфрәте дә ярылып ята иде аларда...

Башкалардан ни көтәргә?..

Хәй аганың «вакыты житкәч» дигән фаразы да расланды: Йосыф Акчура турында хәзер «адәм рәтле» языла башлады инде. Казандагы кечкенә генә булса да бер урам хәзер аның исеме белән атала...

* * *

Якуб ага Агишев әйтмешли, үзенә күрә «мудрыйлыкка», хәтта, мин әйтер идем, хәйләкәрлеккә дә ия булган Хәй ага кайвакытларда балаларча садәлек (наивлык) та күрсәтә иде. Бәлки, шул садәлек, беркатлылык артында хәйләкәрлек тә яткандыр?

1968 елны Шиһабеддин Мәрҗанинең тууына 150 ел тулу уңае белән «Казан утлары» журналында (№1) минем «Мәрҗани турында берничә сүз» дип исемләнгән мәкаләм басылып чыккан иде. (Ренат Харисның тәкъдиме белән аның бик популяр эшләнгән варианты шул ук гыйнвар аенда «Яшь ленинчы» газитендә дә дөнья күргән иде.) Гомумән совет чорында дип әйтерлек, һәрхәлдә, Ватан сугышыннан соң Мәрҗани хакында басылган беренче махсус мәкалә булды ул. Җәмәгатьчелек тарафыннан ул мәкалә олуг галимебез эшчәнлеген, аның бай мирасын яңа баштан өйрәнә башлауның беренче кыю адымы кебегрәк кабул ителгән иде. Күпләргә баш өстендәге чалмага гына карамыйча, чалма астындагы башка да игътибар итәргә иде дигән сүзләр ошаган булуы ачыкланды.

Бу очракта шуны да истә тотарга кирәктер, мөгаен. Шуннан ел ярым элек Хөсәен Фәезханов хакында «Казан утлары»нда чыккан «Олы мирас» исемле күләмле мәкаләм дә файдаланылган чыганакларның муллыгы, яңалыгы, төплелеге белән тиешле яңгыраш тапкан иде. Шуңа күрә Мәрҗани хакындагы әлеге махсус чыгышым, кайбер кимчелекләре булуга карамастан, тагын да саллырак яңгыраган иде. Гәрчә һәр икесе дә танылган мәгълүм галим тарафыннан түгел, бәлки монарчы билгесез аспирант каләме белән язылган өйрәнчек әйберләр булса да.

Дөрес, Мәрҗани мирасын олылау өчен сөенүчеләр күп булган шикелле, бу адымга шикләнебрәк караучылар да табылды. Кайберәүләр үземнән: «Парткомга чакырмадылармы үзеңне?», яисә «КГБ егетләре килмәдеме янына?»—дип сораштыргалаган иде. Ләкин, әллә заманасы алышынуга таба йөз тоткан, әллә кешеләре үзгәрә башлаган, һәрхәлдә, бернинди «ул-бу» килеп чыкмады әлеге публикацияләрдән соң. Бәлки, киресенчә, буа ерыла башлаган төсле башка чыгышлар да барлыкка килгәләде. Мәсәлән, «Казан утлары» журналы, «Яшь ленинчы» газитенең саннары таралып атна-ун көн узуга өлкә комитетының рәсми органы булган «Социалистик Татарстан» газитендә дә Мәрҗани хакында бер мәкалә чыккан иде. Аны редакциянең соравы буенча Шакир Абилов язган иде. Боз кузгалган кебегрәк булды әлеге 1968 елда.

Моның шулай икәнлеге тиздән үзен тагын да яхшырак сиздерә башлады.

Бер көнне ишек шакыдылар. «Керегез, ачык!» диюгә ишектә иң элек күзлек пыялалары, шома итеп кырылган түгәрәк чырай пәйдә булды, аннары кара кәстүм-чалбарлы, ак күлмәкле Хәй аганың базык гәүдәсе күренде. Култык астында папкасы бар иде.

—Өең якын булгач, алдан сөйләшеп тормыйча гына килдем әле,—диде ул.

«Өй» дигәч тә, анысы ул вакытта университет китапханәсенең (янасы түгел, ишек алдындагы искесенең) артындагы элекке ат абзарыннан хезмәткәрләр өчен хәстәрләнгән «көнбатыш ярым-циркуль»дагы тулай торакның унике-унөч метрлы бер кечкенә бүлмәсе иде. Диван-карават, кием шкафы, тактадан оештырган китап киштәсе, балалар ятагы, аш өстәле, арзанлы карсак суыткыч белән тыгызланган бүлмәдә бер урын табып, Хәй аганы шунда чакырдым. Табуретка утыргач, ул игътибар белән бүлмә буйлап бер күз йөртеп алды. Аннары буйыйсы урынга обой белән генә тышланган, такталардан оештырылган киштәгә, йокы диваны өстендә гел «бармак янатып тора торган» китапларга озак кына карап утырды.

—Торагың әйбәт кенә икән,—диде.—Иң мөһиме—китапханә янында гына. Әллә кайларга барып йөрисе түгел. Гыйлем кешесенә ни кирәк тагын! Болай фатирына бәреп керүгә гаҗәпләнмә син. Бер мөһим эш килеп чыкты әле. Шиһаб хәзрәт Мәрҗанинең сайланма әсәрләрен басмага әзерләргә дигән карарга килдек. «Мостафад әл-әхбар» китабының беренче томын, пачти тулысынча, башка хезмәтләреннән дә сайланма өзекләр алырга исәп. Әлбәттә, хәзерге әдәби телгә күчереп, гарәпчә текстларны тәрҗемәләп бирербез. Менә шул китапка сине гыйльми редактор итеп чакырырга исәп. Шуңа ризалыгың кирәк иде.

—Кызык идея,—дидем мин һәм сорап куйдым,—дирекция, бигрәк тә директор үзе нинди фикердә?

Чөнки институт директоры Мидхәт Мөхәррәмовның бик сак кеше икәнлеген белә башлаган идем.

—Ничек дим инде, ул чыннан да бик сак кеше шул. Ләкин Альфред Халиков, Җәмил Гыйльманов, Сәлам Алишлар, шулай ук башка тарихчылар да бик уңай карыйлар бу мәсьәләгә. Өстә дә каршы булмаслар шикелле. Мәкаләләр чыкты бит инде.

—Мәкаләләрнең үз дәрәҗәсе,—дидем мин шик-шөбһәмне белдерергә теләп,—китапка карата мөнәсәбәтләрнең икенчерәк булуы ихтимал. Муллалык тамгасы нык сугылган бит...

—Алай ук түгел инде хәзер,—диде ул көр тавыш белән,—заманалар әкренләп булса да үзгәрә. Әнә моңарчы чыккан мәкаләләрне дә әйбәт кенә «йоттылар» бит. Аннары обкомда да тарихны аңлый торган фән кандидатлары, хәтта докторлар да бар. Алар арасында аңлы кешеләр дә җитәрлек бит. Син, давай, артык шикләнмә, ризалыгыңны бир!

Авызы әллә ничә кат пешкән картның мондый наив өметенә гаҗәпләнсәм дә, өлкә комитетында утырган әлеге кандидат-докторларның үзләреннән күбрәк шикләнсәм дә, артык бәхәсләшмәскә булдым. Сонра, эшләр барып чыкмаса, «син дә карыштың» диюләре мөмкин бит. Шуңа күрә сүзне икенчерәк якка бордым:

—Кем әзерли ул җыентыкны? Китап кайчаннар өлгерер икән?

—Дөресен әйткәндә, мин күптән эшли башлаган идем. Бөтенләй әзер дип әйтергә дә ярый. Кайбер вак-төяк өстәмәләр генә калды.—Төп мәсьәлә буенча килешенгәч, Хәй ага култык астындагы папкадан машинкада басылган бармак калынлыгы кульязма чыгарып, миңа сузды:

—Мәрҗани хакында бер популяр китап та язып куйган идем. Аны да карап чыгарсың инде.

Монысына да риза булдым. Тәҗрибәле галим күрсәткән ышанычтан горурланып та куйдым хәтта. Язманың кайбер битләренә күз ташлап утырганда Хәй ага торып басты:

—Кара аны, бу әсәрем үземә бик тә ошый! Яратып яздым мин аны! Шуны онытма, ярыймы?

Монысы инде «тәнкыйтьләп, бәйләнеп маташма» дип әйтергә теләведер. Ирексездән елмаеп җибәрдем. Хәй ага исә моны үзенчә аңлады бугай, канәгать чырай белән горур гына китеп барды. Орчык кадәре кечкенә, дөресрәге, тәбәнәк буйлы картта никадәре җегәр, көч һәм алга таба матур омтылыш дип сокланып калдым. Омтылган нәрсәләренә ирешүен теләдем.

Әмма Мәрҗани китабы дөньяга чыкмыйча калды. Китапның эшләнеп беткән

кульязмасын өлкә комитетына соратып алдыралар һәм аны рецензиягә философия фәннәре докторы, университетның фәнни эшләр буенча проректоры профессор Мансур Абдрахмановка бирәләр. Күрәсен, махсус күрсәтмә-теләк белән бергә биргәнгә охшый. Шуңа күрә ул үз рецензиясенең ахырында: «Билгеле Казан мулласының нигездә мәчетләр һәм муллалар хакында XIX гасырда язылган бу китабының бүгенге көн совет җәмгыяте өчен кыйммәте, кирәге бар микән соң?..» дигән рәвештәрәк нәтиҗә ясаган, диделәр.

Коммунистларча партиялеге, партиячел принципиальлеге белән автоном республикада киң танылган, депутат һәм Югары советның рәисе дә булып торган мөхтәрәм профессорның мондый кырыс хөкеменнән соң, билгеле, китап турында сүз кузгатырга урын калмый.

(Җәяләр эчендә булса да шуны өстәргә кирәк табам. 1972 елда бугай, миңа бер эш белән Мансур ага Абдрахмановның өендә булырга туры килгән иде. Төп тема буенча сөйләшү тәмамлангач, ул, җаен китереп, әлеге рецензиясе өчен, кыеклап дигәндәй, аклана башлады. Кульязмада китап төзүче җибәргән «кимчелекләр, методологик җитешсезлекләр» булуын әйтте. Сүзләрен, ниһаять, шундыйрак фикер белән очлады:«Берәр сәләтле, белемле егет булса, үземә аспирантурага алып, Мәрҗани хезмәтләре буенча диссертация яздырыр идем. Аның мирасы, һичшиксез, өйрәнелергә лаек. Ләкин искечә түгел, яңача өйрәнергә кирәк аны. Хөкем сөргән гомум идеология, политика белән дә исәпләшергә кирәк. Өлкә комитетында мәсьәләнең менә шул ягына игътибар иттеләр».)

Шулай да, Мәрҗани китабы, икенчерәк, Әнвәр Хәйри әзерләгән вариантта барыбер дөнья күрә алды. Дөрес, егерме еллар чамасы узгач кына (1989), Яхъя Абдуллин редакциясендә. Хәй ага язган, әлеге «үзенә бик тә ошаган» популяр китабы исә 1968 елда ук басылып чыккан иде. Чорына хас чикләнгәнлекләре, тиражының ул чор өчен чамалы булуына карамастан, Хәй аганың ул хезмәте Мәрҗани мирасын киңрәк белдерү юлында үз бурычын беркадәре үтәде дип әйтергә мөмкин. Аның бер нөсхәсе авторының: «Миркасыйм дус! Карт көнемнең бер истәлеге. Хисмәтуллин. 26.VI.68» дигән кечкенә автографы белән хәзер дә китапханәмдә саклана.

* * *

Хәй ага Хисмәтуллин белән соңгы очрашуларның берсе тагын Лобачевский бакчасына туры килде. Әкрен генә атлап, эштән кайтып баручы карт мине күрүгә кулын изәп чакырды һәм якындагы утыргычка барып чүкте.

—Аяклар...—дип куйды мин янына килеп утыргач, аннары шаяртып та алды.— Йә, нәрсәләр җимергән булып йөрү? Үзгәртәсеңме соң бу фани дөньяны?

Минем дә кәеф шаянрак дулкында иде.

—Сез бизәп, тәмам матурлап бетергән дөньяны үзгәртеп тору кирәк булыр микән соң?

—Аңламадым,—диде ул җитдиләнә төшеп,—минем алай дөньяны бизәүгә дәгъвам булмады шикелле...

—Дәгъва булмаса да, нәтиҗәсе ташка басылган бит, Хәй ага!

—Тагын да аңламадым. Нәрсәгә ишарә итәсең? Ачыграк итеп әйт!—үзе күзлеген салдырып яулыгы белән сөртә башлады.

Мин кайчандыр татар теле кагыйдәләрен ул язган дәреслекләр буенча өйрәнүемне, аларда исә һәр җөмлә саен диярлек «матур» сүзенең кулланылуын әйтеп, мондый төчелекнең сәбәбе нәрсәдә, әллә үзегез дә шулай дөньяны үзгәртергә теләдегезме, дип сорадым. Соравым шаян гына түгел, усалрак та килеп чыкты бугай, картның күзлек пыялалары кичке кояшта берничә кат ялтырап алды. Бераздан башы селкенгәләве дә сирәгәйде.

—Алай икән,—диде ул суза төшеп, аннары, бераз уйланып торгач, хикәя сөйләгән төсле салмак кына сөйләп китте.—Син, энем, кешедән көләргә бик яратасың шул. Сәбәбен белмәсәң дә, көләргә тырышасың. Алай ярамый... Сталин чорында, аннан соң да цензураның бездә ничек ачкырыуын белмисең генә түгел, күз алдына да, бәлкем, китерә алмыйсың. Тарихи, әдәби хезмәтләр түгел, хәтта тел белеме буенча

язылган китапларны да кырык иләктән иләп, сөзеп чыгаралар иде. Ни өчен, ничек итеп дисеңме?

Бик гади, хатаны, этлекне мисаллардан эзлиләр иде. Әйтик, үрнәк рәвешендә китерелә торган җөмләләр кемнеке? Кайсы авторның нинди әсәреннән алынган? Берәр тыелган, сәяси гаепләнгән кешенең сүзләре түгелме?.. Алай гына түгел, исән-имин язучыларның әсәрләреннән дә мисалларны чамалап файдаланырга кирәк икән. Янәсе, берәрсеннән күбрәк мисаллар алып, аны классикка әверелдермәс өчен. Шулай ук ул мисалларда сүзлекләрдән куылган гарәп-фарсы сүзләре дә булмасын... Кыскасы, төрле яклап чикләүләр. Шуңа күрә күп очракта мисалларны үзебезгә ясарга, мәгънәләре чиновникларда шик тудырмасын өчен мөмкин кадәр гади, хәтта примитив итәргә, еш кына «бизәп, матурлап» та куярга туры килә иде... Ә син «төчеләнү» дисең. Беләсең килсә, ул төчелекләр чын-чынлап ачыргалану нәтиҗәсе иде... Йә, аңладыңмы инде?—Мин сорауга тиз генә җавап бирү халәтендә түгел идем. Кайчандыр көлкеле, хәтта мәгънәсез булып тоелган күренеш артында никадәр зур фаҗига да ятканлыгын аңладым. Тетрәнүдән гафу да үтенә алмадым ул мәлдә.

—Аннары шуны да сиңа әйтергә теләр идем,—диде Хәй ага уйчан кыяфәт белән.—Син, Миркасыйм энем, гомумән кешеләр, күренешләр хакында кырыс, кискен рәвештә фикер йөртергә, сүз әйтергә яратасың. Алай катгый хөкем чыгарырга ашыкма син. Дөреслек синең генә милкең түгел бит. Гомумән, кешеләр, аларның эшләре турында сүз әйткәндә, арада тагын берәр кешегә җитәрлек урын калдырып сөйлә. Арадан башкалар да, үзеңне бәреп екмыйча гына, узып китәрлек булсын. Дөнья—катлаулы нәрсә ул. Анда бер син генә яшәмисең бит...—Бу нәсыйхәтне тыңлап утырган чакта мин Хәй ага Хисмәтуллин утызынчы еллар «сират күпереннән» ничек сау-сәламәт уза алды икән дигән табышмакка «ачкыч» таба язган шикелле булдым...

Якуб ага Агишев та Габделхәй аганың «ара калдыру» хакындагы әлеге сүзләрен, исемен әйтеп үк, искә төшерергә ярата иде.

Шулай ук Лобачевский бакчасында әлеге нәсыйхәтне ишеткән чакта, мәрхүм әтиебезнең бер сүзе дә кылт итеп искә төшкән иде. Берәр кешене, яисә нәрсәнедер артык мактый яки яманлый башласаң, ул бүлдерә иде:

—Әкрен, әкрен, чамалап. Кирәге чыга калса, яманларга да яки мактарга да урын калсын!

Мондый сәнгатькә өйрәнер өчен, әлбәттә, күп көч, озын гомер кирәк икән...

Ләкин синең үзеңә «узып китәрлек урын калдырмасалар» нишләргә соң?..

*Ахыры киләсе санда*

# Б

**БӘШИРОВА** Зәйнәп Хуҗихан кызы (5.10.1903, Казан губ., Лаеш өязе Балтач а. – 8.7.1984, Казан), шагыйрә. Мәскәү журналистика ин-тын тәмамлый (1928). 1928-30 елларда «Эшче» (Мәскәү) г-тасында эшче яшьләр бүлеге мөдире, 1931-34 тә Горький өлкәсе Кызыл Октябрь р-нында чыгып килгән «Октябрь коммунасы» г-тасында мөхәррир булып эшли. 1935-37 дә Татарстан дәүләт нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты секторында өлкән мөхәррир. 1938-58 дә китапханәче хезмәтен башкара. Шигырьләре 1920 еллар вакытлы матбугатында еш күренә. «Очкыннар» (1921), «Яшь инкыйлабчы җырлары» (1923) исемле шигырь җыентыклары авторы.

Әд.: Гайнуллин М. Зәйнәп Бәширова // Совет әдәбияты. 1963. N8; Фәйзуллин Р. Авылдаш // Казан утлары. 2003. N10.

**БЕЛӘШЕВ** Аллаяр (19 йөзнең ахыры, Рязань губ., Әҗе а. – ?), язучы, төбәк тарихчысы. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. 20 йөз башларында Урта Азиядә мөгаллимлек итә. 1915 елда «Шура» ж-лында беренче шигырьләре басыла. Шул ук елда «Көйле сүзләр бәйләме» дигән шигъри җыентыгы дөнья күрә. Төркестанда яшәүче халыкларның этнографиясенә һәм тарихына багышланган күп кенә мәкаләләр һәм туган авылының тарихи үткәнен бәян иткән «Әҗе авылы хакында» (1924) исемле китап авторы. Шул китапта китерелгән библиографик белешмәгә караганда, Б. дистәдән артык исемдә фәнни-популяр һәм әдәби әсәр язган.

Әсәр.: Төркестан мөселманнары // Шура. 1914. N 22; Көйле сүзләр бәйләме. К., 1915; Әҗе авылы хакында. К., 1924; Өмид (Шигырьләр) // Мирас. 1998. N 4.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БЕЛОСТОЦКИЙ** Юрий Вячеславович (17.4.1922, Таулы Алтай авт. өлкәсе Чой р-ны Ынырга а. – 20.10.1983, Казан), язучы. Чиләбе хәрби очучылар уч-щесен тәмамлый (1941). 1942-45 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Свердловск (1945), Казан (1946-47), Кострома (1947-49) шәһәрләрендә спорт, ДОСААФ оешмаларында эшли. 1949-54 тә «Северная правда» г-тасы (Кострома) журалисты. 1955 тән кабат Казанда: «Советская Татария» г-тасында бүлек мөдире, 1969-76 да Язучылар берлегендә әдәби консультант. 1950 елларда яза башлый. «Кырлар өстеннән самолёт оча» («Самолёт идёт над полями», 1954), «Катлаулы вираж» («Крутой вираж», 1957), «Тревога белән күккә күтәрелү» («Вылет по тревоге», 1978), «Канатка канат куеп» («Крылом к крылу», 1982) повестьлары Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына багышлана. Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Зарипов М. Киңрәк колач белән // Казан утлары, 1975. N11; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**БЕЛЯЕВ** Ислам Габделхак улы (14.3.1926, ТАССРның Тәтеш кантоны Уразлы а. – 21.11.1986, Казан), шагыйрь, журналист. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1954 елдан «Яшь сталинчы» г-тасы редакциясендә (1958-59 да баш мөхәррир), 1959-64 тә КПССның өлкә комитеты инструкторы, 1964-67 дә РСФСР Дәүләт кинематография комитетының Казан кинохроника студиясендә баш мөхәррир, 1967 дән Татарстан китап нәшриятында өлкән мөхәррир. «Кояшлы таулар» (1966), «Кояш законы» (1969), «Язгы яшен» (1976) исемле шигырь җыентыклары авторы. Б.ның поэзиясендә авыл б-н бәйле балачак кичерешләре, романтик омтылышлар өстенлек итә. Күп кенә лирик әсәрләрендә, ш.и. «Чәчәк куям» (1978) җыентыгына тупланган истәлек-очеркларында авторның Бөек Ватан сугышы елларына карашы, һәлак булган яшьтәшләрен, якташларын сагыну, туган җиргә мәхәббәте чагыла. «Солдат төймәсе» (1974; рус теленә тәрҗемәсе «Степные тетради», 1982) повесте булган вакыйгаларга

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2005 ел, 4 саныннан басылып килә.*

нигезләнеп язылган. Б. сценариесе буенча 1966 елда «Габдулла Тукай» исемле документаль фильмы төшерелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*З.З.Рәмиев.*

**БЕЛЯЕВ** Николай Николаевич (23.9.1937, Ярославль ш.), шагыйрь, тәрҗемәче. ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Казан ун-тының геол. ф-тын (1961), М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсны тәмамлый (1975, Мәскәү). Геолог, геофизик, журналист, ТРның Язучылар берлеге әдәби консультанты (1989-92) булып эшли. «Аралар авазы» («Голоса расстояний», 1967, тулыландырган варианты, 1998), «Җил» («Ветер», 1969), «Юл чаты» («Перекрёсток», 1972), «Казан дәфтәре» («Казанская тетрадь», 1980), «Меңъяфрак» («Тысячелистник», 1984), «Лирика» (1987), «Карлыгач эзе» («След ласточки», 2001) шигъри җыентыклары авторы. Б. поэзиясенә эчкерсезлек, әхлак юнәлешләренең аныклыгы, этик мәсьәләләрне чишүдә компромисска бармау хас; аерым очракларда публицистикага тартымлык бар. Шигырьләре б-н шагыйрьнең шәхси кичерешләрен һәм социаль рухын һәрвакыт нечкә аңлаучы замандашына мөрәҗәгать итә. Казанга, Татарстанга багышланган шигырьләр шагыйрь иҗатында аерым урын алып тора. Рус теленә Дәрдемәнд, Һ.Такташ, С.Хәким, Х.Туфан, И.Юзеев, Ш.Галиев, Р.Харис шигырьләрен тәрҗемә итә. 1992 елдан Владимир өлкәсе Собин р-ны Ворша авылында яши.

Әд.: Хаким С. Об этой книге // Беляев Н.Н. Казанская тетрадь. К., 1980; Воздвиженский В. «Как время катится в Казани золотое...» // Беляев Н.Н. Лирика. К., 1987.

*А.Э.Скворцов.*

**БЕНДЕЦКИЙ** Александр Григорьевич (16.1.1911, хәзерге Черкасск өлкәсе Золотоноша ш. – 1.5.1943), язучы, тәрҗемәче. 1932 елдан Казанда яши. Әсәрләре 1930 еллар ахырында басыла башлый. Иҗаты: «Ул кайтыр» («Он вернётся», 1938) повесте, «Ватан сугышы әлифбасы» («Азбука Отечественной войны», 1940) шигъри җыентыгы, «Ил намусы өчен» («За честь родной страны», 1940) шигырь һәм җырлар җыентыгы. Рус теленә Г.Тукай, А.Алиш, Г.Кутуй, С.Хәким шигырьләрен, әкиятләрен тәрҗемә итә. Агитбригадада белән сугышчылар алдында чыгыш ясаганда һәлак була.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиограф. справ. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**БИБИГӨЛҖАМАЛ** (19 йөз), шагыйрә. Кайбер мәгълүматларга караганда, Б. – билгесез бер шагыйрьнең тәхәллүсе. Иҗаты аз өйрәнелгән. Проза катыш шигъри формада язылып, эчтәлеге б-н «Таһир илә Зөһрә» дастаны сюжетын хәтерләткән һәм шигъри юлларында халык авыз иҗаты үрнәкләре (мәхәббәт җырлары, хатлар) киң файдаланылган «Бигайәте мәгъшукнамә» («Чиксез гашыйклык китабы») исемле әсәр авторы. 1888-1915 еллар арасында әсәрнең бик күп басмалары дөнья күрә.

Әсәр.: Бигайәте мәгъшукнамә. К., 1888.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; Яхин Ф. XIX гасыр кыйссасы «Бидгать-намә» // Әдәби мирас. Өченче китап. К., 1996.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БИГИЕВ** Заһир Ярулла улы (1870, Ростов-Дон ш. – 1902, шунда ук), язучы, публицист. Татар әдәбиятында реалистик роман жанрына һәм публицистикага нигез салучыларның берсе. Ахун гаиләсендә туа, Муса Бигиевнең абыйсы. Ростов-Дон шәһәрендә рус мәктәбен тәмамлый, 1886-91 елларда Казанда Күлбуе мәдрәсәсендә укый. 1891 елдан башлап гомеренең ахырынача Ростов-Дон шәһәрендә мулла булып тора. 1893 тә Урта Азия халыкларының тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен өйрәнү максаты б-н Төркестан буйлап сәяхәт кыла. Берничә тапкыр С.-Петербургта, Мәскәүдә, Кырымда була. Рус, төрек, Көнбатыш Европа әдәбиятларын тирән белгән, берничә чит телдә сөйләшкән. Уналты яшендә Б. беренче әсәрен – «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» («Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә», 1887) романын яза. Өч елдан икенче романы – «Гөнаһе кәбаир» («Зур гөнаһлар», 1890) басылып чыга. Бу романнарда әдип 19 йөзнең 2 нче яртысындагы татар тормышының төрле социаль катлауларын тасвирлый, җәмгыятьтәге комсызлык, икейөзлелек, эчкечелек кебек ямьсез күренешләрне тәнкыйтьли, гуманистик позициядән торып үзенең әхлакый идеалларын бәян итә. 1891-92 дә язылган «Катыйлә» («Үтерүче хатын») һәм «Мөртәд» романнары басылмыйча кала, аларның кульязмалары сакланмаган. Б.нең «Мавәраэннәһердә сәяхәт» («Ике елга арасына сәяхәт», нәшере 1908) исемле юлъязма китабы та-

тар әдәбияты тарихында публицистика жанрындагы иң күренекле әсәрләрнең берсе булып исәпләнә. Анда ул 1893 тә Идел буе, Каспий һәм Төркестанга ясаган сәяхәте тәэсирләрен, Төркестан халыкларының авыр тормыш фаҗигаләрен, Россиянең колониаль сугышларына каршы көрәш күренешләрен, бер уңайдан татар халкының язмышы турында уй-фикерләрен бәян итә.

Әсәр.: Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә. К., 1887; Гөнаһе кәбаир. К., 1890; Мавәраэннәһердә сәяхәт. К., 1908; Повестьлар. К., 1960; Татар мәгърифәтчелек әдәбияты. К., 1979; Зур гөнаһлар: романнар, сәяхәтнамә. К., 1991.

Әд.: Гайнуллин М.Х. Татар әдипләре (иҗат портретлары). К., 1978; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; Миңнегулов Х. «Исмең синең милләт яшәдекчә яшәр» // Мирас. 1995. N 11/12.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**БИКМӨХӘММӘД** (17 йөзнең ахыры — 18 йөзнең 2 нче яртысы), язучы. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. Касыйм морзасы Галикәй Аталыкның «Галикәй Аталык васыйәтнамәсе» китабыннан көлеп, пародия рәвешендә язылган «Хәрамнамә» (1690) әсәре авторы. Юрау китабы «Фалнамә» (1690) кульязмасы да аның тарафыннан күчерелгән диган фикер бар.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БИКМӨХӘММӘТЕВ** Роберт Гата улы (11.1.1929, Баш. АССР, Илеш р-ны Илеш а. — 28.8.1995, Мәскәү), әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче, филол. фән. д-ры (1983), проф. (1987). Рус, татар, башкорт телләрендә яза. Казан ун-тын тәмамлый (1952). Беренче хезмәтләре 1948 дә басыла. 1956 елдан Мәскәүдә яши. 1956-59 да СССР ФАнең М.Горький исем. Бөтендөнья әдәбияты ин-тында эшли. 1960-61 дә «Дружба народов» ж-лында баш мөхәррир урынбасары. 1962 дән Мәскәү ун-тының әдәбият тарихы кафедрасында укытучы, милли әдәбият секторы мөдире. Г.Ибраһимов, М.Җәлил, Г.Тукай, Ш.Бабич, Ә.Фәйзи, Һ.Такташ, Х.Туфан, Ә.Ерикәй, С.Хәким, М.Әмир иҗатларын өйрәнә. Хезмәтләренең төп темасы — бөтендөнья мәдәнияте яссылыгында СССР халыкларының милли әдәбиятлары, әдәбиятларны өйрәнүдә тарихи-чагыштыру методологиясе, әдәбиятларның бер-берсенә йогынтысы закончалыклары. «Поэзиябезнең үлмәс чәчәкләре» (1960) китабы татар поэзиясең күпгасырлы үсеш тарихына багышлана. Кайбер хезмәтләре инглиз, немец, поляк телләрендә басылган.

Хезм.: Дорога остаётся. М., 1969; Орбиты взаимодействия. М. , 1983; Муса Джалиль. Личность, творчество, судьба. М., 1989.

Әд.: Шариф А. Не в том ключе // Пути развития советской многонациональной литературы. М., 1967; Ломидзе Г. На уровень новых задач // Вопросы литературы. 1977. N10.

*В.Х.Ганиев.*

**БИКТИМЕРЕВ** Әхмәтҗан (19 йөз ахырлары, хәзерге Яшел Үзән р-ны, Бакырчы а. — 23.05.1915, Томск губ., Тайга ш.), язучы, журналист. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. Урта Азия, Себер, Монголия һәм Төньяк Кытай буйлап озак сәяхәт итә; сәүдә эшләре б-н шөгыльләнә; Самара, Бозаулык, Ташкент, Коканд, Томск шәһәрләрендә яши. 1907-08 елларда Ташкентта «Шөһрәт» г-тасында эшли, «Асия» («Азия») исемле г-та чыгара, «Фикер», «Бәянелхак», «Сибирия», «Идел» г-таларында языша, «Шура» ж-лында төрки халыкларның тарихы, мәдәнияте, тормыш-көнкүреше турында күп кенә мәкаләләр бастыра, арада педагогикага, медицинага багышланганнары да бар. «Үткән мәхәббәт» (Оренбург, 1905), «Ятим Сабир, яхуд Бай кызы» (К., 1907), «Хәлфә» (Эстәрлетамак, 1912) исемле проза китаплары, мәктәпләр өчен «Русия тарихы» (К., 1914) дәреслеге авторы.

Әсәр.: Үткән мәхәббәт. Оренбург, 1905; Төркестан вилайәте // Шура. 1908. N 6,8,12,13,23,24; 1909. N 2,6,10; Хәлфә. Эстәрлетамак, 1912; Русия тарихы. К., 1914.

Әд.: Г.М.Г. Идарәгә мәктүб // Кояш. 1915. 7 июнь; Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. К., 1986. 4 том.

*З.З.Рәмиев, М.И.Әхмәтҗанов.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

Тәлгат
НӘҖМИЕВ

## ШАЯН КӨНДӘЛЕК

### Таң алдыннан өйләнәләр

...1972 елның апрелендә Армиядән кайттым.

Бер атна үтте микән, Саба районы мәдәният йортына эшкә чакырдылар.

Совет урамындагы Мәрхәбә апаның балчык белән сыланып, акка буялган тыйнак кына йортына фатирга урнаштым. Өй эчендә пыяла рамда Габдулла Тукай рәсеме тору да күнелемә хуш килде. Иң беренче эш итеп хуҗабикәнең киселеп, капка төбендә берничә җәй пешеп яткан утынын ярырга керештем.

Кич кырын, сәгать дүртләр-бишләр тирәсендә, мөлаем гына бер кыз, серле генә итеп исәнләшеп үтә бит... Кыскасы, күз төшәрлек иде ул. Гәүдәсе дә җыйнак, елмаюы да май кояшы кебек. Чиләнгән һәм миләнгән бүкәннәрне яра алмыйча азапланып, чәй эчкән арада Мәрхәбә ападан бу егерме яшьләр чамасындагы туташның кем булуы белән кызыксынам.

—Медсестра ул. Бүлнистә эшли. Бакча башында—Камәриядә тора. Төпле егете юк бугай...

Шинелен салып, ялгызлыктан башын кая куярга белмичә: «Кошлар сайрый тирәктә, ашкынулар бар йөрәктә»,—дип йөргән солдатка ашыгыч стратегик чара күрергә кирәк иде. Бәхеткә каршы, шул көннәрдә ниндидер концерт килде. Чакыру билеты алдым да менеп киттем мин бакча башына. Бераз каршы килеп карады да ризалашты тагын күрше кызы.

Саба инеше өстеннән салынган асылмалы басма аша киттек мәдәният йортына. Концерт бик шәп булды. Шул кичтә үк ана анасына тагылган сабый бала кебек ябыштым мин.

Ярар, көннәр үтә. Шулай, әйбәт кенә йөреп торабыз. Яшь вакытта күнелгә иләс-миләс фикерләр дә кереп куя бит. Авылында егете бардыр, анда булмаса армиядәдер кебек тоела. Эчне ниндидер корт кимерә.

1973 елның язгы бер матур көнендә, Лемара минем фатир хуҗама кереп, әнисеннән телеграмма килүе турында әйткән дә юлга кузгалган. Шул хәбәрне ишеткәч, минем йөрәк-бавырым өзелеп төшкәндәй булды. Эчкә тагын җен коткысы керде. Икенче кешегә кияүгә димләмиләр микән, янәсе?!

Читтә егете булып, шул кайтты микән әллә?

Тиз генә киендем дә, чын мәгънәсендә куа киттем. Арча ягына поездның кичкә таба гына китәчәген чамалыйм. Саба авылы башына чыгуга бер йөк машинасы очрады, әрҗәсенә менеп бастым. Бик җилле көн иде. Шәмәрдәнгә җиткәндә, «Мин сине яратам», дип кычкыра торгач, башымдагы эшләпәм очты. Шоферны туктатырга яхшысынмадым. Алга китеп, шуны әйтергә кирәк, соңгы утыз ике ел эчендә бу юлдан мин күпме үткәнмендер, анысын санап булмый. Әмма узган саен машинамның тәрәзәсеннән үрелеп, эшләпә очкан җирне карыйм. Тәлгат Нәҗми һаман шул баш киемен эзли икән, дип уйлый күрмәгез тагын... Урыс әйтмешли, «дело не в шляпе»! Шашынып-хыялланып, сөю һәм сөелү ләззәтеннән «исереп» йөргән көннәремне искә төшереп, яшьлегемне сагынам мин бу урында. Ниндидер, әйтеп булмый торган искиткеч рәхәт мизгел кичерәм.

Кайттым да. Дөрес, алай бик эреп каршы алмадылар. Өйләренә кереп чәй эчтем. Кич клубка чыктык. Анда мин көнләшерлек шикле кешеләр күренмәде үзе.

Йокларга өйгә кертмәделәр. Ике-өч йорт аркылы карт әбинең (булачак бабайның, төп нигезе) келәтенә урын җәелгән икән миңа. Шунда йокладым. Бик туңдым. Чөнки иртә язда төннәр салкын була бит. Суык җелегемә үтте. Тешләр-тешкә тимәде. Хәзер анда бозау кадәр эт—«Вулкан» яши. Шул келәтнең янышнан үткән саен яшьлегемнең, салкын, ямьсез, шыксыз, әмма өметле хатирәсе яңара.

Икенче көнне кыш буе җыелган тиресне ат арбасына төяп, бәрәңге жиренә түктек... Шул мизгелдә бакча башыннан гына бер егет килде безнең янга. «Шушы икән?»—дип уйлыйм эчтән генә. Исеме Ленар булып чыкты. Бедер-бедер сөйләшәләр болар. Мин лычкылдап беткән тиресне каерам.

—Кияүгә чыкмыйсынмы соң әле?—дип сорый Ленар.

—Юк әле,—ди Лемара.

—Болай булгач, озак йөрмәссең инде,—ди тегесе, миңа таба ым кагып...

Эчкә җылы керде.

Егет булып башка кайтмадым бугай Сежегә.

Ярар, матур гына, тәртипле генә йөреп торабыз. Мине алты айдан соң жирле радиотапшырулар оештыручысы итеп редакциягә күчерделәр.

1973 елның июнь аенда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә имтиханнарны (читтән торып уку бүлегенә) уңышлы гына тапшырып кайттым. Мәдәният бүлеге мөдире, остазым Госман Гарипович белән бераз «әңгәмә» корып утырдык.

—Автоклуб өчен микроавтобус тибындагы яңа машина кайтты,— ди бу. — Өйләнсәң, биреп торырмын, яме,—дип тә өстәде...

Кичен Лемарам янына ашыктым. Сагынышканбыз. Әмма күңелсез хәбәр җиткерде бу миңа. Әнисе тагын чакырып телеграмма суккан моның. Башыма кабат әллә нинди азгын уйлар килде. Мәңгегә югалтмаммы? Кыскасы, кот очудан тиргә баттым, аркамнан кара тараканнар чабышып үткәндәй булды. Шуннан ике дә уйлап тормыйча, әйтеп салдым:

—Бүген өйләнәм мин сиңа! Яңа машина да кайткан.

Һәм тыкрык буйлатып күтәреп диярлек алып та төштем. Ерак түгел бит. Хәләлемнең бер кулыннан тоткан килеш тәрәзәгә шакылдатам. Мәрхәбә апа (ул—элеккеге Таҗи мулланың карчыгы) чыкты.

—Мондый эш булмый. Икегезнең дә әти-әниегез бар. Башта авылларыгызга кайтып, рөхсәт сорагыз,—ди бу.

—Минем бүтән тәкатем калмады. Фәрештәләрнең «амин» дип дога кылган минуты җитте. Бар, төш, шу,—Лемара фатирына—Камәрия апа янына,—дип бик каты итеп әйттем.

Нишләсен бичара карчык. Таягына таянып, без төшкән тыкрыктан юк булды бу...

...Икенче көнгә мәдәният бүлеге мөдиренә шылтыратам.

—Госман абый, берничә көннән машина кирәк булачак бит. Өйләндем мин.

—Кайчан?

—Бүген. Таң алдыннан.

## Уңайсыз...

Авылга кайтып киттек. Бабай белән әбидән бик әйбәтләп кызларын сорый башладым. Бабай каршы килеп маташкан була. Икебезгә бер «зәхмәтне» кәктек. Шуннан йомшап китте. «Уйлап бетерербез»,—диде дә йокларга чоланга чыгып китте.

Әби безгә урынны алты почмаклы өйнең түр ягына, сап-сары итеп юылган идәнгә җәеп бирде (бик әйбәт кеше ул). Кызы «мәсьәләнең» хәл ителгәнен әйткәндер инде. Иртән бабай өй ишеген ачып, өч-дүрт җөмләле фатихасын әйтте:

—Монда уйлап бетерәсе калмаган икән инде. Аллага тапшырдык!

Без, шагыйрь әйтмешли, киттек Казанга туп-туры карап. Укырга керү-кермәү ачыкланмаган бит әле. Бигрәк барысы бергә өелде. Чыдаган башка рәхмәт.

«Катык поезды»ннан төшеп, университетка юл алдык. Ак колонналары белән каршы алды ул безне—нибары бер тәүлек гомер иткән яшь гаиләне. «Монда Ленин, Толстой кебек олы шәхесләр укыган»,—дип таныштырам җәмәгатемне.

Беренче катка кереп, игъланнар тактасы янына килдек. Боерыклар чыккан. Әнә—безнең группа. Әмма фамилиямне таба алмыйм. Күзләрем әлҗе-мөлҗе килә.

Ин беренче Лемара күреп алды (ярый аны алып килгәнмен әле). И сөенештек. «Күрдеңме, юк-бар кеше алмады сине!»—дигән булам. Тизрәк кайтып китәргә ниятләдек. Әле үземнең әти-әнидән дә өйләнергә рөхсәт сорыйсы бар бит...

Шундагы бер белдерүгә күзем төште. Шул ук көнне сәгать икедә «установочная сессия» башлана диелгән. Егыл да кит. Ярты сәгать вакыт калган. Бер килсә, килә бит ул. Бичәмне яшь Ульянов һәйкәле янындагы «таба» кырыена утырттым да, лекциягә кереп киттем. «КПСС тарихы»ннан икән беренче дәресләре. Эдуард Еникеев дигән укытучы шундый салмак кына, җайлы гына итеп укый инде менә. Үтереп-үтереп йокыга тарта. Тагын шагыйрь әйтмешли, баш мәтәлә алга да, баш мәтәлә артка да...

Ике пар лекциягә генә түземлек җитте. Шылдык әкрен генә вокзалга.

Шулай итеп, студент һәм кияү (ир) булу ләззәтләрен берьюлы кичерә-кичерә, газиз әти-әниемнән өйләнергә фатиха алып, Байлангар авыл Советына никахны законлаштырырга гариза калдырдым да, без өйләнгәч төн кыска булды, дия-дия, уникe көнлек беренче сессиягә китеп бардым.

Уңайсыз булса да языйм әле. Шул кадәр озак булып тоелды ул тәүге тапкыр аерылулар. Ярый әле группада Лемарага тач ошаган бер кыз бар иде (фамилиясен язмыйм, йә ире көнләшер)... Лекция буе «ашардай» булып, шуңа карап утырам. Ошаса ошар икән. Суйган да каплаган. Бит уртасында мәхәббәт чокырына кадәр туры килә. Утыра торгач, күзләр дә очрашкалый, оялып та куям үзем.

## Һәм укыйбыз...

Сулар ага торды. Габдулла Тукай урамындагы Дәминова Гөлсем апаның ишегалдындагы кечкенә өенә башка чыктык. Өч тәрәзәле шушы тыйнак кына йортта үткән көннәребезне хәзер дә сагынып искә алабыз. Утын ягып җылыта идек. Лемарага декрет ялы бирделәр. Өебез кечкенә булса да нурлы, җылы. Мин эштән кайткач, укыштыргалаган да булам. Тагын сессиягә барасы, имтиханнар тотасы бар бит. Лемара да булышырга теләк белдерде. Әлеге дә баягы «История КПСС»тан конспект язарга тотынды бу «беспартийная» башы белән. Берме-икеме калын дәфтәр сырлады. Укып карыйм, каймагын гына сөзеп бара инде, малай.

Тормыш матур гына дәвам итә. 19 май—Пионерия көнне улыбыз туды. (Алга таба узып шуны искәртим: кызыбыз Гөлназның дөньяга аваз биргән көне—29 октябрьдә—Комсомол бәйрәмендә, оныгыбыз Гадел дә Татарстанның мөстәкыйльлек көнен сайлады. Үзебез дә Совет Армиясе һәм 8 Март тирәсен

чамалаганбыз). Шомырт чәчәге өстенә ап-ак кар яуган иде ул иртәдә, күршеләр бакчасыннан бер кочак чәчәк җыйдым да (рөхсәт белән, билгеле), киттем нәселебезне дәвам итүчене күрергә! Әле әнисе аякка басмаган иде. Ниязны алып чыгып күрсәттеләр. Үземнең «курнос» борынны шундук таныдым. Җәмәгатемә исән-сау терелүен теләгән кош теледәй кәгазем белән күчтәнәчләремне керттердем дә, малай белән мактанырга редакциягә йөгердем.

Ә минем шомырт чәчәкләремнең исе палатага гына түгел, бөтен коридорга таралып, дару исләрен хәйран баскан икән.

Ул чәчәкләрнең закымы озакка барды. Колхозларда, фермаларда йөргәндә асыл затлар танып: «Мин синең Лемаран белән бергә бәбәй таптым. Безнең мужиклар еш килә алмадылар, килсәләр дә букет күтәреп йөрмәделәр, авылда чәчәк кайгысымыни анда! Алып төшкән ризыгына, шомырт чәчкәләренә рәхмәт»,—дип әйтүчеләр булгалады әллә ничә еллар үткәч тә.

Менә инде хәзер читтән торып университетта өчәүләп укый башладык. Доцент Флера апа Сафиуллина «Татар теле белемен кереш»тән керә иде (хәзер ул фәннәр докторы, профессор, дистәләгән китаплар, дәреслекләр чыгарды). Таләпчәнлеге истә калган аның.

Мөхтәрәм мөгаллимәбез безгә «Телләрнең генеалогик классификациясе»н ятларга биргән иде. Шуның күләмен ничек тасвирлыйм икән? Общий дәфтәрдәге өч кушбитнең һәр шакмагына ике багана итеп берәр тел (барысы 200гә якын) тезелеп төшкән иде. Шуның кайсы телгә, төркемгә, нинди төркемчәгә кергәнен истә калдырырга кушты һәм җәйге сессиягә килгәч, болай диде Флера апа:

—Әгәр дә телләр классификациясен ятламаган булсагыз, мина имтиханга кереп тормагыз...

Мин шулай иттем дә. «Койрык» белән кайтып, җәй буе Лемара белән шуны өйрәндек. Тота да имтихан ала бу: «Удмурт» теле кая керә?

Мин карамыйча: «Фин-угыр телләренең Пермь төркемчәсенә»,—дим. Аннан сорасам, ул да белә, ятлап бетергән бит, малай. Без шул «каһәр төшкән» телләрне өйрәнә башласак, бишектән Нияз да «мес-мес» итеп яткан жиреннән: «Ыгы-ыгы»,—дип тавыш бирә. Тәмам өйрәнеп беткәч, «дүртле»ле куйдырып кайттым. Югары белемне әнә шулай бик тырышып, бөтен гаилә белән, ягъни заманча әйтсәк, «семья подряды» нигезендә алдык без...

## Гаилә плюс бәхет?..

Нинди зур мәгънә салынган бу ике сүзгә. Гаилә бәхете ул—бер-береңә һәрчак кирәк булып, бер-береңә ышанычлы таяныч булып бер түбә астында мөмкин кадәр килешеп яши алудыр. Менә без утыз ел Сабанын саф һавасын сулап, уртак фикерләр белән хыялланып яшәгәнбез икән, димәк, монда нәрсәдер бар инде...

Гомер буе хезмәт сөючәнлеге белән аерылып торды ул. Декрет ялы бетәр-бетмәс, балаларны карарга кеше табып, эшкә чыкты. Ул заманнарда өчәр ел өйдә тору мөмкинлеге юк иде. Бер минутын да бушка уздырмады, «белем»гә йөрмәде, капка төбенә чыгып утырып, «ләчтит» сату кебек мавыгулардан ерак торды. Лемарамның иң теләп башкара торган эше—чәчәкләр үстерү. Гөлләрне бик ярата ул. Җәй көне бакчабызда, алай-гына түгел ишегалдыбызда аларның берничә дистә төрен очратырга мөмкин. Узган җәйне өстән-өстән генә санаган идек, илле җиләгә җитте алар. Мәсәлән, розаның гына берничә төре—алсуы, кызылы, ак белән кызылның бергә кушылганы, хәтта кытай розасы да бар. Өйдәге гөлләрнең саны кырыкка тулган инде. Ул аларны сабый кебек тәрбияли, сөйләшә, исемнәре белән эндәшә. Читтән шыпырт кына карап торсаң, әллә җинеләя микән дип тә уйлап куярга мөмкин.

Бер елны хәсрәтле дә булдык. Шул көннәрдә ахирәт дусты Нәсфия шылтыратты.

—Хәлләрегез ничек?—ди бу.

—Коточкыч начар,—минәйтәм.

—Бер-бер төрле нәрсә булдымы әллә?

—Булды шул, булды.

—Нәрсә булды? Сузма, әйт инде?..

—Лемараның сары розасы бетләде...

## Мин үзем җайлы кеше...

...Күптән түгел генә салынган абзарыбызның озынлыгы ошап бетмәде хуҗабикәгә. Шуның печәнлек өлешен кыскартырга кирәк дип берничә тапкыр әйтеп карады ул. «Кычытмаган жиренне кашыма әле»,—дип нокта куйдым бу әңгәмәгә.

Яңа ел алдыннан Казаннан алтын куллы энесе, ягъни минем каениш Лемарик кайтты. Минем өйдә юклыктан файдаланып, печәнлекнең шул өлешен сүтеп ташлаганнар болар. Бер атна буе, карлы буран астында, үзгәртеп кору белән шөгыльләнделәр. Төгәлләү өлеше Яңа ел чыршысы ачылган көнгә—24 декабрьгә туры килде. Кешеләрнең хатыннары кышкы сабантуйда—шул тантанада мәш киләләр. Ә минеке—түбәдә.

Кайткач:

—Фейерверклар ничек булды соң?—дип сорадым.

—Шәп,—диделәр апалы-энеле,—моннан, түбәдән әйбәтрәк күренә икән ул.

Гомумән, Лемараның, андый гына вак-төяк балта эшләре кулыннан килә. Чөнки бабай тимер һәм агач эшен бик булдыра. Каннан киләдер инде. Берсендә, кайтсам, осталар ясаган өйгә керә торган баскычны сүтеп җыеп ята бу. Лемарик белән мин ясаган эт оясын да ошатмады хуҗабикә. Аны кечерәйтеп, түбәсен матур гына итеп калай белән ябып куйган үзе. Кыскасы, күңеленә охшаганчы, канәгать булганчы тырыша ул, максатына ирешмичә туктамый.

Тормыш итәргә мин үзем дә җайлы, тыныч кеше инде. Теге вакытта: «Абзарны ник кыскарттыгыз!—дип тә тавышланмадым. Минем Лемарага үз гомеремдә бер тапкыр да: балтаны дөрес тотмыйсың, яисә кадакны туры какмыйсың, дип кисәтү ясаганым юк. Нервысын бозсаң, кан басымы күтәрелә аның. Болай да җәй житә башласа, борчылып тора. Эссегә чыга алмый. Бакчада кичен, төнге уникеләргә кадәр эшли, чәчәкләре, яшелчәләре арасында кайнаша. Капка төбендәге электр баганасына ишегалдын яктырта торган итеп лампочка куйдырттым. Шуның яктысына рәхәтләнә инде эшләп. Миңа рәхмәт укый. Үзем иртән торып язарга гадәтләнгән мин. Шуңа күрә кыска җәйге төннәрдә ул ятканда, ә мин торып маташканда очрашкалыйбыз без...

Хөрмәтле асыл затлар, сез инде бу кеше хуҗалыгында бер дә эшләми икән, русча итеп әйткәндә «работадатель» ролен генә үти икән, дип уйлап куйгансыздыр. Һич алай түгел.

Ир-ат вазифалары тулысынча минем өстә. Табу-кайтарту, эшләтү һәм башкалар. Язын жир казу, тирес һәм ком кертү, түтәл әзерләү кебек чараларны җыйнаулашып башкарабыз. Хәтта оныгыбыз Гадел дә уенчык «КамАЗ»ы белән ком ташый, тик машинасының бензины гына тиз бетә.

Әхәт Сафиуллин

## АЧЫКЛЫК КИРӘК!

ПАМФЛЕТ

Валлаһи дип әйтәм, быелгы ел илебез тарихына (анда гына сыйса әле!) ришвәтчелеккә каршы көрәштә иң кискен борылыш елы булып кереп калачак: барлык ришвәтчеләрнең эш хакларын арттырдылар! Дөрес эшләделәр: эшкә килүгә ришвәт турында түгел, эш турында гына уйласыннар! Икенче яктан, моны ачыклык дип тә карарга кирәктер: хәзер безнең халык иң ришвәтче ришвәтчеләрнең кем икәнлекләрен дә белде. Бу инде ришвәтчелек мәсьәләсе, ниһаять, бөтен ил буенча рәсмиләштерелде дигән сүз. Димәк, хәзер инде халык ришвәтчеләргә ришвәтне әнә шул рәсмиләштерелгән хезмәт хакларыннан ким бирергә ярамаганлыкны да белеп торачак. Әйтик, берәр йомыш белән Путин янына керергә телисең ди. Моның өчен башта аның ярдәмчеләренең берәрсенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ә аның хезмәт хакы, ришвәтчелек өчен дә өстәгәч, сиксән мең чамасы! Димәк, хәзер аның янына илле мең белән генә килә алмыйсың инде. Чөнки хәзер ришвәтчеләргә ришвәтне ришвәт алмасыннар дип күтәрелгән акчаларыннан ким төртү гомумән килешми. Монысы да ачыклык бит аның!

Беркөн үз Президентыбыз да үзебезнең ришвәтчеләребезне җыеп, әгәр дә ришвәт алуыгызны дәвам итәсез икән, икенче тапкыр җыйганда журналистларны да чакырам, дип котларын алды. Ришвәт дигәннән, аның һәр нәрсәгә үз бәясе бар икән. Баланны балалар бакчасына урнаштыру өчен бер бәя, югары уку йортына кертүгә икенче бәя, малаенны армиядән йолып калуның үз бәясе. Президент әйтүенчә, малаең солдат киеме кимәсен дисән, кырык мең сумыңны җәлләмәскә кирәк. (Шунысы сөенечле: Президентыбыз ул бәяләрне яттан белә диярлек - ришвәтчеләрне куркытканда әйтеп күрсәтте. Димәк, ришвәтчеләргә каршы көрәш төгәл мисалларда барачак.) Армия турында ишетүгә үк, мин күршем янына атылып кердем.

—Альбертыңны армиядән калдыру өчен нишләп туганнарыңнан илле мең сум җыеп йөрисең син, - мин әйтәм. - Кырык мене дә житә икән ич—әле генә Президент үзе әйтте!

—Ә арадашчылар?—диде ул мина.—Бардын да төрттен генә түгел, башта бирер кешесен табарга кирәк бит әле аның. Президент шунысын искә алмаган...

Ай-яй, бу арадашчыларның житмәгән жирләре юк, валлаһи! Мин аларны Чубайс белән Миллер тирәсендә генә бөтереләләр дип йөри идем, баксан, безгә дә килеп житкәннәр икән бит!

Менә шул арадашчы халыктан котыла алсак, ришвәт хакы да шактый кими төшәр иде. Тик алар тамырын бары тик бу мәсьәләгә дә тулы ачыклык кертү юлы белән генә корытырга мөмкин. Ә моның өчен ришвәт бирүне үтә күренмәле (хәзер өстәгеләр ачыклыкны шулай дип атап йөртә) итәргә кирәк. Әйтик, хөкүмәт һәр нәрсәне хәл иткәндә бирелергә тиешле ришвәт күләмен

билгели, аны Дума аша үткәреп законлаштыра, Президент кул куеп, ике башлы каракош сурәте төшерелгән мөһер шапылдатып үз көченә кертә. Менә аннан соң тиешле йомышыңны йомышлаган өчен тиешле ришвәт хакын законлы рәвештә расланган тиешле прейскурант буенча тиешле кешесенә тиешенчә тапшырасың да, ришвәтче исә аны синең намуслы рәвештә биргәнеңне, үзенең намуслы рәвештә кабул итеп алганын раслап, мөһер суккан рәсми бланкта рәсми белешмә язып кулыңа тоттыра. Сизәсеңме, монда инде арадашчының бер тиенлек тә кирәге калмый! Ә ришвәтче үзе алган шул ришвәтеннән ришвәт салымы түләргә тиеш.

Хөкүмәт казнасына ришвәт салымы да керә башласамы?! Ул хәзер керә торган салымнардан дүрт-биш мәртәбә артык булачак, чөнки безнең тормышны ришвәт белән изгән, ришвәт белән баскан. Менә шуннан соң балалар пособиесен дә актыгында сөткә җитәрлек итеп арттырырга мөмкин булачак. Хәер, ул хәзер дә аз түгел инде түгелен: тәп-төгәл җитмеш мең сум! Трамвай билеты ике мең сум торган чактагы акча белән. Ә хәзер ул җитмеш меңне алу өчен безнең ил баласы тәп-төгәл мең ай, ягъни сиксән өч ел бала булып калырга тиеш. Ләкин, ни кызганыч, балалык чоры алайга сузыла алмый... Шул ук вакытта пособиеләрен дә арттырып булмый, чөнки балалар ришвәт алмый. Ә ришвәт алмаганнарга кем өстәсен?! Шуңа күрә социаль пособие дигән нәрсәләре көненә ике сум да утыз өч тиен килеш кала инде...

Тагын бер нәрсә. Минемчә, Президент, хөкүмәт ришвәткә каршы көрәш белән бергә урлауга каршы көрәш буенча да кискен борылыш ясарга, ягъни ришвәтчеләрнең ришвәтчелек өчен өстәлгән хезмәт хакларына караклык өчен дә шул дәрәҗәдә үк өстәргә тиеш. Чөнки ришвәтчеләребез караклык белән дә бик эзлекле һәм нәтиҗәле рәвештә шөгыльләнә бит. Шулай булгач, урлау турында түгел, эш турында уйласыннар өчен дәүләтебез каракларының, ягъни шул ук ришвәтчеләрнең хезмәт хакларын тагын бермә-бер арттырырга кирәк. Тик монда да ачыклык булсын—кайдан күпме умыруыннан чыгып (урлауларын барыбер дәвам итәчәкләр, чөнки чир китәр, гадәт калыр, ди халык), барлык караклар да караклык салымы түләргә тиешләр! Әгәр дә мәгәр ришвәтчелек салымы кушылган казна байлыгына караклык салымы да өстәлсә, ул чагында безнең акча Казан Кремлен тагын бер кат стена белән әйләндереп алырга, шул стеналарны тагын бер кат чит ил яктырткычлары белән урап чыгарга, аны тәүлегенә егерме дүрт сәгать яктыртып торырга һәм күгебезне фейерверклар белән зур бәйрәмнәрдә генә түгел, ә һәр ял көнендә балкытырга, тагын бер-ике җиргә мәңгелек ут ягып, сугыш һәм хезмәт ветераннары хөрмәтенә, буш шешәләр җыеп йөрүче пенсионер скульптурасын бастырып куярга да җитәр иде.

Кыскасы, бездәге акча, кемдер әйтмешли, санап бетергесез! Бары тик ришвәтчеләр белән караклар тыйнаклыгыннан гына котылырга кирәк. Менә шуннан соң яшәп күрсәтер идек без!..

Бу хатны «Казан утлары»н 1988 елдан башлап бүгенге көнгәчә яздырып алып укучыгыз Шафикова Рәшидә яза. Миңа инде 72 яшь. Кырык ел шәфкать туташы булып эшләдем. Инде ялдамын, II группа инвалидмын. Башлангыч мәктәпне дә, уртасын да туган телебездә укыдым. Бәхетле булдык шуның өчен, рәхәтләнеп ана телебездә, туган телебездә сөйләшәбез. Җәй айлары авылга, туганнар, якташлар янына кайткач, «Апа, сез күптән шәһәрдә яшәсәгез дә, бер дә рус сүзләрен кулланмыйсыз»,—дип әйтәләр. Ә хәзер авылда беренче сыйныф балалары рус телендә укыйлар! Шул балаларны кызганам. Болар инде Габдулла Тукайны, Һади Такташны укучы булырлармы дип йөрәгем әрни. Дөрес, татар телен дә укыталар, чит тел өйрәнгән кебек… Журналымны күршеләремә, танышларыма да укытам, алдагы елларныкын китапханәгә тапшырам. Сезнең журнал ярдәме белән гәрәпчә укырга өйрәндем, зур рәхмәт сезгә. Латинча язылган текстларны яратып укыйм. Шигырьләрне көтеп алам. Сәхнәгә чыгып Һ. Такташ, М. Җәлил шигырьләрен сөйләгән чакларым булды…

Оренбург өлкәсе, Новотроицк шәһәре.

* * *

Мин «Казан утлары» журналын 41 ел рәттән алдырам. Гомерем буена яратып укыган журналым—«Казан утлары», яратып тыңлаган радиоым Татарстан радиосы булды. Алгач та иң беренче шигырьләрне укыйм, 1-2 мәртәбә. Аннан чәчмә әсәрләрне, аннан тәнкыйтьне. Хәзер олы яшьтә мин, 80 белән барам, күзләрнең күрүе дә кими…

Туып-үскән җирем Оренбург өлкәсе, Иске Шалты авылы. Шунда гомер итеп, 83 елны Башкортстанга килергә туры килде, язмыш кушуы буенча. Сагынган чакларымда, кайгылы чакларымда «Казан утлары»н укып, Татарстан радиосын тыңлап, җаныма тынычлык, рухи азык алдым. Алты бала үстереп, алар бар да таралып бетте, бабаем белән икәү торып калдык. Шөкер, әле дә «Казан утлары» бар, шуны укыйбыз, һәрбер санын көтеп алабыз. Татарстан радиосына да безнең рәхмәтләребезне тапшырсагыз иде.

**МИНҺАҖЕВЛАР**

Серафимовка бистәсе, Башкортстан.



*Казан һәм Уфа язучыларыннан бер төркем. Уңнан сулга: Гайнан Әмири, Габдрахман Минский, Мәхмүт Хөсәен, Әмирхан Еники. 1960 ел. Уфа.*



*Тәнкыйтьче Гомәр Гали. «Атака» (1930), «Совет әдәбияты» (1933, 1935) журналларының баш мөхәррире булып эшләгән. 1949 елда алынган фото.*



*Калмык шагыйре Давыд Көгелтинов һәм КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин. 1981 ел.*



*Шагыйрь һәм тәрҗемәче, Г. Тукай премиясе лауреаты Семен Липкин һәм мари әдибе Ким Васин Кырлай урманында. 1976 ел.*



*Күренекле дирижер, Татарстанда симфоник оркестрны оештыручы һәм аның беренче җитәкчесе (1966) Натан Рахлин (1906-79). 1972 елда алынган рәсем.*



*Татар язучылары халыкара ПЕН-клуб конгрессында. Уңнан сулга: Разил Вәлиев, Вахит Юныс, Әхәт Мушинский, Рафаэль Мостафин. Мексика. 1996 ел.*

## Нурзидә Нотфуллина (Нурзилә)

Нурзидә Камил кызы Нотфуллина (әдәби тәхәллүсе—Нурзилә) 1970 елның 8 октябрендә Татарстанның Кукмара районы Түбән Өскебаш авылында туа. Беренче әкият-шигырьләре башлангыч классларда укыганда ук «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасында, «Ялкын» журналында басыла.



Туган авылы мәктәбендә сигез классны тәмамлагач, Нурзидә Арча педагогия училищесында белем ала. Аннан соң үзе белем алган мәктәпкә кайтып башлангыч классларны укыта, өлкән сыйныфларда татар теле мөгаллимәсе була. Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлый. 1 сентябрь иртәсендә мәктәп сукмагыннан түгел, Казандагы мәшһүр Матбугат йортына илтүче урамнан атлап китүенә дә инде дистә ел үткән. Хәер, ул бу урамга ялгышып кына чыккан зат түгел. Мәгариф эшендә башлаган сукмагынюлын дәвам итә Нурзидә—«Мәгариф» нәшриятында мәктәпвуз дәреслекләре һәм балалар китабы редакторы булып эшли. Нурзилә—әдәбият сөючеләр өчен яхшы ук таныш исем. Аның хикәяләре «Казан утлары», «Мәдәни җомга», «Мәйдан», «Идел» кебек абруйлы газета-журналларда дөнья күрде. Ул инде «Мәгариф» нәшриятында «Кашлы балдак» исемле хикәяләр тупламасы да чыгарган автор.

«...Белгәнебезчә, хикәя—әдәби жанрларның иң авыры,—дип яза Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин яшь авторның беренче китабына язган кереш сүзендә. —Ул каләм иясеннән сюжет кора белүне, нык тупланганлык, фикер тыгызлыгын, кечкенә генә мәйданда зур көрәш сурәтләүне сорый. Шулар өстенә тормышны яхшы белү, башкаларны кабатламыйча, әсәрең өчен сайлап алган вакыйганы үз стилең, үз әдәби дөньяң аша ачу да зарури. Бу нисбәттән караганда Нурзилә—шактый кыю. Ул үз әсәрләрен ниндидер «изм»нар кысасына чикләмичә, иркен яза. Аның хикәяләрендә кырыс реализм белән мистика да табигый үрелеп китә...» Яшь автор турында байтак олпат язучыларыбыз да шушы фикердә.

2006 елның 28 февралендә, Кабул итү комиссиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә язучылар: Фәнис Яруллин, Шәүкәт Галиев, Мөдәррис Вәлиев), Язучылар берлеге идарәсе Нотфуллина Нурзидә Камил кызын (Нурзиләне) бертавыштан Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.



Ictimagi-mədəni tormışıbızdan

# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ГОРУРЛЫК СИМВОЛЫ

***

Татар халкының бөек улы, Советлар Союзы Герое, Ленин бүләге иясе шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналар, Россия Федерациясенең бик күп төбәкләрендә, шулай ук якын һәм ерактагы чит илләрдә үткәрелеп, ниһаять, Мәскәүнең үзенә килеп житте. Дөрес, бирелә, шагыйрьнең бер гомер этабы үткән шәһәрдә, төрле дәрәжәдәге юбилей чаралары монарчы да уздырылган иде. Ә менә Әдипләрнең үзәк йортындагы (ЦДЛ) зур концерт залында үткән әлеге кичә берничә айга сузылган бәйрәмнең үзенә күрә бер йомгаклау аккорды буларак кабул ителде. Анда Татарстанның әдәбият һәм сәнгать әһелләреннән торган зур делегация һәм РФ дәүләт учреждениеләре, иҗат берлекләре, җәмәгать оешмалары вәкилләре, күренекле язучылар, галимнәр, сәясәтчеләр катнашты. Табигый ки, кичәдә милләттәшләребез бик күп иде.

Тантаналы кичәне кереш сүз белән Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева ачты. Иң әүвәл ул Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең сәламен җиткерде, аннары Муса Җәлилнең бөтен ил халыклары өчен рухи ныклык һәм каһарманлык символына әверелүен искәртеп үтте, 2006 елның республикабызда Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителүен искә төшереп, аның күренекле юбилейларга гаять бай булуы турында әйтте һәм шагыйрь истәлеген кадерләп саклаучы мәскәүлеләргә ихлас рәхмәтен белдерде.

Россия мәдәният һәм гаммәви коммуникацияләр министры Александр Соколов бәйрәмдә катнашучыларга РФ Президенты Владимир Путинның тантаналы кичәдә катнашучыларны һәм кунакларны сәламләвен ирештерде, шәхсән үзе Муса Җәлилнең күп халыкларга үрнәк булырлык иҗатына һәм героик яшәү рәвешенә югары бәя бирде.

Җәлилнең дөньякүләм танылган иҗат батырлыгына соклану Мәдәният һәм кинематография буенча федераль агентлык җитәкчесе Михаил Швыдкой, М. Горький исемендәге Әдәбият институты профессоры Евгений Сидоров, «Литературная газета»ның баш мөхәррире Юрий Поляков, Мәскәү Язучылар оешмасы идарәсе рәисе Римма Казакова, СССРның халык артисты Василий Лановой чыгышларында да шәхси уйхисләр белән өртелгән үзенчәлекле бәяләмә рәвешендә яңгырады.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимовның татар һәм рус телләрендә ясаган чыгышын тамашачылар тәэсирләнеп тыңлады, Җәлил белән бергә башка каләм әһелләренең дә башы киселүе, сугыш кырларында җәмгысе 34 язучыбызның ятып калуы, гомумән, ил азатлыгын саклауда татар әдәбиятының зур югалтулар кичерүе аларның күңелләрендә горурлану катыш ачыну хисләре уятты. Әмма олы шигъриятебез үзенең тугрылыклы варислары иҗатында яшәвен дәвам итә. Кичәдә танылган шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Разил Вәлиев, Зиннур Мансуров, Лилия Газизованың Җәлилгә багышланган шигырьләрен укулары тамашачы тарафыннан нәкъ менә дәвамчанлык чагылышы итеп кабул кылынды.

Рәсми чыгышлар җыр, бию, нәфис сүз белән аралашып барды. Аларны Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең егет һәм кызлары, җырчылар Лилия Гобәйдуллина, Владимир Васильев, Рената Талипова (Мәскәү), артистлар Ринат Тажетдинов, Рамил Төхфәтуллин, Зөһрә Шакирҗан, музыкант Рөстәм Вәлиев, бертуган Нурбәк һәм Байбулат Батуллиннар һ.б. сәнгать осталары башкарды. Җәлилнең оныгы Татьяна Малышева, залдан сәхнәгә күтәрелеп, фортепьяно өчен прелюдия уйнады.

Әдипләрнең үзәк йорты фойесында татар китапларын сату да оештырылган иде. Бу кичтә Муса Җәлилнең өр-яңа томлыкларына ия булучылар байтак булды. Фоэда куелган газета-журналларыбыз да әдәбият сөючеләрдә зур кызыксыну уятты.

Тантаналы кичә алдыннан Казаннан килгән бер төркем язучыларны Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге тулы вәкаләтле вәкиле Назиф Мириханов кабул итте. Халкыбыз тормышының күпкырлы көнүзәк мәсьәләләренә багышланган әлеге җанлы сөйләшү һәр ике як өчен дә файдалы булды. Очрашуда Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты.

***

Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган чаралар эстафетасын Екатеринбург шәһәре дәвам итте. Урал төбәгенең үзәгендә оештырылган әлеге чараларда мәдәният министры урынбасары Андрей Кузьмин җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә катнашты.

Делегация составында галимнәр Азат Әхмәдуллин, Радик Сабиров, М. Җәлилнең музей-фатиры директоры Гүзәл Сакаева, шагыйрь Газинур Морат һәм бер төркем сәнгать әһелләре бар иде.

Беренче көнне Урал дәүләт университетында «Җәлил укулары» дигән исем астында фәнни-гамәли конференция узды. Конференцияне университет ректоры Владимир Третьяков ачты. Аның фикеренчә, каһарман-шагыйрьнең иҗатын өйрәнүдә хәзер Татарстан галимнәре генә түгел, башка республика һәм өлкә белгечләре дә зур эш башкарырга тиеш, алай гына да түгел, Россия әдәбият белемендә Җәлил мирасын өйрәнү аерым бер өлкәгә әверелергә хаклы.

Конференциядә катнашучыларны шулай ук Свердловск өлкә Думасы рәисенең беренче урынбасары Наил Шәймәрданов, Свердловск өлкәсе мәдәният министры урынбасары Петр Стражников сәламләде. Россия Язучылар берлегенең Урал бүлеге җитәкчесе Юрий Казаринның чыгышы да конференциядә катнашучыларда зур кызыксыну уятты. Аерым алганда, ул Җәлил иҗаты Россия мәктәпләрендә һичшиксез өйрәнелергә тиеш, дип белдерде. Ю. Казарин шулай ук үз чыгышында Урал төбәге язучылары исеменнән М. Җәлил исемендәге интернациональ премия булдыру турында тәкъдим белән Россия Язучылар берлегенә мөрәҗәгать итүе хакында да җиткерде.

Икенче көнне өлкәнең Халык иҗаты сараенда М. Җәлилнең 100 еллыгына багышланган зур тантана булды. Аны Свердловск өлкәсе мәдәният министры, Җәлилнең 100 еллыгына багышланган чараларны әзерләү һәм оештыру комитеты рәисе Наталья Ветрова ачты. «Җәлил иҗаты—татар халкының гына түгел, бөтен Россия халыкларының уртак казанышы»,—диде министр үз чыгышында. Ул февраль ае дәвамында җирле китапханәләрдә, мәктәпләрдә, югары уку йортларында, музейларда Җәлил рухы яшәгәнлеген билгеләп үтте.

Аннары Татарстан мәдәният министры урынбасары А. Кузьмин чыгыш ясады, ул тамашачыларга Президент Минтимер Шәймиевнең М.Җәлилнең 100 еллыгы уңаеннан котлавын ирештерде. Бу көнне сәхнәдә шагыйрьнең үлемсез әсәрләре, аның шигырьләренә язылган җырлар яңгырады. Казан артистлары, Урал дәүләт консерваториясе ректоры, атаклы музыкант Шәүкәт Әмиров (90 нчы елларда ул Казанда да яшәп һәм эшләп алды) җитәкчелегендәге кыллы уен кораллары оркестры чыгышы да тамашачылар күңеленә хуш килде. Оркестр башкаруында Салих Сәйдәшевнең атаклы маршын алар аягүрә басып, алкышлап тыңлады.

Соңыннан Казан кунакларын Татарстан Республикасының Урал төбәгендәге вәкиле Равил Бикбов кабул итте.

Екатеринбургта халкыбызны туплауда, төрле милли-мәдәни чаралар үткәрүдә М. Гафури исемендәге татар-башкорт мәдәни оешмасы җитәкчесе Сөфхәт Надыйровның зур өлеше бар. Үз милләте өчен җан атып яшәүче әлеге шәхес зур хөрмәткә лаек. Свердловск өлкәсендә Җәлил юбилеен үткәрү буенча да ул күп эшләрдә башлап йөргән, хәтта шагыйрьнең юбилей медален булдыруга да ирешкән.

***

Апрель ахырында Берлинда герой-шагыйрь Муса Җәлилнең 100 еллыгына багышланган юбилей чаралары үткәрелде. «Россия халыкларының Берлиндагы дуслары» лигасы аларны оештыручыларның берсе булды.

Аерым алганда, 26 апрельдә Берлинның Рус йортында Алманиянең татар җәмагатьчелеге вәкилләре катнашында М. Җәлилгә багышланган тантаналы кичә узды. 27 апрельдә исә юбилей кичәсен Берлинның татар җәмгыяте оештырды. Плетцензее төрмәсендә җәлилчеләр җәзалап үтерелгән урынга чәчәкләр куелды. Шулай ук Берлинның татар җәмгыяте вәкилләре белән очрашулар, фашизмга каршылык хәрәкәте музеена бару да оештырылды.

Юбилей чараларында катнашкан Россия делегациясе составында гомерен Муса Җәлилнең иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнүгә багышлаган язучы Рафаэль Мостафин, шагыйрьнең Казандагы музей-фатиры мөдире Гүзәл Сакаева, шагыйрьнең кызы Чулпан Җәлилова бар иде.

## ҮЗЕБЕЗНЕҢ БӘЙРӘМ!

«Казан утлары» журналының 1000 нче саны чыгуны киң җәмәгатьчелек зур вакыйга буларак билгеләп үтте. 1000 нче сан чыгу — быелгы Әдәбият һәм сәнгать елының төп сәхифәләреннән берсе булып тора. Бу табигый, чөнки «Казан утлары» Президентыбыз Минтимер Шәймиев сүзләре белән әйткәндә, иҗтимагый-әдәби журналларыбыз арасында үз укучыларына 1000 тапкыр барып ирешкән беренче басма. Бу—һичшиксез, олы казаныш һәм аның мәгънәсе бик тирән... 1000 сан—халкыбыз турында мең китап, рухи хәзинәбезнең мең томы дигән сүз».

Шушы уңайдан 10 апрельдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында махсус рәвештә оештырылган әдәби-музыкаль кичәдә дә журналның әлеге тарихи миссиясе чыгыш ясаучылар тарафын-

нан әледән-әле игътибар үзәгенә алынды. «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин үзенең чыгышында бу кичәнең гадәти юбилей чарасы гына түгел, ә тарихи мәгънәгә ия рухи бәйрәм икәнен әйтеп узды. Чыннан да, ул язучыларның, журналны чыгаручыларның, әбүнәчеләрнең олы бәйрәменә әверелде. Бу кичәдә журналның 1000 санын чыгаруда катнашкан элгәрләребез дә хөрмәтләп искә алынды.

Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева үз чыгышында «Казан утлары» журналының халкыбыз язмышында нинди зур роль уйнавын, гомумән, аның теләсә нинди катлаулы чорларда да ил белән бергә яшәвен, шуна күрә әлеге басманың яшәешебезне тулы чагылдырган үзенчәлекле рухи елъязмага әверелүен искәртеп үтте, редакция коллективын шушы зур казанышка ирешүләре уңаеннан ихлас тәбрикләде һәм журналның бер төркем хезмәткәрләренә—Мансур Вәлиев, Гөлзадә Бәйрәмова, Флера Сабироваларга «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләрен тапшырды. Кичәдә каләм әһелләреннән—Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, драматург Туфан Миннуллин, шагыйрьләр Лена Шагыйрьҗан, Рәдиф Гаташ, Марсель Галиев, прозаик Камил Кәримов һ.б.лар чыгыш ясады. Алар абруйлы әдәби басмага ихтирамнарын хикмәтле сүз белән дә, шигъри багышлау белән дә аңлаттылар. Кичәдә тәкъдим ителгән әдәби-музыкаль номерларны танылган актерлар, җырчылар, музыкантлар башкарды. Фойеда «Казан утлары» журналының тарихына багышланган күргәзмә эшләде.

## ГАЛИМ ЮБИЛЕЕ

Президент Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә Россия Мәгариф фәннәре һәм Татарстан Фәннәр академияләре хакыйкый әгъзасы Мирза Мәхмүтовны кабул итте. 1 майда галимгә 80 яшь тулды. Аны тәбрикләп, Президент әлеге юбилейның республиканың күпмилләтле халкы өчен әһәмиятле вакыйга булуын әйтте. Ул Татарстанда гына түгел, аннан читтә дә танылуга ирешкән галимнең мәгариф өлкәсенә керткән бәяләп бетергесез өлешен билгеләп үтте.

«Бүгенге көндә, мәгариф өлкәсендә реформалар барган шартларда, без кабат-кабат Сезнең хезмәтләргә мөрәҗәгать итәбез. Сезнең тәҗрибәгезне өйрәнәбез»,—дип белдерде М. Шәймиев.

Президент академик Мирза Мәхмүтовка, фәнне һәм мәгарифне үстерүгә лаеклы өлеш керткәне, күпьеллык, фәнни-оештыру һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденын тапшырды. Юбиляр, үз чиратында, республикада фәнгә зур ярдәм күрсәткәне өчен Минтимер Шәймиевкә рәхмәт белдерде.

Мирза ага Мәхмүтов — «Казан утлары» ның редколлегия әгъзасы да әле. Өлкән остазыбызны котлыйбыз!

## КИТАП ТУРЫНДА ХИТАП

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Китап бәйрәме үткәрелде. Аны Татарстан китап нәшрияты, Язучылар берлеге, «Татмедиа» агентлыгы һәм Мәдәният министрлыгы бергәләп оештырды.

Әдәби-музыкаль кичәне Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров ачты. Ул Президент китапханәсенә тәгаенләп классик әдипләребезнең купломлыкларын бүләк итте. Әлеге бүләкне Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева кабул итеп алды һәм китапларны Президентның үз кулына тапшырачагын әйтте. Зилә Рәхимҗан кызы шулай ук 23 апрельнең ЮНЕСКО тарафыннан Халыкара китап һәм авторлык хокукларын яклау көне итеп билгеләнүен дә искәртеп узды. Татар китабы ирешкән уңышлар —безнең уртак казанышыбыз. Казан шәһәренә, Италиянең Турин шәһәре кебек, китап башкаласы булып танылырга насыйп итсен»,—диде ул.

«Идел-Пресс» нәшрияты директоры Ислам Әхмәтҗанов исә Тукай юбилеена үзләре нәшер иткән китаплар турында сөйләде. Бәйрәмдә шулай ук республикабызның танылган сәнгать осталары Илһам Шакиров, Айрат Арслан, Илдус Әхмәтҗан, Зөһрә Сәхабиева, Рафаэль Сәхабиев, Фердинанд Сәлахов, Илсур Сафин, Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор ансамбле, язучы Камил Кәримов, шагыйрьләр Илсөяр Иксанова, Газинур Морат, быел гына шигырь китабы дөнья күргән 11 яшьлек Булат Садретдинов һ.б. чыгыш ясады. Театрлаштырылган күренешләрдә Татар дәүләт академия һәм Татар дәүләт яшь тамашачылар театрлары артистлары катнашты.

## ҖЫРЧЫНЫҢ ЯҢА ВАЗЫЙФАСЫ

ТР Мәдәният министрлыгында Россия балалар фонды Татарстан бүлегенең хисапсайлау җыелышы булып узды. Аның эшендә Россия балалар фонды рәисе урынбасары Раиса Скрынникова, республикабызның законнар чыгару һәм башкарма хакимият органнары, бизнес, иҗат интеллигенциясе вәкилләре катнашты.

Җыелышта катнашучылар Ф. Маликованың, сәламәтлеге какшау сәбәпле, фонд рәисе вазыйфаларын туктату турындагы гаризасын канәгатьләндерде. Фондның яңа рәисе итеп татарның танылган җырчысы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, «Салават» эстрада театры директоры, иганәче Салават Фәтхетдинов сайланды.

Россия балалар фонды—илдә балаларны

яклау максатыннан оештырылган тәүге иҗтимагый оешма. Бүген Россия төбәкләрендә әлеге фондның 73 бүлеге эшләп килә. Аның нигез салучысы һәм алыштыргысыз җитәкчесе—язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Альберт Лиханов.

## ИГЪТИБАР: КОНКУРС!

### «Яңа татар пьесасы—2006» конкурсына нигезләмә

Татар театрының 100 еллыгы уңаеннан, Татарстан Президенты тарафыннан игълан ителгән Әдәбият һәм сәнгать елы кысаларында драматургия өлкәсендә «Яңа татар пьесасы—2006» конкурсы үткәрелә. Конкурсны гамәлгә куючылар: Татарстан Мәдәният министрлыгы, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Татарстан Язучылар берлеге, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе, «Казан утлары» журналы һәм «Татарстан яшьләре» газетасы.

Авторлар конкурска татар телендә иҗат ителгән, сәхнәдә куелмаган пьесалар гына тәкъдим итә ала; узган «Яңа татар пьесасы» конкурсларында катнашкан әсәрләр кабул ителми. Конкурс ябык; тәхәллүс белән имзаланган әсәрләр (текстларның компьютерда яки язу машинкасында басылуы шарт) 3 нөсхәдә кабул ителә; автор турында белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, адресы һәм телефоны, кыскача иҗат биографиясе) ябыштырылган аерым конвертта тапшырыла.

Конкурска юлланган пьесалар кире кайтарылмый һәм рецензияләнми, алар Г. Камал театры китапханәсендә саклана.

Пьесалар конкурска 2006 елның 31 декабренә кадәр кабул ителә.

Текстларны почта буенча түбәндәге адреска җибәрү сорала: **420021, Казан шәһәре, Татарстан урамы, 1 нче йорт, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, «Яңа татар пьесасы— 2006» конкурсы.**

Җиңүчеләр 100, 75, 50 мең сум күләмендә акчалата премия белән бүләкләнә.

Барлык премияләр дә конкурсның генераль һәм рәсми химаячеләре тарафыннан бирелә.

Конкурс турында өстәмә мәгълүматларны конкурсның координаторы Гөлнур Гыйматовадан 8 (843) 293-52-50 телефоны буенча яки почта аша алырга мөмкин.

Конкурс 2 этапта уздырыла:

—1 нче этапта (2007 елның 1 февраленә кадәр) жюри әгъзалары конкурска килгән барлык пьесаларны укый һәм 2 нче этапка узган 10-15 пьесадан торган шорт-бит төзи. Бу шорт-бит гаммәви мәгълүмат чараларында һәм www. KamaLtat.ru. интернет сайтында урнаштырыла.

—2 нче этапта жюри җиңүче әсәрләрне билгели.

Конкурста җиңеп чыгучы авторларның исемнәре 2007 елның 27 мартында премияләрне тапшыру тантанасында игълан ителәчәк. «Яңа татар пьесасы» конкурсына җибәрелгән пьесаларны бәяли: жюри рәисе—Миркасыйм Госманов, жюри әгъзалары—Фәрит Бикчәнтәев, Илфак Ибраһимов, Равил Фәйзуллин, Гали Арсланов, Шамил Закиров, Нияз Игъламов, Миләүшә Айтуганова, Илдар Хәйруллин, Айгөл Габәши, Юныс Сафиуллин, Исмәгыйль Шәрәфиев, Шамил Фәрхетдинов, Фаил Ибраһимов, Илфир Якупов.

Конкурста җиңеп чыккан пьесалар «Казан утлары» журналында һәм махсус җыентыкта бастырыла, шулай ук театрларга сәхнәләштерү өчен тәкъдим ителә.

## АРХИВЧЫЛАР БҮЛӘК АЛА

Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе башлыгы Д. Ибраһимов җитәкчелегендәге республика архивчылары күптән түгел Мәскәүдән Россия тарихчыархивчылар җәмгыятенең III Бөтенрусия конкурсының беренче дәрәҗәле дипломын алып кайтты.

Татарстан архив хезмәте вәкилләре Русия тарихчы-архивчылар җәмгыятенең IV корылтаенда һәм «Русиядә архив белеме һәм архив эше (1991-2005 еллар): үткәннәргә нәтиҗә ясау» дигән Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясендә катнашты. Россия тарихчы-архивчылар җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе рәисе, академик И.Таһиров корылтайда катнашучыларны Татарстан бүлеге эшчәнлеге белән таныштырды. Милли архив директоры урынбасары Н. Шарангинаның «ТР Милли архивы документларының гражданлык җәмгыятендә кулланылышы» дигән доклады эчтәлеклелеге өчен махсус билгеләнеп үтелде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Мамадыш районының Кече Кирмән авылында яшәп иҗат итүче язучы **Рафаил Газизов**ның «Мәгариф» нәшриятында чыккан «Бүләгем» исемле китабы Г.-Х. Андерсен исемендәге Халыкара дипломга лаек булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Авылда». **Рифкат Вахитов** рәсеме.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Рәфыйк Шәрәфиев**.

# Яңа китаплар




**Зөфәр Бәширов.** Онытылмас йөзләр. Незабываемые лица. Фотоальбом.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.—160 б. Тиражы—2000 данә.

Бу басмада язучылар, галимнәр, рәссамнар, музыкантлар һәм артистларның фотожурналист Зөфәр Бәширов (Гомәр Бәшировнең улы) тарафыннан төрле елларда төшереп алынган 150 дән артык фотосурәте тупланган. Шуларның өчтән бере чамасы—язучылар, шагыйрьләр, драматурглар. Алар арасында Х. Туфан, Г. Бәширов, М. Әмир, Ә. Еники, С. Хәким, М. Кәрим, Н. Нәҗми, К. Кулиев, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, И. Юзеев...

Сәнгать, фән өлкәсендә зур казанышларга ирешкән шәхесләр дә байтак әлеге альбомда: Н. Җиһанов, Б. Урманче, Җ. Фәйзи, С. Садыйкова, Р. Яхин, Н. Даутов, И. Шакиров, М. Госманов, В. Мирзаянов, Ә. Кәримуллин, А. Халиков... «Бу альбом халкыбызның талантлы уллары һәм кызларының якты йөзләрен онытылмас хатирә итеп калдыру нияте белән әзерләнде», ди фотохудожник.

Шәхесләр турында биографик мәгълүматлар татар һәм рус телләрендә бирелгән.




**Марсель Галиев.** Рух.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.—559 б. Тиражы—2000 данә.

Марсель Галиевнең күләмле бу китабы өч бүлектән тора. Тәүге әсәр—телебезнең бөеклеген, сүз хикмәте, татар жыры, татар исеме хакында лирик-фәлсәфи уйлануларга корылган. Монда—яңа эрага кадәр яшәгән һун бабаларыбызның юлбашчысы Баһадур Җаниядән башлап, Атилла, Чыңгыз хан кебек сәргаскәрләр турында да шигъри тыгызлык белән язылган этюдлар керә.

Икенче бүлектә—милләтебезнең күз нурында булган мәртәбәле шәхесләре: әдәбият-сәнгатебездә зур урын билгәгән асыл затлар турында сурәтнамә—истәлек-хатирәләр оста каләм белән бәян ителгән.

Китап соңында, «Сүзләрдән—сәйләннәр» бүлегендә афоризмнар, тапкыр җөмләләр, сүз уйнату, гыйбрәтле гыйбарәләр, уйны уйдырып салган фикри табышлар да укучы күңеленә хуш килер дип ышанабыз.



Рәфыйк Шәрәфиев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)